Әхәт Гаффар
# Энә күзе

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2006
УДК 821.512.145-3
ББК 84(2Рос=Тат)-4
Г26
**Гаффар Ә.Г.**

Энә күзе: Хикәяләр, повестьлар, пьеса / Әхәт Гаффар. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. — 287 б.

ISBN 5–298–03979–0

Татар әдәбиятының күренекле каләм ияләреннән берсе Әхәт Гаффарның бу китабындагы яңа хикәяләре һәм повестьларында икенче бөтендөнья сугышыннан соңгы татар халкы тормышы тасвирлана. Язучының иҗатына чынбарлыкны кырыс, шул ук вакытта моңсу сурәтләү, ялкынлы әхлакый мәсьүллекне дәгъвалау, каһарманнарының күңел, рух дөньясын заманның катлаулы җирлегендә күрсәтү хас.

ISBN 5-298-03979-0

© Татарстан китап нәшрияты, 2006
© Гаффар Ә.Г., 2006

## ТАЛАНТЛЫ ӘДИП

Язучылар әдәбият мәйданына төрлесе төрлечә килә. Кайберләре өметле яшь язучы булып бишәр, унар ел йөргәннән соң гына ачылып, танылып китә. Кайсылары яшь вакытларында бөтенләй башка һөнәр ияләре булып һәм шул һөнәрләре буенча әйбәт кенә эшләп йөри дә, соңыннан яза башлап, күренекле язучы булып китә. Кайсылары туганнан бирле үзләрен язучы санап һәм дөнья кадәр «әсәр» язып та халыкка таныла алмыйча кала. Ә кайберләре исә, беренче әсәрләре белән үк укучы күңеленә килеп керә һәм тиз арада ихтирам казана.

Әхәт Гаффар (Габделәхәт Габдрахман улы Гаффаров) — әнә шул соңгылары җөмләсеннән.

Ул әдәбият мәйданына 1972 елда «Казан утлары» журналында басылган «Әҗәт» исемле беренче хикәясе белән килеп керде. Нибары чирек басма табак күләмендә генә булса да, «Әҗәт» язучылар тарафыннан да, укучылар тарафыннан да бик җылы кабул ителде. Чөнки әлеге әсәр теленең төгәллеге һәм образлылыгы белән дә, фикеренең фәлсәфи тирәнлеге белән дә, персонажларының гадәт-холыкларын, рухи халәтләрен бөтен нечкәлекләре белән, җанлы итеп сурәтләве җәһәтеннән дә уңышлы эшләнгән булуы белән аерылып тора. Ә бу әдәбиятыбызга тагын бер сәләтле язучы килүе хакында сөйли иде.

Шуның өстенә «Әҗәт» авторы Әхәт Гаффарның яшь булуы да аның киләчәктә тагын да саллырак, колачлырак әсәрләр язарына өмет уята иде.

Беренче карашка «Әҗәт» хикәясендә алай исне китәрерлек берни дә юк кебек. Анда Мәрьям исемле тол авыл карчыгының төш күрүе хакында сүз бара. Карчыкның «төшенә әллә ниткән кеше чырайлы бер козгын кереп йөдәтте. Каурыйлары тузгып беткән ул кара кош, зурайганнан-зурая барып, баганадан баганага, тупылдан тупылга күчә-күчә, ниһаять, аның (карчыкның. — *В.Н.*) корымлы кирпеч морҗасына килеп кунды. Ә ул үзе яшел чирәмле ишегалдында тавык-чебеш ашатып йөри, имеш. Козгын, болай да, тегеләй дә кууга карамастан, ач кара күзләре белән тын гына ялварып ашарына сорады. Суга чылаткан ипи кыерчыгы ыргыткач алмады, канлы ит кисәгенә генә риза булды. Аннары, каурыйлары тузгыган киң канатларын җәеп, тавыш-тынсыз гына кузгалды да, торган саен кечерәя барып, күздән югалды... Иләмсез зур һәм шөкәтсез кыяфәтле козгынның ерактан гыжлап көлүе генә ишетелеп калгандай булды...»

Хикәянең оеткысы менә шул. Шушы төш ипле генә яшәп яткан Мәрьям карчыкның тынычлыгын ала.

Мәрьям карчык, кара козгынның ни өчен аннан ашарга соравын, аннары нигә гыжгылдап көлеп китү сәбәбен ачыкларга тырышып, бөтен узган тормышын күңеленнән үткәрергә мәҗбүр була. Нибарысы сигез битле хикәядә автор шул авыл карчыгының бөтен тормышын, холык-фигылен шундый ачык һәм аңлаешлы итеп сурәтләп бирә ки, әйтерсең без Мәрьям әби белән бергә яшәгәнбез, әйтерсең ул безнең үз әбиебез.

Ә теге козгынның Мәрьям әбинең төшенә керүе юкка гына булмаган икән. Күпме уйлап та төшенең мәгънәсенә чыга алмагач, ул моны яшьлек ахирәте Галимә карчыкка сөйләп карарга була. Әмма Галимә дә анык кына итеп берни әйтә алмый. Шулай да сүз арасында:

«— Берәрсенә әҗәтең юктыр ич? — дип сорап куя.

— Кит әле, булмаганны... Күпме гомерем калгандыр... Шушыңынчы кешегә әҗәтле булып тораммы суң? — диде Мәрьям әби».

Әмма Галимә ахирәте әйткән юралыш аның күңеленә кереп кала. Уйлана торгач, ниһаять, исенә төшерә. Улы Нәкыйп сугышка киткәндә, үзләренең ипиләре булмаганга күрә, Мәрьям үз күршеләре Гөләндәмнән бер бөтен кара икмәк алып торган иде ләбаса. Ул икмәкне урталай кисеп, яртысын Нәкыйп фронтка алып киткән, яртысын әнисе Мәрьямгә калдырган икән ич. Шул чакта Нәкыйп әнисенә әйтеп киткән: «Гөләндәм апага әйт, үз бурычымны кайткач үзем түләрмен», — дигән. Тик Нәкыйп сугыштан кайтмаган. Шулай булса да ана кеше аны кайтыр дип көткән. Шуңа Гөләндәмгә әҗәтен түләмәгән. Әҗәтен түләп куйса, малае кайтмаска да мөмкин, ә ана кеше әҗәте бар кеше аны түләмичә дөньядан китәргә тиеш түгел дип уйлаган. Һәм тора-бара, хәтере йомшап, ул хакта онытып ук җибәргән. Тик теге козгын, аның төшенә кереп, ашарына сораганнан соң һәм ахирәте Галимә, әҗәтең бармы әллә дигәч, әлеге әҗәтен исенә төшерә. Шул ук кичне, күәсенә оеткы салып, ипи камырын кабартырга куя. Анда да малаем кайтыр дигән өметен өзеп түгел, ул моны малаем кайтканчы әҗәтне биреп куйыйм, бер эше кими торсын дип эшләргә була.

Ә икенче көнне иртән ферма ягына таба баручы хатын-кызлар капка төпләрендәге усак бүрәнәдә башын күкрәгенә салып утырган Мәрьям әбине күреп, хәлен сорашып китәр өчен якынрак килсәләр, Мәрьям әбиебез, яшь бала кочкан кебек, күкрәгенә кызарып пешкән бер бөтен икмәк кыскан килеш... дөнья куйган булып чыга.

Хикәя шулай тәмамлана. Алда әйтеп үткәнемчә, әсәрдә шаккатырлык бернәрсә дә юк кебек. Барысы да үтә гади, гадәти. Әмма әсәрне укып чыкканда тәннәр чымырдап куя, күзгә яшь килә, тамак төбенә төер килеп тыгыла.

Монда хикмәт нидә соң? Бу әсәр нәрсәсе белән шулай көчле тәэсир итә? Югыйсә кешеләр арасында үзара әрләш-талаш, үтереш-суеш, алдашу-хыянәт кебек гайре табигый, һушларыңны алырдай хәл-хикмәтләр хакында көн саен газета-журналлардан укып та, телевизордан күреп тә, радиодан ишетеп тә торабыз лабаса. Әмма алар бу заманда безне бик алай шаккатырмый. Ә монда — Әхәт Гаффарның әлеге «Әҗәт» хикәясендә — гап-гади бер карчыкның гап-гади тормышы һәм гади генә, тыныч кына дөнья куюы хакында гына сүз барса да, әсәр безне дулкынландыра, җаныбызга тәэсир итә, һәм монысы — иң мөһиме! Бу әсәр безне тормыш, яшәеш һәм яшәүнең мәгънәсе хакында уйланырга мәҗбүр итә. (Шулай икәненә ышанмаучылар булса, хикәяне игътибар белән укып чыгарга киңәш итәм.) Моның сере шунда: беренчедән, автор чын рәссамнарча, һәр сүзенең кадерен, тәмен белеп, нәкъ кирәген генә сайлап һәм образлы (сурәтле, саллы) итеп яза; икенчедән, яза торган материалын яхшы белә; өченчедән, каһарманының уй-фикерләрен тирән һәм төгәл итеп, укучыны һич икеләнүсез ышандырырлык итеп сурәтли.

Шуңа күрә дә Мәрьям әби образы очраклы бер карчык образы гына булып калмаган, ә бәлки татар хатын-кызларының асыл сыйфатларын: сабырлыгын, тыйнаклыгын, түземлеген, эшчәнлеген, намуслылыгын һәм гаделлеген чагылдырган. Бөек Ана образы дәрәҗәсенә күтәрелгән.

Сүз уңаеннан шуны да әйтеп үтим: Әхәт Гаффарның бу хикәясе мәктәп дәреслекләренә, хикәяләр антологияләренә кертелде һәм ул инде иң зур сынауларны үтте: берничә тапкыр урыс телендә Мәскәү нәшриятларында һәм дөнья халыкларының тугыз төп телендә басылды. Һәм һәркайда югары бәя алды.

* * *

Хуш. Бу урында миңа: «Син, абзый, нигә әле Әхәт Гаффарның беренче әсәре хакында шулай тәфсилләп, җәелеп сөйләдең, аның бит әле бик саллы романнары, повестьлары, драма әсәрләре һәм күп кенә башка хикәяләре дә бар лабаса», — дип әйтәчәкләрен бик сизеп торам. Ул хакта сүз булыр. Тик аңарчы сүземнең башында мин язучыларның әдәбиятка килү юллары турында әйтеп киткән идем. Ләкин әдәбиятка килү, ягъни Язучылар берлегенә әгъза булып алыну белән генә эш бетми бит әле. Киресенчә, эш башлана гына: иҗат берлеге таныкнамәсе алуга ирешкән кеше язучы дигән абруйлы исемне акларга — язарга, яңа әсәрләр иҗат итәргә тиеш була. Монысы инде, ай-һай, җиңел эш түгел! Кайберәүләр беренче китаплары белән шаулап, ялтырап әдәбиятка килеп керәләр, әмма иҗади яктан алга таба үсмиләр, ә киресенчә, сүрелә баралар һәм уртакул язучы булып калалар. Кайсылары гел дә сүнеп, язудан туктап, югалып бетә. Ә кайберләре — болары чын мәгънәсендә талантлылары — язучы дигән зур исемгә лаек булгач, дәртләнеп яза башлый, аларның иҗаты һәм сыйфат ягыннан, һәм сан ягыннан үсә, камилләшә бара.

Әхәт Гаффар — әнә шул соңгылары сафында баручы әдип. Моның чыннан да шулай икәненә ачык дәлил — аның әсәрләре. Беренче хикәясе китергән уңыштан рухланып һәм канатланып, әдип иҗатын бик нык активлаштырды. Бүгенге көндә ул — өч роман, дистә ярым повесть, 15 драматик әсәр, бихисап хикәяләр, телевизион пьесалар авторы. Сүз җаеннан әйтеп үтәсем килә: Әхәт Гаффар үзенең бер «Әҗәт» хикәясен язу белән чикләнгән булса да, аның исеме әдәбиятыбыз тарихына кереп калыр иде. Андый камил эшләнгән һәм андый тирән фикерле хикәяләр безнең әдәбиятта алай бик күп түгел. Әмма күрәсез, куанычка күрә, Әхәт аның белән генә туктап калмады, халык әйтмешли, шуннан соң ат урынына эшләде.

«Әҗәт» хикәясенә исә ни өчен җентекле тукталуыма килсәк, моның сәбәбе бик гади. Хикмәт шунда: Әхәт әлеге хикәясендә башланган тик үзенә генә хас иҗат үзенчәлекләренә шуннан соң язылган барлык әсәрләрендә тугрылыклы булып калды. Теләсә кайсы әсәренең ярты сәхифәсен уку белән үк, авторы кем икәнен кара-

мыйча да, Әхәт Гаффарныкы икәнен белеп була. Чөнки аның үзенә генә хас язу стиле, үзенә генә хас сүз әйтү, җөмлә төзелеше бар. Беренче карашка барыбызга да билгеле булган вакыйгаларны ул үзенчә күрә, үзенчә — көтелмәгән якларыннан ачып күрсәтә. Әдип үзе сурәтли торган вакыйгаларны һәм күренешләрне кыска гына, әмма шул күренешләрнең һәм вакыйгаларның асылын образлы һәм төгәл итеп ачып бирә торган җөмләләр белән яза. Сурәтли торган материалын җанлы итеп, күз белән күреп булырлык итеп күрсәтеп бирә.

Әхәт Гаффарның тагын бер иҗади үзенчәлеге шунда: ул күбесенчә авыл кешеләре, гади кешеләр тормышы турында яза. Аларның яшәешен, уй-хисләрен, эчке матурлыгын, эшчәнлеген, намуслыгын, кешелекле, ярдәмчел, гадел, киң күңелле, бабаларыбызның гореф-гадәтләренә тугры булуларын яратып, белеп сурәтли. Бездә соңгы елларда авылны ярату, авылны сагыну турында, авылга кайтып килергә теләүләр хакындагы җырлар модага кереп китте. Гаҗәп хәл: барысы да авылны, әниләрен сагына. Әмма берсе дә авылга кайтып яшәргә теләми. Шуңа күрә ул җырлар ялган булып яңгырый. Ә менә Әхәт Гаффар, әти-әниләре инде күптән вафат булса да, җәй көннәрендә атна саен диярлек туган авылына — Балык Бистәсе районындагы Олы Әшнәккә кайтып йөри, шунда торып китә. Туган нигезен барлап, саклап, сипләп яши. Аның төп иҗат чыганагы — авыл, күпчелек әсәрләренең каһарманнары — авыл кешеләре. Чөнки Әхәт яхшы белә: халкыбызның телен, гореф-гадәтләрен, бабаларыбызның милли традицияләрен, бер сүз белән әйткәндә, генофондыбызны әлегә авыл саклап килә. Безгә менә шуны югалтмаска, шуны сакларга кирәк. Бу җәһәттән шәһәргә һичнинди өмет-ышаныч юк. Шәһәрдә яшәүче татарларыбыз күзгә күренеп интернациональләшә, генофондын югалта бара. Милләт буларак йотылып, югалып калмыйк дисәк, авыл белән араны һич кенә дә өзмәскә, авылга игътибарлы булырга кирәк. Сүзебез белән генә түгел, ә бәлки эш-гамәлләребез, шул исәптән иҗатыбыз белән дә. Әхәт Гаффар әсәрләре безгә шул хакта катгый төстә искәртә.

* * *

Әй бу вакыт дигән нәрсәнең тиз үтүләре! Җыйнак кына гәүдәле, эре бөртекле кап-кара калын чәчле, җемелдәп торган кара-коңгырт күзле, кара һәм куе салпы мыеклы бер егетнең минем янга — «Казан утлары» журналы редакциясенә, оялчан-тыйнак кына килеп кереп:

— Вакыйф абый, мин — сезнең якташыгыз. Олы Әшнәк авылыннан Габделәхәт атлы җегет булам. Фамилиям — Гаффаров. Сезнең янга танышырга дип керүем иде, — дип сүз башлавы әле кичә генә булган иде кебек. Баксаң, ул көннән соң утыз биш ел вакыт үтеп киткән икән ич инде!

Әлеге беренче очрашуыбызда янып торган егерме ике яшьлек егет булган якташым, күрше авыл егете Әхәт Гаффарыбыз да алтмышны ваклый икән ләбаса. Мондый чакта минем Султан бабам: «Без картаймый, кем картайсын?» — дия торган иде...

Әмма Әхәткә аһ орырлык берни юк. Киресенчә, аның горурланырга, куанырга тулы хакы бар. Чөнки аның гомере заяга үзмый. Әхәт ул елларны иҗтиһадлы эш белән, актив иҗат белән үткәрде. «Әҗәт», «Гозер», «Бер йотым су», «Бишек», «Су астындагы чишмә», «Сызылып таңнар атканда», «Бодай бөртеге һәм тегермән ташы», «Яшиселәр алда әле», «771 аршын җир», «Әкәмәт», «Богау» — болар Әхәтнең Татарстан китап нәшриятында басылып чыккан китапларының исемнәре. Ә җәмгысе — унбиш китап. Барысы да саллы, укыла торган китаплар. Шулар арасыннан «Долг», «Глоток воды», «Зерно и жернова» — болары русчага тәрҗемә ителеп, Мәскәү нәшриятларында чыккан китаплары. Өч китап. Әмма татар язучыларының кайберләре Мәскәү нәшриятларында бер китап та чыгара алмыйча калуын исәпкә алганда, бер татар әдибенең өч китабы басылып чыгу бу инде уен-муен гына түгел, ә зур казаныш. Чөнки Мәскәүдә урыс булмаган язучыларның китапларын бик сайлап, нечкә иләк аша үткәреп кенә чыгаралар.

Проза әсәрләреннән тыш Әхәт Гаффар байтак сәхнә әсәре дә язды. Драматурглар әйтә: «Пьесаны язып була, язуы рәхәт, әмма сәхнәгә куйдыру бик авыр, шунысы теңкәгә тия», — диләр. Чыннан да, аларның сәхнәгә менү бәхетенә ирешә алмыйча калган әсәрләре шактый еш була. Әхәт бу җәһәттән дә бәхетле әдип: аның язган барлык пьесалары да диярлек татар театрларында уйналды. Ә «Язлар моңы» дигән драмасы күренүе белән үк драматургиябезнең алтын фондына кереп калды инде.

Әхәт Гаффар хакында сүз алып барганда, аның әйбәт журналист һәм җәмәгать эшлеклесе дә икәнен искәртеп китмәү гаделлек булмас иде. Республикабыз газета-журналларын укып баручылар күрә булыр, аларда Әхәт Гаффар каләме белән актуаль темаларга язылган мәкаләләр һәм очерклар һәрдаим басылып килә.

Ул берничә ел Әлмәттә яшәп, Татарстан Язучылар берлегенең Әлмәт бүлеге белән җитәкчелек итеп тә кайтты. Күрәсең, эшен әйбәт алып баргандыр, шул елларда аны Әлмәт шәһәр советына ике чакырылышта депутат итеп тә сайлаганнар иде. Белүемчә, Әхәт анда да түрәләр әйткәнне хуплап, «ә» дигәнгә «җә» дип, кул күтәреп кенә утырмады, кирәк чакта аларга үз фикерен һәм, сайлаучылар мәнфәгатен яклап, үз сүзен кистереп әйтә, хәтта тарткалашудан да тайчынып тормый иде.

Әхәт Гаффар бүген дә дәртләнеп иҗат итмәктә һәм газета-журнал редакцияләрендә дә эшләп йөри. Чәче һаман шулай кара, бер генә бөртеген дә чалартканы юк, мыегы да шулай калын һәм салынкы, күз очкыны да сүнмәгән-сүрелмәгән, иманлы нур чәчеп тора.

**Вакыйф Нуруллин,**

*Россия Федерациясенең һәм*
*Татарстан Республикасының*
*атказанган мәдәният хезмәткәре*

# КЕШЕЛӘР

## ФАТЫЙМА

Баз кебек тып-тын өендә Фатыйма кичләрен җәтмә үреп утыра торган иде. Кызы кул эшенә тотына. Улы клубка, йә балаганга — янгын өенә кәрт сугарга чыгып китә. Бәйләүләрен тотып, кайчагында тирә-күршедәге тол хатыннар җыелгалый. Ирләр дә кергәли. Тегене-моны сөйләшкәлиләр. Җыр җырламыйлар. Бер тапкыр самавыр куеп, сөтле чәй эчеп алалар. Җанга рәхәт булып китә. Башка көнне бәйләмгә бүтәннәргә кереп утырасың. Анысында чәйне алар куя. Шулай чиратлап бара инде. Беркем әҗәтле калмый.

Җәтмәнең төбе юкә бау белән матча кадагына бәйләнгән. Сүз артыннан сүз, күз артыннан күз. Сул кулда кылыч шуа, уң кулда соса йөри. Хатыннарның һәр сүзен, җәтмәнең һәр күзен җөпләп, төеннәр төйнәлеп бара.

Тышта буран. Электр белән радио чыбыклары гүелди. Бөтен өй Гаффарларның мандолинасы шикелле зыңлап тора. Йә чатнама суык. Күктә тулы ай, җирдә зәңгәр күләгәләр. Берара этләр өреп алгалый, тонык кына итеп, кар шыгырдап кала. Чана белән тартып, кемдер колхоз саламын йә печәнен урлап кайта инде. Бу кәсепкә Фатыйма үзе дә чыккалый. Югыйсә — беттең. Мал-туарыңны тезмәдәге белән генә кыш чыгарырмын димә. Куркып ятсаң, абзар түбәсенең каткан саламын куптарырга, йолкырга, өйгә кертеп эретергә кала. Нихәл итмәк кирәк?! Аркаңа чана бавын асасың да, бисмиллаңны әйтеп юлга кузгаласың. Күз курка, кул эшли ул. Тотсалар, беттең инде. Тик, Аллага шөкер, тотмыйлар. Сине төрмәгә ябудан, сыер, сарык-кәҗәңнең эштән чыгуыннан, дөньяга колхозга ни файда?!

Үз тамагың кайгысы хәттин ашкан. Трутдингә тигән ашлык очын очка ялгарлык кына. Акча юк. Ул учка керсә, теш сызлаулары басыла, билләһи газыйм. Шунда йөрәк тә кагарга тотына. Налог түләнмәгән бит әле. Заем дип тә теңкәгә тияләр. Язга кергәндә ит заты күрми башлавыңда аларның ни эшләре бар. Бәрәңге белән сөт, кысыр ашка каласың. Ипи санаулы. Аны күз карасыдай кадагын кадакка, куш учын учка санап кына тотасың. Җир яшәргәч, кызарып борнаган кычыткан, кузгалакка, аннары ирен яргычы белән какыга, соңрак балтырганга керешәсең. Барысыннан да битәр черек бәрәңгегә күз тимәсен. Ходай рәхмәтле диген, әле дә ярый ул бар.

Берзаманны язгы сулар ташып төшә. Буа бозы зәңгәрләнеп кабара. Су буаны ашып ургый, аннары ишә дә алып китә. Бу вакытка Фатыйманың җәтмәсе бәйләнеп беткән була инде. Ул аны карама көянтәгә беркетә, озын юкә сапка утырта. Өр-яңа чабатасын киеп, сул кулына киндер букча аскан килеш җәтмәсен иңендә тибрәтә-тибрәтә ташкын инеш ярына килеп басуларны Фатыйма өзелеп көтә, тотыласы балыкларның букчасында шапырдашуын ишеткәндәй булып, кыш буена хыяллана, табада сөякләренә хәтле эретеп кыздырыласы балык исен җир ачыла башлаганда ук бөтен җаны белән сизә иде.

Инешнең авылдан башлап Атау эче болынына кадәр буеннан-буена җәтмә белән балык сөзүче ирләр, егетләр йөри. Араларында хатын-кызлардан фәкать ул гына — ире сугышта башын салган тол хатын. Моңа ул тамчы да уңайсызланмый, бер дә оялмый, һич тә хурланмый. Киресенчә, үз тамагын үзе, балалары, оныгын туендыра алуына горурлана ул. Мондый чакларда үзен ниндидер күпер итеп тоя һәм үзе аша башкаларны үткәреп җибәрүне яшәвенең асылы дип аңлый иде. Аның инеш ярындагы борылмалы, авыр, озын юлы иртән кояш чыгу белән башланып, кичен шул ук кояш баеганда гына тәгәлләнә. Тоткан балыкларын ул баш саныннан, ничә таба куырырга җитәр дип санамыйча, газаплы тормышының алтын бәхет тәңкәләре дип кабул итә сыман иде.

Фатыйма, менә шулай колхоз эшеннән бушаган вакытын балык тотып үткәрә, су тәмам тонмый торып туктамый. Берочтан ярга су кагып чыгарган, су астында ятып күтәргесез авырайган, әмма черемәгән агачларны, әүвәлге буаның кара бурасыннан калган, ләм асларыннан актарылып чыккан имән субай калдыкларын җыеп өя, бераз кипшегәч, балалары белән бергә йә күтәреп, йә арба белән тартып кайта. Бу утын кара көзгә шае җитә, кышка да керә, мал-туардан калган камыш, бәрәңге сабаклары, курпы, кизәк белән кушып якканда шөкер итәрлек бәрәкәтле була. Шуның белән мунча ягып җибәрсәң дә галәмәт яхшы. Ул судан чыккан имән, нарат субайлар, турап яккач, эретелгән бакыр шикелле көйриләр.

Фатыйманың мунчасы кара иде. Ярга уеп, дүрт яктан су ташы өелгән: түшәменә урталай ярылган бүрәнәләр тезелеп, аңа тыштан туфрак өелгән, идәне белән ләүкәсе генә чын такта, мичендә кирпеч заты юк, ул да гади таштан. Аның каруы мунча ташлары гаҗәеп куәтле пар бирә: аларның һәркайсы Атау эченнән җыеп, чиләк-көянтәләп ташылган. Җип-җиңел, күзәнәкле ташлар, борынгы болгар кабиләсенең җимерелеп, тетелеп, эзе дә калмаган ниндидер бер шәһәренең язгы ташулар белән актарылып, ләм белән бергә

болынга чәчелгән ташлар. Атылган йолдызлар юкка чыга, ә Фатыйма борынгы ташларны да кешеләр күңелендә йолдызлар итеп балкыта белә иде.

Фатыйманың бакча башыннан башланган инеш чокыры кырыена җир уеп ясалган кара мунчасына бөтен оч кешесе ягып керә һәм аннан тән керләрен генә юып калмыйча, ә бәлки җаннарындагы бөтен пычракларыннан да арынып чыга. Аның хәерчелеге бөтенесен тигезли һәм бала-чаганың да, ир белән хатыннарның да, карт-корының да рухларын баета: ачлыгын оныттыра, яманлыкларын пар белән бергә төннектән сыгып чыгарып, һавага тарата, яхшылыкларын чабынган саен гөбердәп кенә торган каен себеркеседәй сихәтле итә, өметләрен сабын күбегедәй күпертә иде. Бу мунчага борылмалы-сыгылмалы сукмактан килеп, Фатыйма уйган җир баскычлардан күтәрелеп керсәләр, чыгып киткәндә исә аяк табаннары туфракка тимичә, күңелләре белән зәңгәр күктәге болытларга шае күтәреләләр кебек иде.

Шулай итеп, Фатыйманың салам түбәле өендә, җир идәнле өйалдында тол хәерчелектә үткән бар гомере, язмышы кара күмер булса да, ул күмер кешеләрнең җаннары түрендә өсте-өстенә җыела килеп һәм тыгызланып, чын алмазга әверелә барды. Бөек тираннан башлап, чабатага юкә каезлаган чакта тотып алган һәм штраф салган урман каравылчысына кадәр аның хәерчелеген һәм иманындагы шул алмазны үз файдасына үзләштерде, ашады, эчте, исерде.

Аны ни өчендер үзара кушаматы белән Фатыйма Мүчи дип атыйлар иде. Фатыйма — мучение... Мученица.

## ӘХМӘТҖАН

Кайсы гына тарафка юнәлмәсен дә, ни генә ниятләмәсен, аның юлы һәрвакыт упкынга килеп төртелә иде. Канатларын тилгән кебек җәеп һәм киереп, ул әлеге упкыннарны очып кына үтмәкче була да — кире тартып төшерәләр. Андый чакларда ул үзен оясыннан егылып төшеп, юан тупыл кәүсәсенең төбенә сыенган карга баласы хәлендә тоя иде. Шуңа күрә канатларының ни өчен бәйле, аягының ни өчен тышаулы икәненә, ни өчен күрмәскә, ишетмәскә, дәшмәскә дучар ителүенә гомере буена төшенә алмый интекте.

Аңа бер генә упкынны уңышлы үтәргә ирек бирделәр — сугыш упкынын. Исән-имин калды. Җиңделәр.

Сугыш тынгач, ул Германия хәрабәләренең берсеннән инәләр табып алды. Крупп корычыннан коелганнар, күрәсең, яхшы да иделәр соң. Көрәштәшләре биштәрләренә аналары, хатыннары, кызларына атап, күлмәклек тукыма, аккордеон да баян, тегене дә моны төйнәде. Ә ул солдат капчыгы төбенә шул инә капларын салып куйды.

Илгә, авылына, өенә кайтышлый эшелоннар туктап торганда, станцияләрдә, пароходта, пристаньнарда шул малы белән кәсеп итте. Хаталанмаган икән: таланган, бөлгән илдә дөя кайгысы түгел, шул инә кытлыгы икән. Сатулашырга туры килмәде. Халык кулың белән бергә тартып алырга әзер булып чыкты.

Соңрак авылдашлары белән телгә килгән вакытларда аны әлеге ирексездән кылган кәсебе өчен хурларга торучылар да булгалады. Әллә ни исе китмәде. Әнә, өйләренә әрҗә-әрҗә мал озаткан генералларны күрсеннәр иде дә шуларга тешләре үтсен иде.

Сугыштан өенә кайтып төшсә, йорт-җир тузган, бар булган мал-мөлкәт туздырылган, терлек-туар кырылган, хатыны хәлдән тайган, колхоз күтәрәмгә калган. Бусы аның һәммәсенә тигез булды. Тәңрегә үпкәләрлек түгел. Нихәл итмәк кирәк?! Язмышыңа язганны өскә кунган тузан бөртеге кебек өреп төшерәсеңмени! Бер мин генә түгел дип, кул кушырып утыру да ярамый. Колхозга ышаныч аның күңеле пошынуында тоз шикелле эреп юкка чыкты. Кырыкмаса кырыкка ярыл, шартла, бет — юк инде. Учка керергә өлгерми — оча да чыга: бирмәгәнеңне талап алалар, калганына кан елатып налог салып китәләр. Артык кәҗә бәтие асравы да җинаять санала.

Берара каңгырап, шулай иза чигә торгач, ул болай итте. Бәрәңге бакчасын уртадан бүлеп алды да төрледән-төрле алмагач, чия, кура җиләге, шомырт утыртты, өч баш умарта кайтарып куйды. Бал кортларын кыш чыгарыр өчен подвал казып керде. Күп итеп яшелчә, хәтта кавын да үстерергә өйрәнде.

Бакча үсте, нык тамыр җибәрде. Тактадан куыш корып, ул шунда мылтыгын кочаклаган көенчә төннәр чыга торган булып китте. Югыйсә малай-шалай, егетләр кеше-кара күрмәгәндә бакчасын басарга күп сорамыйлар. Умартасын ачып, балын кәрәзе-ние белән урлап та чыккаладылар. Алар аны өйләренә алып кайтмыйлар, ә кайдадыр аулак урыннарга посып ашыйлар.

Менә шулай, стаканлап шомырт, кура җиләге, чия, карлыган, килолап алма, бал сата-сата мал туплады, бура сатып алды, салам түбәле иске йортын сүтеп, такта түбәле яңаны салып керде. Колхозның бер мыскал да ярдәме тимәде. Киресенчә, бер генә көн печән чабарга, урак белән иген урырга, тирес чыгарырга, чәчүлек ташырга, урман кисәргә чыкмый калсаң, җаныңны кыярга торалар. Шуңа күрә кул көчеңне

генә түгел, ә җаның-тәнеңне дә кол иткәннәр шикелле тоелган чаклар да байтак. Асраган сарыгыңны Казан базарына илтеп сатарга теләсәң дә, авыл советы рәисе алдына кәгазь сорап барырга кирәк. Тагын бер кәгазьне ветлечебницадан алырга мәҗбүрсең. Суйган сарыгыңның тиресен илтеп тапшыру да күңелгә тия: колаклары булмаса, алмыйча боралар. Тамгасы булу шарт. Кешенекен урлап суймаганыңны шулай исбат иттереп мәсхәрәлиләр.

Ә печәнне «уфалла» белән тартып ташыйсың, киптерәсең инде. Утын кирәк булса, каравылчыга ялынырга, аны көйләргә кирәк. Хезмәт көненә бүлеп бирелә торган ашлык көч-хәл белән җитә.

Барысына да сул кулыңны селтәп, дөнья читенә чыгып китәр идең — паспорт юк. Бирмиләр. Кайда тусаң, шунда җан тәслим кылырга хөкем ителгәнсең. Рөхсәтсез барырга мөмкин булган урын берәү генә иде: авыл зираты, өч аршынлы кабер, кысанмы, иркенме икәнлеге инде сиңа кагылмаган ләхет. Ясиннарны да качып чыгарга калды. Картлар җомга намазына җыелудан мәхрүм ителде.

Соң, җәмәгать, авыл кешесенең җирдә үзе теләгәнчә яшәтмәү нинди хәл инде ул?! Балыкны сусыз яшәргә өйрәтергә маташу ише нәрсә түгелме соң бу?!

Әхмәтҗан төннәрен балаларының да шушылай яшәү ихтималын уйлый, баш вата, аңлый алмый интегә иде.

Ә аракы күп, очсыз иде.

Шушылай яши торгач, ниндидер авыруына дәва алмакчы булып, Әхмәтҗан тилебәрән орлыгы ашаган иде. Дәваланды сиңа, пычагым. Әхмәтҗан абзагыз нишләп ташлаган диген? Аркылы яткан салам аның күзенә бүрәнә булып күренә икән дә, шуны зур итеп атлап чыга икән. Ул гына да түгел, сыер урыныннан туң тизәк күтәреп керә дә хатынын тирги, имеш. Бөтен-бөтен ипиләрне нигә чыгарып атасың син, янәсе.

Ә тормыш итү әнә шул тилебәрән ашаган ише башны тинтерәтер, шаштырыр дәрәҗәдә авыр иде. Монысына һичкемнең исе китмәде.

Бу нәрсә гади кешенең гадәти тормышы иде.

Әхмәтҗан шулай яшәде. Каркылдап йөрмәсә дә, Карга дигән кушамат йөртте.

## ГОМӘР

Кичә кичен яңгыр явып киткән иде. «Сталинец» комбайны иртән урмады. Басуга уракчылар, атлы лобогрейкалар да чыкмады. Игеннәр, җир, үләннәр юеш. Күк йөзен авыр болытлар баскан. Кистереп җил исә. Сагышлы, моңсу. Аргы яктагы болында авыл көтүе утлап йөри, елга буенда ук дуңгыз көтүе кәс актара. Электр станциясе турбинасыннан шаулап су акканы, генераторның гүләве ишетелә. Эшкә чыкмаганнарның кайберләре тегермәндә он тарттыра. Беркөнне генә хезмәт хакына арыш бүлеп биргәннәр иде. Амбар алдындагы ындыр табагында гына берничә хатын-кыз белән ир-ат күренә.

Гомәрне — башта батальон, аннары полк комиссарын — көшел каравылларга куйганнар иде. Ташып өлгерергә ат, машина җитмәгәнгә күрә, бу басуның бодаен комбайннан туп-туры җиргә генә бушатырга туры килә. Аннары гына төяп, ындыр табагына төшерәләр. Ул, кожанын бөркәнгән көйгә ышык, яктан көшелне казыбрак кереп, шуның җылысында ята, тәмәке көйрәтә. Ташлап кайтып китсәң дә булыр иде, көшел янына көпә-көндез генә түгел, төн уртасында да килеп урлаулары икеле. Бар, урлап кара: тотсалар, эшең бетте. Көшел саклаучыдан да битәр басу каравылчысы бар бит әле. Шуңа күрә бу көшелне дә Тегермән очы урамына терәп диярлек салдылар да.

Әйе, бодай көшеле җылы иде. Карлы-яңгырлы окопта сиңа елышып утырган солдат аркасы шикелле. Яисә ачык һава астындагы концлагерьдагы әсирдәш дустың кебек...

Гомәр, соңгы уен ишетмәделәр микән дип, көшел башыннан үрелеп, авыл ягына караш ташлады. Кеше-кара юк иде. Бер оя каз гына камыл арасыннан башак чүпләп йөри. Кайсы хәерсезенекеләр икән? Күреп алсалар, хезмәт көнен кисеп калалар ич инде. Фатыйма Мүчинекеләрдер әле. Бая, кармакларын тотып, балыкка төшеп киткән иде. Мондый көнне калдырмый инде. Ул, тагын Әхмәтҗан Карга белән Харис Чебен, аннары аргы якның Хәсәне — балык җене кагылган кешеләр. Ул үзе дә тотар иде. Ярамый. Болай да кырын карыйлар. Җае чыккан саен, шул немец әсирлеге белән күзне ачтырмыйлар. Менә укытучы башы белән көшел каравылларга калды. Мәктәпкә аяк бастырмыйлар инде, тик кулы барган башка эшкә дә җибәрмиләр.

Ул көрсенеп куйды да, җилдән ышыкланып, тагын тәмәке төреп кабызды. Шуны суырганда, Атау эче юлыннан төшеп килгән бер малайны күреп алды. Яланаяк, сатин ыштанының балакларын сызганган, күлмәкчән генә. Аркасына кармак таягы салган, балык тезелгән тияк тоткан. Кискен җил аны туктатып-тукта-

тып калдыра. Аннан, күкрәге белән этелеп, тагын атлап китә. Гомәр аны таныды — Сары Пышлак. Аны сары чәчле, сипкелле булганга, яратып, шулай дип йөртәләр иде.

Малай аны күрсә дә, сүз катмады, юлында булды.

Ул аны:

— Карале, Сары Пышлак, — дип туктатты. — Кил әле монда!

Малай тыңлап, сүзсез генә аның каршысына килеп басты, җиңе белән кызарган борынын сөртеп алды.

— Кая бардың?

— Балыкка ич, — диде малай, тияген күтәрә төшеп.

— Бәртәс тә каптыргансың түгелме соң? — дип сораган булды Гомәр ташбаш, жумба, кылчак, алабуга балыклары арасында кызылканат чамалап.

— Капмый карасын! — диде малай.

— Бүген үләнгә бармадыгызмыни?

— Пычрак ич. Минем тачканың көпчәге патшипник. Мондыйда тыгыла ул. Тузган да.

— Андый чакта нишләтәсен беләсеңме соң?

— Белмәскә! Өстенә пес итәсең. Чажылдап йөреп китә.

— Аягың туңмадымы?

— Туңды инде шунда. Өйдә бетә ул.

— Кил әле монда, — диде Гомәр, учы белән көшелне көрәп. — Утыр әле шушында. Хәзер җылытабыз аны, улым.

Сары Пышлак ул казыган чокырга кереп утырды. Гомәр аның аягын бодайга күмеп куйды, кожанын ачып иңенә япты.

— Җылымы?

— Беләм инде.

— Карының ачтымы?

— Әти ипи бирер әле. Безнең агач караватастындагы фанир яшиктә башланмаган ипи бар әле.

— Атаң өйдә түгел ич. Районга китте. Әнкәң дә ындыр табагында.

— Беләм. Субай Гаптулласының ләбәгрике шистирнасы җарылган, әти шуңа китте. Амбарда капчык та җитми ди, шуны да җүнәтә.

— Мәле, тамагыңны ялгап җибәр, Сары Пышлак, — дип, Гомәр кул астындагы брезент капчыктан кисәк-кисәк бәрәңге кушып пешерелгән ипи телеме сындырып бирде, сөтле чәй салынган шешәсенең кәгазь бөкесен ачып сузды.

Малай карышмады. Үзенә әңгәмәдәш табылуга хуш булып: «Башлы малай күренә бу», — дип уйлады Гомәр.

— Мәктәпкә кайчан барасың әле?

Сары Пышлак, тәмләп чәйни-чәйни, имән бармагын тырпайтып күрсәтте: бер елдан, янәсе.

— Бәлки, сине мин дә укытырмын әле.

— Син укытучы түгел ич, — диде малай, ипиен чәй белән йотып җибәргәч.

— Укытучы шул, — диде Гомәр, еракка караш ташлап. — Арифметика укытучысы. Алгебра, геометрия, тригонометрия укытучысы. Син боларны белмисең әле, Сары Пышлак.

— Белми ди сиңа! — диде малай. Аның үзенә кушаматы белән дәшкәнгә исе дә китми иде. Тачка белән үлән алып кайткач, атасы аның башын шулай дип сыйпый. — Минем апалар белән абыйлар аларны су урынына эчә. Әти дә төне буена кушып-алып утыра. Рифкәмисия бит ул!

Шунда Гомәр әллә нишләде. Кулы ирексездән малайның аркасына ятты. Әллә нишләп ачылып китте. Башыннан кичкәннәрне хәзер сөйләп чыкса, йөрәгендәге кара таш шушы малайның чиста күңелендә эреп юкка чыгар төсле булды. Һәм ул Сары Пышлакка сөйләде дә сөйләде. Мәктәпне тәмамлаганнан соң, Чистайда белем алуы, укыта башлаганын; сугыш ачылгач, политрук сыйфатында сугышканын; әсирлеккә эләгеп, иптәшләреннән берәрсенең аның «коммунистен», «политкомиссиарен» икәнен әйтеп сатмагае дип куркуларны; Демблин концлагеренда берәүнең Курмаш яшерен оешмасына керергә кыставын, ләкин моны провокация-мазар булмагае дип, баш тартуын, әмма ачлык мәҗбүр иткәч, «Идел-Урал» легионына керергә дучар булуын; аннары батальон белән Франциягә җибәрелеп, җае чыгу белән француз каршылык хәрәкәтенә барып кушылуын; азат ителеп туган илгә кайтарылгач, кулга алынып, ни гомер Кола ярымутравында — бу юлы совет концлагеренда тотылуын, тәмам бетәр дәрәҗәгә җиткәнче урман кистерүләрен, хатынының шунда берничә мәртәбә очрашуга килүләрен; инде менә акланып, кайтарып җибәргәч тә һаман тикшереп тинтерәтүләрен, җүнле эшкә алмауларын, хәзер менә көшел каравылында торуын, алай-

болай сагалап торып, харап итә күрмәсеннәр дип, колхозның сыңар уч ашлыгына да кызыкмавын; тагын балалар укытырга теләвен — боларның барчасын сагынып, горурланып, рәнҗеп, хурланып, гарьләнеп, әрнеп сөйләде дә сөйләде.

— Кайтырга вакыт, — диде Сары Пышлак, тияккә тезгән һәм кипшенә башлаган балыкларыннан бодай бөртекләрен сыпыргалап. — Өйләдән соң печәнгә барасы. Кызыл елганы карадым. Ярда урак белән урырлык калган икән әле.

— Анда ничек төшәсең? Тирән ич ул.

— Җип-җиңел ул. Бауга тотынып. Мырный өстән тотып тора.

«Мырный» дигәне Сары Пышлакның энесе кушаматы икәнен Гомәр белә иде.

Гомәр малайны сораштырган булып, үзенең әле генә сөйләгәннәрен онытырга теләвенә төшенде. Малай алдында оят булса да, шулай кирәк икәнен ул бик яхшы белә иде.

— Хәреф танýйсыңмы соң әле? — дип сорады ул.

— Танымаска!

— Укый ук беләсеңме әллә?

— Белми ди, бар!

— Кем өйрәтте?

— Кем булсын тагын. Үзем!

— Нәрсә укыганың бар?

— «Замана балалары» дигәнне.

— Исеңдә калдымы?

— Калмыйча! Анда бер малай сугышка китә, шунда атасын очрата. Аннары кайта да калхузда тары үстерә. Шуны олауга төйиләр дә сугышка җибәрәләр. Ә үзенең гелән-гелән карыны ач.

— Кем язган?

— Карамадым. Анысы кемгә хаҗәт аның?

Сары Пышлак торды, ыштанын каккалады, кармак таягы белән тияген иелеп алды.

— Кесәң бармы, Сары Пышлак? — дип сорады Гомәр.

— Кесәсез ыштан нәрсәгә ул?

— Әйдә, бодай тутыр. Тавыкларыгызга сибәрсең.

— Сиптерер әти! Белсә, иманыңны ала. Галуш эченә салып кайткач, әнинең дә кирәген бирә әле. Мин борчак кына алам. Аңа бригадир абый сүз әйтми. Ә печәнгә бәйләнә, тачканы актара, тәр-ре.

— Колхозныкын урган дип шикләнәдер.

— Ык итмәгәе мык итсен. Мин актарттырмыйм. Актарып кына карасын!

— Нишләтмәкче буласың?

— Нишләтим ди. Әтигә әйтеп, өнен алдырттырам — шул. Әтидән курка ул. Безнең әти рифкәмисие! — дип, малай «дөңк» иттереп йодрыгы белән күкрәгенә сукты.

— Бар, Сары Пышлак, кайт инде. Әнә җир кипши. Үләнгә барасың бар. Ял ит.

— Аңынчы балыкны чистартам әле. Әнинең вакыты җук.

* * *

Юк, онытмаган икән малай. Нәкъ егерме ел узгач, авылга Сары Пышлак китап чыгарган икән дигән хәбәр таралды. Гомәр ул китапны тиз тотып кулына төшергән иде. Теге чакны сөйләгәнне чәчми-түкми язып чыккан. Дөрес. Гомәр Ишмөхәммәтов дип куймаган куюын, вакыйгаларын да үзгәрткән. Ә төптән караганда, аның язмышы чаткылары — *«Томанга уралган Англия яры күренмәс булгач,* — дип укыды Гомәр, — *озатучы совет капитаны, әсирләрне тезеп, формаларны салырга боерды.*

*— Тикшерелгәнчегә хәтле әнә тегеләрен кияргә, — диде капитан, тоткын киемнәрен күрсәтеп...»*

Кием генә күрсәттеләрме соң? Тагын бер тәмуг кичерделәр! Бервакыт, авылга кайткач, Сары Пышлак аның янына менде. Әче бал белән юанып утырдылар.

— Теге яңгырлы август көнен ничек онытмадың син? — дип сорады ул.

— Беренче дәрес онытылмый ул, Гомәр абый, — дип җавап бирде Сары Пышлак.

## КӨЗГЕ

Куәтле язгы ташу башта җәелеп, шаулап, аннары эреле-ваклы ерганакларга елышып, сыясы-сыеп узган да киткән инде. Гөрләвекләрнең юлларына, яңа борынлап чыккан сап-сары чебешләрнең якты дөньяны

бер итеп чәчелүләре ише, үги ана яфрагы чәчәкләре сибелгән; кайберләре инде менә сулырга да авышкан, алар бүген бар да иртәгә юк чигенә җиткән.

Сулган чәчәкләрне күрмиләр. Бигрәк тә әле күптән генәме дигәндәй алар кояшның баеган чагында соңгы мәртәбә балкып сүнгәч. Аннары өскәрәк, югарыгарак карарга керешкән булалар: әнә инде, имеш, шомырт та ак чәчәкләрен тәлгәшләнергә көйләгән, тупыл бөреләре яланаяк йөргәнеңдә табаныңа чартлап ябыша да өйгә ияреп керә, әчкелтем-татлы исләре кичен кергәнеңдәге мунча парына кушылып тарала, тын алганың саен, бәлзәмдәй исен бөркеп, йоклаганың вакытында үзен фәрештәдәй сиздереп, белгертеп тора. Тупыл чәчәгенең бөресе икегә аерылып, ярылып, җиргә өзелеп төшәр-төшмәс вакытта, инеш балыклары әле ташудан соңгы болганчык судан анда-сандагы чишмә тамакларындагы тонык, саф урыннарга елышучан. Ташу узганлыгын, яз чәчәкләренең сула барганлыгын, инде, ниһаять, кояшның калыкканлыгымы, сүрелгәнлегеме мәлен искәргән хәлдә, бу балыкларның ана дигәннәре уылдык чәчә дә, ата димәкләре шунда сут җибәрә. Урын тымызык, камыш, тал тамырлары арасы, аралыклары былтыргы кышкы тыенкылык сасысыннан чистарган, юылган, арчылган, ачылган чак. Иң мөһиме — әлеге тымызыкка, аулакка таба йөзү, шунда барып җитү дә, соң мәртәбә дигәндәй, һич ирешмәслек күк йолдызларының санын ишәйтү.

Эзләшеп торуның хаҗәте юк. Йолдызлар көзен күктән коелышканда, аларның һәммә иҗтиһады су дәрьясын гизә.

Кырмыскалар, умырзая, бал кортлары уянышкан инде. Урман күгәрченнәренең ояларында тәкатьсез рәвештә дәвамнарының икенчесен исән-имин борынлату өчен каурый белән сөяккә калган хәлләре. Тургайдыр, сыерчыклардыр салган йомыркаларын әйләнгештергәләп барлый, ишегалларында ялгыз ата казлар түземсезләнеп таптана.

Бу — ата чабак балыкларының да күзе кызарган чак.

Ә бакаларның, базлардагы, бозы эреп бетмәгән күлләрдәге су кәлтәләренең уяныр-уянмас вакыты әле.

Менә шул чакларда адәми затларга нидер, нәрсәдер тансык, җитмәүчән.

Шушы ташка таш бәрелешеп ярылышкан, чәрдәкләнгән, вакланган, әллә ничәмә-ничә кыйпылчыкка, алардан комнар хасил булуга куанышкан вакытта, Билал, җае килгәндә, балык тотарга ашкына. Җәтмә белән сөрә-сөрә Хәсән тобасы төбендәге утырык комлыкны әйләнеп узгач, инешнең шуннан соңгы тарайган, шунда хәтмәле яңа көч алган шәттә ургылыплар торып аккан төшенә җиткәндә, ул озын, шома, җиңел юкәгә сапланган җәтмәсен тотып, тымызыграк урыннарны үзе белгәнчә кымтырыклап сөзеп баручы Тимерче Сөләйманнан беркавым аерылып торды. Ике бәртәс, өчәр кадакка тартымлык ике чуртан, дүрт-биш данә кылчак, хәтта уч калынлыгы зурлыктагы бер кара балык Сөләйманга ияреп барган Әсфәндиярның брикҗин капчыгында ара-тирә шапырынгалап куя иде инде. Ташбаш, жумба, әле бәп-бәләкәй сыла, тыгыз алабуга балыклары да хәйран гына әләкте. Күңел өчен дә, табын өчен дә җитәрлек. Шуңа күрә Билалның җәтмәне тагын салып, ни әләгәсенә кызыксынуы басылды да, ул шушы борылышка ташкын таратып салган, урыны-урыны белән өеп куйган эреле-ваклы таштыр, агач кәүсәсеме, тамырымыдыр арасыннан нимедер караштыргалап, әрле-бирле йөренергә кереште.

Тапты.

Ул кара савыты иде. Аны күрү белән Билал әллә нишләп китте: шул бит ләбаса инде — ул әллә кайчан, дүрт дистә чамасы ел әүвәл мәктәпкә шуңа тач итеп тегелгән, бөрмәсеннән сүстән үрелгән тасма уздырылып тартылган, китап, дәфтәрле букчасы тарафыннан һич аерылгысыз асылынып йөртелә торган кара савыты. Шома, авызы яртылашына тиклем эчкә таба батырып ясалган кара савыты.

Өч бармагы белән тотып ләмнән аерып алганда, ул авыр иде: ком тулган.

— Менәтерә! — диде Сөләйман.

Билал аның җәтмәсендә беләк буе җайлы бер бәртәснең вак тәңкәле сыртыннан кичке кояш аллаган су тамчылары тамгалаганын шәйләп алды.

— Тагын сөр, Сөләйман абый! Моннан тагын чыга әле, — диде Әсфәндияр.

Җәтмәсен агым уңае буйлата уздырып сөргәч, Сөләйман:

— Чыкмый кая китсен, оланнар, — диде. Җәтмәдә эреле-ваклы балыклар тыпырчына иде.

Ә Билал, инде бүтән һичнигә исе китмәстән, су буендагы ике ташка җайлап аяк баскан көйгә әлеге табылдык кара савытын суга манчый-манчый, селеккәли-селеккәли комыннан арындырырга кереште. Күпме генә селкә-айкамасын, ком катнаш ләм, инде әллә кайчан үтә-бара торган гомерне барлап санагандагы шикелле, авырыксынып кына чыга, коела иде.

Әлегегә нидер каршы төшә иде бугай. Айкаганы саен, Билал кара савытының авызына нәрсәнеңдер бәрелә, кайта-кайта сугыла иканен белеп, күреп алды. Ә бер дә бер мәлне — Хәсән тобасының текә боры-

лышлы биек ярыннан бирге сөзәклеккә ишелеп төшкән кояш нуры сирпелмәсендә сулы учындагы инде чистара башлаган савытта нәрсәнеңдер балык тәңкәседәй ялтырап киткәнлеген чамалап алды.

Ул әлеге кара савытын юа да юа бирде әле. Ә теге көмеш «тәңкә», мурдага эләккән балык сыман, чыгар юлын тапмыйча интегеп бәрелә дә сугыла торды.

Комның тәмам юылып беткән бер мәлендә Билал, ниһаять, күрде: табылдык кара савытына көзге кыйпылчыгы эләккән икән.

«Хәтерлисеңме, син?» — дип уйлады ул. Әүвәлгечә. Хәзер ул болай уй уйламый инде.

...Ә мөкаддәс Чулманны чал дулкыннар чуарлаган чак иде. Дулкыннарда мең-мең кояш чагылышы. Әйтерсең лә ул дулкыннар кояш белән качышлы уйный. Яр комында, ташларда да киң сулыштай иркен итеп дулкын шаулый, дулкын шаулый. Искән җилдән чишмә исе килә сыман...

Сине зур төзелеш колач җәйгән яңа шәһәргә илтәчәк су трамвае килергә ашыкмады.

Без текә яр астында йөрдек. Аяк астында юеш чуерташлар кыштырдады. Син, кояшка күз кыса төшеп, ара-тирә гөрләп үткән көймәләргә кул болгадың. Яланаяклап суга кердең, тешләреңне җемелдәтеп көлә-көлә, учларыңа су тутырып миңа сиптең, дулкын-дулкын чәчеңне артка чөеп, ак йөзеңне салмак искән җилгә куйдың... Ә мин сиңа кулымны сузгач, миңа таба атламадың.

— Юк, юк, хәзер чыгам... — дидең.

Янибыздан үткән-барганнар безнең якка күз атканда ни уйладылар икән? Мөгаен, безне гашыйкларга охшатып, эчтән генә көнләшкәннәрдер. Йә булмаса көрсенгәннәрдер. Без икебез ике яр читендә басып торганны алар каян белсен? Арабызда ул көн төпсез упкын иде. Төпсез упкын. Син зәңгәр дулкыннар кочагында тирбәлгән көймәләрне, баш очыңнан гына һава ярып үткән акчарлакларны, мин утырган дәү агач төбен генә күрдең, учыңа алган судагы кояш чагылышына карап сөендең... Ә мин, соңгы кабат кояшка күз аткан төсле, сиңа карадым.

Аннары без дебаркадерга таба киттек. Син әүвәлгечә бер сүз дә эндәшмәдең... Ялгыз балыкчы карт янына ук килдең дә, ул тоткан ак балыкларны жәлләп, сулы чиләккә иелдең. Миңа:

— И җанкайлар... кызганычлар, — дидең.

Мин баш кактым:

— Корбаннар кызганыч була. Аларны һәрчак күрү кирәк тә түгелдер, бәлки. Югыйсә без үзебезне гел уңайсыз хис итәр идек төсле...

Минем туктаусыз сөйләшәсем, үземне тыңлатасым килде. Шуңа күрә, күңелемне башка уйлар телгәләсә дә, сүзсез гаҗиз булганчы дип сөйләндем дә сөйләндем... Әйтерсең лә бүген кояшлы гадәти бер көн, әйтерсең лә безне бәйләгән нечкә җепләр шартлап өзелмәгән...

Син:

— Шулай да кешенең һәр адымы бу җиһанга күп газап та китерә, — дидең.

— Нәрсә?

— Күрдеңме? Син бу мизгелдә бер җан иясен чиксез газап тәмугына дучар иттең. Син камкага бастың... Фатыйма, Фатыйма, киявең килә, кач, кач... Ул үлде... Ярый, бусы — ирексездән, ялгыш. Бусы — кечкенә, чүп...

Син, иелеп, бармак очың белән бик сак кына теге чуар бөҗәккә кагылдың. Ул җансыз иде.

— Бүген синең каршыңдагы бу бәндәне газапларның иң авыры — аерылу газабына ташлаганың хакында уйлыйсыңмы икән син?.. Ник китәсең миннән?.. Юк, юк, син кызганма! Мин балык түгел, бөҗәк түгел... Кызганма...

Моңарчы син тыныч идең. Хәзер менә кинәт кенә синең йөзең үзгәрде. Кашларың әз генә калтырап, иренең чак дерелдәп куйды... Сиздерергә теләмичә, кырт борылдың, култыксага таяндың да тирән итеп сулыш алдың... Аягың астындагы бәләкәй фаҗига синең күзеңне ачты. Син, ниһаять, мин утырган черек төпне, изүе ачык ак күлмәгемне генә түгел, йөрәгемне, җанымны да күрдең. Үтә күрдең...

Син:

— Дәшмә инде... Кирәк түгел!.. Аңлаттым ич. Нәрсә өстим? Беләсеңме... язгы урманда йөргән чакта кызлар чәчәк җыйды ди... Күрше аланда алар моңарчы очрамаган тагын да матуррак чәчәкләргә тап булдылар... элекке чәчәкләрнең барысын ташлап, яңа бәйләм бәйләделәр... Ишетәсеңме? Мин дә шулай хисләремне алыштырдым... Башканы ошаттым, — дидең.

— Умырзая — алыштыргысыз. Үзең шулай дия идең.

— Бәй, син умырзаямыни?

— Син мин тапкан, тик өзмәгән беренче чәчәк идең.

— Кеше гомере — язгы алан. Ул бер кат чәчәк ата. Алыштыргысыз чәчәк...

— Син һаман шундый. Һәрбер әйткәнең — китап сүзе.

Балыкчы агай:

— Тс-с! Балыкларны куркытасыз, — диде.

Без дулкыннар чайкаган дебаркадерның аргы ягына чыктык. Анда һичкем юк иде. Җил дә тими уза.

— Җил...

Мин:

— Ышык, — дидем.

— Утыр, — дидең син.

Без аркылы салынган бер тактага утырдык.

— Нидер булган иде ич... Нидер булган...

— Белмим. Хәтерләмим. Бәлки.

— Белмим дисең. Ә хатларың?

— Ялгышмасам, соңгысында «Оныт, оныт бөтенләйгә» дип язылган.

— Бусы исеңдә икән.

— Исемдә.

— Исемдә... Берчакны без унынчыда җәдәч аерган идек. Син гел шулай «исемдә!» дия торган идең. Тәки оттың. Зәңгәр яулык. Исәнме ул?

— Тузды инде. Мин аны Братскидан китәр алдыннан үзебез төзегән соңгы йортның соңгы ташы астына салып калдырдым. Яба идем — тузды. Без кызлар белән һәрчак шулай, кирпеч астында йә бияләй, йә бакыр акча калдырабыз. Бәхеткә юрап.

— Ә синең ядкарең... һаман миндә. Кая барсам да. Кичә алып кесәгә салган идем. Менә... менә ул...

Син учымдагы үрелмәле көмеш чылбырга тагылган алтын тәңкәгә озак карап тордың.

— Талир тәңкә...

— Талир тәңкә... Хәтерлисеңме, унынчыны бетергәч бүләк иткән идең. Ни әйткәнең әле дә булса колагымда чыңлый төсле: «Истәлегем, әбидән калган. Югалтма, яме?» Дүрт ел менә. Сакладым...

Күзең яшьләнде, ахры, кулъяулыгыңны чыгарып:

— Әй, тузан, — дидең.

Ярга көчле дулкын кагып, «Ракета» якынлашты. Иңеңнән авыр йөкне алып ташлагандай, син тирән сулап куйдың. Әллә, киресенчә, ул җаныңның тетрәнүе булды микән? Мин үзем дә сизми калдым.

Кешеләр җыйналды. Басма төшерделәр. Син дә тордың. Әкрен генә:

— Йә, хуш, — дидең. Кулымдагы тәңкәгә ымладың да: — Югалтма, — дип пышылдадың. Пышылдадың... Нигә?

— Хуш...

Сузган кулың сөялле иде. Братски, Чаллы тамгалары.

— Син гафу ит. Ә теге егет, беләсеңме, мине үлемнән йолып калды. Тайгада ял итә идек. Аягым таеп, текә ярдан көчле агымлы елгага егылганмын. Миңа берни дә булмады. Ә ул үзе чак-чак үлми калган. Биш ай ятты. Ә мин...

— Ә син аның янына йөри идең, шулаймы? Рәхмәт һәм бурыч йөзеннән.

— Мин яраттым...

— Рәхмәт һәм бурыч йөзеннәнме?

— Уйламадым. Тик сөюем рәхмәт әйтүем булмады. Гомерем өчен, дөрестән дә, мин аңа бурычлы идем.

— Вәгъдәң белән син миңа да бурычлы идең. Моңа ядкарең дә шаһит.

— Талир тәңкә... Җирдә яшәү тәңкә шикелле уч төбендә ятса икән...

Син йөгердең. Култыксадан каерылып карап калдым. Учымдагы талир тәңкә, көзге кебек нур балкытып, суга чумды. Талир тәңкә. Синең вәгъдәң. Беренче вәгъдәң...

Кара савытындагы кыйпылчыкта офыктагы кояшның соңгы нуры уйнаклап алдымы соң, әллә бер-бер кошның очып үткәнендәге күләгәсе чагылып алды микән? Юк. Билал анда үзенең йөзеннән әллә кайчан гаип булган сипкелләреннән берсен күреп алырга өлгерде.

Аның ул сипкеленнән гайре калганнары кайларда сибелеп ята икән инде? Әллә кайда түгелләрдер, күрәсең: күк йөзендәге йолдызлар янәшәсендә генәдер.

Юк икән. Әнә генә ич ләбаса: әлеге көзге кыйпылчыгына әллә кемнең чәч толымы очындагы йолдызлар балкышы тернәкләндереп киткән шикелле булып алды. Ул — Билал — үзенең тумышыннан бирле бүгенгегә кадәрге гомерендә фәкать бер генә мәртәбә сиздермәстән капшап карарга кыйган чәч толымы очының исе. Чакрым арасыннан да сизелеп, сиздереп торган зәңгәр мәтрүшкәнең утта берара кайнаганыннан соң, чәй чынаягыннан бөркелепләр торып, җанга иңеп керүчән исе. Эретелгән кургашынның койган урында җәелепләр китеп таралганы кебек күзгә күренеп.

Инешнең мондагы тар төшендә, бөтерелеп-бөтерелеп, әллә кая ашкынган язгы мул суның ахыргы ташкыны ага да ага бирде.

Ә Билалның уң кулындагы инде чистартылган кара савыты төбендә чәнти бармак тырнагы хәтле генә көзге кыйпылчыгы торып калды.

Ахшам кояшын кыл урталай бүлеп, бака челәне очып үткәндә, Билал яшәүнең үз йөрәгенә төбәп атылган һәрбер ядрәне:

— Инде! — дип куа белгәне сыман, хәзер дә: — Инде! — дип куйды.

Ул Сөләйманның:

— Әсфәндияр, монау эт балыгын йолкып ат әле, — дигәнен ишетте.

«Эт балыгы, — дип уйлады Билал. — Яшәүчәнлек дигәндә аңа биргесез су хайваны юк бит ул».

— Нигә атасың ди аны? Безнең мәче моның өчен җанын бирә, — диде Әсфәндияр. — Кылчыксыз. Эче тулы уылдык.

— Шулай. Җаны теләгән җылан итен дә ашар, — диде Сөләйман.

Ә болганчык су бөтерелә-бөтерелә акты да акты.

Батыры алдыннан тәмам кызарган кояш шикелле, бераздан — канатлары киселеп, тәңкәләре кырылганнан соң эче чистартылган теге-бу балыклар, таман итеп тозлагач, онда әвәләгәч, майлы табада алтынланып, чаж да чож пешәрләр. Шик юк.

Билалның да һичнинди шиге калмаган иде инде. Әллә кайчан инде Фирая аңа яз исенә, дымына тулышкан тыкрыктагы иске читән буенда:

— Чыкмыйм. Син әллә нинди, — дигәч, Билал өйләренә төшеп китте. Ә анда аның соңгыга биргән кесә көзгесен уң кулының учына салган иде дә, ул чактагы көчле бармаклары белән чәрдәкләп ватып, кыйпылчыкларын шушы инешкә койган иде. Ә берсен — учын канатканын — икенче көнне теге савытка тыгып ыргытты.

— Җитәр, — диде Сөләйман. — Кайтабыз.

— Шәп эләкте, — диде Әсфәндияр.

Билал: «Язмыш балык түгел, — дип уйлады. — Балыкның тотылмаган иң зурысы берәү генә була».

Ул әлеге кара савытын чалбарының уң кесәсенә салганда, теге көзге кыйпылчыгы, ниһаять, чыгып, аның учы төбенә кадалды да бер тамчы кан саркытып чыгарды.

Тик Билал моны бүген тоймады әле.

Яшәү белән көзге арасында кабер генә булганлыгын һичкем алдан тоймый.

## ҖИРЛӘГӘЧ

Гомерем буена: «Үләсем килә», — дип яшәгән идем. Үлгән чакта гына: «Яшисем килә», — дип әйтә алмадым. Ә яшәргә дә, үләргә дә соң иде инде.

Үлгәч, мине татар зиратына күмәргә теләмәүчеләр булган икән. Мин чуаш хатыны Василиса гына шул. Югыйсә бу татар авылында даным да, шөһрәтем дә бар иде бугай. Мине Василиса Павловна дип йөрттеләр. Ә миңа әбиләрнең, бабайларның, балаларның — һәммәсенең Вәсилә дип дәшүләре, эндәшүләре үз иде. Мал докторы булсам да. Тик минем хакта ат духтыры дип һичкем әйтмәгән. Берзаманны мине Кәримулла абый чакырткан. Урамыбызда безнең өебезгә ике генә өй үткәч торалар. Аның үгез бозавы бар иде. Шуны печәр чак җиткән. Эшемнән бушагач, авыл көтүе кайтканчы шуларга бардым. Кәримулла агай капка төпләренә тирә-күршедәге тимерчене, пенсиядәге укытучы Госман абыйны — биш-алты ир-атны җыеп куйган. Әлеге малның аякларын тышаулап, бар көч белән җиргә егып салырга дип инде. Килеп җиттем дә, җирдәге бауны алып, теге үгезне юмалый-юмалый аякларын урап алгач, бер генә тарттым. Мин кызу эшләргә күнеккән. Шуннан соң абзарга кертеп япкач, утлыктагы үләнне чемченергә дә керешкән. Мин өйгә кайтып киттем, теге ирләр карап калды. Иртәгесен аларның таң атканга хәтле мине сөйләп утырганнарын җиткерделәр. Әллә тагын... Белгәнемне, кулымнан килгәнне генә эшләдем. Белгечлегемә укытканнарынча, өйрәткәннәренчә, күнеккәнемчә. Эшләргә гадәтләнеп була инде ул анысы. Яшәргә дә. Үләргә гадәтләнү генә юк бугай. Хәер, бөтен нәрсәгә өйрәтәләр, өйрәнәләр. Соңгы сулышыңны ничек сулыйсын гына әйтмиләр. Аны үзең генә аласың. Бусы — беренче дә соңгы тапкыр гына. Анаң кендегеннән аерылгандагыча. Югыйсә ана карыныннан төшү, кендек киселү, имчәктән аерылу — сизмәвең, белмәвең аркасында җипҗиңел ул. Сизә, белә, аңлый торып, туган җиреңнән аералар икән, монысына түзәргә ярый. Иң газабы — чит-ят туфракта сине гүргә иңдерүләре икән. Әби белән бабайны, алар белән бергә булачак әтиемне өй түбәләре такта белән ябылганы өчен чуаш иленнән Себергә сөргәннәр. Әйтерсең лә ул сөрүчеләрнең табут-

лары, ләхетләре, баш казыклары такта булмаган. Ярый инде, агач яручы ирем миңа ниятләнгән ләхет такталарын да җеген-җеккә китереп эшләгән. Аның соңгы тапкыр иренемә тидергәннән соң калган бер тамчы су да үтмәслек, сеңмәслек, кермәслек итеп.

Шулайга күрә рәхмәтем йөзеннән, ахыргы сулышымда мин: «Ләәәә иләәһә илләллаһу Мүхәммәдррасүлуллаһ», — дип калырга өлгердем. Югыйсә мине күрше урыс авылына илтеп җирләсеннәрмени? Ирем — саф мөселман, кызым — мөэминнән, ә минем чукынганым, тәре тагып йөргәнем юк. Мин — чуаш кызы. Безнең Себердәге авылга ни чиркәү, ни мәчет салдырмаганнар. Кемдер Инҗил, кемдер Коръән яшерсә дә, барлыгын һәммәсе белә иде анысы.

Баракта торган чагында, ирле-хатынлы Исмәгыйль абый белән Мария апа сәкесе астындагы сандыкта шул китаплар аслы-өсле тора иде. Безгә әле бусын, әле тегесен укыдылар. Исмәгыйль абый бөти тагып йөрде. Аны күмәргә алып киткәндә, Мария апа аңа үзенең алтын тәресен тагып җибәрде, үзенә шул бөтине киеп калды.

Укыдым инде. Институтта аспирантурага калдырабыз дигән көннәрдә концертка барган идем. Шунда бер татар егете үз гармунында уйнап, гел миңа карап кына җырлады. Өйләнештек. Аның Татариядәге әнисе вафат булгач, шунда кайтып төпләндек. Мин үлгән көнне ул авылдагы бер абзый мине мондагы зиратка җирләргә ярамый дип йөргән. Ә мин яшь кенә муллага: «Ләәәә иләәһә илләллаһу»ны әйткән идем инде.

Мин булып мин дә яткан мөэмин-мөселман зираты очсыз-кырыйсыз булыр, Алла боерса.

Монда гүр кысан кысанын. Тик туфрак авыр түгел.

* * *

— Яшәгәндә күк иркен. Үлгәч йолдызлар да җиңеләя, — дигәч, Вәсилә ак яулыгының уң очы белән иң соңгы тамчы күз яшен сөртеп алырга өлгерде.

Әллә кайда аҗаган уйнап алды. Тулган ай зәңгәрләгән зират астындагы тугайда карт бия әле генә карыныннан төшкән колынын ялый башлады. Себер карурманында табылган бер мәхбүс мәетнең алтын тәресе рухына кадильяның төче төтене иңде. Ә Татария авылындагы агач йортның мич авызы каршында күрек элмәге ычкындырылмаган тальян гармун телләрендә Вәсиләнең ире буыннары каткан бармаклары белән ниндидер көй эзләп интегә иде.

Янындагы ак эткә ул:

— Кушыл, Акбар, — диде.

* * *

Аның миннән соң бүтән берниндн хатын-кызны якын итмәслеген соңгы тамчы суын иренемә тидергәндә дә белә идем инде. Әйтмәдем генә. Ахыргы сүзне әйтмиләр. Үлгәннәрнең әйтми калдырганы терeләрнең төшләренә керә.

*2001 ел, 12 ноябрь*

## КАРАЧКЫЛАР

Зират каеннарына кичкырын кара каргалар килеп кунган иде инде. Әсхап үзләренең яшелчә бакчаларына карачкы ясап куйды. Авыл көтүе кайткан, сыер, бозавы, ике яшьлек үгез абзарга ябылган, сарык, бәрәннәр урнаштырылган, тавык-чебеш үз урынында, үрдәк бәбкәләре тук. Акбар атлы эт тыныч кына ята, ике мәче кайда йөри икән — йөрсеннәр. Кызлары Хәдичә телевизор карыйдыр инде. Ә уллары Гаденән мотоциклын төзәтте дә... Кая барасын үзе чамалыйдыр тагын. Иртәгә аның соңгы имтиханы — унынчыны тәмамлый.

Әсхап шуларны уйлый-уйлый да, уйламыйча да, болай гына — бәрәңге белән карлыган арасындагы өч сажин аркылыйга, сигез сажин буйлыйга утыртылып хәстәрләнгән яшелчә бакчасын караштыра иде. Болай... тишеләсе әйбәт тишелгән, борнаган, яфрак җибәргән анысы. Тик иртәләрен түтәлләргә үз тавыкларыннан битәр... күршедәге Гөлбаһар тавыклары, өстәп кара каргалар төшеп актарынмасынга куркытыр өчен әнә нинди карачкы ясап куйды бит әле! Хәйран-тамаша! Нәкъ үзе.

— Бу ни бу? — дигәнгә ул борылып та карамады.

Ире инде — Сәгыйт. Кайткан.

Әсхап юеш, балчыклы кулын күлмәк итәгенә сөртеп куйган булды. Белеп инде. Ире кайтканда кулын итәгенә ничек итеп сөртәсен чамалый ул. Редисканың җирдән калыккан кызыл өлеше сыман, кояшка янган сыйракларыннан тез югартын шалкандай ак төшен чак-чак кына күрсәткәндәй итеп.

Сәгыйт, үзенең солдат киемен элеп ясалган карачкыга ымлап:

— Бу ни бу? — дип сорады.
— Син, — диде Әсхап.
— Күрәм. Ә бу киемнең эшкә җарарлыгы да барые ич әле.
— Җарар сиңа, бар! Эретеп җабыштырасың да җабыштырасың. Утыңда иләк булып беткән ич инде.
— Бетсә суң! Моңынчы ул тишекләрдән төшереп калдырган нәрсәм җугые ич әле.
— Тишәргә сиңа бир инде анысы.
Сәгыйт хатынының күлмәк изүендәге төрән шикелле күгәреп күренгән төшкә кырын гына карап куйды да:
— Анысы ярый инде, — диде.
— Нәрсә анысы? Ни җитмәгән? — диде Әсхап.
— Җитүе җитеп бара бугай инде анысы, — диде Сәгыйт.
Әсхап, күлмәк итәген югарырак күтәреп, кулын сөртте дә:
— Таныдыңмы суң? — диде.
— Нәрсәне? — дип сорады Сәгыйт. — Бу ни бу дидем ич!
— Син, — диде Әсхап.
— Минем гвардия сержанты киемемнән башкасын тапмадыңмыни?
— Шушысы әйбәт, — диде Әсхап.
— Суң?
— Син әрмиедән кайткач, мин синнән курыкканыем.
— Суң? — дип кабатлады Сәгыйт.
— Менәтерә, хәзер тавык, каргалар курыксын инде.
— Курыксын? — диде Сәгыйт. — Бәлки, алар мине... ни... яратып кунаклардыр.
— И-и-и! — диде Әсхап.
Сәгыйт түзмәде: су сипкечне мичкәгә чумылдырып алды да, шуннан сарымсак түтәле буйлата сиптереп узгач, кырыс төстә:
— Аш пешкәнме? — дип сорады.
Әсхап, тыныч, сабыр, ягымлы гына итеп:
— Мунча да әзер инде, — дип җавап бирде.
Кичке тузан басылган, тулган Ай калыккан, шомырт, чия, алмагачларның ботаклары төнгә каршы турайган иделәр. Сәгыйт, соңгы тапкыр шикелле итеп, сигарет суыра-тарта яшелчә бакчасына чыгып басты. Яланаяклап. Ак күлмәк-ыштанлы килеш. Рәхәт иде. Шомырт, канәфер чәчәге, инеш суы исе килә. Абзардан тирән итеп сыер сулаганы ишетелә. Ә кысыр җирдәге кыргый чиялектә өзелеп-өзелеп сандугач сайрый. Тын. Тып-тын. Мунчала күлендә бер-берсен бүлдерми генә бакалар сайраганын тыңламасаң. Әйбәт. Әнә, карачкы да ап-ачык шәйләнә. Шәп. Солдат киемле карачкы. Аныкы. Торсын. Яхшы. Шәлперәек түгел ич. Асылынып, хәлсез-әхвәлсез тормый. Сак тора. Һәрвакыт әзер булып. Мунчала күленә салып казыклаган юкә кабыклары шикелле җебергә, аннан ары таралырга, сүтелергә дигәнмени? Бигрәк тә мунча кереп чыкканнан соң. Әнә ич: Ай ничек тулган! Әйе, тын. Улы Гаденнәннең капка төбендәге мотоциклы сүнгәч бигрәк тә. «Иеме, Ай?» — дип уйлады ул. Ай «Ие» дисенмени инде?! Ул дәшми. Эндәшми. Тәгәри шунда. Май ае себеркесе белән изеп, таптап, «Аһ! Аһ!» дидертә-дидертә чапкачыңнан суң, Әсхапның ләүкәдән әллә ишелеп төшүе, әллә күтәрелеп китүе шикелле.
Сәгыйт сигаретын актык мәртәбә суырды да, анда-санда борнаган бәрәңгеләргә таба чиертеп җибәрде. Күрде: утлы төпчек тулган Айга җиткән бермәлне... әйе, күрде: күршесе Вәдүтнең хатыны Гөлбәһар да үзләренең яшелчә бакчаларына карачкы куйган икән. Зәңгәр күлмәк кидертеп. Сәгыйтнең солдат киемен көтеп-көтеп тә киелмәгән, тузмаган-туздырылмаган крепдешин күлмәген.
Тулган Ай нуры шул күлмәктәге түм-түгәрәк ак борчакларга үтәли төште дә эреде дә бетте... Сәгыйтнең кырыс кына саркып чыккан ике бөртек күз яше сыман.
Ул йокларга кереп китте.

* * *

Ай тәмам калыккан, шомырт, чия, канәфер, алмагачларның чәчәкләре кояш чыкканчыга хәтле шәлперәйгән иде әле.
Зират каеннарындагы кара каргалар әледән-әле бер-берсен бимазалаштыргалап йоклый да йоклый.
Авылда берараны сандугач та тынып торды.
Шул чакта солдат киемле карачкы:
— Нихәлләрең бар суң? — дип эндәште.
Зәңгәр крепдешин күлмәкле карачкы:

— Менә, җуып, үтүкләп чыгарганнарые әле, — диде.
— Син һаман әүвәлгечә икәнсең, — диде солдат киемле карачкы.
— Син дә шундый, — диде зәңгәр күлмәкле карачкы.
— Нинди?
— Мин сине өзелеп көткән, ә син кайткан көндәге шикелле.
— Нинди?
— Үпкәләмә инде.
Ике карачкының бер-берсенә, ниһаять, якынаюын, кочаклашуын тулган Ай гына карап торды.
Җир уянып килә иде инде.

*2002 ел, 22 октябрь*

## КЫЛЧЫК

Капка төбенә бер йөк салам китереп аудардылар. Көн авыр, салкынча, болытлы, аяк асты пычрак. Туңдырган да иде инде. Аннары җебетте. Алай да рәшәткә буйларында, өй, абзар түбәләренең яссырак төшләрендә, агач араларында кар эреми калган. Ул тагын атна-ун көннәрдән соң — декабрь башларында гына ятар, ахрысы. Шуңа күрә сугымга да керешмәгәннәр иде әле. Абзар-курада мал-туар, ишегалдында кош-корт. Таң күзеннән алып, эңгер-меңгер төшкәнче карыйсы, ашатасы, сугарасы. Кул бушамый. Ә җан тыныч — монысы яхшы. Җәй коры килсә дә, яңгырлар да куандырып киткән иде. Печән күп, Аллага шөкер. Ике баздагы бәрәңге белән мал чөгендере дә җитәрлек. Келәттәге ашлык та шактый мул. Кибет хәлләре генә мөшкел дип... Аллага шөкер, җаның теләгән бар да бар. Уч төпләрен кычыттырырдай акчасы гына артык юмартланып китәргә ирек бирми. Монысы бөтенеңә тигез инде. Мирдән узып булмый. Тиз көндә җайланыр да шикелле түгел. Телевизор әйтеп торган хәвеф-хәтәрләрне генә күрергә, кичерергә язмасын. Ул кара-каршы атыш, җимерү, кан кою, җан кыю өннәрне алып бетерде. Ил кырыкмаса-кырыкка таркалды, бөлде. Саулык бирсен дә, йорт-җирең бөтен торсын инде. Калганын күз күрер тагын. Хәер, кичермәделәрме соң? Кичерттерделәр!

Менә бүген хуҗалык өстәмә салам бүлде дә бер трактор арбасы кадәрлесен аударып киттеләр ич әле. Анысы печәне тезмәләргә дә шыплап тутырылган, лапаска да өелгән, бер чүмәләсе бәрәңге бакчасы башына да очлап куелган. Иншалла, күз тимәсен. Саламы да әйбәт. Сап-сары, төп буйлары алланып тора, эт эчәгеле, зәңгәр чәчәкле, билчәнле, коры. Бер-ике күтәрәм кадәресен яңгыр каралтканы, салкын катырганы да эләккән эләгүен. Зыянлы түгел. Маллар астына түшәргә ярап куя ул. Саламсыз тирес була димени?

Йөкчеләр риза-канәгать калды бугай. Саламны бушаткач, өйгә керделәр. Акча-фәлән бирү бетте бит инде. Лотфия апалары итле аш сосканда тамак кырырга да өлгермәделәр, алларына тып итеп кызыл чөгендер белән алсуланылган әче бал банкасы килеп кунды. Аларга тагын ни кирәк? Бер-ике кашык аш кабып куюга, чынаякларын күтәрделәр. Шуннан соң чүпрәсенә төшеп җиткәнче, тозлы кәбестә генә шыгырдаудан туктамады. Сүз өчен шул саламны мактадылар инде. Дөнья хәлләренә кереп тормадылар. Җае ул түгел. Бүтәннәргә дә кайтарасылары бар әле. Әйтмәделәр димәсеннәр өчен генә шикелле, аларның быел язын Азәрбайҗанда үтерелеп кайтарылган полковник Минзөфәрләрен искә алдылар да кузгалдылар. Болдырда тәмәке кабызып тарткан арада, «Лотфия апагыздан яшереп кенә тотылган нәрсә» дигәнне бик аңлаган кыяфәттә бер литрлы банканы кабымлыксыз гына өстәделәр дә тагын кырга чыгып киттеләр.

Сәнәк сабы очын иягенә терәп, Расих салам өеме янында ялгызы басып калды. Бераздан ярдәмгә Лотфиясе чыгып җитәр.

Ян бакчаның рәшәткәсе өсли генә атып, саламны чүмәләгә куясы. Куелыр. Кайткан ич әле. Бар. Менә. И, әүвәл! Шуны үзең ашардайга җитеп, бер учына тилмергән заманнар! Кар явып торамы, җирдән себертәме — кышкы кичләрдә генә чанада тартып, язгы болытлы төннәрдә генә күтәреп алып кайткан чаклар... Рөхсәтсез генә инде. Йөрәге җитеп, сиңа кем рөхсәт итсен? Богыл төбендә калган карлы-бозлысын бит әле ул. Үз йөрәгеңне төн җәтмәсендә чабак балыгыдай чәбәләндерә-чәбәләндерә урлаудан кала бүтән чарасы юк иде ич аның. Урлау иде микән соң әле ул? Атаң шул бер чаналык, йә күтәрә алганчыдан да авыррак итеп бәйләнгән бер көлтәлек салам хакын да хаклап, сугышта башын салмаганмыни? Айсыз, болытлы төннәрне сайлап кына, җан тирен чыгара-чыгара алып кайтырга яраган ул салам урлаганга санала икән, аның гомере өзелү урлауның иң зурысы булмаганмыни? Атны дилбегә белән тыйгандай, йөрәгеңнең ярсып тибүен арка бавы белән тыя-тыя кайтып кергәннең соңында әнкәң тамак ялгарга тәгәрәткән бәрәңгедән гайре ризык заты тапмый икән, ул әнкәңнең шуңа оялуы әлеге урлау оятыннан кечерәк идеме әллә? Сәкедәге ике кызыңның, бишектә яткан улыңның тәмле йокысын тоя-тоя, беләкләрең талганчы, маңгай тирең

чишмәдәй ургып чыкканчы хатыныңны яратасы урынга икәүләп әллә кайдагы көртләр баскан салам богылына таба чыгып китәсең икән, синең ул беләк талуыңны, тир тамчыларыңның кайнарлыгын югалтуың кайсы ягы белән бер күтәрәм салам урлаудан кечерәк иде, йә? Әй! Нинди урлау ди инде тагын? Дөньяның өзелеп төшкән керфегенә дә тимичә яшәделәр ләбаса!

Шулай колхоз авылдан ике чакрым ераклыктагы Ялпы тавы каршындагы салам богылын ташытып бетергән иде. Кул чанасы тартып, Расих белән Лотфия төнлә шуның калдык-постыгына дип киттеләр. Сәнәк сабын тилгән канатыдай талгын гына айкый-айкый, кар баскан туң саламны каерганда, Расих нигәдер аркан борылып карады. Әллә ничек — янында хатыны юк шикелле тоелып китте. Ә ул шунда икән. Каерып чыгарган саламны чанага төявеннән туктаган да, төягән кадәресенә аркасын терәп, кинәт аязып киткән кара күктәге айга карап тора. Ә ай тулган, якты иде. Шуның фаш итәренә өркеп киткәнме соң дип уйласа, юк икән, тәмам онытылган, ай нурына йотылган, монда түгел, — әллә кайда. Шунда — айда иде, ахрысы. Расих сәнәген кадады да, төнге авыл урамына кергән чакта карны шыгырдатмый йөрергә күнеккән гадәтенчә, сак кына аңа таба атлады.

Янына җитте, ай нуры зәңгәрсу-алтын төскә манчыган йөзенә карады. Күрде, тойды: Лотфиясенең япан кырдай чиксез моң, ниндидер үкенеч, рәнҗеш белән тулы битендә, бәләкәй-бәләкәй айлар булып, күз яшьләре ялтыраша иде. Фәкать иң беренчеләре генә ирен почмагында туктаган да мәрҗәндәй агарып калган. Мыегындагы боз сөңгеләре белән чәнчәсен дә онытып, ул иренен башта бер, аннары икенче мәрҗәнгә тидереп-тидереп алды. Әлеге бөртекләрнең тозлы боз салкынын тояр шикелле иде дә — юк, эретелгән ике тамчы кургаш йотып җибәргән сыман булды. Ә аннары... алтынланып яткан саламның салкын кочагында әллә тычкан чыелдады, әллә тыенкы гына итеп Лотфиясе көлеп куйды. Расих үзе моны ишетмәде дә кебек. Ә менә ялгыз ай күргәндер. Бәлки, көнләшкәндер үк. Шушы тау итәгендәге түгәрәк күл буенда җәйләрен үсә торган алпут гөлләренең ал чәчәкләре ачылып киттемени! Аның көлүе шулай тоелды... Анысы Лотфиясен аннары соң да шулайрак көлдергәләгәне булгандыр инде ул. Тормыш ич бу. Тик нәкъ шул чактагы ишесен бүтән ишетмәде бугай дисә ничек инде... Ие.

И, дөнья диген! Нечкә генә алтын сабакта тибрәлгән ач башаклы гомер. Юк-юк, ни генә дисәң дә, — тук башаклы, тук. Бугай.

Шуларны уйлый-уйлыймы, искә төшерә-төшерә, хисләнә-хисләнәме, хәзер ул капка төбендәге саламның бер күтәрәмен алдына җәйлап куйды, аңа иплӛп кенә сәнәген батырды. Нәкъ элеп алам да рәшәткә башыннан бакчага атам дигәндә генә, ниндидер бер саламның шартлап сынганын ишетеп алды. Әллә сәнәк сабымы? Йөрәгенә башта энә очы тидеме соң, аннары күгәрек кадак килеп кердеме, анысы урынына очында бер тамчы су тамам-тамам дип торган сырлы-сырлы боз сөңгесе кадалдымы...

Күз алмасын башак кылчыгы чәнечкән шикелле генә булды.

*2002 ел, август*

## АРА

Аерылышканнар иде инде. Җәйге челләдән соңгы эңгер-меңгер узып, караңгы төшкәч, бер хатын зират каршындагы өйнең бикләнмәгән капкасын ачып узды да болдыр ишеге төбендә тукталып калды.

Ул, һәрвакыттагыча зәһәр итеп:

— Миргазыян! — диде.

Шуны гына көткәндәй, өй ишегенең тупсалары шыгырдады да бер ирнең йомшак тавышы ишетелде:

— Әү, әү... Синме, Зөләйха?

— Мин ием әле.

— Берәр хәл чыкты мәллә?

— Җук.

— Балаларыбыз ни хәлдә?

— Җахшы!

— Суң?

— Ни... мунча җакканыем.

— Әйбәт булган.

— Кайт, кереп чык.

— Мин чыктым инде.

— Каян?

— Мунчадан.

— Кемдә?

— Кемдә булсын — үземдә.

— Җаңгызыңмы?
— Җаңгызыңмы дип... Синең белән түгел ич инде.
— Кем белән суң?
— Үзем.
— Әйдә, кайт. Аркаңны уармын.
— Удылар да.
— Кем?
— Син түгел ич.
— Кем?
— Әйтәм ич — син түгел инде.
— Сабын... мунчала...
— Шәп булды, шәп.
— Чәчеңне җуарга... кычыткан суы барыемы суң?
— Жук. Ул моны белми әле.
— Кем?
— Син түгел ич инде.
— Кем суң?
— Белмисең әле.
— Кемне, Миргазыян?
— Аны инде. Кемне булсын тагын!
— Кемне?
— Җарар. Ниттем инде... беренчесенә баштанаяк җуындырып чыгардым. Аңынчы шәпләп чабындырдым.
— Мине шикеллемени?
— Сине шикелле шул. Бүтәнчә нишлим суң?
— Әйбәт булдымы?
— Әлбәттә. Әнә, җоклап ята. Эреп. Синең шикелле... Исеңдәме?
— Исемдә.
— Бар, өйгә кайт инде.
— Кайтмыенча кая барыйм суң?.. Ә син?
— Мин калыйм инде.
— Җалгызыңмы?
— Нигә ялгызым булыйм ди? Әйттем ич: эреп җоклый әнәтерә.
— Кем? Кем?
— Син түгел шул инде, Зөләйха.
— Әй!
— Җахшы, җәме? Бар, өйгә кайт. Балалар көтәдер.
— Алар сине көтә.
— Җарар... җарар, көтмә инде. Булды-бетте, җәме?
Шулчакны өйдән берәүнең:
— Миргазыян, — дигәне бу хатын белән ирнең арасын төнге ярканаттай ярып узды.
— Әнәтерә, дәшә, — диде Миргазыян.
Шуннан соң Зөләйха айлы төнне сагайтып, каршысына өреп чыккан этләргә һичнинди илтифат итмәстән өенә кайтып керде дә... яккан мунчасына кереп, баштанаяк юынды. Каен себеркесе белән бетенгәнче чабынмакчы иде дә... мунчасының пары сүрелгән икән шул инде. Чүмеч белән селтәп торып су җилпесә дә, мунча ташлары әллә «пыш», әллә «сез» дигән шикелле генә чыжылдады. Ә каен себеркесенең уртасына кушып бәйләнгән зәңгәр мәтрүшкәләрдән аның Миргазыяны исе килә иде шикелле.
— Әй! — дип, Зөләйха шул ис белән әллә наз тансыклаган имчәкләрен уды, әллә шунда мунчаның бәләкәй тәрәзәсеннән ургып кергән тулган айның сары йөзен юды.
Шунда аның Миргазыяны булсамы? Зөләйха:

Алым җәл түгел сиңа,
Гөлем җәл түгел сиңа, —

димәс идеме дә, Миргазыяны:

Әллә ниләр бирер идем
«Аһ» дигән сүзләреңә, —

дип әйтмәс идемени?

Зөләйха бу мәлдә зират турысындагы өй болдырының биек ишеге төбендә тәмәке тартып утырган иргә өй түреннән берәүнең:

— Ни... Нитмә инде... Кил, ят, — дигәненә Миргазыянның:

— Мин нитим әле... монда гына җатып торыйм булмаса, — дигәнен каян ишетсен соң?

Ерак ич. Дүрт өй аркылы. Яшәү белән зират арасы. Аяк белән аяк арасы гына түгел.

*2002 ел, октябрь*

## ӘЛЛӘ ТАГЫН

Бала чагында тәгәрмәчле тачкы этеп, ә инде әз-мәз буй-сын җибәргәч, ике көпчәкле арба тартып, үз кулы белән җеген-җеккә берәмтекләп утаган, тешәүле урак белән урган, шәп итеп тапалган, аннары кыргыч белән кырылган, янавыч белән янаган, чалгы белән чапкан үләнне җан ачыйгысын чыгара-чыгара тартып кайткан борылмалы-сыгылмалы озын-озак юлларны инде дә менә хәзер, әллә күпме еллар үткәннән соң, кулына җиңелчә зәңгәр чиләк тоткан килеш, унбиш йотым чамасы чәй ясап салынган полиэтилен шешә, андый-мондый очрак килеп чыкмагае дип, күн кынга тыгып куелган үткен пычак салган көйгә туган авылы ягына җиләк җыярга дип кайтып баруы Хәйгә ел буена җитәрдәй әллә нинди бер ләззәт тойгысы бирә торган иде.

Югыйсә ул шәһәрдәге фатирына, андагыларга бакча җиләкләрен кайтарып биреп, болар инде кайнатма рәвешендә тиешле савыт-сабага тутырып куелган, кыш фасылының һәр аенда фәлән дә төгәнчә сыйланырга дигәндә караңгы бүлмәләрендәге саклык урынына иплəп урнаштырылган. Моңа караганда да мулрак итеп, кара карлыган да, хәтта үтә тансыклы ният белән каен җиләге дә җитәрлектән уздырып хәстәрләнгән. Аннары соң кара җимеше, өреге, йөземе китә дә, анысын, акчаң бар икән, өйдәгеләре үзләре белгәненчә әзерли. Шул ният белән мәшгульләре чагында белдекле кыяфәттә боларның кул астына килеп кермәсәң, сабыр иткәннәренә шөкер генә төстә ут-күз тирәсеннән, савыт-саба әтрафыннан, мал суйганда аяк астында буталышкан этнедер, мәченедер берәр төрле калҗа хисабына читкәрәк куып җибәргәндәй, синең кирәкмәслегеңне белгертеп, боларның җиләк-җимеш кайнатулары, ут гөрләп торган төштән куып җибәрүләре — менә ни-нәрсә рәхәт! Уттагы кайнатманың урта төшенә ургып чыккан алсу күбеге барыбер синең тансыклаган чәеңә керә инде ул. Ләхетеңә кертеп яткырулары алдыннан хушбуй, исле сабын тәмнәрен соңгы мәртәбә тоеп, иснәп өлгергәнең шикелле.

Әйе. Нәкъ. Шулай шикелле. Шунсыз ничек инде?

Хәй үзенең туган авылына җиләк җыярга дип кайткан иде. Җиләк дигәч тә, ул хәтле дә әллә ни мал, ризык түгел инде ул анысы. Ул үзенең кайчандыр әллә бәхет кичергән, әллә хәсрәт чиккән җирләрен җанының килсап астындагы тары кабыкларыдай тетелепләр бетеп, үз-үзен киле төбендәге алтын-сары бер бөртектәй хис итәр чамасыннан чарасыз калган чагын күз алдына китереп, өзгән җир җиләгенең беренчесен муенына элгән тырысына салмыйча калмый, бармак арасына эләктергән бөтәнен, гомерендә беренче тапкыр... әллә кемне инде... ирексезләп үпкәне сымак, иренәнә тидерми, үпми, суырмый, йотмыйча булдыра алмый инде.

Шуннан соң ул үзенә ияртеп алып килгән бәгъзе тирә-күршеләрен иң күп уңган, пешкән җиләклек үйдыгына куя да — әллә кая китә дә бара. Йөри. Туктый да — чүгә. Тегеләр исә — ирле-хатынлымы, бала-чагамы, әллә кем челләдә көч-хәл белән күмәкләшеп тә, аерым-аерым да үз чиләкләрен тутырып җыеп яткан арада, әллә кайдан, һәммәсенә дә ишетелерлек иркен, көчле тавышы белән:

— Әү! Кайтабызмы инде?! — дигән сөрән сала.

Аның авазы яр битендәге каеннарның авыр, яшәү белән тулы яфракларына ялгызак бер җил, Гайшә-Фатыйма кулының сихәтле ымы кебек, үзенең тылсымлы салкынчасын өреп киткән шикелле генә була.

Җәйге челләдә кошлар тына. Әллә нидә кемнеңдер (аның инде) бала чагында мич аралыгыннан ишетелгән сыман, тыйнак кына итеп, ниндидер бер кыр чикерткәсе аваз салып куя.

Сандугачларның инде киләсе елга хәтле тынып калганнары вакытында ниндидер, кайдагыдыр чикерткәнең бер сайрап алуы да тансык.

Йөз үбешкәннең соңында актык тапкыр тагын бер мәртәбә үпмичә калуың өчен мең үкенгәндәге кебек.

Әйе. Ә ул үз насыйбына язган җир җиләген үтә дә кызу җыеп ала торган иде. Кеше анда җиләк барлыгын һич белмәгән, белалмаган җирдән. Әллә инде бүтәннәрнең кулы, өне, уе, әнкәсе әйтмешли, иҗниган җиләкле үйдыклар, чокыр-чакыр буйлата былтыргымы, быелгымы язгы ташкыннар акканда уелып-уелып төшкән кисентеләр, һәммә үлән, аларның тамырлары, бөҗәкләр, киләсе елны һичшиксез убылып төшәсен белгән кәлшә үләнле, тукранбашлы, миләүшә, кыңгырау, кояш чәчәкле яр буйлары аны гына көтеп торалардыр кебек, ә челлә әлсерәткән кәлтәләр, кара, җиз, көл төсендәге еланнар очраганда аңа һичкайчан тимичә сузылып китәләр.

Юлдашлары янына әйләнеп килгәндә, аның чиләге түбәләмә тулып, муенына аскан тырысына чаклы җиләкле була да, аның култык астында сары, күк мәтрүшкәдер, меңьяшәр чәчәгедер, курчак-курчак шикелле итеп, ишелгән үрмә үләнедер, баудыр белән йомшак кына төйнәлгән булыр иде инде. Ул аларны кеше күзенә күренмичә үскән урыннардан һичкемнең карашы төшмәс вакытларда гына җыеп алучан. Үткен пәкесен җайлап, фәкать бисмилласын әйткәненең соңында гына. Билендәге каешына тагылган күн кындагы гаярь пәкесен кояшта уйнаткалап алгач, дару үләннәреннән кыласы гамәле өчен гафу итүләрен, кичерүләрен сораштыра-нитә генә. Кояшка карап алып, аның нурыннан әлеге шифалы үләннәрнең сыек күләгәсе үзе дога кылган арада кая таба авышканын чамалагач, белгәч кенә.

Ул җиләкләрнең һәр бөртеген беренче итеп үпкән, соңгы сулышында инде мәңгелеккә фәкать күреп кенә калгандай әллә нинди бер-бер иренне үз җанына суырыплар алгандай гына кыяфәттә уңмы, сулмы кулының сизгер бармаклары очына эләктерә дә күкрәгенә җан кисәгедәй элеп йөртелгән бамбук үрмәле тырысына агы да, алы-гөле дә күренердәй сурәттә төпчеп куя белә торган иде.

Быел ул җир җиләге вакытында үз авылына кайткан таныш-белешләрен өлгергән җиләкләрнең үзен генә көтеп торган бер урынга ияртеп алып барды.

Килеп җитеп, җиләккә иң ишле уйдыкны күрсәтеп биргәннән соң, ул үрдән түбәндә үсеп утырган зәгыйфь кенә, тик киң ябалдашлы бер карама агачы төбенә елышты. Җиләкнең анда да иҗниган икәнлеген Хәй тумышыннан дигәндәй белә инде. Җиләк ул кирәк чагында язмышыңа шиксез табыласы кыз-кыркын гына түгел. Ул һәрвакыт күнегелгәнеңчә ашыкмады, кабаланмады, үрсәләнмәде. Әнкәсенең «үз насыйбың үзеңә була ул» дигәне шушындый чакта гел искә төшә дә куя.

Әнкәң сүзе — соңгы сулышыңның тыны ул.

Бер якка да күз-керфекләрен сирпеп карамаган килеш тә ул: «Җиһан», — дип уйлаганын әллә тойды, әллә белде.

Җиләк җыйганда Хәйнең бармаклары үтә дә җитез, ә инде дә җәһәтле берәр кырмыскамы, кыр кандаласымы чиләгенә төшсә, ул аларны өзеп алган берәр үлән сабагына үрләтеп йә башка җаен табып, үз ирекләренә җибәрәсен бик яхшы белә иде.

Янәшәсендә генә бер бытбылдык аваз салды да шундук тынды. Чикерткәнең дә тынганын искәреп, алдындагы җиләкләрнең күз алдыннан үз яфракларына посуын абайлагач, Хәй тиздән яңгыр ява башлыйсына төшенде.

Күккә карамаган да иде әле. Җыюын гына белде. Ул аларны бәгъзеләр ише берәмтекләп чүпләми, — үләнне сул кулы белән тарагандай кайтарып сала да, чемне уң кулы бармаклары арасына бөтен буена тартып-сузып, тегене астан-өскә бер генә тартып куя: өлгермәгәннәре, пешеп ашканнан соң җебегәннәре шуып, изелеп шунда кала, ә учына исә аңа насыйплары гына — иң өлгергәннәре, булган дигәннәре генә эләгә, башта тырысына, аннары читтәге зәңгәр чиләгенә шыбыр-шыбыр килешеп коела. Инде ипле аскан тырысына йөз дә утыз бөртек чамасы җиләк чүпләп тутыргач, әлеге чиләгенә бушатса — яхшы. Югыйсә күз камаша башлый. Шуннан соң җиләк җыюы ләззәттән бигрәк газапка әверелә. Күп үбешә торгач, иреннең бүртеп авыртырга тотынганы шикелле. Инде кул астындагы дәү әрекмән яфракларын өзеп алып, катлы-катлы, аркылы-торкылы рәвештә чиләгенә ябасы гына кала. Зәңгәр, сары мәтрүшкәгә дә өстәп әле.

Япты.

Шунда ул үзенә атап берәүнең:

— Бәхет нәрсә икән ул? — дип эндәшкәнен ишетеп алды.

Югыйсә аулак, үзе генә белеп төшкән бер урын иде ләбаса.

Карасана: алдына кеше төшкән икән.

Ул чакыргач, монда ике ир-ат, өч хатын-кыз килгән иде. «Волга» машинасында. Бусы шуларның иясезе, җиләктәй... түгел, алмадай аллы-гөлле пешкәне, урын җитмәгәнгә күрә Хәйнең алдына утырып барырга теләгәне Мәрфуга иде. Ул аның тол калганын ишетеп белә иде инде.

Хәй:

— Яңгыр килә, — диде.

— И, килмәгәе әллә тагын!

— Тәгаен ява бу, — диде Хәй. — Эләктерсә, җиләк җии дә төшә инде.

Ул Мәрфуганың, үрне сөзеп, үзән кашына карап алганын шәйләп алды. Күзенә чалынган бер җиләкне өзеп алганда: «Мул», — дип уйларга өлгерде. Пешкән дип, тәмле дип түгел.

— Тегеләр әллә кайда чемченә шунда. Ә син аулакта икәнсең, — диде Мәрфуга.

— Шуңа күрә алга төштеңмени?

— Төштем әле менәтерә. Төшәсем килеп китте. Алдыңа.

Былтыргыдан калган печән богылына кунган ялгыз тилгән кисәк кенә «кый-йак» дип аваз салып куйды. Ә Мәрфуганың һәрбер сүзен Хәй әлеге тилгән авазымы, әллә үзе өзеп алгандагы әрекмән яфраклары са-

бакларының тартылыплар каршы торганыдаймы ише сузынкылы — әллә моңсу, әллә тыенкы, әллә юмарт, әллә сусыл шикелле итеп ишетте.

— Жый, — диде Хәй. — Миңа җитте инде. Төштән соңгы җиләк күзне камаштыра.

— Ә миңа җиткәнмени?

— Җитмәгәне дә насыйбыңа булсын.

Мул хатын күккә карап алды, аннары, Хәйнең дару үләннәре ябулы чиләгенә ишарәләп:

— Тулдымыни? — диде.

Хәй:

— Тулды, — диде.

Мәрфуга:

— Бәхетле кеше син, — диде.

— Синеке тулмадымыни? Җыярга кирәк.

— Җыйдым инде. Тутырып кына булмый.

— Чиләгеңнеме?

— Чиләк су белән дә тула ул. Бәхетем тулмый.

Күк йөзен ялтыратып, әллә аҗаган яктысы, әллә яшен уты уйнап алды.

— Үз насыйбың үзеңә инде, — диде Хәй. — Яңгыр килә.

— Килсен. Әй килсение дә ул — каплап китсение.

— Шул гына җитмәгән иде тагын, — диде Хәй.

— Каян беләсең?

— Нәрсәне?

Мәрфуга:

— Әллә нишләп... җырлыйсым да килми, ичмасам, — диде.

Хәй үр кашыннан ургып чыгып, бу ялгыз карамалы аулак үзәнлеккә ишелеп төшкән кучкыл зәңгәр болыт өеренә караган гына иде дә «килсение дә ул» дигәннең иясенә кырын карашын юнәлтсә... ул аны үзенең кулы... әллә тегенең теләге янәшәсендә җиләк җыя дип сөйләшкән иде ләбаса. Ә Мәрфуга, исендә дә юк сыман итеп, чүгәләп кенә тора икән. Эссе булыр дип кигән җиңелчә алсу күлмәген каршы искән җил уңаена үзенең бөтен җиренә сылаган да куйган. Ярда үскән камыш төбендәге сай, җылы суга килеп яткан зур, шома, матур балыкмыни.

— Яхшы, — диде Мәрфуга.

— Нәрсә яхшы?

— Монау караманы әйтүем әле.

— Ни дип?

— Тора да тора.

— Тормыйча суң. Ята алмый ич инде ул.

— Ята алмый шул.

— Ә ятса? Кисеп ташласалар ятмый нишләсен.

— Бернишләми. Күләгәсез кала. Эзсез, — диде Мәрфуга.

Болында ис булмый. Анда төсләр, уйлар чуарлыгы гына бар. Ә Хәй тойды: Мәрфуга ягыннан учагы яңа гына ягып җибәрелгән мунча исе килә иде бугай.

Ул үзенең күз карашын керфекләренең төбе-тамыры белән Мәрфугадан каерып алды да, тамарга иелеп торган ике җиләкне өзеп, тырысына салып куйды.

— Гайрәтле җыясың, — диде Мәрфуга. — Кемгә дип инде?

Хәй:

— Яңгыр килеп җитә, — диде.

— Карама ышыклар иде әле. Әнә нинди җәлпәкле.

Хәй:

— Куе да, — диде.

— Яңгыр тисә, җиләк җии, әме?

— Җии, — диде Хәй.

Күлмәге капланганга күрә, Мәрфуганың әллә түм-түгәрәк, әллә очлы икәнлеге беленмәгән тезенә үзенең мул учы белән таянып, бөтен буена сылу мәчедәй сузылып басуын, аннан иелеп итәген каккалаганын, аны әле алга, әле артка авыштыргалап караганын, шуннан соң:

— Карасана, җиләккә утырганым икән ич! Ә бүген җиләк таплары аркама тач шикелле тоелганые, — дип, бу аулак урындагы әле һичнинди кеше аягы басмаган урынны, кеше кулы тимәгән җиләкләрне ипләп кенә таптый-таптый каршы үргә таба суйкыйлата инде кайтырга чакырып, машинадан кычкыртырга ке-

решкән туганнары ягына куе үлән тыгызлыгын каерыплар ера-ера үтә дә бер саллы төстә атлап киткәнен саран гына карап калганда, зәгъфран утлы яшен яшьнәгәч, Хәй күк көлтерәвенең ике-өч тармаклы гөрселдәвен искәрде дә, күлмәгенең эсседә, баягы бәйләнчек кигәвеннәрне, бөгәлчәннәрне куа-куа, үзен тирдән арындырырга теләгәндәй җилпенсенеп куйды.

Ә Мәрфуга бара-барышына:

— Килә-әм! — дип, уң кул учын изеп болгады да капылт туктап калды, аннары: — Әй-й! — диде. — Әйтмәдең ич.

— Нәрсәне? — дип сорады Хәй.

— Бәхетнең нәрсә икәнен.

Хәй эндәшмәде.

Мәрфуга торган саен иңә-төшә китеп барды.

Җиләк вакытында гына кыска бермәлне үз уңаена эләккән һәркемне дә, җыелган, җыелмаган җиләкләрне дә яшәү мизгеле белән коендырып китә белә торган куәтле яңгырның беренче авыр тамчылары Хәйнең чиләге тоткасы астына кыстырылган әрекмән яфракларына тама, алардан мәтрүшкәләргә үтеп керә башлаган иде бугай инде.

Хәй: «Әллә тагын», — дип уйлады да, зәңгәр чиләгенә карап:

— Сөбханалла. Өч банкы кайнатма чыга, — диде.

Бөҗәкләр дә посышып бетте инде. Җил күтәрелде. Ул үзен чакырып кул изәгәннәрен шәйләп алды.

Күңелендә: «Җиләк вакыты бер генә шул», — дигән әллә тиңсез, тирән бер үкенеч, әллә якты бер өмет килеп кунганын тоеп өлгерде.

Кыйгачлый бәреп яуган яңгыр аның җыймый калдырган зәңгәр мәтрүшкәләренең йомык ябалдашларын үбәргә керешкән иде инде.

Кайдагыдыр үлән куелыгында ялгыз бытбылдык кычкырып куйды.

*2003 ел, 2 апрель*

## КАЗЫЙНЫКЫЛАР

Ул күптәннән ияләшкән, гадәтләнгән вакытында уянып китте. Болай дип тә әйтеп булмастыр — уяттылар: өйләре тирәсен ата-бабаларыннан калган тал, тупыллар әйләндереп баскан, аларны әллә никадәр кара карга өере сырып алган. Әнә шулар сызылып таңнар атканда дәррәү каркылдашырга керешә инде. Әллә кайчангы истәлек-хатирәләрен төшеңә кереп, иң татлы берәр күренеш, хис мизгеленә ирешкән мәлендә хәтмәле өркетеп уяткан шикелле итәләр.

Аның каруы шул мәлдә үк йорт-кура артындагы инде кыргыйланып беткән куе чия бакчасында сандугач сайрап торып җибәрә. Әнкә сандугачлар сайрамый. Алар сабыр гына үз көмешләрен көтеп торучан. Әлеге асыл кошның аваз салуы дәвамында каргаларның каркылдашуы һичкайчан тотылмаган бакыр акча кебек тоныкланып кала.

Вәдүт берара тегесен-бусын ишетеп, тыңлап ятты әле. Көннең аяз, эссе буласын күз ачу белән үк башта тойды, аннары күрде.

Ул иплэп кенә җәелгән урыныннан торды да, үзе генә белгән, үз-үзенә Аллаһы Тәгаләгә, ахирәттәгеләргә, исән-сауларга әйтә торган догасын багышлагач, үзләренең бакчалары ызаны буйлата агып төшкән чишмә суында тешен чистартты, кырынды, кулын, битен юып алды. Тege-бу хаҗәтләреннән соң үзе төндә йоклап чыккан болдырга кереп, шундагы газ плитәсенә ут кабызды да, чәйнеккә чүмечләп чишмә суы салгач, утка куйды, ул кайнап чыкканчы, баскычка утырып, «Ява» сигаретын тартып алды.

Ишегалдын баскан кычытканны, әрекмәнне бер тапкыр чабып, кипшенгәч җыйнаштырып куйган иде инде. Карасана, ни арада тагын баш төртеп чыкканнар да яңабаштан буй җибәргәннәр икән. Шулай инде: әниләренең вафатыннан соң өйләрендә торучы юк. (Әтиләре сугыш җәрәхәтеннән иде.) Һәр бирмеш көндә йөреп, җылы табан асты белән шомартып такырламагач, чистартып себермәгәч, йорт-кураны чүп үләннәре, төрледән-төрле чәчәкләр басымчак итә.

Су кайнап чыкканнан соң чәй ясагач, өйалдына кереп, ул чаршау артында яткан энесенең бил чамасына аягы белән төрткәләп:

— Тор, Вәлиша! Җиләккә барасы бар, — диде.

— Нитмә әле, җәме! — дип, Вәлиша теге ягына әйләнеп ятты.

Әмма торды әле, ишегалдына чыкты да, якты көнгә, кояшка карагач:

— Бүген эссе була икән. Мин җиләккә барып тормыйм, — диде.

— Алайса кышкы зәмһәрирдә кайтып җыярсың инде. Мин челләдә җыеп кайтыйм әле, — диде Вәдүт. — Чәй кайнады, ясалган, эч.

— Җарар, — диде Вәлиша.

— Яхшы. Мин әйләнеп кайтыйм инде.

— Алай-болай була калса, кайда йөрерсең?

— Бу юлысы — Карама чокырында. Алай-болай булмас, борчылма. Яхшымы?

— Җахшы, — диде Вәлиша.

Ә Вәдүт, өйалдына кереп, унике литр сыешлы эмаль чиләген алды, җиләк җыйганда тизлек, җәһәтлек өчен муенына тагып йөртә торган бамбуктан телеп үрелгән тырысын, су тутырып, «армейски» флягасын тотты да китте-барды. Вәлиша исә, гадәтенчә, тәмләп йоклап калды.

Вәдүткә үзе белгән өч чакрымдагы җиләкле җиргә барып җитүе ни тора соң ул. Андагы һәр төштәге җиләклекне аңа үзенең вафаты елы алдыннан да күпкә элгәрерәк әнкәсе өйрәтеп калдырган иде.

Айга менеп китәр идем,
Сине анда дисәләр.
Кайда соң син,
Кайда соң син,
Җилләр дә әйтми исәләр, —

дип җырлый-җырлый, тырысы аша үткәрә-үткәрә җиләк белән чиләген тутыра ук язды.

Тургайлар юк, тынганнар, ә анда-санда аяк астына килеп чыккан еланнар — карасы, көл төслесе, алтындае аны өркетми. Ялгыш басмаса, ыжламыйлар да, ичмасам, — тимиләр.

Җиләккәме, чикләвеккәме, гөмбәгәме барды исә ул үзен табигатьнең күндәм фәкыйре дә, зарыгылган патшасы да итеп тоя, шушы тоюы белән кырмыскаданмы, шөпшәдәнме башлап, «кый-ак» дип очкан тилгәннәргә хәтле үзен таныганнарын, үзеннән шөбһәләнмәгәннәрен белә, шул белүе белән горур да, мәгърур да, тыныч та, сабыр да. Булды, чиләге тулды инде. Аның җиләк-фәләнме, чикләвекме җыйганда кулы-кулга иярми дә йокмый — әллә мизгел, әллә кан агышы кебек, вакытны тоймыйча эшли дә эшли. Тик ул төштән соң берәр сәгатьтән соңга кадәр өлгертәсен өлгертеп, җыясын җыеп куя инде. Шуннан ары мәгънәсе юк: кояш төшлектән авышкач, барча нәрсә югала, поса, кача.

Җыйганын күтәреп тузанлы юлдан җәяүләп кайткач, энесе Вәлиша:

— Суң? — дип сорады.

Ул:

— Яхшы әле, яхшы, — диде.

— Миңа өлеш чыгарасыңмы суң?

— Ярар. Бар әле, чишмә суы алып төшә тор.

— И-и, — диде Вәлиша. — Бераз ятып тор, абый. Хәл ал, җәме!

Вәлиша чиләк, чүмеч тотып, бакча башындагы тирән ерганакта күзе тибеп торган чишмәгә чыгып китте. Ә Вәдүтнең челлә йомшарткан, җебеткән, изрәткән, йокымсыраткан тәнен, буыннарын беркавым язып алу нияте белән болдырдагы үз урынына ятуы гына булды, — капка төпләренә бер машинаның килеп туктаганын сизенеп кенә түгел, ә бәлки белеп үк торды.

Ул, ишегалдындагы араларына чирәм сарган яссы ташларга яланаяклап баса-баса, капка төпләренә чыкты. Чыннан да, кап-кара «Волга» тора, аның ян-як ишегеннән ике кеше җиргә төшеп басты.

Чәче ап-ак берәү, аңа кулын сузып:

— Әссәламегаләйкем, — диде.

— Вәгаләйкемәссәлам, — дип, Вәдүт аның кулын кушучлап алды.

— Ялгыш кермәдек микән?

— Бу өйгә ялгыш кермиләр. Алай кергәннәрнең дә әйдәр маягы шушында.

— Әйбәт... Без Ленинградтан идек.

— Кайдан, кайдан? — дип сорады Вәдүт.

— Петербургтан.

— Яхшы, узыгыз, — диде Вәдүт.

— Рәхмәт. Безне сезгә җибәрделәр.

— Кем?

— Теге очтан бу очка. Син белә дип әйттеләр.

— Нәрсәне?

— Сезнең зиратыгызга минем әти Габдулла күмелгәнен.

Вәдүт аны:

— Җирләнгәнен, — дип төзәтте.

— Әйе, җирләнгән. Мин бер туганым белән аның каберенә таш яздырып алып кайткан идем. Кайда җирләнгәнен, каберен авылда беркем белми икән.

— Ә мине белә дип килдегезмени?

— Белә, диделәр. Белә торгандыр, диделәр... Без аның каберенә таш яздырып кайткан идек.

— Брат, — диде Вәдүт. — Мин үз авылымның сигез йөз ел әүвәл үк шушында торганын беләм. Ә... кем әле? Габдулла. Бездә андый исемнәр күп ич ул. Бездә кушамат белән әйтешле. Калганы уч төбендә генә шикелле. Шуннан беләбез.

— Казыйныкылар без.

Моның шулай дип әйткәне соңында Вәдүт аңа төбәлебрәк карап алды. Әһә, чал чәчле, чал кашы тоташыр-тоташмас, чал мыек, ә бу шул мыегын йә учлап тоткалый, йә сыпыргалый.

— Казыйныкылармыни? — дип сорады Вәдүт.

— Казыйныкылар, — диде килгән кеше.

— Ул без инде, — диде Вәдүт. — Безнең нәсел. Морзалар нәселе.

— Мин аларын белмим инде... кем әле?

— Вәдүт мин.

— Әйе, белмим инде, Вәдүт.

— Әһ! — диде Вәдүт. — Әйдәгез суң инде алайса.

Тегеләр капка төбендәге машиналарына кереп утырды.

— Утырыгыз, — диде чал мыеклы кеше.

— Мин җәяүләп кенә барам, — диде Вәдүт. — Миңа иярегез.

Зират алар өеннән дүрт дистә сажин чамасында гына иде.

Барып җиттеләр, койма буена туктадылар. Теге якта өч кабер тоташлый куелган яшел буяулы тимер чардуган, анда куе канәфер куаклары үсеп утыра, шул канәфер арасында ике ак мәрмәр кабер ташы агарып тора.

Ул ташлар җим чүпләргә ниятләп кунган ак күгәрченнәргә охшаган иде.

— Әйдәгез. Шушында ул, — дигәч, Вәдүт чүгәләде дә, күңеленнән генә иренен сизелер-сизелмәс кенә кыймылдатып, үзе белгән догасын укып алды. — Монда безнең әти белән әни ята, — диде ул аннары. — Ә Габдулла абый — әнә, алар янәшәсендә. Уртак чардуганда, — дип, ул ата-анасы каберләре белән бергә тимер чардуганга уратып алынган тәрбияле калку җиргә ымлады.

— Ә чардуганын кем куйган? — диде кунак.

— Без.

— Гафу итегез, ничек инде... ул сезгә чит кеше бит.

— Түгел. Зиратта чит кешеләр булмый. Без — Казыйныкылар, — диде Вәдүт.

Шулай дигәч, ул, кырыс күз яшен күрсәтмәскә теләп, йөзен тирә-юньдәге каен яфракларын, чукларын, толымнарын сак кына сыйпап агылган мәңгелек җил иркенә бирде.

Аннары тыныч, сабыр, түземле итеп:

— Ташыгызны үзегез куярсыз, — диде. — Зарыккансыздыр. Үзегез тәмләп эшләгез. Сез хәзер Җир белән Күк арасында. Ә, болай, сез кем соң әле?

Агай:

— Казыйныкылар, — диде.

Белүенчә, аның улы Гомәр эндәшми, сүз әйтми иде әле. Үзенең нинди адәми зат, кем нәселеннән икәнлеген бераздан соң аңа ерактан — әйткәннәренчә, Ленинградтан алып кайтылган кабер ташы әйтер, зират тынлыгы пышылдар.

Казыйныкылар. Болар мең елдан ашып көн күргән, тереклек иткән, яшәгән бу авылның Тимер Казык йолдызлары ише иде дә...

Шулай дип уйлады гына әле. Чулпан йолдызыннан торып түгел.

Моннан.

Җирдән.

Зираттан гына.

Кояш авышкан, түбәнәйгән иде инде. Вәдүт янәшәдәге бер каберне әйләндереп алган тимер чардуганның көнбатыш тарафы төбендәге миләүшә чәчәге башларының ябылырга керешкәнен искәреп алды. Тегендәрәктәге әллә кем, әллә кайчан, әллә кемгә утыртылган ике колач чамасы юанлыгындагы, инде өч җәпле тармаклары корып, кайрысы кутырлаганнан соң әләмләнгән карт каен төбеннән биш-алты сөям арырак үсеп утырган Татар билчәне чәчәгендәге вак-вак таҗларга соңлаган ике умарта корты кунып, үзләренә кирәккә тыныч, сабыр гына ниндидер ниятле мәшгульлектә иде.

Ул «Казыйныкылар»ның калай тагарагында вак комга чуерташлы цемент измә болгатканда көрәкләре чыгырдаганын ишетеп торды. Үзеннән унбиш сажинлап түрдәрәге борын-борынгыдан бирле мәңге яшел ылыслы, киң тармаклы кап-карт ялгызак нараттан шушыңынчы былтыргы көзен, быелгы кыш, язын үз урынында эленеп торган бер күркәнең ниһаятьтә барыбер җиргә килеп төшкәнлеген искәреп калырга өлгерде.

Ул: «Әни безне самавырда чәй кайнатырга дип шундагы күркәләрне җыярга чиләк тоттырып җибәрә торган иде», — дип уйлады.

Кайдадыр шушы тирәдәрәк аның бабасы Габделнасыйр Казый белән әбисе Һидиястә җирләнгән булганын ул чамалый иде чамалавын. Тик ул кайдалыгын күпме генә сораштырып йөрмәсен, тәгаенен әйтеп, күрсәтеп бирүчене тапмады.

Алайга китсә, кемнең җиңел туфрагы кайда да анда хәзер ни нәрсә икәнлеген белергә калсаң, мәхлукларга зират кынамы соң — бөтен дөнья җире төтмәс иде ул.

Оныту, онытa алу — мәңгелек мән.

Коръән шулай куша.

Аның каруы Вәдүт бу зиратта кая тезләнсә дә, үзенә дип аталган өч аршын җир ачылып китәргә әзер икәнлеген яхшы белә.

Җылы йомшак җил сирпелеп узганда, каен, нарат, усак, өрәңге агачларының, канәфер, сәрви, балан, миләш куакларының яфраклары лепердәшеп алды, рәшәткә буендагы кычыткан, сукыр кычыткан, әрем, әрекмәннәр — тагын әллә нинди үләннәр, үсемлекләр башларын талгын гына иешеп куйды.

Гүя бер-берсенә сәлам иңдерештеләр, әлегә исән-сау икәнлекләрен үзара хәбәр итештеләр.

Күк йөзе ап-аяз иде. Көнчыгышның миләүшә түсенә кергән, көнбатышның алсулана барган, Күпер урамына тузан туздырып, яңа сөт исе таратып, авыл көтүе кайтып кергән чак.

Зираттагы һәммә карышта хәрәкәт сизелеп торып, кемнәрдер кемнедер эзләп йөриләрдер шикелле иде.

Вәдүт үз янындагыларга:

— Алай-болай көрәкләрегезне онытып калдыра күрмәгез тагын. Кирәге чыгуы ихтимал, — диде.

Гомәр, әллә ничегрәк сагаеп:

— Нәрсәгә? — дип сорады.

Вәдүт:

— Җиләк җыярга, — диде.

*2003 ел, август*

## ИДЕ

Бу юлы Сабан туе көнне әти мине ипподромга алып китте. Чабышта аллы-артлы килгән алгыр өч атны чалдылар. Янып, җиргә сузылып ятканнары өчендер инде. Аларны ипподром әйләнәсе буенча егерме биш чакрымга җибәргән булганнар.

Икән.

Сәгать ярымда үтәсе араны бер сәгатьтә куганнар. Мин моны соңыннан гына белдем әле. Ул көнне мин дә әйләнәгә яланаяк килеш йөгерешкә кергәнием дә иң алдан килеп җиткәч җыгылганыем. Аннары сулышым тигезләнгәч, ул чалып ташланган атларны күргәч, мине дә суясы булганнар кебек булып китте.

Ул атлар нигә дип беренчегә, икенче, өченчегә җитешеп, үзләреннән арттагыракларга баш бирмәделәр икән? Аңышып җиткермәгәннәрдер инде.

Йөгерештән килгәч, күршесе белән утырган чагымда әтиемнең әлеге авып егылган атларның беренчесенә атап:

— Шашлыкка булыр, — дигәнен ишетеп алдым.

Тегесенең:

— Аптырыйсы түгел. Калганнары казылыкка китәр, — дигәненә мин төшенә алмыйча утырдым әле. Йөгерештә сулышым капканые шул.

Мин тыңлап кына утырырга яратам. Аңлап җиткерүе генә кыенрак әле. Йөгерештә иң алдан килгәнем өчен миңа пәке бүләк иттеләр. Кызыл саплы, әллә ничә җәпле. Санап бетермәдем әле. Олы пәкесен ачып, авылдагы дәү әтинең өйрәткәненчә, баш бармагым тырнагына тидереп алган идем. Хәтәр дә үткер икән.

Ул пәкене бүләк итеп алгач, әти янына зәңгәр басмалардан йөгерепләр менеп киттем ич инде. Сакчылары аңа таба чит кешеләрне якын җибәрми. Ә ул әллә ниткән тап-таза абыйлар мине бик яхшы таный. Аларны үткәч, әтинең тезенә менеп утырдым.

— Әти, — дидем. — Беренче килдем, — дидем. — Менә бүләккә пәке бирделәр, — дип, теге әллә ничә җәпле пәкене тирләгән учымнан ачып күрсәттем.

Узышта бүләккә ирешүе җиңел эш түгел ич ул. Пәкемә карап та тормыйча, әти:

— Яхшы, улым, — диде.

— Әйбәт пәке, — дидем мин.

Әти:

— Әйбәт булырга тиеш иде, — диде.

— Әти, әү, әти, — дидем мин. — Бу пәке, акчага санасаң, күпме тора икән ул?

— Оныттым, — диде әти. — Түләнелгән.

Алдан болайрак булган иде: мин тел очыма килеп терәлгән сүземне әйтеп өлгермәдем, әтинең үз күршесендәге абыйның тезенә тезе белән кагылып куйганын абайлап алдым. Әле беркем дә кумаганга күрәдер инде, тыпырчынып, әйләнгәләп, чөйкәлгәләп, пошкырынгалап таптанган атларга ияге белән генә ишарәләп, әти:

— Әнә шунысы килсен, — диде.

Теге абый:

— Хәзер, — диде дә, каешындагы мобильнигын кулына алып, бармаклары белән төймәләренә баскалагач: — Ахалтәкин, — диде.

Бөтен кеше, дәррәү килеп, чабышка чыгасы атларны озатып җибәрде.

Атлар ыргылыплар торып кузгалып киткәч, халык утыргач, тагын әллә нишләгәндә мин:

— Әти, әти, син бу пәкене түләнелгән дип әйттең, — дидем.

Ул, мине тезендә тибрәткәләп:

— Шулай, — диде.

— Алайса минем йөгерештә иң алдан килүемә дәме? — дип сорадым инде.

Әти:

— Анысына аерым түләнелгән ул, — диде.

Мин:

— Әти! Әни кайда ул? — дип сорадым.

— Дәү әниең, дәү әтиең янына авылга китте, — диде ул.

— Ә апам белән абыем?

— Бөтенесен бергә утыртып җибәрдем, — диде әти.

Мин:

— Ә мине нигә аларга утыртып җибәрмәдең? — дип сорадым.

Ул:

— Синең монда кирәк булганыңа күрә, — диде дә: — Бу пәке бик кыйммәт тора, улым, — дип өстәде.

Мин:

— Әти, — дидем.

Тезеннән алып, ул мине янәшәсенә бастырып куйды да:

— Карап тор, — диде. — Ахалтәкин алдан килергә тиеш.

— Ә бүтәне җиңсә? — дип сорадым мин.

Әти:

— Бүтәне җиңми, улым, — диде дә мине тагын тезенә утыртты.

Чабышка киткән атлар әллә ничә мәртәбәләр әйләнеп чаптылар да чаптылар, чаптылар да чаптылар. Халык шау-гөр килешеп утырды да басты, басты да тагын утырышты.

Әти генә утырган урыныннан кузгалмады. Янындагы бер абый аңа әллә ничә мәртәбә әллә ниткән ялтыравыклы калай савыт биргәләп, әти ничәмә тапкыр ниндидер суны уртлап-уртлап куйгалады. Шул очтан миңа да гел-гел пепси-кола биргәләп тордылар. Эссе көн булгач, бигрәк тә йөгерештә беренче булып килгәч нишлисең инде? Эчәсең. Эчми хәлең юк.

Ә атлар бу арада һаман әйләнә-әйләнә чаптылар да чаптылар. Аларның ипподромда әйләнә-тора чабышканын карап утырганда башым әйләнеп бетте.

Бер дә бер заманны карасаммы, күрсәмме?

Теге атлар чабышындагы килеп җитәрләре урындагы бер абый үз кулындагы аклы-кара шакмаклы флагын күтәрде дә төшерде, күтәрә дә төшерә барды. Башта өч тапкыр бик гайрәтле селтәнеп, аннары үз турысыннан узган һәр ат саен сүлпәнәйгәннән-сүлпәнәя барып, теләмәгән шикелле итеп. Ә башта селтәгәне саен беренче, икенче, өченче булып килгән атлар әллә нишләп егылдылар да җиргә яттылар, егылдылар да яттылар.

Мин әтидән:

— Алар нишләп алай итәләр? — дип сорадым.

Ул:

— Түләнелгән, — диде.

Ипподромдагы шыгрым халыкның һәммәсе торып басты да кул чапты. И чаптылар да инде.

Әти генә һаман тик кенә утырып торды. Кулын да чапмады. Ул теге ягындагы әлеге абыйга:

— Яхшы, — диде.

Теге абый аңарга кулын сузган иде дә, мин әтинең моны күрмәмешкә салынганын шәйләдем.

Күрдем. Мин бөтен нәрсәне шәйли беләм.

Башта беренче килеп җитә язган атның алгымы, арткымы аягын юри чалганнарын, шуннан аның гөрселдәп авып, җирдән әллә күпме шуып барганын абайлап өлгердем. Икенче килгәнен суйганнарын мин әти тезеннән ычкынып, аралыктагы баскычтан түбәнтенгә таба йөгерепме, чабулапмы, аксак-туксаклапмы ашыгып, атлыгып төшкән чагында күрдем. Мин ул атлар янына барып җиткәндә, өченчесенең дә бугазын кистеләр.

Мин: «Йөгерештә мин дә беренче килгәнием ич. Мине дә суярга кирәк», — дип уйладым да иң алдан килгән Ахалтәкин аты янындагы кучкыл канлы юеш кызыл комга барып яттым.

Әйттем ич: миңа бүләк ителгән кызыл саплы пәкем үткен... иде... дип.

Мин чын-чынлап йөгерешкәнием ул, әни.

*2003*

## ЭНӘ КҮЗЕ

Авыл кучкыл канга баткан иде.

Өй саен булмаса да, өченчесе дигәндә капка асларындагы ерганак ише җирдән сузылып-сузылып кан агып чыккан да укмашып каткан. Бу — көз көне, аның да ахыры; җир туңып, кар яткач була торган хәл.

Әйе, авылда сугым башланган вакыт.

Ягъфәр автобустан төшеп калды да, әлеге кан ерымнарын, мөгезле эре терлек ашказаннарын тискәре ягын әйләндереп бушатканнан соң калган, инде суык куырып, түмгәк иткән сыек-яшел калдык-постыкка игътибарын, карашын юнәлтәсе килмәстән ары таба — авыл очыннан бирегә таба сигезенче санынча торган йорт-җире тарафына атлый бирде. Уң яктагы инешнең тирән ярларындагы тал-куакларны, әрекмән, әрем, гөлбадран курпыларын бәс сарган, күк гөмбәзе чалт аяз, һава саф.

Дөнья болай тып-тыныч. Әйбәт йоклагандагы шикелле. Йә адәми затның инде вафат булганлыгын, мөгаен, белгән, ә күңелнең, зиһеннең моны әле тәгаен кабул итеп җиткермәгәнлегендәге кебек.

Эңгер-меңгерле көздән соң кинәт килгән шикелле тоелган ачык кышка кергәндә шундый тойгы, уй биләп алучан.

Ә бөтен җир, чыннан да, ниһаять мәрткә киткән, тик тере, ап-ак иде. Табигать үзенчә мәңгелегендә, тик кешеләрнең дә әлегә гүрдә түгеллеген өй морҗаларыннан чыккан яшел-зәңгәр төтен баганаларының югарыга таба үрләгәннән соң да тәмам гаип булмаганнары белгертеп тора иде.

Турыга үрләгән төтен баганалары һәрвакыттагыча нидер әйтеп тора. Нидер дип, әллә нине түгел инде: әнә монау өйдә итле шулпа пешә, тегесендә, бәлки, өчпочмактыр, бусында, ихтимал, ит бәлеше үктер, ә анаусында һич кимендә кыстыбый ише бер-бер нәрсәдер.

Менә боларның иң кимендә ике тәүлек чамасына сузыласын Ягъфәр яхшы белә. Җәйге челләдә яңгыр явасын, кышкы зәмһәрирдән соң буран чыгасын чамалагандай.

Ул белгәннәрнең һәммә чамасын бүгенге көндәге морҗа төтеннәре әйтми иде әле.

Ә исә ул үз авылына төтен күзләр, кан исе иснәр, ашар ризыгын эзләр өчен дип кайтмады.

Аныңча, болай гына.

Аңа, болдыр тәрәзәләрегезнең пыяласын кыеп төшергәннәр, ишекнең йозагын койганнар, бөтен өегез шәрран ачык тора дип хәбәр салганнар иде.

Менә шундый хәл-әхвәлне инде өченче тапкыр төзәтергә, бикләргә кайтып барышы.

Үзенең туган йортын бимазалаулары аңа кайбер мәетләрнең бакый ләхетен ишүгә тиң сыман тоела.

Шуңа күрә аның синоптикларның Атлантикада һаваның түбән басымы Татарстандагы антициклонга карата көнчыгышка күчү ихтималы бар, тик әлегә аның төньяктан бәреп керүе шикле дигән фаразына ышанган хәлдә үз авылына кайтып килеше. Кар-буран чыгу ихтималы булса да, һава температурасы күзәтелгән еллык күрсәткечләрдән узмаска тиешлеге аны юлга әйдәде. Озакка сузылган кара көзнең бу киңлекләрдән чигенеп, яшь-ыркынның куеннарына елышканнан, карт-корының җаннарыннан үткәннән соң ара үтеп китеше.

Бугай.

Әлегә исә авыл кучкыл канга баткан, һәммә нәрсә күктән иңдерелгән зәңгәрсу нур белән өретелгән иде.

Калганын кем белә инде тагын. Бәлкем, гап-гади генә итеп, көндәлек бер-бер тәмле нәрсә пешереп тора торганнардыр. Автобустан төшеп калгач, Ягъфәр авылга җәяүли килеп кергән иде.

Авылның кучкыл канга батканына аның исе китмәде. Дөньяда һәммәсе фани. Һични бакый түгел.

Анда-санда очраган авылдашларына ул дүрт-биш сажин җитәр-җитмәстән ук «Әссәламегаләйкем!» дип эндәшеп килүчән дә «Яхшы!» дип узып китүчән. Киң күңеллесенә дә, коры җансызына да. Үзен таныклаганнары белән кулын биреп хәл-әхвәл белешә, ә каршысына таба ике адым ара атлауны авырыксынганнарга үз сәламен фәкать иңдерә белеп кенә ымлый.

Үзенең:

— Исәнмесез, — дигәненә:

— Ярый. Беркөе, — дигәннәрне ул һичничек кабул кылмый. Чөнки ул белә: болар — «Аллага шөкер!» диюдән мәхрүм мәхлуклар.

Аның:

— Шөкер дип әйтегез, — дигәненә мондыйлар барыбер:

— Ярый, шулай диик, — дип узучан.

Мондыйларның авыру икәнлеге, кешенең ихлас сәлам иңдерүен үзләренең кара җаннары белән кабул итә алмаулары аңа яхшы билгеле. Шуңа күрә андыйларның кешедәге иманнан, игелек, савап, деннән өркәк күргәндәй тайчынулары, мәңгелек җәһәннәм җиле, тәмуг салкыны тойгандай читләшүләре дә аңа бик таныш. Шулай итеп, ул аларның инде тумышларында ук кичергән үлемнәреннән котылмакчыдай, ваз кичмәкчедәй булып, ахыр килеп, шуның фаш ителгәнен яшерергә теләгәннәрен дә ул әйбәт белә.

Моны алдан сизмәү, белгәнең соңында аңышмый калу — шайтанга әфсен өрүдән гаҗиз калуың белән бер.

Дип әйтмәсә дә, һич кимендә шулай уйларга кирәклеген ул беркайчан да онытмый, исендә тота торган иде.

(Шуңа күрә Ягъфәр кешенең елмаюлы йөзенә караганда атлап киткәч калган эзеннән күбрәкне танырга өйрәнде. Күптәннән бирле инде.)

Аның исә ирене һәрчак алсу, сусыл, изүе ачык, аяк атлавы шөбһәле түгел, ә бәлки нык, ышанычлы, бераз тирбәнүле, тыйнак, бераз шаян, тик гаять сак.

Шәһәр автобусыннан төшеп калгач ук, авыл һавасы бүтәнчә, тын алуы җиңелрәк кебек. Бүтәнчә дип... әйтик, үз авылыңа таба әйдәгән юлдагы бер әчмуха тузан да, әгәренки бөртекләп җыя алсалар, бишегеңдә яткан чагыңда имезлек итеп каптырсалар да ризыктыр ул. Ә кыш көне дисә, әйтик, бүген, керфегеңә кунган бер кар бөртеге дә әнкәңнең әллә нидә генә — кемдер чит-ят күреп алганчы ук иң арып тупасланган урта бармагы белән суллы-уңлы сөртеп алырга өлгергән мул тамчылы тозлы күз яшеннән дә җылырак булырдыр иде.

Бөтен һава, челләдән соңгы эңгер-меңгерне тутырган черки көтүен хәтерләткән ише, әлҗе-мәлҗе сыкыга көмешләнеп торса да, Ягъфәрнең сыңар керфегенә дә һични кунмады. Ул, болай, мыегының кабарганнан-кабара барганлыгын тоя тоюын, тик авылына керә-керешли, күрешкәне саен салып тормас өченгә кесәсенә тыккан бияләеннән арынган, инде бераз туңа төшкән шул бармаклары, учы белән мыегын уңлысуңлы сөртергә теләмәде.

Гүргә иңгәннәргә генә ни яңгыр тими, ни кар төшми.

Шунысы яхшы.

Һәммә җирнең, ниһаять, ап-ак кебек тоелганы шикелле. Хәер, инде утырган кар әллә зәңгәрсу, әллә алсу, әллә яшькелтем, әллә күксел иде. Кайсы тарафка, нәрсәгә каравыңа карап. Кышның үз фасылына кергән, хуҗа булган чагында зарыккан кешеләр инде утырды дигән карны әле ахак, әле миләүшә, әле зәбәрҗәт, әле — күзне чагылдырганда, камаштырганда — кара төстә итеп күрә ул. Җирне тәмам туңдырганнан соң ике көн дәвамында тыныч кына яткан кар иртән-иртүк аяз күкле авылга сул як үр кашыннан ипләп кенә кояш күтәрелгән вакытта атлаган һәр адымың саен иң кимендә кырык дүрт төскә керә.

Кар шулай әлегә түземле генә яткан да куйган. Болай итеп асрарга исәпләнгән мал-туар гына тыныч ята. Ә инде сугымга куелганнары яңа карның ятуы адәми затларның уянуы, пычак кайравы икәнен һич белми, белә дә алмый. Аларның нәкъ шул һични белмәгәннәре мәлендә сугым башлана.

Мал-туар, терлек-җанвар, кош-корт кичәгене хәтерләми. Аның каруы алар бүген ни буласын белмәү белән... бәхетле.

Авылның кучкыл канга батканлыгын алар беркайчан да күрми инде.

Ягъфәрнең Тегермән очы урамындагы үз өйләренә кадәр атлап кайтып җитәренә чакрым чамасы бар әле. Аның уң иңбашына ике тоткычын кигезеп күтәргән җирән төстәге нык букчасы саллы гына авырлыкта иде. Әллә ние дә юк шикелле үзе: ике ипи, терсәк буе бер тутырма, төрле-төрлесеннән өч кап чәй, ун савыт шәп сыра, өч шешә аракы, ике кадаклап хәлвә, бер калҗа пешкән ит, ысланган балык, алма, ике литрлы савытта үзе тозлаган кара гөреҗдә гөмбәсе... Сигарет, шырпы, алты-җиде данә шәм...

Җитәрлек.

Ахирәттәге ата-анасы, шундагы исемле, исемнәре билгесез туган-тумачаларыннан гайре Ягъфәрне бу кыш башында һичкем көтми. Үксез өйләренең болдырындагы пыяласын ваткан, ишек йозагын, тупсасын каерып аткан бәгъзе затсызы, оятсызы аның кайтып төшәсеннән шикләнәдер шикләнүен. Алар Ягъфәрнең үзләрен беләчәген, белгәч нишләтәсен яхшы чамалап торадыр. Монысы тәгаен.

Тик хикмәт анда түгел. Бар мәгънә аның менә кайтып килүендә әле ул.

Ярар. Һич киме бер генә кош-корт та үзе борнаган, җим ашаган, канат ныгыткан ягына мәгънә эзлисе, табасы өчен әйләнеп кайтмый.

Шулай да һәрбер әйләнеп кайту — инде әллә кайчан узганны мәңгелеккә теркәп кую ул. Үзеңнән кала, бәлки, һичкемгә хаҗәтсез нәрсәне беркем дә күрмәс йолдыз итеп.

Олы юлдан уңга борылып кергән авыл урамы буйлап үткәндә каршысына очраган, йә аркасы ягыннан килеп чыккан көпчәкле трактормы, ат җигүле арбамы кешеләренә ул кулын да күтәргәләде, сәламен дә юллады. Ә тегеләр аның шул кулы селтәләгәнен сәлам санап кына кабул кылдылар, күрәсең: туктамадылар, уздылар да киттеләр.

Ул җанын тыеп, яңа карны шыгырт-шыгырт иттерә-иттерә кайтып бара әле. Әнә, мәктәптә физкультура укытучы Илтөзәр капка төбеннән уң кулын күтәреп сәлам биргән булды. Тик «безгә кереп чык әле» дигән ымын белдермәде. Димәк, хәзергә Ягъфәрнең аңа керәге юграк, — әлегә үзенеке бар. Эчәренә. Чәй түгел инде.

Аларның урам юлыннан арырак торган өйләре ягыннан да кан исе килгәнен тойган Ягъфәр бу очракта һични уйламады.

Шулай. Бүген уй уйлар көн түгел. Ул аяк киеменә ябышкан пычрак катыш карны кагып, юлының очына якынлаша иде. Юл кеше үзе теләгән чакта төгәлләнә.

Югыйсә кайсы капкадан керсә дә, ул үзенә атап чәй кайната башлыйсыларын белә.

Тик бүген кирәк түгел. Ул бүген биредә кирәкмәгән вакытта яуган яңгыр белән, алдан белеп торган шәттә дә һичничек туктатып булмастай боз бәрү белән бер; үрелеп, кисеп алганың соңында, кортлы икәне беленгәч, селтәп читкә ыргытылган гөмбә, мал-туар суелгач түшкән җебек көн, кулыннан эш килмәгән бер адәм актыгы тарафыннан бугазы киселеп бетмәгәнгә күрә җан тәслим кыла алмый азапланган ап-ак каз, аркасындагы канатын күпме җилпүгә карамастан, һичкем күзенә чалына алмауга гаҗәпләнгән фәкыйрь бер фәрештә генә.

Хәер, бу авылдагы һәр өй, хуҗалары — аныкы, берәрсенә кереп очрашып сөйләшүдән гайре һичкемне аптыратканы, йөдәткәне юк.

Ул сул якта кала торган Югары оч тыкрыгы башындагы өйгә һичбер мәртәбә борылып карамыйча калмас иде.

Исән-сау кешенең узып китешли карап китә торган ягы була.

Әүвәлрәк, әллә кайчан инде, әлеге тыкрык очланып, чирәмле тар урам аша алма бакчалы йортта ул яшертен дә, сиздереп, белгертеп тә җан атып йөргән Фәйрүзә бар иде.

Хәзер юк инде.

Бар. Яши. Тик кеше кешесе булып.

Шунысы хәерле.

Әлеге өй былтыргы шөпшә оясыдай буш, тәрәзәләре соң чикләвегенә хәтле аҗаган ашап, каралтып бетергән кәшәнкә шикелле.

Ярар инде. Ягъфәрнең үз өйләре дә шундыйрак.

Фәйрүзә аның төшләренә кереп йөдәткәли икән, аңа шуның өчен дә рәхмәт яусын.

Ул: «Бу дөньяның сиңа насыйп итмәгәне шау кайнаган самавырсыз калганы юк әле», — дип уйлап куйды.

Аның ике кызы, Фәйрүзәнең ике улы бар — тагын ни җитмәгән?

Дөньяның бизмәне тигез.

Табан астындагы яңа карның атлаган саен тигез шыгырдаганы яшенсез күк көлтерәгәне, чишмә күзендә иң киме биш-алты ком бөртегенең тавышсыз гына кыштырдап торганы, тегермән ташлары келтерәгәне сыман.

Алдагы йорт турысыннан юлына каршы кара яшендәй чәчрәп өреп чыккан йөнтәс зур эткә ул, сул кулының бармакларын киң тырпайтып, учын каршы куйды. Аңа карамады да. Игътибар итмәде. Шул гына. Эт тынды да, ак очлы койрыгын шәлперәйтеп, капканың ике тактасы астыннан — череп сынган ике такта арасындагы үз тишегеннән кереп шылды.

«Шулай, — дип уйлады ул. — Тагын бер өйдән соң ләтчәсе чыга инде».

Үткән-барганында чалбар балагына тигәнәк кебек ябышырга торган чәңгелдек сары бер эт бу юлы аның аяк астына чәчрәп чыкмады. Югыйсә нәкъ менә шул чәңгелдек, әнчек эт кайткан саен Ягъфәрнең теңкәсенә тигәнгә, бөтерелеп аяк арасында чуалганга, ул алдан ук таш әзерләп куючан. Тик ыргытырга язмасын. Аның саен котырына гына.

Юл ачык. Тагын дүрт өйдән ары зиратка җитәсең, ашыкмыйча гына бара торгач, ахирәттәге әти-әниеңнең, барча туган-тумачаларыңның якты рухларына белгән догаларны күңелеңнән әйтәсең дә, аннары Ягъфәрнең туган өе инде.

Буш. Салкын.

Урамда очраган этләрне ул күз карашы белән дә туктата белә. Туктамасалар, буш кулың белән, каен җиләге өзгәндәй генә сак кыланып, табан астыңнан берәр таш-фәлән алгандай гына иту кирәк.

Теге әнчек эт, күзгә бәреп кергән черки сымак, капка астыннан атылып килеп чыкмады.

Чөнки ул бүген тук икән. Аның хуҗалары сыер суйгандыр, ә моңа талак телеп ашатканнар, бавыр, йөрәк, үпкәне ярганда кешеләргә ашарга ярамастай төерләрне ыргыткалап торганнардыр.

Тук эт кешегә өрми.

— Кайтып киләсеңмени?

— Нихәлең бар, Рәҗәп абый?

— Аллага шөкер. Кайтып киләсеңмени дим ич.

Ягъфәр юри-мырый:

— Юк, китеп барышым иде, — диде.

— Чү! Алайга табамыни? Китүчеләр болайга бара торганые.

— Бу очтан нәкъ шул табантын китәләр ул, Рәҗәп абый, — диде Ягъфәр.

Рәҗәп:

— Кая, энем? — диде.

Ягъфәр аның, сул күзен кыса төшеп, уң кашын ничек сирпүеннән үтә гаҗәпсенгәнен искәртеп алды да:

— Зиратка, — диде.

— Ә! — диде Рәҗәп. — Зират якын ул.

— Чираты ерак булсын.

— Кая, Ягъфәр?

— Әлегә гүргә түгел.

— Алайса утыр әле.

Юри сүз уйнатуын бүтән кирәкмәс санап, Ягъфәр:

— Утырсам, озакка китә, Рәҗәп абый, — диде.

— Ниме суң? — дип сорагач, Рәҗәп салам җәеп утырган бүрәнәдән торды да, алдын-артын юк-бар чүп-мазардан каккалап алгач: — Әллә таптыңмы, наным? — дип сорады. — Шулай сизәм.

— Рәҗәп абый, — диде Ягъфәр. — Менә хәзер мин сиңа наным түгел, бәлки запастагы капитан.

— Тыңлыйм, — диде Рәҗәп.

Ягъфәр бер тезе ямаулы чалбар, уң җиңе өчпочмаклап умырылып, мамыгы күренеп торган — Урта рус калкулыгындагы һәммә халыкка гадәти җылы сырма, башына инде нинди җәнлек тиресеннән тегелгәнлеге билгесез бүрек, аягына кирза итек кигән, каш-керфеге төссез, күзе әллә яшькелт, әллә зәңгәрсу, борынының сул ягы көрән миңле, ирене кысынкы, ияге көчсез рухсызларныкы ише җәйпәк булган Рәҗәп каршысында кún пәлтәсенең сул як кесәсеннән кулъяулыгын чыгарып барлады. Шуны пөхтәләп ачкач, Рәҗәпкә әле күрсәтергә ашыкмыйча, уң кул учына карап алды, шуңа «уһ» дип тынын өргәннән соң:

— Мә, сержант. Атаң — өлкән лейтенант Казыевның Кызыл Байрак ордены. Бусын да ал, — дип, Ягъфәр аңа, уң кесәсеннән алып, ак тышлы бер кенәгә сузды. — Нумерын карап торма — аныкы.

— Инде! — дип, Рәҗәп Ягъфәр биргән орденны сул кулы учында әйләндерде дә күз карашын уң кулындагы кенәгәгә юнәлтте. Аннары тагын — анда да монда, монда да тегендә. — Рәхмәт, брадәр.

— Брадәр түгел. Погонсыз капитан.

— Кит әле, Ягъфәр! — диде Рәҗәп. — Эзләп таптыңмыни?

— Эзләмәдем, — диде Ягъфәр. — Таптым гына.

— Ә «За отвагу» медале, Кызыл Йолдыз ордены, «За Кенигсберг» медале?

— Оныкларыңның балалары табып кайтыр әле.

— Дисеңме?

— Димим, — диде Ягъфәр. Аннары: — Аларны — орден-медальләрне — хәзер дә коялар, — дип өстәде.

Рәҗәп күз карашын кеңәгәдән сул аягындагы кучкыл кан каткан күн итек башына юнәлтеп алды да, карашын еракка төбәп, тагын:

— Дисеңме? — дип сорады.

— Дим, — диде Ягъфәр. — «За взятие Берлина» булмас инде булуын. Тик «За взятие Вашингтона» да эләкмәс.

— Ягъфәр наным, әйт әле: әтинең бу орденын каян таптың суң? Әгәренки сер булмаса.

— Сатып алдым.

— Сатып?

— Сатып.

— Ничек инде ул?! Әтине фотокарточкага төшергәннәр дә — тегеләр киткәч карасак, кәчтүме шәп-шәрә!.. Шуннан соң күп тә үтми үлде.

— Урыны оҗмахта булсын, — диде Ягъфәр. — Анда орден-медальгә карап кертмиләр ич.

— Каян беләсең?

— Аннан җәннәт медале тагып чыккан әрвах юк, — диде Ягъфәр. — Медальне бу дөньяның тәмугында гына күп тагалар.

Көн ап-ак. Аяк алыштырган саен, кар шыгырдый. Мунчада бер тапкыр парланып, мунчалалап, сабынлап юынып алгач, ләүкәдә ике-өч кат чабынып чыгылган тәннең, бармак белән ышкып карасаң, өлгергән кәбестәдәй сәламәт шыгыр-шыгыр иткәне шикелле.

— Шулай да, наным... — диде Рәҗәп.

— Суык булгач, Хәтер көнендә пычак калынлыгы гына бер-бер нәрсә кабарга киткән идек.

Рәҗәп аннан:

— Пычак калынлыгы күпме була суң ул? — дип сорады.

— Яткырып тотсаң — шулхәтле, кайтарсаң — арта, ә сабына утыртып сагайтсаң, нәкъ сиңа таманча, Рәҗәп абый... Әйтәм ич, Казанда Хәтер көне быел салкын туры килде. Бер иптәш белән, чәйме, мәйме эзләгәндәй, Ирек мәйданыннан аскарак төшеп киттек. Анда Ленин бакчасы бар. Шунда һәр шимбә көнендә пионер значогыннан башлап Ленин орденынача сатыш та алмаштырыш бара. Атаңның бу орденын шул төштә таптым.

— Күпме тора диделәр?

— Анда димиләр, Рәҗәп абый.

— Димлиләр үк мәллә?

— Әйе. Араларында кергәнне-сатканны күзәтеп, барлап торучы берәү тора.

— Карасана! Нәкъ төрмәдәге сымак икән. Каплаган да куйган смотрящщий!

— Шулайдыр инде.

— Суң?

— Анда атаңның бу ордены илле тәңкә тора.

Рәҗәп, гадәтенчә:

— Инде! — дип куйды. Аннары, бүрәнәдәге саламны тараткалап: — Утырыйк әле, — диде.

Утырыштылар.

— Аның минем әтинеке икәнен каян таныдың суң?

Аның янында үзеңнең гакыллы икәнлегеңне белгертеп торуның хаҗәте юк иде.

— Эзләп таптым. Тезеп куелганнар. Кеше ул орден-медальләрнең бөтенлеген карый. Янәмәсе, сакланышлары нинди дә, таушалмаганмы, ядрә-фәлән тимәгәнме, сугышның башында бирелгәнме, ахырына табамы...

— Аның аермасы бармыни?

— Сугыш башлангандагысының көмеше күбрәк.

— Беткән чагында?

— Әзрәк, — диде Ягъфәр.

— Нигә алай икән?

Ягъфәр биштәренең алгы кесәсенә үрелде дә, сындырып клиндер кисәге кабып куйды. Аны гадәттә авыл кешеләре, бу юлысы шушысы белән сөйләшеп торулары авырыксындыра торган чаклар була. Бөтен белгәнеңне сөйләргә керешсәң, болар сине аңгырага санаудан да һич тайчынмыйлар. Чөнки авыл кешесе үз-үзен җир кендегенә санаганлыгын ул бик яхшы белә. Синең саллы дигән бер кадаклы гереңне бер потлы буш сүз белән авыштырулары аларга һични тормый.

Шуңа күрә Ягъфәр теге сугыш алдыннан коелган орден-медальләрдәге алтын-көмеш микъдарының ахырга нигә кимегәнлеген әйтеп, сөйләп тормады. Югыйсә он белән он, ипи белән ипи аермасыннан ук керешәсе була. Алай итсәң, сүзнең дилбегә очына җитәм димә.

Ягъфәр:

— Казыев абзый бу орденын сугыш башында алган, — диде. — Ул вакытта илнең алтын-көмеше байтак булган әле. Ахырында ничек төткәзеп бетермәк кирәк?

— Алайса теге фотокарточкага төшереп йөргән адәм актыклары көмеше күбрәк булганга күрә урлаганнармыни инде?

Ягъфәр җавап бирмәде. Чалбарының уң кесәсенә кулын тыкты да, үзе белгән бер-бер нәрсәне капшап алгач, учын Рәҗәп Казыевка ачып күрсәтте.

Ул Рәҗәпнең аптырап калып, сискәнепләр торып киткәнлеген, утырган җиреннән калкып, тагын сеңүен кырынмы, турымы карамастан ук күреп, белеп торды.

— Тәре бит бу, наным! — диде Рәҗәп. — Фашистларныкы!

— Аларныкы, — диде Ягъфәр.

— Каян алдың? — дип сорады Рәҗәп. Ягъфәр җавап бирмәде. — Шул ук... базардан мәллә?

— Шул базардан, — диде Ягъфәр. — Сугыш базарыннан.

— Монысын да шуннан... сатып алдыңмы әллә?

Ягъфәр әлеге свастикалы көмеш тәренең әнкәсе вафатыннан соң аның сандыгындагы нигәдер патша заманыннан калган «40 копеекъ» маркасы ябыштырылган бер конверттан табып алганлыгын әйтеп тормады.

— Ә моның көмеше күпме тарта? — дип сорады Рәҗәп.

Ягъфәр:

— Монда алтын-көмешкә караганда кан күбрәк, — диде.

— Синең атаңны мең дә тугыз йөз утыз тугызынчы елның язында армиягә алганнар дип беләм, — диде Рәҗәп.

— Бу көмеш тәрегә дә шул ел басылган, — диде Ягъфәр.

Рәҗәп:

— Бу сугыш ачылган ел ич инде, наным, — диде. — Польша.

— Сугыш ачылган ел, Польша, — дип җөпләде Ягъфәр.

— Шул елны шуның өчен бер-бер нимес солдатына биргәннәр инде, — диде Рәҗәп.

— Орденның мондыен сугыш башында солдатка такмыйлар.

— Офицерга гынадыр шул.

— Иң кимендә — группенфюрерга, Рәҗәп абый.

— Анысы кем була инде, Ягъфәр? — дип сорады Рәҗәп.

— Группенфюрер була, — диде Ягъфәр.

— Суң мин надан ич инде, наным. Ниме дип кистереп әйтмисең?

Ягъфәр:

— Нәрсәне, Рәҗәп абый? — дип сорады.

— Группенфүрер дигәнеңне. Кара, әйтеп бетергәнче телең сынар, ә! Безнеңчә ничек була суң ул?

— Аларча була, Рәҗәп абый.

— Бу тәренең күпме торганлыгын әйтмәдең ич әле.

— Өлкән лейтенант Казыевның орденына караганда күп мәртәбә кыйммәтрәк, — диде Ягъфәр.

— Нигә кыйммәтрәк, наным... капитан? — дип сорады Рәҗәп. — Әгәренки, аңлавымча, бу фашист тәресен атаң кулга төшергәч диюем инде.

Шул вакытта Рәҗәпләрнең кече капкалары ачылып китте, аннан, мунча мичենә тыгылган утын астына каен тузы ягып җибәргәннән соң морҗасыннан ургылып чыккан кара төтен шикелле, кара-корым бер эт атылып килеп чыкты да... Ягъфәрне күргәч, сыртын кырт кирегә борып куйды. Ул капкадан ике хатын күренеп, берсе алдан тартып, арттагысы этеп, калай тагарак өстерәп чыгардылар. Алдагысының Рәҗәпнең хатыны Гөлсинә икәнлеген Ягъфәр таныды инде. Арттагысы кызлары Сәгыйдә иде, ахрысы.

Гөлсинә, аны күреп алгач:

— Исән-саумы, наным? — диде.

— Аллага шөкер! — диде Ягъфәр.

— Менә без шундый инде, наным, — диде Гөлсинә. Аннары Рәҗәпкә: — Пычак бир әле, — диде.

Рәҗәп киеменең уң кесәсеннән чүпрәк төргәге чыгарды да:

— Мә. Үткен. Кулыгызны кисә күрмәгез, — дип, пычакны бүрәнәнең сул ягындагы черек ботак урынына кадады.

— Кыршалмады микән инде? — дип сорады Гөлсинә.

Рәҗәп:

— Төрмәдә ике ел каешландым, — диде. — Пычакның ни икәнен генә беләм.

Ягъфәр күрде: йөзе трактор двигателе клапанын таптатып ясалгач кайралган, сабы пластмассадан аллы-гөлле итеп төпләнгән пычак.

Әлеге хатын уңган юка гына ефәк яулык япкан, сырма кигән, карамы, күрәнме икәнлеге танымаслык трико тарткан, пычракка катып, кар ягылган бутыйлы, ә боларны салып атса, су иясенә тиң хикмәтле, бар бөтен җире үз урынына җитешле булыр иде шикелле.

Шанель ислемайлары сибенеп, Диор киемнәре киенер урынга Гөлсинә әле генә ишегалдыннан капка төбенә тартып алып чыгарылган тагаракны әйләндереп бушатты да ире Рәҗәптән сорап алган пычагы белән ак карга яткан яшькелт-зәңгәр өемне буеннан-буена ерып чыкты.

Ә аның белән янәшә торган кызы:

— Әни, әйләндеримме инде? — диде.

— Капла, кызым, — диде Гөлсинә.

Гөлсинәнең ярып, ә кызының әйләндереп каплаган сыер ашказанынннан кайчандыр болыннарда борнап та, аннары соң чәчәк атам дигәндә чабып киптерелгән үләннәр, чәчәкләрнең ахырга ни кыяфәт алганлыгын Ягъфәрнең беренче тапкыр гына күрүе түгел.

Фәкать шунда Гөлсинәнең яланкуллап әүвәлге чәчәкле болын печәне боткасында ни рәвешле кармаланып торганыннан соң:

— Карале, Рәҗәп! Инә кергән булган икән, — дип, нәрсәнедер кармалап тапканыннан соң иренә чистарткандай күрсәтеп биргәндә, Рәҗәп:

— Яхшы. Атом бомбасы түгел лә, Гөлсинә, — диде. — Бер көн ашатмый тотканыем, Ягъфәр энем, — диде Рәҗәп. — Ә каласы нәрсә барыбер кала икән.

— Әле ярый кадалмаган, — диде Гөлсинә.

— Кадалса суң, — диде Рәҗәп. — Аны барыбер суясы иде ич. Эч мае гына да дүрт чиләк чыкты, энем, — диде ул Ягъфәргә. — Ышанасыңмы-юкмы?

— Әйбәт булган, — диде Ягъфәр.

— Әйе... Моның — әти орденының, дим инде — бәһасе күпме тора дидең әле? Ә! Йөз, әме бит? Шул бәягә сатып алалармы?

Ягъфәр аның «йөз» дигәнен «илле»гә төзәтеп тормады.

— Алалар.

— Әйтик, әгәренки мин шунда барсам. Алалармы?

Ягъфәр:

— Алалар, — дип кабатлады.

— Ә мин, әйтик... йөз илле сум куйсам? — дип сорады Рәҗәп. Аннары, пышылдап: — Сатып алалар да — саталармы?

— Сатылалар, — диде Ягъфәр. — Барып өшәнмә.

Ул утырып торган бүрәнәдән иңә башлаган суыктан арынырга, аягын, җанын, бәгырен язарга теләп басты да, теге хатын-кызларның яңа суелган сыерның ашказанын, эчәкләрен эш итәргә ишегалдындагы мунчага алып кереп киткәннәрен искәреп, урамның үзе кайткан тарафыннан бер ир затының килгәнен күргәч, өске киеме итәген кайтара төшеп, кулын уң кесәсенә тыгып алды. — Шушы җитәме, Рәҗәп абый?

Аның кулындагы дүрт иллелек акчаны шәйләп алган Рәҗәп, һич кабаланмыйча, тып-тыныч итеп:

— Җитә, — диде.

Күктән, сабыр гына итеп, сирәк, бик сирәк, тик инде озакка киләсе суык кышның җемелдәвек вак кары төшкәли иде.

Ягъфәр өенә кайтып китте.

Каршысына килгән ир заты аны:

— Нихәл, энем? — дип сәламләде.

— Аллага шөкер, Сәхәбетдин абый, — диде Ягъфәр. Аның чиста тастымалга ни төреп тотканын төгәл аныклап, ул: — Кемнәргә юл тоттың? — дип сорады.

— Тилчә Закир абыйлар дәшкәние. Үгезләре ике яшь ярымлык. Сорагач, ничек тик торасың инде? — диде Сәхәбетдин.

— Савап булсын.

Шулай дисә дә, ул әле генә әллә кайдагы Сират күпереннән ары таба үткәндәгедәй бер хис кичереп алгандай булды.

Юк. Тәмугтан үтте бугай.

Кайсы тарафка икән?

Бу дөньяны кемнәр генә белеп бетерсен соң?!

Ягъфәр үз чалбарының уң кесәсендәге янәшә ике орденны (берсе — Кызыл Армия сугышчысыныкы, икенчесе — фашистныкы) тоеп барды.

«Күрәсең, ахырзаманга хәтледер», — дип уйлады ул.

Аннары соң, үзенең ни уйлаганын үзе дә белеп, аңлап, кабул кылып бетермичә:

— Энә күзе, — диде.

*2003*

## ШОМ

Көтмәгән-нитмәгәндә ул: «Ни-нәрсәне оныттым соң әле?» — дип, әллә сүзләп, әллә уйлап, ишегалдында арлы-бирле йөргәләде дә, иртәнге кояшка таба әкрен генә барган куе күксел болытны шәйләгәч:

— Яңгыр яумагае, — дип, үзалдына сөйләнеп куйды.

Ул шундук, бүген уянгач, әнкәсе өйрәтеп калдырган көндәлек догасын укырга онытканлыгын исенә төшерде, моңа әлеге аерым болыт тавы сәбәпче түгел икәнлегенен үз-үзенә катгый искәртергә кирәк тапты.

Ул арада капка төбеннән арырак юлдан өчме-дүртме хатын-кызның әле кызып, әле саран сөйләшеп уза баруларын ишетеп торды, аларның тәгаен дүртәү икәнлеген чамалады. Бәлки, бишенчесе дә бардыр әле. Авыл көтүе узгач тавышларның, авазларның сан-исәбен аеруы, санавы кыен хәл.

— Килә инде бу, — диде берсе.

Таныды: Кое тыкрыгы очындагы Күке Халисәсе.

— Әллә кире борылабызмы? — диде бүтәне.

Бу ягымлы тавышлысы башлангыч сыйныфлар укытучысы Миләүшә инде.

— И, яусын сана. Ул хәтле җиер нәрсәм юк әле.

Монысы Әтәч Мәрванының хатыны Рәсиха икәнлеген ул капка ачып карамаса да таныды.

Шуннан соң ул менә өрәм, менә өрәм дигәндәй колагын шәңкәйтеп торган Чуерташ кушаматлы эткә шым булырга ым какты да ирексездән иртәнге бу көннең авазларын, тавышларын тыңлый бирде.

Иртән-иртүк көтү кугач, аны-моны карагач, ашагач, эчкәч, чөгендергә барышлары уңаенда, анда көн дәверендәге тузан белән кояш арасына керер алдыннан бу әлеге хатын-кызларның элеккеге эч пошуларын, кичергән иңрәүләрен, ары таба күрәсе изаларын үзләренчә басулары гына икәнлеген ул яхшы белә.

Ул — Әсәт (әйе, ул Әсәдулла атлы, алтмыш икенче яшенә чыккан таза бер ир заты) ишетеп торганының ни мәгънәсен, ни асылын, ни-нәрсә хакында икәнлеген әллә аңышты, әллә аңышмады да шунда. Аңышмады дип... капка төбенә чыксын да:

— Бармагыз!

Йә:

— Җитәр инде! Бот арагызда күбәләк канатлары кагынасы нәрсәләр! — дип кычкырсынмыни соң?

Нихәл итмәк кирәк инде: болар — чөгендергә баручы хатыннар. Алар буйдан-буйга чакрым ярым араны билләрен баглап, җаннарындагы гомерлек тышауны инде җиде кат күккә чөеп атасылары килсә дә, күңелләрендә ниндидер җыр йөртәләр, ара-тирә сүз кайтарыша-кайтарыша бураздналарының яртысына җитеп, ә инде теге башына ирешкәч, тәмам суынып тәмсезләнеп беткән чәйгә дә риза-канәгать калалар. Тик үзләренең кем икәнлекләрен белсәләр дә, ни җәй, ни көз эшләгән әҗерләрен алалмыйча адәм хуры ителәләр.

Әсәт кинәт кенә болар хакында: «Коллар», — дип уйлаганына сәерсенеп куйды.

Ул белә: авылның таш күперенә җитәрәк, боларга Югары оч, Тегермән очы, Төбәк, Сазлык урамнарындагы хатын-кызлар да кушылып иярә.

Өстәп, җиткән егет-кызлары, бала-чагалары, хәтта оныклары да.

Анда инде сүзләре бүтәнчәрәк булыр, кемнең кайсы җире кычыта да, мәсләкләре ни? Бөтенесен эш тузаны томалаган, ничаралык йөге баскан.

Елыйсылары килердер — күз яшьләре чыкмас; каргыйсылары килердер — сүзләре килмәс; тик башлары турысындагы камфара төсле иксез-чиксез күк йөзендә каргышлары ирешердәй ялгыз козгын да очмас.

Әсәт:

— Йа Алла! — дип куйды.

Татар хатыннары йорт башыннан кеше исәбендәге ният белән чөгендер игә. Челләдә. Башларында — уңып беткән яулык, күлмәкләре — һәркайсының үз җаенча, әлбәттә, ямаусыз түгел; мутикләрен бәргәннәре саен, бөтен гәүдәләре дерелдәп-дерелдәп киткәли.

Әсәт: «Анда бер генә агач та, күләгәсе дә юк... Үз бөкреләреннән кала», — дип уйлагач, сыер, бозау, сарыклар абзарын чистартасы дәү көрәген өстерәп, ишегалдының капка баганасы төбеннән үзләре йөри торган бәдрәф ишегенәчә урык-сурык йөренеп килде.

Әйе. Советлар хөкүмәте мәңгелеккә дип биргән егерме биш сутый җирдән бәрәңге алганда әнкәсенең — үз ире — Әсәтнең атасы ярты капчыкны күтәрергә тотынгач:

— Өшәнмә, Әпсәләм — үзем. Бүген Мәсрурә апа мунча якты. Кара каен себеркесе бар. Чабындырсам, теге ярчыгың чыкмый калмас, — дигәнен ишетеп калганын Әсәт менә хәзер — шушы мәлдә генә нигә исенә төшерде соң әле?

Шәйләгәндәй түгел. Күргәндәй итеп.

Шундук: «Ә ул чөгендердәгеләрнең кайсысыдыр ничә атналык көмәнледер инде», — дип уйлаганына сискәнеп китте.

Әсәт мәктәптә авыл балаларына сыер, ат, дөя, тәгәрмәч, өй, алмагач, сөлек, урак, чүкеч, дага, кыяр, өтерге, бишек, мылтык — тагын әллә ниткән рәсемнәр ясарга өйрәтте.

Ә үзенең байтактан, инде бик күптәннән бирле Төбәк елгасы белән Чүнник чокыры уртасындагы — чама белән — инде шыр бушаган бәрәңге басуы кырыйлата кем тимер таякмы, кем тимерчыбыкмы, сәнәкме; кем тимер көрәкме, ухватмы — бүтән нименедер апрель ае азагы карына кадый-чыгара, кадый-чыгара өшегән бәрәңге чокып, казып алган, җыйган, шунда райкомның беренче секретаре... кем әле?.. әйе, Ларин җитәкчелегендәге зәңгәр киемле, кызыл кайтармалы ...нәрсә инде... милиция отрядының боларны килә-килешли уратып алган, ул арада өчесенең бу сугышта каһарманнарча һәлак булган, икесенең хәбәрсез югалган — кем югалткан? — берсенең мич башында сызлана-сызлана яшәү көтеп үләргә яткан ире хакына — өметле-өметсез алты хатынның (иң өлкән дигәненә кырык ике яшь) үзләренә ияртеп килгән кызкыркынны куып, таратып җибәрергә өлгергән, әлеге алты хатын-кыз янына теге отрядтагы йөргән егете — фронттан кайткан аксак Сөләйманын таныгач качмый калган Зәйтүнәнең шәлен кайтарган көйгә шул Сөләйманның бу Зәйтүнә каршысына тора-торып: «Гаеп итмә. Исән-сау кайта күр», — дип, үз-үзенә пистолетыннан атканын... — менә шуны, менә шуларның бөтенесен җыйнап, рәсемгә төшерәсе килә иде.

Әсәт: «Курыктым», — дип уйлады да теге болытның, Кояшны узып, ары таба — Анатыш ягына киткәнлеген карап торды.

Тегеләр уратып алып, өйләренә дә кереп чыгарга рөхсәт ителмичә штыклы мылтык сагында киткән алты хатынның берсе Әсәтнең әнисе — тугыз бала анасы Мәмдүха иде. Иң соңгы хатының Архангельск ягыннан килгәне аның һаман исендә әле. Атасы исә канкойгыч Балатон сугышында ятып калды.

Әйе. Ул әнә шундый-шундый сурәтле, эчтәлекле рәсем ясый алмады.

Ул үз-үзенә: «Куркыттылар ич, — диде. Аннары: — Оныттырдылар... Оныттым», — дип уйлады.

Ә балалар — аның укучылары — йомрандыр... дуга, чүмеч, йолдыз, пәйгамбәр тырнагы чәчәгедер рәсемнәрен килештереп ясыйлар иде.

Ул хатыны Наҗиянең киң, якты болдырдан:

— Әсәт! Ниме дип тик торасың анда? Абзарны чистарт та, ашап-эчкәч чөгендергә китәсебез бар, — дигән ипле тавышын ишетте.

Аның хатыны — авыл кибетчесе; тик нишләтәсең инде: мал-туар тоткач, әлеге дә баягы, чакрым ярым буйлы чөгендердән өч рәт алмыйча чараң юк.

Әсәт үзенең бүген нине онытканлыгын исенә төшерергә вакыты җитмәслеген искәрде.

Көн, болай, Аллага шөкер: яхшы. Теге ямьсез болыт, ниһаять, ары узды да китте. Көн шомсыз, хәвефхәтәрсез булырга охшап тора: инеш борылышындагы текә ярга оялаган керәшәләр шактый югарыдан очалар, чуар күбәләкләр чәчәкләргә таба түбәнәйде, бал кортлары да кузгалышты.

Ул тиз тотып абзар-кура чистартасын, кулын-битен сабынлап югач (бүген кырынып торасы түгел, чөгендер тузанына ярамаган тагын, кайткач, мунча кергәндә карар әле), үзенең, Наҗиясенең мүтикләрен игәүләп үткерлисен... тагын нәрсә?.. Тегесен-бусын ниятләп торды да кинәттән генә әнкәсен өшегән бәрәңге җыйган җиреннән мәңгегә алып киткәннәрен моңарчы һичкемгә сөйләргә онытканын — ә, юк! — курыкканын исенә төшерде.

Шомланып китте. Китте дә — әлеге шомның бүгенгенеке генә түгеллегенә төшенде. Ул моның ләхет такталарына көрәк-көрәк туфрак ишелгәндә дә иңдереләсен аңлады.

Аннары — иңәсен.

Ул: «Яхшы. Бүген чөгендергә барасы. Өшегән бәрәңгегә түгел ич», — дип уйлады.

Шулай да, шулай да... Шулай да менә бу җанның бер кисәге иртән-иртүк нигә туңып китте соң әле, ә?

Әллә кайларга ашкынган кыяфәтен тыярлык, чикләрлек итеп тимер чылбырга бәйләнгән арлы-бирле сырпаланган, өзгәләнгән эткә Әсәт:

— Әйбәт, Чуерташ, — диде.

Ә ничекләр генә итеп, ерак та, якын да түгел, — офык читендә, күз абайларлык киңлек чигендә, аннан ары өстәрәк, тагын да югарырак аҗаганнар уйнагандамы, күк капусы ачылгандамы, ахыр килеп, әйтик, әтраф-әтраф яшен яшьнәгәндә тегермән ташлары әйләнгәндәй тавышлы күк көлтерәүләре чакларындамы... күл бакасы бакылдаганда, сандугач сайраганда, ат кешнәгәндәме — тагын нәрсәләрнең нишләгәннәрендәме вакытларда ул үзенең бала чагында өреккәнлеген, курыкканлыгын, моннан да битәр шомланганлыгын әле борный гына башлаган җаныннан күкләргә аштырырга иңрәп ялварганда: «Бу бәрәңге хәлләрен балаларыбыз күрмәсен иде», — дип, теләгәнен исенә төшерде.

Аларның балалары булмады.

Нинди генә докторлар да әйтеп бирә алмаган сәбәпкә ул хәзер төшенде: дөньяга килми калган ул балалар — аныкылар — теге озын-озынчалы бәрәңге базы тирәли язгы карга күпме кадалып та, чәнчелеп тә тимер таяк очларына эләкми калган туң бәрәңгеләр булгандыр, мөгаен.

Әйе, мөгаен.

Тәгаен икәнлеген Әсәт шушы мизгелдә аңлады. Ул өшегән бәрәңгеләр боларның дөньяга килми калган балалары — шомлана-шомлана, шикләнә-шикләнә, курка-курка чәнчелгән тимер таяклар очында калтыранып, тимер көрәкләрнең салкын бишегендә тирбәлеп, мәңгелектә калганнар.

Икән.

Ул Наҗиясенең болдырдан:

— Эшең беттеме инде? — дигәнен ишетте.

Әсәт һәрвакыттагыча йомшак кына итеп, сәхнәләрдәме, мәҗлесләрдәме җыр җырлаганын халык яратканынча матур гына итеп, кайвакытны гармун күрегенең сузылганын инде тәмам иткәннән соң да кала торган тавышы белән сузып, болдырга аркан торган килеш аңа:

— Бетте, — диде.

— Кер. Капкалап ал да — барасыбыз бар.

Әсәт:

— Кая? — дип сорады.

— Кая булсын — чөгендергә, — диде Наҗия.

Әсәт: «Атам-анам мине бу дөньяга капкалап алырга да тузан белән кояш арасында чөгендергә барырга дип яратмаган, тапмаган», — дип уйлады.

Ул болдыр тарафына:

— Хәзер, — диде. — Алып барырсыз.

— Кая? Кем? Бөтен халык чөгендердә ич инде, — диде Наҗия. — Машина юк, җәяү барасы.

Ул: «Бөтен халык чөгендердә чагында кемдер... ләхеттә булырга тиеш», — дип уйлады.

— Мин җыенып беттем инде, — диде Наҗия.

— Мин дә, — дигәч, Әсәт келәткә керде дә мылтыгын барлап куйды.

Ул авыл мәктәбендә рәсем, сызым, физкультура укыта. Тик аның үз күңелендәге, җанындагы барча шомны, куркуны сизәрдәй, ишетердәй, елардай, елмаердай, көләрдәй, тәпи атлап китәрдәй, абыныр-сөрлегердәй, ахыр килеп, үзенең каберенә соңгы бер учмы, көрәкме туфрак салырлык бер генә баласы да юк иде.

Аның нишләгәнен ике йөз дә җитмеш биш йортлы авыл ишетми дә, күрми дә калды.

Ул мәңгегә: «Яшәве авыр. Үлүе җиңел», — дип уйларга өлгерде.

Ә бу вакытта Чуерташ сузыплар-сузыплар уларга кереште.

*2004 ел, июль — август*

## АКБАР

Акбар кушаматлы эт адәми затларның җансыз берәүне акка төрелгән килеш, ниһаять, җиргә күмеп куйганлыкларын зираттагы бердәнбер юан карт нарат агачы төбенә посып күзәтеп торды. Тегеләрнең гамәлләре тәмам икәнлегенә төшенгәч, әле генә җыйнаулашып, ашыгып, алмаш-тилмәш көрәк алыштыра-алыштыра күмеп киткәннәреннән соң калган дымсу бер калку өем туфрагын алгы аякларындагы тырнаклары каерылып, шуларның төпләреннән кан тамчылары чыккач, шул кан, тырнак, җир, җан исе саркып, сыктап беткәненә хәтле актарды да актарды, казыды да казыды.

Һични чыкмады.

Ул үз хуҗасының кайдадыр шунда икәнлеген тәгаен белә, ә барча белгәнлегенең чигенә җитәрлек түгеллегенә Кояш тәмам офыкка иңгәч кенә ышанды, биреште, чигенде.

Мәңгегә.

Әлеге адәми затлар төшлектән соң таралышты. Шул ук — билләренә тиклем үләннәр, чәчәкләр арасына иртән-иртүк салынган сукмактан берсе артыннан берсе тезелешкән көйгә тыныч кына сөйләшә-сөйләшә китеп, капкадан чыккач, һәркайсы үз тарафына таралышканнан соң, Кояш инде тәмам сүрелеп бетеп, Ай калыккач кына ул — Акбар — алгы тәпиләрен калку җирдән аерды да ялап-ялап алды; тырнак төпләрендәге ком, үзле кызыл балчык катыш үз канын төчкереп-төчкереп атты. Күпме актарынса да, казып төшәренә көч-куәте җитмәслегенә һич кенә дә килешәсе килмәс борын, әле вак-вак кына атлап, әле терек-терек йөгереклэп, әлегә кая барасын белмәгән хәлдә әллә кайсы тарафка юнәлде.

Кояш калыккан, Ай баткан вакытларда ул үзенең кеп-кечкенә икәнлеген чамалый. Тик арт аякларына басып барган чагында, үз буен кешеләр буе белән чагыштырганда биегрәк икәнлеген раслау өчен, ул үз койрыгын болгап ямакайлануга, ялагайлануга мохтаҗ түгеллегенә төшенә иде. Анысы, нишләсә дә, аның ни колагы, ни койрык очы беркая да җитми җитүен. Алайга калса, әтәч кикриге дә салават күпереннән узмый, сыерлар көтүендәге ала-кола үгезнең үкерепләр торып алуы да күк күкрәве түгел; урамдагы ата казларның да, кәкере муеннарыннан гайре, аннан уздырган, алдырган әлләниләре юк.

Әйе, ул — Акбар — бәләкәй эт. Тик аның үзеннән кечкенә, көчсез дип, моңарчы бер генә кырмыскага да басканы, һичбер күбәләкне тешләгәне, ичмаса, уен өчен генә булса да берәр чыпчыкны тотам дип куркытканы юк әле. Авыл урамы буенча үтеп барганда, көпә-көндезме, кара төннәрдәме, кышкы бурандамы, язгы ерганаклар ташып аккандамы тегенди-мондый этләр каршы чәчрәп чыкса, ул аларны үз капка асларына ничегрәк куып кертү ысулын яхшы белә: күрмәмешкә салыша да, эндәшми-нитми генә үтә дә китә. Бөтенесе ык итмәгәйләре мык итсеннәр шунда.

Үзенә каныгырга ниятләгәннәргә тамагын әрәм итеп торсынмыйни соң? Үзеңне күрсәтә белергә кирәк. Югыйсә алар барчасы да ата этләр. Ә ул үзенең ана эт икәнлеген быел язгы гөрләвекләр кузгалганда, ташу төшәр-төшмәстә сизде, тойды, белде. Тиңең югында корсак күрсәтмәктән ни мәгънә? Аркага ятуы җиңел ул. Кыр этләре өере узып киткәндә, ә бүре-фәлән килеп чыккан очракта аркан ятып, эч күрсәткәндә ярый: алар бәләкәйләргә тими. Ни кышын, ни язын. Җәен бигрәк тә. Кешеләр генә күзләренә карап өлгермәстән уздырып сүгенә, тик кенә торган чагыңда да тибәргә җай табып тора, кул асларына туры килгән таштыр, агач, тимер кисәгедер атарга яскана.

Эттән шикләнгән кеше үз-үзеннән, үзе уйлаган уйдан курка.

Акбар үз ниятләрен кылырга куркучы кешеләрдән шикләнергә кирәклеген күптән өйрәнде инде.

Ул — Акбар: ап-ак булганына күрә, кашлары уртасындагы, койрык очындагы, алгы тәпиләрендәге кара тапларга карата юри ак бар аты кушылган Акбар. Әллә күпме этләрнең, үз хуҗаларын кыяк үләнле, пәйгамбәр тырнагы чәчкәле, шайтан таяклы, кычыткыланлы, инде буйга үсүдән узып, корыгач сузылыплар торып җиргә авып төшкән каенлы, шул — Акбар өнәми торган әллә нинди чит-ят исле урынга күмеп киткәннәре соңында килеп, борыннарын төрткәннәре, тырнакларын канатканнары юк. Аларга әйбәт, рәхәт. Өйләреннән берәрсен күтәреп алып чыгып, бөтенләйгә калдырып киткәндә дә аларның караучы кемнәреләр кала.

*Ә менә мин, Акбарның, беркеме дә юк.*

*Кичәгенәк авыл көтүе кайткач — сыерларны, сарыкны, кәҗә, бозауларнидыр кайсын аратага япкач, кайсысын абзарга куып керткәч, сыерларны савып, тугайгамы, бакча башларынамы төнгелеккә аркан-лагач, тавык-чебешләр, әтәчләр инде әллә кайчан куначаларына кунаклагач, минем хуҗамны берсе теге яктагы, берсе бу яктагы ике ир кеше инешнең түбәнге очына җәтмә белән балык тотарга алып төшеп киттеләр. Мин — Акбар — дәшкәч, иярми нишлим инде? Иярдем.*

Һәр адымнарын карап торды, басып йөргән эзләрен иснәп барды. Балык күп эләкте. Кайтышлый аның хуҗасы тегеләрдән артка калды. Башта утырып торды, аннары җиргә ятты. Ятты да тынды. Акбар моның бөтенләйгә икәнен тойды. Әлеге ике ир кеше, балыклы букчаларын тотып, юеш җәтмәләрен озын сапларында тирбәтә-тирбәтә кайтыр якларына таба киттеләр дә бардылар. Ичмаса, бер генә тапкыр да әйләнеп карамадылар. Югыйсә үткән юлыңа әйләнеп карашлы, әледән-әле борылып кайтышлы, барлыйсы, ышанасы ич ул.

Тегеләр китте. Акбар үз хуҗасының битен әллә күпме ялады да ялады — уята, торгыза алмады.

...Бөтенләйгә ятканнарны тәмсез ис бөркүчән кучкыл-шәмәхә чәчәкле, ялгыз нараттан былтыр ук коелышкан күркәле, иссез әрем үскән җиргә күтәреп алып баралар да бер казыган чокырга күмәләр дә китәләр. Акбар боларның һичкайсын белмәс иде белүен. Бу сиңа ялгыз хуҗаңның, сине кеше итеп, үзенең җылы, тыныч кочагына кертеп яткыруы гына түгел.

Әнә аны дымсу туфрак өеменнән Ай беткәнче казысаң да чыгарып булмады. Тирән. Ул аннан Кояш тәмам күтәрелеп, су эчәсе килгәч кенә китеп барырга мәҗбүр булды.

Акбар инешнең комлы ярыннан, иелә төшеп, су эчте эчүен, ә шуннан ары, өметен өзмичә, өйләренә кайткан иде дә — кызыл чәчәкле пыяла тәлинкәсенә бернәрсә дә салынмаган. Менәтерә, болдыр ишегенә борынын күпме төрткәләде инде, баскычны күпме тырнады, өреп тә чинап, шыңшып та карады — әаның юан нарат төбеннән кача-поса карап торган чакта бөтенләйгә күмеп калдырылган хуҗасы өйдән чыкмады, дәшмәде, күренмәде. Югыйсә Акбар бүген бер-бер сугым көне икәнлеген алдан белеп, әллә ничә көн көткән иде инде. Каян белә дигәндә, ул кара мыеклы мөлаем ике кешенең машиналар арлы-бирле чабышкан юл ягыннан тәгаен кайтасын, аңа әллә нинди тәмле ризыклар бирәсе көннәре җиткәнлеген өзелеп-өзелеп көтә иде.

Бүген аларның кайтасы көне. Ә аны фермадагы бүгенге сугымга дәшеп алмадылар. Ансыз — Акбарсыз ничек икән инде? Андый-мондый ит-мазар калҗасы, талак (тулысы белән), кап-кайнар бавыр, йөрәкнең тамыр-бизләре, карта (үзләре алып китмәгән шәттә) тәгаен аныкы булган вакытлар шулай бетте дә китте микәнни? Ә андый-мондый ит-мазар калҗасы тияр сыманлыгын ул сиземләп, чамалап куйган иде инде куюын.

Бугай.

Юк. Бүген җир астыннан үзле балчык исеннән гайре бер нәрсә дә бирмәсләр күк.

Икән.

*Күнеккәнемчә, мин бу вакытта әйбәт хуҗамның йоклап ятканын мендәре янәшәсендә саклап, сагалап торам инде. Ул исә көтеп-көтеп тә кайтмагач, Ай чыкканда тагын су эчеп мендем дә кырын ятып йокладым. Йолдызлар сүнгәч, мине бер абый үз кочагына күтәреп алып киткән чагында да йокладым әле. Болай гына инде — йоклаганга сабышып. Юри-мүри генә. Мине тагын нишләтерләр икән дип. Мондый чакта карышырга ярамый. Өрсәң — бигрәк тә харап.*

*Кирәк чагында өрмәүдән хәерлерәк нәрсә юк. Моны мин яхшы беләм.*

*Мине әнкәм имиеннән аерып, адаштырып калдырганнан бирле. Мине күтәреп чыктылар да и уйнаттылар, и чаптырдылар. Карасам — зур ишегалдында беркем дә юк. Ул кичне Ай бик салкын иде. Ап-ак җир суык, тәннәрем туңып бетте. Мин ап-ак маэмайны ак карда ничек күргәннәрдер, — бер апа кеше кызы белән үзләренә алып кайттылар да, башта ап-ак җылы урынга куеп, өстемә кап-кайнар су сиптеләр. Өшим дип торам. Бик тәмле, хуш исле күбектә юдылар. Ак мәчеләре бар икән — мин аңа өрмәдем дә. Икебез бер савыттан ашадык, чәчәкле савытлардан чиратлашып су, сөт эчтек. Ашадык та ашадык, эчтек тә эчтек.*

*Шуннан соң безне аерып, мине купшы кара мыеклы бер кеше җылы, кояшлы, яшел үләнле җирдә калдырып китте. Ул авыл икән. Сыерларны шунда күрдем. Сөзәм дип, мөгезләрен терәп килгәннәренә дә өрмәдем. Мин беркемгә, бернәрсәгә тимәдем, өрмәдем.*

Аның йомран, әрлән ояларын да казыганы бар. Чыксалар да, ул аларга тимичә, әллә кая талпыныптал пынып йөгергәндә куып җитеп тотып алырга да яскана иде дә... үз-үзен тыя иде: күбәләк икән — очсын, әкәм-төкәм икән — шуышсын, керпе икән — туктатканда уфылдап йомарланган булсын; ул аларга тими, мәчебашлы ябалакларның үз ниятләре, йорт-җиргә ияләшкән үтә мут, елгыр ике сасы көзән дә әллә ни кыланмак була. Бөтенесе каядыр бара, ул — Акбар — күпмесенең усал ниятенә аркылы төште, яхшысына сөенде.

Ә кешеләрнең сүгенсә куркытмаган, ашаса тук булмаган, эшләсә булдырмаганнарыннан ул гелән-гелән читләшә, аларны ят итә, өнәми, үз итми иде. Ул андыйларга өрергә дә артыксынды. Ата казларны котыртудан ни мәгънә?

Акбар шулай сыер фермасы, атлар абзарында каравылчы булып торган хуҗасы Сәлахетдинне озак, бик озак оныта алмыйча изаланды.

Сәлахетдин йоклап ятканда, айлы төн уртасындамы, таң ата башлаганда күктәге йолдызлар берәм-берәм сүрелә, сүнә керешкәндәме Акбар гел уяу, сакта була белде. Шуңа күрә ул үзен кичтән иртәнгәчә бөтен хуҗалык мал-туарына, мөлкәтенә хуҗа итеп тоя, ә андый сизгер хезмәттә чагында бөтен нәрсә аның хезмәтчесе иде.

Ә болай тамак тук, өс-тән бөтенлеккә бөтен.

Чөнки кайбер чакны кичләргә кырын Сәлахетдин:

> Танкыларда янган чакта
> Көчкә чыгып өлгердем,—

дип җырлый-җырлый, әллә кайчангы — яньчек, ямалып беткән алюмин савытының капкачын тутырып, аңа ризык куя да:

> Әйдә, Акбар, куен җаным,
> Сиңа да баш өлгерде,—

дип, аңа кичтән суелып, туналып, туралып, үлчәнеп, ниһаять, алып китеп, каядыр җыйналып куелган берәр сыерның шунда калдырылган башының көттереп пешерелгән кайнар итен, җылы сөякләрен иплэп куя торган иде.

Ялгызы калганда Сәлахетдин кешеләр, халык арасында сүз әйтмәү, катмау гадәтен ташлый, ипле итеп, җайга салып, җырга көйләп кенә Акбар белән сөйләшә.

Җәяүле буран себерткәндә, җәйге чиллә төннәрендә, күзгә күктән яңгыр яуган чакларда Акбар үзе дә әллә нишләп китүчән, үтә моңаючан бер җан иясе ул. Күрә торып җырласынмыни соң?

Юк. Ярамый. Сәлахетдин әйтмешли, кеше көләр, пәрәми.

Шул Сәлахетдинне җиргә күмеп киткәч, Акбар үз күңеленнән генә моңаюыннан, Айга карап, кешеләрчә җырлыйсы килү ымсынуыннан бизде, кире кайтты.

Онытты.

Инде.

Тәмам.

Хәер, вакыты-вакыты белән үтә гаярь тернәкләнеп, шаяргалап, җанланып, моңсулыкларын мул суларга агызып җибәргәләгән чаклары да булгаламады түгел. Теге — берсе җилпәзәк матур, озын чәчле, җитез килеш-килбәтле, бик юмарт сүзле, бүтәне кара мыек-сакаллы, кырыс холык-фигыльле абыйлар үз өйләренә кайтып төшкәләгәндә. Бигрәк тә болар йөгерек сулы инеш буенда төнгә каршы учак ягып җибәреп, тәмле, хуш исле ит пешереп, үзләренә ияртеп төшкән гармунчыны уйнатып, җырлатып, аңа үзләре дә кушылып китеп, тора-бара болар янына тирә-күршедәге бала-чага җыйналышып, ахырда чибәр, тыгыз тәнле кызлар, таза-сау саллы егетләр, ирләр дә тартылып тупланган, көрнәлгән чакларда бигрәк тә күңелле, җайлы, рәхәт, шәп була торган иде.

Иде шу-ул... Иде-е.

Сыерлар гына ул бүген ни ашаганнарын белмичә күши дә күши; атлар да, камытлары бүген бумаган икән дә, ыңгырчаклары сыртларын кырмаган, арба тәртәләре тәҗедән читкә каермаган, чана табаннары чалуларга бирешмәгән икәндә, шуңа шат-канәгать. Алар бүтән һәммә нәрсәне үз хәтерләреннән тиз кайтаручан, чуалтучан, югалтучан.

Ә аның — Акбарның исендә. Исендә.

Һәммәсе.

Сәлахетдинне тырнакларын каердыра-каердыра күпме ясканса, күпме тырышса да казып чыгара алмаган көзге көннән соң япа-ялгызы аның инде бикле болдыры төбендә бөгәрләнеп төн уздырыр-уздырмас газапланган, аннары көн кичергән, кич җиткәндә ул берәүнең:

— Әйдә, Акбар, — дигәнен ишетте дә колагын шәңкәйтте.

Тавышы көр, нык икәненә ышанган Акбар битен сыпырып алды да, өметле-өметсез көйгә, тәпи-тәпи шуңа ияреп китте. Иярмәс тә иде. Тик ул тавыш иясе аңа таныш адәми зат. Мал-туар чалырга гел шуны дәшәләр. Ә ул исә аңа — Акбарга талактыр, йөрәк тамырларыдыр, бавыр бизләредерише нәрсәләр генә ыргытмыйча, корсак итен дә кыеп бирә торган кеше Баһау иде.

Чакыргач ничек бармый калмак кирәк инде? Ул үзенә үтеп китешли урлы-сурлы эндәшкәннәргә ыгызыгыланып артык илтифат итүне өнәми, сөйми, кире кага, шуңа күрә Акбар теге кешенең кушуына буйсынды, моны үзенә карата зур дәрәҗә санады да — иярде.

Күпме казып та чыгара алмаганны казганып кына татып була ул. Әйе, иярде.

Ул Баһауның күпер төбендә ялгыз яшәгәнлеген күптәннән шәйләгән иде инде. Аның торган өе болай ярыйсы яравын. Мунчасы бар — тик Акбар андагы морҗадан мул, хуш исле төтен чыкканын хәтерләми. Абзар-курасы да төзеккә төзек шикелле, ә аннан беркайчан сыер көрсенгәне ишетелми; сарык бәтиенең сөтле иренен ялый-ялый чирәмле капка төбенә чыкканы юк; ичмаса, тавык-чебеш ише вак-төяк тә күренми. Акбарның ул тирәдән узып барышлый искәргәне бар: аннан көндезге тилгәннәр, төнге ябалаклар эзләнмичә, тукталмыйча ары таба узалар да китәләр иде. Чөнки — юк.

Ул менә шушы Баһау белән озак тора алмады. Әйбәт, йомшак кеше иде. Әби-сәбиләргә печән-фәлән китергәндә, ул Баһау чүмәлә, өем башын тотты; чакрым ярымдагы чишмә суына баручыларга бик якыннан гына тәмле чишмә ачып, аны бурап бирде; сер түгел, әби-сәбиләргә кышкы төннәрдә капчыклап фермадан силус китереп биргәләде; җәйге көндезге көннәрдә берәүләргә җыйналышып җир тишәргә тотынып та, су таба алмагач, ташлап китәрләре алдыннан иң төптәге тыгыз пычракны уң кулының кытыршы нык бармаклары белән угалагач: «Тагын ярты сажин да бер дюйм», — диде дә, шуннан башта болганчык, аннары чип-чиста су бәреп чыкты. Аңа моның өчен шешәдән бер чынаяк эчемлек салып биргәннәр иде. Ул аны чайкап торып читкә түкте. Аның каруы теге кое суын алдан аңа — Акбарга эчертте. Акбарның авылдагы бер генә эткә дә хуҗасы пыяла савыттан үзе тотып су эчерткәнен күргәне юк иде әле.

Шул чагында аңа гаять рәхәт булып киткән иде. Ул әлеге вакыттагы кинәнүен онытырга ярамаганлыгын хәтеренә салып куйды.

Ул мәңге онытмый онытуын. Ә кешеләр әллә нишли икән...

Әлеге бораулап кое суы чыгарылган өйдәге хатын, эшләүчеләрне аш-суга чакырган чакта, Акбарга: «Йөрмә әле монда буталып, кеше типкесе!» — дип, галушы йомшак булса да, шактый каты иттереп, аның кечкенә эченә типкән иде. Аңа — Акбарга типкәләгәннәре булмады түгел түгелен. Бервакыт президент авылга сугылып киткән чагындагы үзенә бер тән сакчысы типкәнен кичерде кичерүен (чөнки ул аның мылтык маен сизеп алганы өчен генә, бәладән башаяк дип, балтырына чат кына капмады, ябышмады), ә инде бусы — хәттин ашкан мул хатынның үзенә тибүенә Акбар бик гарьләнде. Шуңа күрә Акбар аның ферма мөдире Мөнип коры яшел үлән өемендә ятканда салдырган алсу трусигын, шуңа өстәп, әлеге мөдирнең кепкасын да сиздермичә генә эләктереп алып, шул мәлдән соң ук теге тәмле су чыккан коелары төбенә куеп китте.

Икенче көнне төш җитәр-җитмәстә, су буендагы араталы җәйләүгә әллә кемнәр генә килеп төштеләр дә аның яңа хуҗасы Баһауны, кулын артка каерып, башын идерттереп, зәңгәр машиналарында әллә кая алып киттеләр. Баһау аңа — нишләргә белмичә аптырап сырпаланган, аянган, өркенгән, курыккан Акбарга:

— Акбар! Ак барында — тап бар, — дияргә генә өлгерде.

*Югыйсә мин — Акбар — теге тулы, матур апаның хуҗам Баһау сыерчык бураннарыннан соң һич кимәгән кожаны кесәсенә бер кәгазь кыштырдатып, учыннан кылтыр-кылтырдатып ни-нәрсәләрдер тыкканын, салганын сизеп, күреп, үрсәләнә-үрсәләнә өргән идем лә ул кана. Ферма мөдире Мөнип миңа төбәп сәнәк ыргытты. Мин елгыр елгырын. Ә хуҗам Баһауны алдылар да киттеләр.*

Әйе, Баһауны йөз сум да җитмеш тиен акча урлаган дип гаепләделәр. Хөкемдар карар чыгарды, ул карар һичнинди каршы гозер булмаганга күрә тәмамы белән расланып куелды: биш елга төрмәгә.

Ферма мөдире Мөнип белән яңа коега тиенгән йорт иясе әлеге матур хатын яккан мунчада бергәләп чабындылар, аркаларын алмаш-тилмәш уыштылар, сый-хөрмәт итештеләр.

Ә Акбар исә боларның инеш суына чумганнары мәлендә үзен шушында алып кайткан теге кара мыеклы ике әйбәт абыйның иясез йорт-җирендәге болдыр астына мәңгелеккә дип кереп ятты да: «Мин Акбар идем!» — дип исенә төшергәч, авылдагы барча этләрне моң-сагышка, уйга салып, соңгы тапкыр, соң мәртәбә өрде дә — тынды.

*Мин — Акбар — үземне тынарга мәҗбүр итеп тындым. Югыйсә былтырлары Сәлахетдин мине Кәрәкә күле буендагы тауда җил каккан су өше дулкын-дулкын айкалган да чайкалган кылган диңгезенә кертеп җибәргән иде дә — и! — кинәнеп, рәхәтләнеп, шунда колачлый-колачлый йөзгән дә йөзгән, ул чакны инде кычкырмас-нитмәс яшь канатлы тәкәрлекләргә өзелеп, кырын карый-карый әз-мәз өргәләгән идем.*

*Минем төшемә югарыдан караганда алгы тәпием табаны хәтле генә тоелган, күренгән түгәрәк күлдәге кыр үрдәкләрен куркытасым, инештәге кондызларны котыртасым — тагын әллә нишлиселәрем килүләре кергә торган иде... Ни ул... берәр матур, сөтле, акыллы сыерның мышный-мышный үлән ашаган чагында көтүченең аңа селтәгән чыбыркы очын иренемә кабып калганнарым күп булды. Мин әнкәмне имеп яткан чагымда бер адәми затның мылтыгыннан чәчрәп чыккан яшен очын гына эләктереп алырга өлгермәдем.*

*Ә болай... миңа дөнья күрсәткән мыеклы абыйларга мин риза-бәхил. Болдыр аслары коры, тын, ипле иде.*

*Үзем шикелле генә кеп-кечкенә бер үкенечем, куанычым калды калуын: теге якты җиһанда алдыма куелган ризыктан кала беркемне, һичбер нәрсәне тешләмәдем.*

*Ә! Соңгы мәлемдә тагын бер әйбер исемә төшеп өлгерде әле. Теге — инде теге — Кояшлы, Айлы, Йолдызлы, таңнар сызылып атканда чык төшкән Үләнле — әйтепләр бетерерлек булмаган тагын әллә нәрсәле җирдә минем үз имчәгемнән аерыплар, каерыплар алып, кайсы кая таратыласы бәгырь көчекләрем булмаганга әллә сөенеп өрәсе, әллә көенеп шыңсыйсы калган.*

*2004 ел, 4 ноябрь*

## КҮРГӘЗМӘ

*Рәссам дустым*
*Шамил Нигъмәтуллинның*
*якты рухына багышлыйм*

Инде һичкем калмагач, ул үзенең рәсем күргәзмәсен япа-ялгызы тагын бер тапкыр карап чыкты. Ә, болай, ике ай буена уйлаганын, тәртипкә тезгәнен, үзе кушканча ничә мәртәбә күчерә-күчерә элдереп куйганын кем санаган. Аны шушы уңай белән оештырылган үзенең хәл кадәри мәҗлесендә көтәләр иде инде. Зарыгып түгел анысы. Анда иясе юк дип тормыйлар: сәгате сукты исә, — башлыйлар. Чөнки хуҗаны көтә калсаң, шулпа куеручан.

Анда кергәч, бер-бер сүз әйтәсе була инде. Шуңа күрә ул үз күргәзмәсен караганнарның аның хакында язганнары теркәлгән дәфтәр куелган борынгы өстәл алдындагы венски урындыкка килеп утырды да — ачты.

Иплəп укыды. Әйбәт язганнар. Гадəттәгечә котлап, тәбрикләп, мактап, алгы дәвамына уңыш теләп. Болай да, шигырьләп тә.

Ул: «Болай ук кирәк түгел иде», — дип уйласа да, барыбер рәхәт булып китте әле. Бал ягылганда кемгә тоз тансык булсын инде.

— Аягыңны ал әле, Камил.

Җыештыручы Хәмдия апа икән. Ул әйтсә, аяк түшәмдә торырга тиешлеген Камил бик яхшы белә. Әнә ул — Хәмдия апа тугызлы чалгыга тиң коралындагы пөхтә чүпрәген бер батманлы чиләгендәге сабынлы суга манчып-манчып, сыгып-сыгып алды да, шапылдатып, имәннән җәйгән паркет идәнгә чәпәгәч:

— Тегендә сине көтәләр, — диде.

Ул, аңа карамыйча:

— Хәзер, хәзер, Хәмдия апа, — диде. — Укып бетерим инде. Калганы соң түгел.

— Кемгә — соң, кемгә — уң. Анда җырларга керештеләр инде, балакаем.

— Уздырмаслар әле.

— Кемнән?

— Синнән, Хәмдия апа.

— Алгырларга бирешкәнем булмады анысы, энем. Аягыңны төшер, уздым ич инде, — дип, Хәмдия шома сапка утыртылган җайлы тимер кыстыргычтагы чүпрәген әле уңга, әле сулга селти-селти, эшерә, айкый, ышкый-ышкый, тик затлы такта җәюле идәндә кемгәдер ияреп кергән бер бөртек комнан да сыдырылган эзе калмасын өчен тырыша-тырыша ары таба узды.

Аның мәйданы зур әле, киң, иркен, үтәсе дә үтәсе. Кеше эзен бетерерлек түгел.

«Уңышлы күргәзмә. Котлыйм. Матур. Киң. Ә менә сул якка куелганнарының ахырдан бирегә таба ике картинасыннан уң тарафтагы өч хезмәте миңа ошамады. Бүтәннәре белән тәңгәл килми. Сурәтләр — контрапост. Киңлек кысага куып кертелгән. Натурализм. Тешләре коелышкан кабада сарык йоны эрләп утыручы әбине бүген кем белсен инде? Базарга чыксаң, бөтенесе бар. Уза-үтешли күренгән натюрмортның хәзер кемгә кирәге бар? Атом заманында бүгенге йон эрләүчене сурәтләү — торгынлык ул. Җитмәсә — контрапост», дигән язуны укыгач, Камил, бөтен күргәзмә залын, мәйданын сискәндереп:

— Хәмдия апа! Контрапост нәрсә ул? — дип кычкырды. — Монда берәү мине торгынлык дигән.

Хәмдия, тыйнак кына итеп:

— Әйбәт, — диде.

— Нәрсә?

— Торгынлык.

— Хурлап язган ич.

— Укыдым, — диде Хәмдия. — Шәп. Мактаган.

— Нинди мактау, Хәмдия апа?

— Тормаслык димәгән ич.

— Нәрсәне?

— Контрапост... Калганын хатының — кем әле? — әйе, Суфиядән сора. Каба тешләрең калынрак килеп чыккан анысы. Буявыңны янга калдырасың килгәндер инде. Хәзер бөтен нәстә кыйммәт ич. Ә өрәңге орчыгыңдагы чүлмәк бөтерчегең нәкъ безнеңчә — суйган да каплаган инде менәтерә. Өстенә баскансың — сыер икәнсең... Бүген болай, иртәгә тегеләй ул, наным. Идән чүпрәген дә гел булмаса бер алыштырасы ул.

— Ә контрапост ни?

— Әллә тагын. Хәзер генә тора-торышка исемә төшми. Онытылган, хәерсез.

Үз күргәзмәсен кулының уңлы-суллы хәрәкәте белән иңләп, рәссам Камил:

— Кайсысы ошый, Хәмдия апа? — дип сорады.

Зәңгәр халатлы, «әби галушы» кигән, башына аллы-гөлле ефәк яулыгын почмаклап япкан, аркылы-торкылы җыерчык челтәрләгән йөзле, мул күкрәкле, күркәм буйлы җыештыручы хатын күргәзмә залының түрендә бүгенгә ахыргы тапкыр яланкуллап сыккан чүпрәкле коралының сабы очын тулышып торган иягенә терәгән көенчә:

— Үзең, энем, — диде.
— Карап чыктыңмы соң?
— Көчкә юып бетерүем ич әле.
— Нәрсәне?
Хәмдия, түшәмгә карап:
— Сиңа килгән халык эзен, — диде.
— Монда берәү өч рәсемемне ошатмый язган әле.
— Анау сул яктагы икесен, монау уң яктагы өченчесенме?
Камилнең әллә кайларга дөрләтеп ут төртәсе, ялкынлатып яндырасы, тик сүндермисе килеп китте. Ул:
— Яхшы, — диде. — Булыш әле, Хәмдия апа.
— Сине тегендә көтәләр ич.
Ул:
— Яхшы. Өлгерермен. Булыш әле, — диде.
Хәмдия кайдагыдыр, ниндидер бөрмәсенә кыстырган халатының итәген ян-яктан төшергәләп, сыйпаштыргалап алды да:
— Нишлисе? — дип сорады.
— Сул яктагы икесен, уң яктагы өченчесен аласы.
— Төшерәсеңмени?
— Миңа биреп торасы, сиңа төрәсе.
— Рамы-ние беләнме?
— Уптым илаһи.
Бая гына венски урындыкка утырган килеш затлы өстәлдәге теге-бу язуларны укыганда йөзенә алсулык йөгергән Камил, көрән кәчтүменең төймәләрен ычкындырып бетергәч, тын буылганнан котылырга теләгәндәй, аклы-кызыллы галстугы төенен сул кулының таза бармаклары белән бушатып атты да:
— Сөяге калсын. Ите кирәк, — диде. — Пәкең бар. Бир әле.
Хәмдия үз халатының уң кесәсеннән ачылмалы пәке алып сузды:
— Мин моны идәндәге төкереп ташланган сагызларны кырырга гына тотам.
— Шуны әйтәм дә — тотсыннар!
— Менә урындык, мә чүпрәк. Аягыңны сөртеп менәсе — эзең калмасын.

Өченче көнне үк өчме-дүртме гәҗит саен теге дә бу телевидение тапшыруларыннан рәссам Камил Касыйминың шәхси күргәзмәсеннән иң кадерле, үтә кыйммәт бәһагә торырдай өч картинасы урлануы хакында шәрехли-шәрехли, җөпли-җөпли әллә күпме хәбәр таралды.
Милиция берни тапмады.
Ә ул исә үзе кичке бер кафеда җаны-тәненә тап-таман диярдәйлек аракыны әфлисун суы аралаш уртлап утырган чагында аңа берәү:
— Исәнмесез! — дип эндәште.
Кем, нигә икәнлеген белешеп тормый-нитмичә генә ул:
— Комси комса — ярыйсы, — диде.
Ул үзе утырган өстәлнең теге ягындагы буш урындыкка затлы киенгән, кап-кара чәчен артка тараган, ә мул мыегы чал булган берәүнең кабатлап:
— Гафу итегез, — дигәненә җавап бирмәстән, сиздерер-сиздермәслек ишарәсе белән официантны әйдәп китерде.
Официант килеп җитәр-җитмәстә, Камилнең әңгәмәдәше:
— Мин кичә сезгә телефоннан чылтыраткан идем, — диде.
— Et belle, — диде Камил. — Бик яхшы. Син кайсы районнан?
— Штат. Массачусетс.
— Кайчаннан бирле?
— Seven — җиде ел инде.
— Атаң-әнкәң?
— Чирмешәндә.
— Нигә аны чыраеңны сытып әйтәсең?
— И абый. Үзең беләсең ич инде.
— Беләм. Ә син?
— Акча юк.
— Әле кичә саңт — йөз диден ич әле.

— Суммы?

— Долларс, энем, долларс.

— Кыйммәт бит.

— Арзан торса, мине тапмасыең. Thousand.

— Саусенд? Мең? Ярый. Алабыз. Stolen... әйе, урланган картиналар бездә кыйммәт тора.

— Очсыз булса, мин аларны... ничек әле? — стоул! ...урлап тораммыни, җүләр!

— Син үзең nut... җүләр, uncle... абый. For every picture — five thousand dollars... бишәр меңнән... унбиш мең.

Камил егетнең кичә кич телефоннан өенә чылтыратканыннан соң (каян тапкан диген, ә? Хәер, тапмас болар!) аның тавышын шәмәхә төскә охшатканын исенә төшерде. Ә бу төсне ул үзенең һәммә рәсемнәрендә афәт, үлем төсмере рәвешендә куллана иде. Шуңа күрә ул:

— No, — диде. — Аухфидерзейн, энем. Эчеп куй.

— Рәхмәт, uncle... абый. The artist stole his best picture himself... әйе... иң яхшы картинасын рәссам үзе урлый...

— Кем атлы әле син?

— Атым юк минем. Ранчо тотмыйм.

— Исемең, дим... ничек әле... nut!

— Эрнест мин.

— Анда... Массачусетсыгызда шулайдыр. Мин синең атаң-әнкәң куйган исемеңне сорыйм.

«Массачусетс» тын гына:

— Эрнест, — диде.

— Белеп кушканнар икән, Эрнест энем, — диде Камил. Бераз тын торгач, ул: — Беләсеңме, Эрнест: һәркем үз җанын үзенчә урлый, — дип өстәде.

Рәсемнәр күргәзмәсендәге сул яктагы икесенә ул «уфалла» арбасының сыгылмалы тоткычын тотып барган үз-үзен, ә ике энекәшенең арттан эткәннәре кыяфәтен генә төшергән иде. Әллә кайдан — өстән, күктән күренгәндәй иттереп. Өчесе дә әнкәләре сатиннан тегеп биргән, йөри-йөри инде чем-каралыгын тән тире бүзгә әйләндергән, кояш алдын-артын чуарлаган трусикчан гына килеш. Бит-йөзләрен тир чишмәләре челтәрләгән. Инде дә рәсемнәрнең уң яктагысының өченчесендә ул тагын үзе инде: затлы көрән кәчтүм-чалбарлы, яшькелт күлмәгенә суйкыйлата ак, кучкыл, кызыл, җете зәңгәр сурәтле галстук таккан кыяфәттә. Күз көне, күрәсең. Шиңгән бәрәңге сабакларының үрмә-үрмә эт эчәгеле, уклары инде учка кадалмастай яшь билчәнле, күзлүтлы — боларның һәммәсе кипсен өчен чәчегә җәеп салынган. Хатынымыдыр, әллә кемдерме инде әлеге куыш эченә кибәргә дип җәелгән сабакларда рәхәтләнеп, кемнедер өметләнеп, өзелепләр көткәндәй кырын ята, имеш. Әлеге хатын-кыз затының борчак-борчак ак төшерелешле зәңгәр күлмәгенең итәге сизелер-сизелмәс кенә күтәрелеп тора. Кайдагыдыр янәшәдәге балан куагының төп буе нигәдер ярык иде. Бер-бер хикмәтсез түгелдер инде, кем белсен. Бәлки, уйдырмадыр. Ә уйдырма тикмәгә булмас: болардагы һәммә шәрехтә, аныңча, татарның үткәне дә, бүгенгесе, күрәчәге дә сурәтләнгән кебек иде.

Камил боларны — үз җаны җимешләре саналырдай рәсемнәрен бик кинәнеп сатар иде дә бит кана...

Сатмады. Чөнки ул аларны үз-үзеннән dollarsларга сатар ният белән урламады ич.

Кеше үз гомерен сатмый.

— Хәмдия апа, булыш әле, — диде ул.

— Хәзер, хәзер, Камил наным, — дигәч, итәгенә кулын сөртә-сөртә, аның янына, җәһәт-җәһәт атлап, Хәмдия килеп басты. — Юеш тисә, бу ябышкак нәмәрсәкәй эләктерми — куба, — дип, ул киң, тирән кесәләренең сул яктагысыннан аңа нәкъ шушы мәлдә иллә дә кирәкле бер тәгәрмәч алып бирде. — Шушының белән чап иттереп ябыштырабыз да кире эләбез дә куябыз аны, энем. Элми кая китсен ул. Эләбез дә куябыз, әме, җанашым. Картина элү муенга элмәк салу түгел ич ул.

Рәссам Камил Касыйми аптырап калуына күрә гайре сәерсенеп, өстәвенә үтә гаҗәпләнеп:

— Каян беләсең? — дип сорады.

— Әллә үзеңне болай беренче генә дип уйлыйсың мәллә? Теге... ни әле?.. Контрапост менә шушы була инде ул... Бүген дә кеше килгәләмәде түгел түгелен. Иртәгә агыласы халыкның эзен ничек юып бетерермен дип торам инде, Ходаем...

*2004 ел, сентябрь — декабрь*

## ANTIQUARIUS

Ике мең дә дүртенче елның октябрь ае башындагы беренче шимбә көненең коры, якты, җылы буласын кичтән кояшның аяз офыкка баюына карап белгән Сафа иртән газ плитәсендә җиз әрмән савытына салынган каһвәне кайнатып чыгарды. Чынаякка салгач, таманча шикәрләп болгатканнан соң, чәй тәлинкәсенә агызды да йотым-йотым эчеп куйды.

Кайнарлата эчәргә ярамый. Югыйсә үңәчеңнең әллә нишләве ихтимал.

Әйе, шимбә көне иде. Кызлары Сәбилә белән Ләбибә ул арада аның белән янәшә үзләре белгәнчә, күнеккәнчә, аннан-моннан дигәндәй, тик ару ашап-эчкәннәренең, киенеп-ясанганнары, хәстәрләнгәннәренең соңында олысы — университетына, кечесе мәктәбенә укырга дип чыгып китте инде.

Ә Сафа исә моңарчы байтактан бирле йокысыннан торган, әгузе бисмилласын күңеленнән әйтә-әйтә, белгән догаларын кабатлый-кабатлый башта тәрәзәнең алтынсу-көрән төстәге пәрдәсен ян-якка көйләп куйган, балконга чыгып, сигарет тартып алганнан соң, өйдәгеләрнең һичкеменә ишеттермәслек итеп, юыну бүлмәләрендә госел коенып чыккан, тешен чистарткан, үткер пәкесе белән кырынган, бите-кулына һәйбәт ислемай сиптергән, шуннан ары эше белән шәһәргә чыгасы, кеше-карага күренәсе өс-башын киеп куйган иде инде. Тоташлый каплаганмы, өзлексез агучанмы көзге болыт-мазарга, кар явулар, сыкы төшүләр, томаннар, бозлавыкларга карамастан ул шулай итүчән.

«Эссе, тузан, яңгыр, буран, суык» дигәннәрне ул өнәми. Алай-болай зарланганнарга ул фәкать:

— Аллаһы Тәгаләгә сүз тидермәгез. Яшәве авыр, үлүе җиңел, — диючән.

Ә бүгенге көн аяз иде.

Шул чакны хатыны Җәмиләнең йокылы-уяулы килеш:

— Чәйнектәге кичәге чәйне генә эчә торсаң ярамаган тагын! —дигәненә ул сискәнеп китте. — Андый-мондый гына мәллә — «Әхмәт» дигәне.

Мондый хәтмәле кискен тавышка бәгъзенең җаны ук кәфенгә төренер иде дә... Сафа моңа күптән күнеккән иде инде. «Түз, йөрәгем, түз» дип торсынмыни?

Күчәреңне вакытында дегетләмәгәнсең икән, тәгәрмәч шыгырдавын ишетмә инде.

Каһвә Җәмиләнеке саналып, ул үзенекен тотканны яратмый иде.

Сафа:

— Кичәге чәй — бүген агу, — диде дә, ары бүлмәгә кереп, әле генә өзәңгеләп, авызлыклап тыйган ярсуын ике йотым шотланд виские белән басып куйды.

Ул үз-үзенә: «Раббым, шушыннан гайре һич гаебем юк», — диде.

Җәмилә, ул нишләсә дә, кытыршы тавышы белән генә эндәшә иде инде. Ә каршы ботаклы тактаны ничек кенә ары-бире ышкылап китерсәң дә, йомычкасы чажлап чыкмый, ышкы авызына бөялә. Андый тактаны йә балта белән чап та бер-бер учакка, мичкә тәгаенлә, йә, болгаплар торып, әллә кая ат та бәр; инде дә аякка чуалганы, кулга тигәне шәтендә илтифат итмә, тәмам оныт.

Җәмилә:

— Барып кайтыр юлыңа, сигаретыңа-мазарыңа ике тиен дә акчасы юк, һаман «инде» дип бара тагын, —диде. — Теш чистарткыч, туалет кәгазе... и-и! — кем ала, нинди акчага?

— Хәзер, — диде Сафа. Анау алма бәлешенең кыентыгын кабып, монау кофены тагын эчеп алыйм инде.

— Алманың күпме сум торганлыгын беләсеңме соң? — диде Җәмилә.

Сафа:

— Беләм, — диде.

— Эшеңнән ни мәгънә соң алайса? — диде Җәмилә. — Кем ашатып тота сине?

— Син, — диде Сафа. Аннары: — Ә сине? — димичә түзмәде. — Булыр әле, булыр, килер.

— Чыгып олаксаңые, ичмасам. Исемә дә алмас идем.

— Алырсың, — диде Сафа.

Җәмилә:

— Кем? Минме? — дип сорады.

— Син генә түгел. Бөтенегез.

— Әй, әйтепләр дә торган була тагын!

— Берәр кайчан кызыллы-кара канатлы күбәләк керер әле.

— Соң? Керсә ни?

— Аңа тимәгез, — дип, Сафа Җәмиләгә әллә кара, әллә уңган көрән, тик панбәрхетле кечкенә генә бер төенчек иңдерде.

— Мә, — диде ул.

— Бу ни бу? — дип сорады Җәмилә. — Шакшы ич бу!

— Яхшы, — диде Сафа.

— Ниме дип миннән болай көләсең соң әле син, беткән нәрсә? Хәерче калдыгы!

Сафа тыныч кына:

— Бәлки калдыгыдыр. Тик ул хәерче булмаган, — диде.

— Кем?

— Белмим.

— Ни беләсең соң син?

— Синең бай икәнеңне, — дип, Сафа әлеге панбәрхетнең төйнәлешен чишә-чишә, почмагын почмакка аерып җәеп куйды да: — Бәхетле бул, — дип, һаман да шул гадәтенчә йомшак кына атлап, аш-су бүлмәсеннән үзенә таба чыгып китте.

Җәмилә:

— Сафа! — диде.

Ул әллә кайдан — өй түреннәнме, җаны чигеннәнме:

— Мин — юк, Җәмилә... ханым, — диде. — Мин хәерче бит.

Өстәлгә кайтарып салынган тузанлы панбәрхет тукымасының тискәрегә кытыршы өслегендәге эре асылташ, зур зөбәрҗәт ташлар кидертелгән ике балдак, тагын ни-нәрсәләрдер җемелдәшеп тора иде.

— Бу каян? — дип сорады Җәмилә.

— «Бандура»ның түбәсеннән, — диде Сафа.

Бүлмәдә әллә Җәмиләнең күз ялкыны, әллә тәрәзәдәге челтәр аша иңеп кергән кояш яктысы җем-җем итеп, салават күпередәй бер балкыш тора иде.

«Бандура» дип алар фатирында күченә-күченә ташланмыйча бишенче тапкырында да торган дәү борынгы бер имән шкафны атап йөртәләр иде.

Шкаф калды. Ә ул — «антиквар» Сафа чалбар кесәсендәге илле җиде кырлы итеп эшкәртелгән бер «пыяла» кисәген барлый-барлый балконда «Прима» сигаретын кабызып, төтенен төрек мөштеге аша җидеме, сигезме тапкыр әллә тартты, әллә өрде дә... инде бөтенләйгә чыгып китешли:

— Яхшы, — диде.

*2006, май*

## ТӘҢРЕ ЮЛЫНДА

Күңлем минем ябь-яшь калыр, һич картаймас;
Җаным көчле булып калыр, хәлдән таймас.

*Г.Тукай*

Дөньяда мондый тузан куелыгындагы зәһәр сүгенү сүзе дә булмас. Котылыр, чистарыр әмәл юк. Җәй ахыры белән көз башы коры килде. Гариза язып та сорап алалмассың. Туфракта дым заты калмады. Трактор тау кадәрле бәрәңге алу комбайнын көчәнүсез тарта. Буразналар асфальт юл белән урман арасындагы басуда өч чакрым буена сузылган. Башына чыгарга өлгергәнче, тын буыла башлый. Авызга каплаган респиратор тыгыла, сөзмәсе туфрак кисәгенә әйләнә. Кая инде аны алыштырып тору! Салып ташлап, авызны яулык белән каплыйсың да барасың. Сулыш алуы тагын авырга килә башлагач, аны авыштырасың гына. Көн ахырына ике яулык җитми. Эш азагына таба бернәрсәсез дә түзәсең. Тамак төбе әчетергә тотына. Төкергәнең төкерек түгел инде, ә пычрак кына. Куе тузан борынны томалый, аңкау төбен кыра, үпкәне гыжлата. Ирен кибә, тешләр шыгырдый. Җитмәсә көн эссе, тирләтә, тән кычыта...

Ә бәрәңге басуының теге ягында — урман. Буразналар очындагы такыр юлдан чирек чакрым араны җәяүләп үтсәң, шунда җитүең ихтимал. Андагы өрәңге агачлары кайсысы сары, кайсысы алсу инде. Кеше аягы басмаган төшкә эләксәң, көрән чикләвекләр орыну белән кишәнкәләреннән коелырга торадыр. Быел чикләвек бик уңды бит.

Шул урман куелыгына уйламый-нитми генә кереп китәсе иде дә бит кана! Юк, колхоз бәрәңгесен аласы бар. Кендегең белән эшләп торган, ял бирмәс комбайнга береккәнсең. Син тузанга тереләй — ләхетсез, догасыз күмелгән шикелле.

Урманга ара-тирә йөрүчеләр бар. Читтән дә киләләр. Авылныкылар да, шәһәрнекеләр дә йә чикләвеген, йә гөмбәсен җыеп китә. Кем кайсысына һәвәс инде. Шәһәрчә киенгән бер ир-ат дүрт тапкыр күзгә чалынды. Иртәнге уннарда Казан автобусыннан төшеп, кара күзлеген кигән килеш уза да кичкырын урманнан дыңгычлап тутырылган рюкзак авырлыгыннан бөкрәеп чыга. Кичә бәрәңге дә сорап алды әле. Алдына асып, чикләвек җыя торган капчыгына салып китте. Уртача гына буйлы, төз, җиңелчә гәүдәле кеше. Сөйләшкәндә елмаеп кына эндәшә. Ирене, чиста итеп кырынган бите, пөхтә мыегы, яңак чокыры елмая, ә кү-

зе ничектер моңсу, уйлы кала. Кемлеген белгән юк, Алла белсен. Елдагы ялын чикләвек, гөмбә җыеп үткәрә, күрәсең.

...Быел яз иртә килде, бәрәңге дә алдан өлгерде. Хәер, сорты да шундый. Бер йөк машинасы, бер арбалы трактор ташып кына тора. Комбайннан бушаталар да озаталар, бушаталар да озаталар. Кая? Билгесез. Синнән сорап торалармыни аны. Тузаны гына болыт булып күтәрелә дә тәнгә йогылмый калганы яңадан басуга таралып куна. Күпмедер туфрак бәрәңгегә ияреп китә, бер өлеше мунчада юыла. Күрәсең, фәкать су гына ага дип ялгышалардыр ул. Туфрак та гел хәрәкәттә, урыннан урынга күчеп йөри булса кирәк. Адәм балалары да шундый инде: башта җирнең өстендә йөри, аннары астына кереп ята. Ире Рөстәмнең вафат булуына да икенче ел китте инде әнә...

И Тәңре! Үз кодрәтең белән тәнгә иңдергән мәдәттән аер, баштан ни бар зиһенне ал. Тик бер сайлаган көмешеңне, шул көмешең назы дөньяга китергән җимешеңне тартып алма икән син. Йә суга сал, йә утка як. Ләкин мине тиңсез иткәнеңә мәңге риза-бәхил түгел икәнемне белеп тор. Моны ялгыз мендәремә сеңгән тозлы күз яшьләремнән сорама, ә тәннәремнән тормыш тузаннарын юып төшергән чагымда салкын мунчаларга кереп кара.

Шулай да ахирәттәге җәннәткә әйләнеп кайтуга караганда фани дөнья тәмугында гомер кичерү артыграк әле. Моның өчен мине гөнаһлы бәндәләреңнән санама син, Тәңрем, яме? Моны синнән бил бөгеп үтенмим, ә бәлки сынымны туры тотып таләп итәм.

Әнә, якты кояш астындагы сарылы-яшелле урманда чикләвек тә өлгереп җитте инде. Ә мин, шул чикләвекләрнең берәрсе эчендә кыштыр-кыштыр килеп таза төш кимергәннән соң аны ташлап качкан ялгыз корт шикелле, тузан эченнән аерылып чыгам да урманга илтүче такыр юлга төшәм әле. Бирәм дигән колына чыгарып куяр юлына дигәндәй, бәрәңге алу комбайны ватылып китте әле менәтерә. Әллә нидә безгә дә урман һавасы сулавы язык түгел ул.

— Кая кузгалдың әле, Кадрия?

— Урманга, Халидә апа, урманга. Әйдә син дә.

* * *

— Быел бигрәкләр дә күп инде, — диде хатын. — Хәйран-тамаша!

— Күп кенәме соң? Җыбыр көтүе булып басканнар.

Хатын аптырап аңа карады да бераз уйлап торгач:

— Нәрсәне әйтәсең әле? — дип сорады.

— Ә син коңгызлар турында түгелмени?

Ягъфәр такыр юлдагы бәрәңгене сарып алган колорадо коңгызларыннан карашын аерды да янындагы хатынга карады. Ә ул, башын артка ташлап һәм чак кына янтайтып, йөзен кояшка каршы куйган. Аның карашын сизеп булса кирәк, хатын тузанлы кара халат якасына шуып төшкән яулык чите белән муенын ышкып алды.

— Мин пәрәвезләрне әйтәм әле, — диде хатын, үз соравына үзе үк җавап биреп. — Бакчи, очалар.

Ягъфәр карашын зәңгәр күк тарафына күчерде. Дөрестән дә, зәңгәр күкне тутырып, әллә кайлардан әллә кайларга таба пәрәвезләр оча иде. Ул быел беренче мәртәбә: «Инде тагын көзләр килеп җиткән икән», — дип уйлады. Имән агачлары, чикләвек куакларының яфраклары яшел әле яшелгә. Ә юкәләр шактый саргайган инде. Өрәңге яфраклары да йөкле хатыннарның йөзләренә яисә карт-корының кул аркасына кунган тапларны хәтерләтеп чуарланган.

— Пәрәвезләр күп икән шул. Җил тымызык булса да, очалар, — диде Ягъфәр.

— Ерак китми алар, төшәләр. Күбрәге башка куна да бөтенләйгә шунда кала.

Ягъфәр аның үреп, баш артына толымлап төйнәгән чәченә күз төшергәнче, хатын зәңгәр яулыгын ябарга өлгерде һәм сүзен бүтәнгә борды:

— Без ул коңгызларга күнегеп беттек инде. Абайламыйбыз. Хәзер ис тә китми.

— Тузан яманрактыр, әйеме?

— Сезне дә ашатырга кирәк ич.

— Кичә биреп җибәргән бәрәңгең чыннан да тәмле булды. Ярмалы икән.

— Кырныкы булганга инде.

Ягъфәр тагын сыңар бәрәңгегә әйләнеп карады. Бәрәңге диярлеге калмаган да инде. Инә төртерлек урыны юк. Коңгызларның тагын берәрсе үрмәләп менсә, үз ишләрен читкә кысрыкларлык түгел. Шуңадырмы калганнары юл буенча ары үрмәлиләр. Җилгә, пәрәвезләр очышына каршы якка. Кая юл тотканнарын чамалапмы, чамаламыйчамы...

...Ул машинадан сикереп төште дә, бүрек колакчынын төшереп, тасмасын ияк астына бәйли-бәйли алга китте. Юлны төньякка таба бер-бер артлы тезелешеп торучы техника тутырган. Аның гөрелтесе бозланып каткан, кар күмгән асфальтны гына түгел, сул яктагы текә таш кыяны, уң яктагы тирән упкын төбен дә дерелдәтә, калтырата шикелле. Тәртипсез искән җил ургымнары җәяүле буранны югары күтәрә, көрт дулкыннарыннан себереп алып, туфрак, төтен һәм сөрем белән куша да йөзгә китереп бәрә, тау сыртына, тырпаешкан таш кантарларына сылый, салкын, дөньяга битараф тоелган кояшны томалап-томалап ала иде. Тынчу, сулап булмый. Броняларга уч-уч кар сибелеп, тимер авазы чыгара. Буып-буып алган сөремнән котылырга теләп, ул юлның әле бер, әле икенче ягына чыккалады. Анда-санда салкыннан бөрешкән солдат төркемнәре очрый. Җиң очыннан күшеккән бармакларын чыгарып, күгәренгән иреннәренә сигарет төртәләр.

Илленче застава турысында кар ташкыны төшеп, бер БТР* ны каплаганын рациядән хәбәр иткәннәр иде. Көтеп тору туйдыргач һәм суык үзәккә үтә башлагач, ул шунда атлады. Мең биш йөз метрлар чамасы баргач, тыгылган урынга якынайды. Юлны кардан чистартканнар, бронетранспортерны казып чыгарганнар икән инде. Эчендә калган өч кешене ничек кирәк алай җылыткач, Пули-Хумрига озатканнар. Килеп җитәрәк, ул чалкан яткан машинаны арттан БТР белән төрттереп, алдан МТЛБ* белән сөйрәтеп, көпчәкләренә бастырганнарын күрде. Казу эшен мегафоннан кычкыра-кычкыра бер өлкән лейтенант оештырып йөргән.

Упкын читендә өсте-өстенә ташланган ике резин көпчәк көйрәп яна иде. Аның тирәли эшсезлектән гаҗиз булып таптанган соляра** тезелешкән, бер-ике офицер да бар. Берсе дә таулар белән чикләнгән әйләнә-тирәне күзәтми. Барысы да диярлек утка текәлгәннәр, әйтерсең лә анда аларга ерактагы туган илнең таныш төсмерләре күренә, көткән туганнары чагыла.

Шунда ул үзенә кырын торган өлкән лейтенант Скворцовның озын буйлы таныш сынын абайлап алды. Ул бер аягына баскан килеш, икенчесен ялкынга тыккан. Итегенең калын табаныннан кар кисәге кубып төште, һавага чажлап бу күтәрелде. Янында бөрешкән рюкзак ята. Өлкән лейтенант чемодан яки фырт дипломатлар йөртергә яратмый иде. Ул, читтән эндәшергә кыймыйча, аның янына килеп басты.

Өлкән лейтенант, аның килеп басуын абайлап, чак кына читкәрәк тыйтаклады. Учак янында урын бирергә теләве инде.

— Лейтенант! — диде ул, аның үзенә борылып караганын күргәч. — Каян килеп чыктың?!

— Каян булсын инде... — дип, өлкән лейтенант моңсу гына елмаеп куйды. — Исәнмесез, иптәш майор!

Алар бер-берсенең кулын каты кысышып күрештеләр. Кочаклашмадылар яисә иңбашларына суккалашмадылар, фәкать күз карашлары гына очрашты, шуннан барысы да аңлашылды.

— Ялың ундүртенә*** кадәр ич әле синең!

— Ниемә миңа ул ял? — дип, Скворцов таптанып алды да утка икенче итеген тыкты. Ул киң учын бәсле һәм бозлы мыегына каплады да, эрегәнен көтмәстән, бозларын куптара башлады.

Учак тирәсендәгеләр тын гына сөйләшә иде. Көлешмиләр, чөнки җаннарын ни биләгәне анык: сугыштан чыгып баралар, юл авыр, озын, алда ни көткәне билгесез, Хикмәтияр кешеләренең тау араларында сагалап торулары ихтимал дигән хәбәр бар, һичкем бу сугышның соңгы корбаны булырга теләми иде. Шуңа күрә өлкән лейтенантның нигә дип киредә ашыкканы турында сүз озайтып тормадылар. Скворцовның хатыны яман бер гамәл кылды, ул инде иренең чекларына да, чүпрәк-чапрагына да мохтаҗ түгел. Әгәр дә өлкән лейтенант өенә акча сала икән, ул моны балалары хакына гына эшли, ә калганнарын, бүтәннәр шикелле, шул ук чүпрәк-чапрак, теге-бу чит ил әйберләре җыюга тотмый, частьтагы комсыз хатын-кызга да туздырмый, җае чыкканда аракы, шәрабка гына ычкындыра.

Шуңа күрә майор, сүзне башкага борырга теләп:

— Мин кар ишелгән җиргә бармакчы идем, — диде.

— Хаҗәте юк инде. Хәзер кузгалырбыз, шәт, — диде Скворцов.

Алар тәмәке кабыздылар да, юлны аркылы чыгып, кыяга ышыкландылар. Өлкән лейтенант рюкзагын битараф төстә пычрак карга ташлады.

— Эх, Скворцов! Ундүрт тәүлек, шайтан алгыры... Юкка кабалангансың. Взводың — Аллага шөкер... Термезда гына көтеп торсаң ни була иде?

— Син башта «ике йөзне»* кайтарып кара, майор... Таптың да соң кешесен!

— Боерык, лейтенант... — диде майор, суыктан һәм сөремнән карлыккан тавыш белән. Шуңа тагын сугыш беткәндә генә үз батальонында шундый хәл килеп чыгуга көенү, борчылу, кайгыру ачысы да өстәлгәндер инде. — Ничек соң?

— Тиешенчә, — диде өлкән лейтенант. — Район хәрби комиссарына үлгәнлеге хакындагы таныклыкны бирдем, акча компенсациясе белешмәсен суздым, ябылган хәрби билетын тоттырдым. Сержантның дипломатын аңа күрсәтмәдем. Чит кеше үлемендә түгел, үз тормышларында актарынсыннар. Анасына тапшырдым.

— Дөрес иткәнсең, — диде майор. — Шуннан?

— Шуннан... Табутны автобуста авылга алып кайттык. Халык җыелды. Анасы миңа ташланды. Кулында — чалгы. Прапорщикка рукопашный кулланырга туры килде... Әфганча ипи-тозлык чамаласам да, татарча ни бум-бум бит инде, ни кычкыргандыр, аңламадым. Комиссар әйтеп бирде: безне козгыннар дип атаган. Әйтерсең лә Искәндәр Газизҗановны мин үтергән йә минем аркада...

— Мин саклый алмадым аны... Аның авылы минекеннән биш кенә чакрымда, урман аша гына...

— Әйтмәдең бит, иптәш майор. Сәлам әйтеп кенә булса да сугылыр идем. Бәлки, кемеңдер калгандыр әле анда.

— Беркем юк инде... Ә эти белән әнине беләсең: алар белән сержант Газизҗанов арасында шул ук биш мең метр ара. Тик урман аша түгел инде. Җир астыннан санаганда...

Сүзсез басып тордылар. Алда двигательләр гөрелтесе көчәйде. БТРны көпчәкләренә бастыргач, йә кабызып җибәргәннәр, йә өстерәтеп китәргә булганнар. Боерыклар яңгырады, юлдагы кешеләр машиналарына таралышты, колонна кузгалды.

— Ә мин Газизҗановка соңгы игелегемне кыла алдым, иптәш майор.

Майор тизлеген арттыра барган колоннадан карашын алды да, үлгәннәргә нинди игелек кыласың инде дигәндәй, өлкән лейтенантка күтәрелеп карады.

Өлкән лейтенант сүзен:

— Дөресрәге, анасына, — дип төзәтте. — Кабул Игосыннан* «ике йөзенче»мне кабул итеп алгач, без аның цинк табутына тәрәзә уйдык. Искәндәрнең карарлыгы калган иде ич әле... Ну, бер күзе юк — күз кабагын тарттырып тектердек. Ике аягы юк — агач табып, ботинкасын кактык та балагына тыктык... Безне Алла үзе генә хөкем итә ала... Баш мие юк — бушлыгын дүрт «Правда» газетасын йомарлап тутырдык. Укып ятсын бу дөньяның хакыйкатен... Кулының кайбер бармаклары юк — аларын шул килеш калдырдык инде. Бармаклар гына бәла түгел. Дөресрәге, әнкәсе соңгы тапкыр улына карап калганда бармак кына нәрсә ул?

Ышкылып диярлек яннарыннан узган бер БМП аларга кар, вак таш чәчрәтеп китте. Майор аның артыннан йодрык болгап калды, чак кына сүгенмәде.

— Менә шул... цинкны эретеп ябыштырдык. Су да үтмәслек булды. Тәрти-и-ип... Россия күмә белә. Күнеккән. Тудыруны гына онытып бара. Россиядә кеше гомеренең озынлыгы сугыш-чират-зират арасы кадәрле генә.

— Бусын арттырыбрак җибәрмисеңме, лейтенант?

— Бездә тизәге дә аз түгел.

— Аны без генә чистартып бетерә алмыйбыз инде.

— Ә мин азрак чистарттым әле! — диде өлкән лейтенант, тавышын күтәреп. — Анда хәрби комиссар мәет исе килеп торган комедия ясап маташмакчы булды. Режиссер!.. Сержантның пирамидасына «Погиб за Родину в РА»** дип яздырган. Ватан өчен, ә үзе эр-ада?! Ватан өчен ниндидер нәм-нәм кабиләсендә һәлак булды дигән шикелле... Кырып аттым. Күзгә төтен җибәреп тормасын.

— Бусы хак, лейтенант, — дип килеште майор. Ул узган машиналарны ерактан чамалап күзәтеп тора иде. Менә ул җанланып китте, БТР капкачыннан башын чыгарып килгән сержантка туктарга кушып кул изәде. Машина, тизлеген арттыра төшеп, упкын ягына янтайды да, көйрәп торган көпчәкләрне сытып үткәннән соң, аларны тәтенәнә күмеп туктады. — Чумдык, лейтенант! — диде ул һәм, юлны йөгереп аркылы чыккач, артына борылып карады, үз янына килеп баскан лейтенантның кулында рюкзагын күрмәгәч: «Рюкзагыңны онытткансың ич!» — диде.

— Ярарсана! — дип кул изәде лейтенант. — Анда җыен калдык-постык кына. Бүтән кирәге чыга гына күрмәсен... Миңа үземнекеләр кирәк иде бит, иптәш майор!

— Ярәшкән кызларың түгел, түзәрсең, — диде майор, машинага үрмәләп. — Өч сәгатьтән — тукталыш.

— Нихәл, егетләр! — дип исәнләште Скворцов, эчкә кергәч.

Аңа бердәм җавап бирделәр. Урак кебек бөкрәеп утырган солдатлар командирлары кергәч җанланып киттеләр.

— Ә шулай да мин сине Термезда кайбер нигъмәт белән көтәрсең дип уйлаган идем, — диде майор. Ул үзенең чемоданын алып, чехоллы фляжка чыгарды да селеккәләп карады. — Минем монда төбендә генә калды инде.

— Термезда прапорщик Василько көтсен! — диде лейтенант. — Ә чемоданың буш, иптәш майор. Хатының чүпрәк-чапраксыз өеңә кертерме соң?

Майор, ачуы чыкканын яшермичә, солдатлар алдында килештермәсә дә:

— Тансыграгы — үзем белән. Шул җиткән... Кружка, геноцвале! — дип боерды майор янындагы грузин егетенә. — Ну, кайтуың белән котлыйм, лейтенант! Безнең чыгып барыш, ә син тәмугка кире әйләнеп килгәнсең. Әйтерсең лә берәр ханымың елап көткән!

— Елап калган бер ханымны күрдем инде, иптәш майор. Җитәр!.. Бәлки, мин елмаеп көткән хатыннарның берсе булса да артсын өчен кайтканмындыр. Чөнки боларның... — дип, өлкән лейтенант машинада автоматларын бот араларына кыстырып барган солдатларга ишарәләде. — Боларның аналарыннан берсе дә Әфганда үтерелгән соңгы совет солдатларының анасы булырга теләми...

Скворцов, йөзен читкәрәк бора төшеп, аракы эчеп җибәрде һәм мыегын бушлат җиңе белән сөртеп алды. Әллә ачык люктан килеп кергән кар көрпәләреннән, әллә тәмәке төтененнән читләшеп, ул үчын күз тирәсендә дә йөртеп куйды. Юк, күз яшен сөртмәде ул, моны майор яхшы белә. Лейтенантлар сугышта еламый. Алар сугышта йә тере калалар, йә үтерелеп кайталар. Бары шул гына.

Бер генә мәлгә күмеп ташлаган истәлекләреннән арынып һәм сүзсез утыруны килештермичә, Ягъфәр хатыннан:

— Исемең ничек? — дип сорады.

— Кадрия...

— Ә-ә-ә...

— Кичә җыйганың ничә стакан булды соң?

— Кем белә инде аны? Бөрчемәгән әле. Таратылган килеш ята.

— Бүген җыйганың... илле стакан чамасы булыр.

— Авыз ит. Тешең үтсә инде.

— Ялгыз хатынга чикләвек вату гына нәрсә ул? Аның теше таудай хәсрәткә дә яхшы үтә.

Ягъфәр теленә искәрмәстән килгән беренче сүзне әйтеп ычкындырды:

— Аерылдыгызмыни?

Һәм шундук хатынның иренен чак чалышайтып кына елмайгандай йөзен күреп, ялгышканын аңлады. Дөрестән дә, хатын-кызның ялгызлыгына ире белән аерылышу гына сәбәп була аламыни? Саный китсәң, моның мең сәбәбе бар ич инде. Бөтен кешенең дә яратуы, гомере тиң түгел шул.

Хатын, аның бу уен җөпләгәндәй тыныч кына:

— Үлде ул, — диде. — Комбайнчы иде. Салам чүмәләсенә күмелеп йоклаган җиреннән машина таптады. Ике елдан артык инде. Таптаткан кешесе гел төрмәдә утыра әле. Гомерем беткәнче гаепле дип язган хатын алдым. Аның ни гаебе булсын?..

— Эчә идеме әллә?

— Улыбызны армиягә алып, Әфган сугышына керттеләр...

Ягъфәрнең күңеленә шом йөгерде. Таш арасында үзенә төбәлгән зәһәр елан башын күрдемени! Хатынның сүзләре аңа таба очкан яктырткыч ядрәләр сызгыруыдай тоелды.

— Өйнең нуры качты, — дип дәвам итте хатын. — Ашаган — аш, эчкән су булмады. Мин үзем түзалганчы тешемне кысып чыдадым инде. Аллаһы Тәгалә сабыр булырга кушкан бит. Хатын-кыз үз башына төшкәнне мең ел да күтәрә ала. Ә ирем куркуын аракы белән басмакчы булды...

— Ә улың... кайткандыр ич?

Хатын йөзен аның тарафына борды. Тик күз карашы ары юнәлде, әллә нинди ераклыкларга китеп барды. Ул капшанып үлән өзеп алды да, сабагын чистарткандай, ике бармак бите арасыннан шудырып чыгаргач, аны кипшегән иренենә кабып кысты. Авызыннанмы, җаныннанмы өзелергә торган сүзләрен бикләп куйды шикелле. Шулай дәшмәскә кирәк булганда яисә эчтәге уйны сүзгә әйләндерер алдыннан, ир-ат сигарет йә папирос кабып кабызыр иде. Хатын-кыз үз-үзен күбрәк эчтән кабыза. Шуңа күрә тыштан көя дә.

— Кайтардылар аны... И-и, кайтарыплар да күрсәттеләр соң, әй?! — диде хатын, тын гына. Ягьфәр аның коңгырт-кара күзе коры икәнлеген шәйләде. — Сөйләпләр генә дә бетермәле түгел... Каян башласаң да, очы-кырые юк. Бу сугыш бетәргә егерме көн калганда үлгәнлегенә телеграмма килде. Шуннан озак тотмадылар... кайтарып киттеләр. Үзен табутының тәрәзәсеннән генә күрдек. Табутын бер старший лейтенант белән прапорщик кайтарды. Күтәреп караган идем, сиздем: улыбызның ике аягы да юк. Табутының аяк очы кош каурые авырлыгында гына. Ир-ат та шулай диде... Кулбашы буш, кул бармаклары кайсы бар, кайсы юк, бер күзе юк, баш мие юк, дип, үзләре үк әйтте. Фәкать солдат формасы эчендә аз гына нәрсә... Җирләп киттеләр... Икенче көнне улымның тиздән кайтабыз дигән хаты килеп төште... Үтергәннәренә сигезенче ай китте. Сигез минут түгел, сигез секунд та истән чыкмый. Суга төшкән инә күк кенә югалды... Иптәшләрен күрсәм, йөрәгемнең кайнар сулышын сизмәсеннәр дип, авызымны тоткан булам. Ә ул әчетеп борыннан чыга... Эх, исән, бик еракта дисәләр, янына егерме ел җәяү барыр идем. Улымның алтмыш хатын саклыйм, кат-кат укыйм. Улкаем, балакаем, дим... Безнең генә балакаебызны үтереп кайтардылар. Ялгышмы, язмышмы — белгән юк. Анда начальникларның балалары бармады бит...

Тарау күз карашын җыеп, хатын Ягъфәргә карады да, кемнеңдер битенә төбәгәндәй, иренендәге инде чәйнәлеп беткән үлән сабагын читкә төкерде.

Ягъфәр өнсез калды. Каршысындагы киң дөнья каядыр чигенде. Кул сәгатенең тавышы ишетелде. Әйтерсең лә бу вакыт агышы түгел, ә шушы дөньяны менә-менә чәлпәрәмә китереп ватачак мина эчендәге сәгать авазы иде. Дөнья шартлар, аның урынына тирән кара чокыр гына калыр кебек. Ул чокыр төтенләп торырмы яки ул сасы су белән туларлмы, әллә анда Кадриянең күзендәге шикелле сагышлы кояш чагылырмы? Ә тирәсендә бу хатын табут «тәрәзәсеннән» күрми калган ике аяк, кул бармаклары, корымлы бер күз, ком-таш белән кушылган бер уч ми, кара ялкын, кызыл төтен булып күккә ашкан кан чәчелеп ятар микән?.. Бер якта ул — Ягъфәр, каршы якта маңгай җыерчыкларына, күз тирәсендәге сырларына, борын яфракларына тузан утырган, шул мина шартлавы күккә чөеп, шушы чуар урман авызындагы яшел үләнлеккә китереп ташлаган җир түмгәген хәтерләтүче Кадрия басып торыр кебек иде.

— Менә шул, — дип йомгаклады үзенең сүзен Кадрия. Кичке кояш яктырткан йөзе сүрелгән, корымланып калган балавыз шәмне хәтерләтә иде.

— Да. Искәндәр, — диде Ягъфәр, читкә карап.

— Нәрсә? Кем дидең?.. Искәндәр шул... Искәндәр — минем улым! Ә син каян белдең әле аны? Әйт, каян? Әллә... Әйт инде, әйт!

Кадриянең сүзләре буталды, чәбәләнде, тузгып-тузгып чыкты. Җаны нишләгәндер, билгесез, һәрхәлдә Ягъфәрнең күз алдына корсагыннан көрткә батып, анда-монда тарткаланган, авызлыгын чәйнәп пошкырынган зәгыйфь ат килгәндәй булды.

— Искәндәр... Шундый җыр бар ич: «Минем басып карый торган талларымны кискәннәр...» Ә синең талларыңны гына түгел, канатларыңны да кискәннәр... Шуны әйтмәкче идем. Бары шуны гына, — диде Ягъфәр. Әгәр бу минутта Искәндәрне белгәнен әйтсә, Кадриянең нишлисен кем белә? Шуңа күрә ул сүзен:
— Авыр сиңа, Кадрия, — дип тәмамлады.

— Үлгәч җиңеләер әле, — диде хатын, басыла төшеп.

...Громов* солдатлары, аның боерыгын үтәп, иптәшләренең һәлак булган урыннарына куелган истәлек һәйкәлләрен үзләре утырган машиналарга салып алып чыктылар. Югыйсә Әфган каршылык күрсәтүчеләре аларны мәсхәрәләве ихтимал иде. Җир туңган иде инде, пирамидаларны ташлы җирдән казып алуы мөмкин булмады. Шуңа күрә аларны БМПга иштереп яисә трос белән тарттырып суырырга туры килде. Шулай итеп, җиде пирамида җыйдылар.

Сержант Газизҗанов боерык бирелгәннән соң — истәлек һәйкәлләре кую тыелгач һәлак булды. Алай да ул шулай ук үзенең соңгы сулышы билгесенә ия иде. Аның исемен калай кисәгенә язып, шуны торбага эретеп ябыштырып утырткannar. Ныклык өчен торбаның башына аркылы-торкылы тимер ябыштырып, шактый тирән күмгән булганнар. Казып ала алмадылар. Шулай ук сөйрәтеп чыгардылар.

Гомумән, үлгән солдатның кабере, аның өстендә бер йолдызы, тәресе, ярымае бар яки берние юк.

## ВЕНСКИ ГАРМУН

Өйдән чыгу белән сулга каерылгач, рәшәткә буйлата тыкрыкка юнәләсең дә, буеннан-буена кырык сажинлап күтәрелгәннән соң, уңга борыласың, ары таба үрдән түбәнтен юнәлгәндә, һәрчак явызларча өреп каршылый, озата торган зәңгәр күзле кап-кара бер эткә янәшә илле-алтмыш адым баргач, сөзәк урыннарында үләнле, текә төшләрендә кат-кат ташлы, үзле кызыл балчыклы тирән ерганак төбендәге Шири чишмәсенә әйдәгән борылмалы-сыгылмалы сукмакка төшәсең. Анда да тагын бераз атлыйсы кала әле.

Кайтканда киресенчә инде. Исәпли калсаң, су юлың шактый хәйранга тарта.

Җәй көннәрендә иплелеккә болай ипле анысы. Менү-төшүләре тәнгә дә, җанга да рәхәт кенә. Кышлар җитеп, язлар да узып киткәндә генә читенрәк: аяк тирән карда йә хәтәр тала, сай ләмдә йә хәтмәле генә чалулый да куя шунда. Тик авырыксынмыйсың да, көрсенмисең дә. Су — изге нәрсә ул. Ә изге нияткә юл чыгулары һич кенә дә муеныңа камыт кию дә аның кисүе түгел инде.

Шәмсенур әүвәл кызчык чагында, ары таба кыз-кыркын булып җитешкәч, шуннан соң кеше кешесенә әйләнгәч, инде менә хәзер әби булгач та әлеге чишмә юлыннан җыенысы Кояшка менеп җитәрлек ара үткәндер инде. Сиксән җиде яшькә җитеп, шултиклем йөргәнсең икән, — шөкрана кыл да, Аллаһы Тәгалә үз мәдәтен бирсен дә рәхмәтеннән ташламасын диген инде.

И ул чишмә юлындагы бар хикмәтне исеңә төшерсәңме? Мең төшеңә дә сыймаслыктыр, билләһи газыйм. Әлеге хикмәтләр димәкне шушы тыкрыктан анда-санда үткән кешеләр язмышына кушып тапкырлаган шәттә иге-чиге фани дөньядан ашып, иңеңә көянтәләп салган чиләкләреңдәге мылкыган су шикелле, бакыйлык мичкәсен дә тутырырлыктыр ул. Ә бәлки чайпалганда тамган тамчылары челләдә һәммәбезне кинәндереп яуган тансык мул яңгырга да җитәрлек булырдыр иде.

Әйтик, теге зур сугыш ачылган хәбәр төш узгачыннан соң авылга килеп ирешелгән мәлдә Шәмсенурның әлеге дә баягы Шири чишмәсенә менеп барышы иде. (Алдагы көндә ир-ат чапкан печән пакусларын кызу-кызу әйләндергән чагында, тамагы чатнагач, яңа гына китерелгән агач кисмәктән ул чүмеч тутырып сап-салкын су эчкән дә, тәнгә тәне кызышканга күрә, эшкә бармаска рөхсәт алган иде.) Ян-яктан үрелгән чикләвек читәне башына җитәр-җитмәс төштә аның түбәннән күтәрелүен шәйләп, матур, мул йөзен тамчы-тамчы тир баскан ире Котдус көтеп торган икән. Атау болыны печәнен чапкан җиреннән арыш басуын атлый-йөгерә турылата үтеп, тыкрык башына төшкән.

Түбән оч та, Югары баш та буп-буш, бөтен дөнья тып-тыныч иде. Тик имән казык башларына өч кара карга кунган да эссегә күрә ачкан кып-кызыл авызларын күрсәтеп торалар.

— Сугыш ачылган, — диде Котдус.

— Әйткәниең, — диде Шәмсенур.

— Нәрсәне?

— Ачыласын.

— Мөгаен дип кенә бардым ич.

— Синең мөгаенеңнең тәгаен чыкмаганы булмады.

— Шәмсенур, чиләк-көянтәңне куеп тор әле.

— Су алып меним инде, Котдус.

— Өлгерерсең.

Әллә кайда гармун уйный башлавын шул чакта читән шыгырдавы басты.

Хәзер исә Шәмсенурның киез итеге табаны кичә кичтән тотынып, бүген дә ябалак-ябалак явып торган калын карны гына шыгырдата.

Теге әллә кайчангы вакытны казык белән казык арасыннан рәшәле Үр тугаенда уйдык-уйдык үскән аклы-сарылы ромашкаларның бер көйгә салмакланып, әллә тәмле тибрәлгәннәре, әллә күзне тозлы яшь томалагандагыча эреп-эреп алулары гына калды.

Җәй көне арканланган чуар бозаулар арасында ул чәчәкләр хәзер дә шунда көрт-көрт агарып үсә дә үсә әле.

Кышларын исә, атлаган саен шыгырт-шыгырт килеп, искә төшкәлиләр дә төшкәлиләр.

Мунча кергән саен, тәннең мәңгегә тыгыз калган төшләре кайчакларны шулай шыгырдап аптыраткалый. Инде ул урыннар берни түгел. Хәтер генә.

Фәкать.

Җидешәр чүмеч су сыешлы калай чиләкләрен инде сырына җитәр-җитмәс кенә тутырып, сыгылмалы, зәңгәр төсе уңган, ак тимер элмәкләре өзелеп төшәр дәрәҗә кыршылып, ашалып беткән көянтәсенә аскан килеш бу таң тәмам аткан чакта карга иң беренче булып салган эзләренә тап-таман гына итеп баса-баса тыкрык очыннан уңга борылып, үзенең капка төбенә җиткәч, Шәмсенур пөхтә көрәп куелган арага керде дә:

— Тагын синмени, Җәүдәт? — диде.

Ишегалдыннан:

— Бүтән кем булсын?! — дигәннән таныды. Әйе, башка беркем дә түгел — шул инде.

Аның үз улын, шушы туган авылына да апкайтып тормастан, Мәскәүдә генә гүргә иңдерделәр. Әллә кемнәргә бик кирәкле бер-бер гамәл кылгандыр инде, күрәмсең. Аның белән су коенышып, урып-җыелган басуларда калган борчак кузакларын утта куырып ашаган, кәҗә бәтиләре белән бер сәкедә кочаклашып яткан, инештә тоткан балыкларын күз бизмәнендә бер-берсен үпкәләттермәслек итеп, үзара тип-тигез бүлешкән, кайсысы гармунда уйнап, кайсысы кушылып җырлаган, кызлар өчен кансыз-нисез генә сугышкалаган, тагын әллә, тагын әллә нишләшкән иптәшләреннән бусы атаклы тракторчы, тегесе әйбәт укытучы, монаусы данлы сыер савучы, анаусы сабан туйлары саен сарык тәкәседер, машиналар алучы — и-и, санап бетерерлекмени соң? — булгач, хөкүмәттән кисә-кисә пенсия алып, оныкларын кинәндереп торалар. Ә моңа җәһәннәмдәге тау-таш арасында ни калган булгандыр инде.

Алла белсен.

Аңа килене Талиянең, оныкларының дуллырлары кирәкмәс. Ак мәчесе, җиде тавыгы, бер әтәче, өстәп, мул сөтле кәҗәсе бик җиткән. Һәркайсы мллийүнгә торырлык.

Аңа улыннан калган әллә ниләр биреп бетермәкчеләр иде. Гармунын гына алып калды.

Әйе.

«Бүтән кем булсын?!» — дигәнгә ул шушылар сәбәпле әллә нишләпләр китте дә инде.

Ә бер чыдамады бит әле. Ялына-ялына кыстый, үгетли торгач, килене Талия белән оныкларына ияреп, диңгезгә тиклем барырга җөрьәт иткән иде. Анда шушы Шири чишмәсе төшләренә кәрә-кәрә йөдәтеп бетерде.

Ул көянтәсен тигез, такыр көрәлгән киң сукмакка буйлый борды да кырыеннан суы чайпалганда боз сөңгеләре матурлаган чиләкләрен куеп торырга ниятләгәндә җиңеләеп китте: кулларын киң җәеп, йөген Җәүдәт тотып өлгергән икән.

— Күпме әйттем, Шәмсенур әби: чykканда капка элмәгеңне булса да келәгә кайтарып сал инде, ичмаса.

— Минем җиде тавыгым да бер әтәчем белән ялгыз кәҗәмә кем кызыксын?

— Мин, — диде Җәүдәт.

— Әйтәм җирле атаң-әнкәңнән урлап әле бодай, әле печән керткәлисең.

— Урлап түгел.

— Алайса яшереп.

— Түгел. Алар белә. Син генә белмисең ул.

Шәмсенур сарык йонынннан көз көне үзе бәйләгән бияләйләрен салды да чиләкләренең тоткасына үрелергә иелде.

— Үзем, — диде Җәүдәт.

— Ярый алайсаң, — дип, Шәмсенур бая кар өеменә кадап куйган көянтәсен алды. Өйгә кергәч: — Нәрсәне белмим? — дип сорады.

— Бүгенгә анау гармуныгызны биреп тор әле, — диде Җәүдәт.

— Уйнамый ич ул. Ватык.

— Төзәттем, — диде Җәүдәт.

— Кайчан?

— Син өйдә югында чакларда.

— Хәзер мин өйдән сирәк чыгам ич, олан.

— Миңа шул җитә.

— Нәрсәгә?

— Төзәтергә дә, уйнап карарга да. Ул гармун көмеш телле. Тавышы әйбәт.

— Синең үз баяның бар лабаса.

— Моңа җитми.

— Нәрсәсе?

— Бу — венски. Баягынак белмисең дип шуны әйткән идем.

— Ә син каян килеп белешле?

— Аның җиз бакалы сул ягындагы тире каеш артына... кояшка каратылган лупа уты белән... так точно!.. Лупа белән... латин хәрефләрендә «L-nt Kotdus. Vena» дип язылган. Аны... Котдус абыйны, дим... шул Венаны да үткәч, Прагада ниткәннәр... күмгәннәр ич.

Шәмсенур аны:

— Җирләгәннәр, — дип төзәтте.

— Аннары ул гармунны командиры сиңа җибәргән.

— Түгел, — диде Шәмсенур. — Инде — түгел. Инде сиңа, улым. Ә! Уйнап бирмисеңме соң?

— Туй җитсен инде.

Җылы ис бөркелеп торган сарайдагы кәҗәсенә кичке ризык биреп, аны савып, аннары — күпме вакыт үткәндер, ул сәгатькә күптән карамый инде— айлы ишегалдына чыккан Шәмсенур тыкрыкка каршы сузылган үз урамнары ягыннан көчәя торып ишетелгән үтә дә таныш гармун авазына сагайган, гаҗәпләнгән, тыенкы шатланган, дәртле куанган килеш: «Җәүдәт», — дип уйлады.

Бүген ул йокларга ятмыйча торган иде әле. Яңа елга керәсе соңгы төн ич. Нәрсәдер көтелгән, ә ул нәрсәдер дигәне, ниһаять, килер шикелле. Ул, җылы киенеп, олтанлы киез итегенең карны шыгырдатуын көчкә тыя-тыя, капка төбенә чыгып баскан иде.

Үз турысындагы рәшәткәнең тыкрыкка терәлгән ягыннан Җәүдәтнең:

— Нигә йокламыйсың, Шәмсенур әби? — дип эндәшкәнен ишеткәч, ул тын гына:

— Бәйрәм итеп йөрисеңмени? — дип сорады.

— Мин түгел.

— Кем?

— Без идек әле.

— Иптәш егетең дә бармыни?

— Түгел.

— Алайса монда таба да килегез инде — күрим.

Якынайдылар, килделәр. Матур бүрек, тун кигәне, күкрәгенә гармун асканы Җәүдәт инде. Ә бусын — кәҗә мамыгыннан бәйләнгән шәленә күперенке кар ятканын — Күке Хәбибрахманының кызын ничек танымаска ди инде? Шулай да ул:

— Синме соң, Зөбәрҗәт? — дигән булды.

Зөбәрҗәт, йомшак кына итеп:

— Без, — диде.

— Аерылмыйсызмыни әле? Яңа елны атаң-әнкәңнәр белән каршылау яхшы.

— Шулай ниятләдек әле, — диде Җәүдәт. — Бүген Зөбәрҗәтнең яңа әти-әнисе була дип торадырыек.

— Ел белән ел арасы түгел ич — ата-ананың искесе-яңасы булмый.

Шәмсенур Зөбәрҗәтнең чак кына моңсу елмаеп куюын шәйләп алды: ул, түбән карап, уң аягы белән яңа карга арлы-бирле дугалар сызгалады да, аскы иренен өстәгесе белән япкандай итеп, әллә кая — моннан ерак-еракларга карап торды. Шулай уйлануы инде. Моның ни икәнлеген Шәмсенур әйбәт белә. Шуңа күрә, аның уен таратырга теләп, ул тиз-тиз генә Җәүдәткә:

— Бу суыкта гармун уйнап, бармакларың туңмыймы соң? — дигән булды.

— Уйнамаганда туңа, уйнаганда туңмый, — диде Җәүдәт.

— Ә сиңа киләсе язда армиягә китәсе бит әле, — диде Шәмсенур.

Зөбәрҗәт:

— Китәсе, — дип җөпләде.

— Көтәсе дә, — диде Шәмсенур. — Иң яманы шул инде аның — көтүләре.

Җәүдәт кинәт ярсу кыяфәттә:

— Ә син үзең, үзең? Үзең ничә ел көттең? Ә? Ә? — диде дә кинәт тынды.

— Менәтерә шул шул. Безнең шушы тыкрыктагы читән соңгы тапкыр бер шыгырдап куйганнан бирле.

— Ә мин әйләнеп кайткач, такта коймаңны авыштырсак... әрләмәссең микән? — диде Җәүдәт

— Карарсыз тагын. Барыбер үзеңә турылыйсы булыр.

...Шәмсенурның җиз тәлинкәле дәү сәгате йөрүдән туктаганга, үзе белгәненчә, мең елдыр инде. Аңа сәгатьнең кирәге дә юк: вакыт агышын ул үз йөрәге тибешеннән төп-төгәл санап бара. Ничектер берчакны — зират каеннарының аскы чукларындагы кайбер яфракларына сары төс куна башлаганда шуның тузанын юеш чүпрәкләп сөртергә тотынган иде. Ни хикмәт диген: келт-келт иттереп йөрде дә китте. Тәрәзәсенә күз салса, «аһ!» дип, тирән бер тын алып куйды: ул зиратка таба көрәкләрен кайсысы кулына тоткан, кайсысы иңенә салган ир-ат барганын күреп алды. Ишеткән, белгән иде инде: Җәүдәтне кайтарганнар. Ул анда бармады. Хатын-кызга зиратка керергә кушылмаган. Еш барсаң, керсәң, адәми затны зират туфрагы үзенә тарта башлый, диләр.

Командиры Җәүдәтнең көмеш телле теге венски гармунын тыкрык аша гына торучы күрше Зөбәрҗәткә тапшырып киткәнен белгәч, Шәмсенурның йөрәге чәнчеп-чәнчеп алды.

Уникешәр чүмеч су сыешлы, тирәли боз сөңгечекләре тезелешкән мөлдерәмә тулы ике чиләген көянтәсез-нисез генә күтәргән килеш эңгер-меңгердән узып, җиһанга караңгылык иңгән мәлдә кышкы тап-такыр тыкрык башыннан сулга борылып, кайнатасы белән кайнанасы — инде үзенең дә, карынындагы көтәсенең дә — йортының капка төбенә таба борылганда Зөбәрҗәт кулына ак калайлы киң көрәк тоткан күрше егетенә:

— Синмени, Исмәгыйль? — диде.

— Зөбәрҗәт апа, Җәүдәт абыйның теге венски гармунын биреп тормассың микән? — диде Исмәгыйль.

Зөбәрҗәт әллә моңсу, әллә кырыс төстә:

— Үзең кер дә ал, — диде. — Тик әйләнеп кайтасы, яме?

— Йә.

*2004 ел, 28 декабрь*

## ЯРА

Сулар ага. Тын инештәй тигез генә тормыш ага.

Тормыш елгалары шаулап ага...

Дулкыннар өстендәге саллар сыман, без дә зәңгәрсу ераклыкларга таба йөзәбез. Тик нигә соң кеше дигәнең ераграк киткән саен каерылып үткән юлына карый? Тик нигә соң әле, ярты юлны узмасам да, минем күз, вакыт томаны аша, юл башыма төбәлә?

Мин хәтерлим...

Йөрәк ярсып-ярсып тибә. Әйтерсең мин тугайларда яланаяк таң каршылыйм. Әйтерсең мин рәнҗүләрдән сыкрый-сыкрый шул тугайның чыклы үләненә ятып елыйм. Әйтерсең мин сөйгәнем белән очрашам.

Әйтерсең мин, авылыма кайтам да яңа, әмма бик тә таныш дөнья шаукымында кайныйм. Әйтерсең мин скрипканың үкенеч-көенеч белән тулы моңында тәэсирләнеп уйга батам.

Мин хәтерлим...

Уйларым карлыгачлар кебек талпына да җилпенә, айкала да чайкала. Мин үземне давылга каршы очкан нәни карлыгач итеп тоям. Күңел тыныч та, тыныч түгел дә сыман. Уйларым — карлыгачлар...

## I

Бала чакта иң яраткан нәрсәм прәннек иде. Иллә ул миңа күп тәтемәде. Кулыма төшкән тәкъдирдә ул учымны рәхәт кытыклый, җылыта кебек тоела. Учымда кош баласыдай кадерләп йөрткәч, мин аны арыш ипие кыерчыгына кушып ашый торган идем. Дәү итеп ипи кабасың, кечкенә итеп — прәннек. Шулай итсәң, ул озакка җитә. Корылай ашаганда бер-ике кабасың да — вәссәлам. Ичмасам, авызны дәү итеп, иркенләп ачасың, күзне йомып рәхәтләнеп ашыйсың.

Әткәйдән тагын бер прәннек сорап алырга кыюлыгым җитми. Шуңа күрә, үз өлешемә шундук ябырылмыйча, абыйларым, энекәшләрем бетергәнен көтәм. Прәннекне аулакта ашавы аерата рәхәт. Әйтерсең бөтен авылда, бөтен дөньяда бары тик син генә прәннекле, син генә чиксез бәхетле.

Минем сабырлыгымны күрепме, әткәй кояшта агарган чәчемнән сыйпап, сүзсез генә иркәли иде. Иллә мәгәр прәннекне башкаларга караганда артыграк биргәнен хәтерләмим. Олыбызга-кечебезгә бер өләшкәндә төп-төгәл икешәр бәхет. Әти авыл халкына үтә гаделлеге белән билгеле иде. Күрәсең, прәннек өләшкәндә дә ул шулай гадел булып кала белгән. Бу яктан без рәнҗүнең, үпкәләүнең ни икәнен белмәдек.

Минем прәннек ашый торган аулак урыным бар иде. Ул — без чыбыркы бөгәлҗәсенә дип тал чыбыгы алып кайта торган буа уртасындагы утрау. Шунда күкрәккә җитеп үскән сусыл, салкынча кәлшәгә чалкан ятып, ләззәт дөньясына чумам. Берзаман, шул рәвешчә күземне зәңгәр күк гөмбәзенә төбәп яткан чагында, мин утравыма исем дә уйлап чыгардым — Прәннек атавы. Мин — пират. Дөньядагы бар прәннекне утрауга ташыганмын да шуның кыл очында басып торам. Аста, прәннек тавы итәгендә, кырмыска хәтле генә күренгән балалар кайнаша. Алар киләләр дә күлмәк итәкләренә, кесәләренә прәннек тутырып китәләр. Тау кимегәннән-кими, мин җиргә якынаям, прәннекләр келтер-келтер җимерелеп мине түбән тәгәрәтәләр... Кайда сез, прәннекләр? Баллы прәннекләр?! Әле генә ничаклы идегез. Кая киттегез?.. Хыялымны күккә аштырган тау!..

Мин әрекмән арасында. Тал ботагында кычыткан чыпчыгы кыбырсына. Буа өсте пыяла кебек. Бас идең дә шуып кит идең...

Бу юлларны язганда да чуар матурлыгы һәм самимилеге белән күңелемдә әллә ниткән нечкә моң калдырган әлеге утрау, онытыла башлаган төш шикелле, күз алдымда төсмерләнә. Аны исемә төшергәндә әллә кайдан, шау чәчәкле болыннардан йомшак, чишмә агышыдай челтерәвекле һәм бөтен күңел нечкәлеген били торган аһәңле көй ишетелгәндәй була. Анда үткән минутлар, мең ел яшәргә туры килсә дә, минем хәтеремнән китмәс төсле. Үтелгән кыенлык бусагаларын кабат кичү бәрабәренә булса да, бу хәяттә хыялларымның канат чыгарган оясы исәпләнгән Прәннек утравыма кабат әйләнеп кайтыр, бер учыма кетердәп торган ипи кыерчыгы, икенчесенә тимгел-тимгел ал прәннек кыскан килеш сандугачлы таллар арасында яңадан хыялланып ятар идем. Гомеремнең башы гына булган һәм чиксез күп бәхетле мизгелләр бүләк иткән бу мөкатдәс утрауны мин һәрчак сагынам...

* * *

Бу юлы кайтуым озакка. Ашыгырга, кабаланырга урын юк. Автобустан төшкәч, һәрвакыттагыча, машина-фәлән көтеп тормадым. Көзге юл көзгедәй шоп-шома: ялтырап ята. Ул урман буеннан сузылган, ашыкмый гына атлавы аеруча күңелле.

Аермадан безнең авылга кадәр унбиш чакрым. Үргә менеп бераз атлагач, зираттагы тупыл һәм каеннарның җиңелчә дулкынланган рәшә аша тибрәнеп күренгән яшеллеге пәйда булды. Алар артында — авыл... Кулларны киң җәеп шунда йөгерәсем килде. Авылга хәтле ерак әле, әмма күңелем аны якынайта. Уенчык тай кебек сикерә-сикерә чабасы иде. Камыллары тырпаеп торган кыр буйлап Кипкән елга үзәненә, күрше авыл тугаена, Күкертлек басуына, үзебезнең Атау болынына, Ак тау сырты буйлап авылга, туган йортның табак-табак ак таш җәелгән ишегалдына тизрәк барып керәсе иде.

Ашыкмадым.

Мин шау-шулы шәһәрдә яшәргә күптән ияләнеп беттем инде. Әйтерсең лә авыл ипие, юеш җир исе, башаклар шавы, ат көтүләре, утын кисүләр — болар берсе дә минем үткәнемдә булмаган. Җир сулышы гүя беркайчан да минем хәтеремә төшеп болай дулкынландырмас кебек иде.

— Яшәү — тауга мену, — ди иде безнең әти. Хак әйтелгән. Артка борылып артык тапталмаган, әмма синнән башка һичкем үтмәгән кыска юлыңа күз атсаң, үр күрәсең. Кайчагында бу үр артында биеклеге һәм текәлеге белән кызыктыргыч тау да чагылып киткәндәй була. Аны тизрәк үтәсе һәм авыр җиңү белән хозурланасы килә.

Ә кайчак, киресенчә, кирегә, түбәнгә очасы, күптән күрешмәгән дустың белән күрешкәндәй, үткәнең белән очрашасы килә:

— Исәнме! Менә мин дә кайттым, таныйсыңмы?!

Мине дә шул кичереш биләде. Әйтерсең лә моңарчы борчып килгән һәм мәңгелек булып тоелган вак-төяк мәшәкатьләр кинәт каядыр артка чигенеп тонықланды, тәмам онытылды... Җан тынычланып, күкрәкләр иркенәеп киткәндәй тоелды, гүя ныгыган, кояшта каралган уллары янына күлмәк-ыштанына кипкән клевер башлары, хуш исле печән ябышып беткән әткәй лапастан төшкән дә, елмаеп:

— Алла теләсә, җитәр инде, — дигән.

Кышка дигән печәннең «Алла теләсә, җитәр инде» диярлек булып җыелып бетүе без малайлар өчен үтә шатлык була иде. Сине хәзер берни борчымый, иңеңнән зур йөгең төшкән, шул көннән көчәнә-көчәнә «уфалла» да, тачка да тартасың-этәсең юк, тачка-арбаның көпчәк-күчәрләренә мул итеп май-дегет сылап җыештырасың да, вәссәлам — син киләсе җәйгә хәтле азат: телисең икән су коен, балык тотып, утлы күмердә кызыл канатлар пешереп аша, урманга чикләвеккә йөгер...

Әмма безгә бик тиз күктән җиргә төшәргә туры килә иде: мәктәпкә барырга вакыт җиткән бит! Әле кайчан гына ялга чыккан идек, әле кайчан гына печән җыеп бетергән идек...

Һәм менә мин күтәренкелек һәм ирек тойгысыннан иләсләнеп атлыйм да атлыйм. Тиздән әнә авылга җитәм инде. Өч ел күрелмәгән. «Күп тә түгел, әз дә түгел, ләкин бер гомер генә!»

Салмак адымнар белән атлыйм. Тирә-юнь — чиксез. Җирдән күк гөмбәзенәчә бөтен төш тынлык белән тулган. Тынлыкны калтыратып чиксез ераклыкның иң читендә ялгыз скрипка моңлы бер көй уйный.

Урман... Җилсез һавада, күбәләкләр төсле, өн-тавышсыз чуар яфраклар чайкала. Шулкадәр тынлык монда, хәтта аларның ботаклар арасында кыштырдап коры кычыткан сабакларына, дымсу җиргә кунулары да ап-ачык ишетелеп тора. Нечкә көмеш пәрәвезләр бормалана-сырмалана рәшәле кырлар өстеннән очып күздән югала. Күңелдә шул пәрәвез җепләре шикелле җиңел агышлы яисә шушы көз шикелле сагышлы уйлар чагылып-чагылып китә.

## II

...Әти көтмәгәндә үлде.

Авыруы озакка сузылмады. Бер айлап күкрәгем чәнчә дип йөрде дә түрдәге агач караватка ятты. Кулак сәнәге ясаган җәрәхәттән бабай да шушы борынгы караватта үлеп киткән. Әйтүләренә караганда, аның атасы да шушында дөнья куйган.

— Мөгаен, килгәндер, — диде әти әнигә. — Кан төкерәм... Хәерлегә булсын.

Кем килгән, ник килгән — без аңышмый да калдык: атна-ун көн тыныч кына яткач, әти бер иртәдә күзен ачмады. Йоклый идек. Әни уятты:

— Торыгыз, атагыз вафат... — диде.

Карарга куркып, без бер-беребездән күзләребезне яшердек. Тышта җил сызгыра, сөякләргә үтәрлек салкын буран котырына иде.

Шешенгәнче елаштык. Күз яшьләре керфекләргә боз тамчылары булып катты. Әтине туң җир астында калдырып кайткач, күңелдәге бушлыкка канатлы бер өмет оялады — кайтыр кебек, мәңгегә китмәгән кебек. Әтине белгән көннәр ерагая барган саен, өмет, җылы туфракка салынган бодай бөртегедәй, бүртә, үсә генә барды. Күпме шундый өметләре бар бу дөньяның!

Елны ел алыштырды. Бер вакыйга сүнде, дистәләгәне кабынды. Аларның халык арасына чышым-пышымлап таралганы һәм әкренләп сүрелгәне дә, тамчылап җыелып кинәт ду кубарганы да булды. Шуларның берсе — минем мәхәббәтем. Анысы да әллә ни зурдан булмады. Нибарысы минем күкрәктә ду килгән йөрәгемә генә дә сыйды ул. Тын күңелем тобасында давыл кузгаткан кеше Миләүшә Сираева иде. Ник аңа тукталганмын? Үз-үземә күпме генә сорау бирсәм дә, аңым җавап тапмады. Мәктәптә булсын, авыл клубы сәхнәсендә, кичке уеннарда булсын, Миләүшә өздереп җырлар иде — күңелемә сагыш кунар иде. Миләүшә өздереп биер иде — күңелем дәртләнер иде. Миңа илтифат итмәве, очрашканда күрмәмешкә салынып качарга тырышуы, гаҗәпләнгәндәй зур ачылган коңгырт күзе, гел көләргә торган чаялыгы, чигүле ак кофтасын һәм кызыл юбкасын кигәч күбәләк кебек җиңеләеп кала торган сыгылмалы гәүдәсе — шулармы мине әсир итте дә, шулармы аның әтисе — Галимҗан абзыйга карата булган дошманлык хисләремне тагын да кабартып җибәрде?

Сигезенче-тугызынчы класста укыганда, Миләүшәгә сүзката, аның белән ялгыз кала алмадым. Хакым юк дип санадым. Галимҗанның кызы турында хыяллануны әти истәлеген пычрату дип санадым. Ике якта

ике ут. Күңел һәм горурлык. Горурлыгым, бик мөһим бәрелештә җиңүгә ирешкән генерал шикелле, көннәрнең берендә күкрәгеп киерде.

Без, унынчы класста укучы егетләр дип әйтимме, булачак солдатлар, мәктәбебезгә ядкарь итеп Бөек Ватан сугышында һәлак булган авылдашларыбыз истәлегенә һәйкәл төзеп калдырырга булдык.

Төзедек.

Тугызынчы май көне иде. Обелискны ачу тантанасы. Бер якта — пионерлар һәм без. Икенче якта — ветераннар. Орден, медальләрен кояш алтынлаган. Араларында — Галимҗан абзый. Дөрес, гәүдәсе председатель чагындагы кебек «мин!» дип тормый.

Директорыбыз Әбүбәкер абый кул изәгәч, обелискны каплап торган җәймә түбән шуып төште. Аннан ветераннар сөйләде. Тыңламадым. Күзем Галимҗан абзый күкрәгендәге бүләкләрдә. Тамагын кыргалап, басынкы тавыш белән ул да нидер сөйләде. Аңламадым. Кул чаптылар. Мәктәп комсомол оешмасы секретаре Миләүшә «Ватаныбыз бәйсезлеге өчен кан койган авылдашларыбызга рәхмәт» әйтте. Октябрятлар ветераннарга чәчәкләр өләште. Галимҗан абзыйга да бер букет. «Кайда син, әти?! Ник кайтмыйсың?! Ник гомерең буе дәшми килдең дә, дәшми үлеп киттең?! Кеше җиңеп үләргә тиеш ләбаса!..»

Тәнемә ток бәрде. Йөгереп кереп, мәктәп эчендәге стендтагы рәсемнәр каршысына бастым. Пыяла астында — һәлак булганнар, исәннәр... Галимҗан абзый... Костюм, ак күлмәк, галстук... «Кайда син, әти?! Монда да юк!» Чыдамадым, Галимҗан абзый рәсемен каерып алып, идәнгә чәпәдем. Идән тулы пыяла, пыяла... Минем күз яшьләре шулай катканмы? «Менә сиңа, менә сиңа, менә сиңа!..» Кулларым, үҗәтләнеп, костюм, ак күлмәк, галстукны дистәләгән кисәкләргә телгәли. «Менә шулай кирәк иде, әти...»

Кулымнан Әбүбәкер абый тотып алды:

— Нишләвең бу, Рәхимов?!

— Шул кирәк аңа! Шул, шул!..

— Кемгә?

— Чәчәк биргән кешегезгә!

— Рәхимов, исеңә кил!

Минем аяк астына Миләүшә иелде:

— Әтине, әтине...

Чыгып киттем. Залга тулган классташларым, пионерлар юл бирде.

— Хулиган...

«Түгел, нәни кыз, хулиган түгел. Кеп-кечкенә Мефистофельнең үз демонына каршы беренче көрәш ачуы...»

...Берничә көннән соң минем хулиганлык комсомол җыелышына куелды.

Әүвәл дәшмәдем.

Мине яклап Миләүшәнең әнисе Вәзирә апа сөйләде. Гаҗәпләнделәр. Югыйсә бит ул мине гаепләргә тиеш иде! Миләүшә кебек. Ул нәрсә диде: «Рәхимов Рахманның өченче көнге тәртибе комсомол исеме белән рәттән тора алмый... Тавышка куям...» Вәзирә апаның чыгышын тыйнаклык дип бәяләделәр.

— Әти... Бу рәсем урынына башкаларның рәсеме туры килүе мөмкин иде ич! — диде Миләүшә.

— Юк, мөмкин түгел иде! — дип кычкырдым мин.

— Әле сиңа сүз бирелмәгән, Рәхимов!

— Соң, бирегез?!

Миңа сүз бирделәр...

...Вәзирә апа укучыларга текәлде. Миләүшә сорау тулы зур күзләре белән бер миңа, бер Вәзирә апага карап торды да, залга төшеп, ишеккә таба йөгерде. Әбүбәкер абый җыелышны ябык дип белдерде. Мефистофель демон алдында кычкырып көлде дә кечкенә җиңүенә сөенеп бетә алмады. «Менә шулай кирәк иде, әти!..»

Аттестат алу кичәсендә Миләүшәне бакчага чакырып чыгардым. Ачык тәрәзәләрдән дәртле җыр, көлешкән авазлар ишетелә иде. Болытлы, һава бөркү. Шатлыктан исергән күңел. Бар да әйләнә. Тик без берберебездән тартынабыз, читсенәбез.

— Ник чакырдың? — ди Миләүшә, коры гына.

— Аҗаган, — дим мин, уйларымнан арына алмыйча.

— Аҗаган, — дип кабатлый Миләүшә.

— Яңгыр явачак.

— Явачак... Ник чакырдың?

— Белмим... менә, — дидем мин һәм Миләүшәне җитәкләп ут яктысы яктырткан каен янына алып килдем.

— «М+Р», — дип укыды ул авыз эченнән генә. — Ни бу, Рахман?

Ул зур күзләрен тутырып миңа карады да иңбашларын сикертеп куйды.

— Төшенмисеңмени?

— Ә?.. Кем язган... моны?

— Мин... Бая гынак.

— Син... миһербансыз. Каенны елаткансың. Елый ич, елый.

— Мин дә... Нәкъ шулай еладым. Теге чакта. Син күңелеңдә тотма. Гафу ит.

— Гафу? Синеме?

— Мине...

— Юк, син мине гафу ит... Тик мин сиңа ышанмадым... Ышанмыйм. Аңла, ышанмыйм... Минем әни... синең әни булачак кеше... ышанмыйм. Юк!

— Сораштыңмыни?

— Кемнән?

— Ну, атаңнан димме, әнкәңнәнме шунда.

— Син нәрсә? Мөмкин эшме?

— Белмим. Мин әнидән сораштым. Гимай абыйдан... Әти сөйләгән иде кайчандыр.

— Ышанмыйм... Ә моны ник яздың?

— Белмим.

— Нәрсә генә беләсең соң син? Үзең белмим дисең, үзең әллә ниләр казып чыгарырга маһир.

— Мин яратам сине... Күп тапкырлар шушы каен шикелле сыкраган йөрәгем шаһит.

Миләүшә миңа борылды. «Мин дошманың түгел, Миләүшә! Карама миңа алай каш астыннан. Карама!»

— Ышанмыйм. Бер сүзеңә дә ышанмыйм!

«Миләүшә, иреннәрең... Кашларың калын, дуга. Муеныңдагы кан тамыры нинди дулкынланып тибә!..»

— Керик, яңгыр килә.

Күк күкрәде. Яшен яшьнәде.

— Чылансак? Минем биисем дә бар...

«И сабый! Синдә бию кайгысы... Көлмәгең нинди килешле. Зәңгәр...»

— Әйт инде берәр сүз, Рахман!

— Мин яратам сине. — «Ник пышылдап әйтәм?»

— Миңа беркемнең дә алай дигәне юк.

— Күлмәгең килешле. Зәңгәр. Зәңгәр кыз... Зәңгәрем...

— Белдем инде. Шаярасың икән. Сүзләрең чын түгел. Мондый сүзләр китапта гына. «Зәңгәрем...» Минме? Син минем кеше күзенә күренерлегемне калдырмадың. Җыелышта. Хәзер — «Зәңгәрем», имеш. Җибәр. Җибәр, дим!

«Талпынма... Зәңгәрем. Миләүшә... Кара, исемең дә зәңгәр икән. Миләүшә — зәңгәр чәчәк».

— Рахман, яңгыр ява ич инде, җибәр!

Класс бүлмәсендәге утны сүндерделәр. Каен да, без дә дөм-караңгыда калдык. «Хәзер тотам да үбәм үзеңне, Зәңгәрем».

Яшен. Чылтырап күк ярылды.

— Уй!

«Аһ!»

Юк, мине яшен сукмады. Мин күкрәгемә Миләүшәнең каплануыннан дертләп куйдым. «Яшендер син, Миләүшә!» Яшен, тагын яшен. «Күк түгелдер, шулай итеп йөрәгем дөбердидер».

Иренемдә Миләүшәнең кайнар сулышын тоям. «Үбимме? Юк, куркытырмын...»

— Җибәр!

— Үзең ич, Миләүшә!

— ...Сукыр син. Үзең шигырь язган буласың. «Зәңгәрем!»

«Сукыр, сукыр... Чыннан да сукыр...»

— Бүген бергә кайтабызмы?

— Беркайчан да кайтасым юк! Башта ышандыр. Әтинең... шундый икәнлегенә. Аннан... аннан... Хуш!..

### III

Исбатлармын. Шуның өчен кайтып барам да. Бәлки, очратырмын. Әүвәлгерәк хыялым белән синең янга, Шаһзадә кебек, ак атка атланып кайтып керермен шикелле иде. Ә хәзер мин җирдән атлыйм. Уйларымны бүлеп, артта ат пошкырды. Нәрсәдер чыңлап алды. Мин сискәнеп киттем һәм кисәк читкә тайпыл-

дым. Каерылып артка борылгач, зур җирән атны, арбадагы яңа киселгән юкә, каен жирдалар өстенә утырган ир-атны күрдем. Ул арыган чырайлы, кырынмаган.

— Урсайгамы? — дип сорады ул, урталай сынган кепка козырегы астыннан миңа текәлеп. Әйтерсең без көн дә очрашабыз, сәлам биреп тору кирәкмәс, хәл-әхвәлләребез болай да билгеле.

— Урсайга

— Кунаккамы, әллә берәр йомыш-фәлән төшепме?

— Юк, болай гына.

— Утыр әйдә, апкайтам, күңеллерәк булыр.

Колак төбемдә генә мышнап, янымнан ат узды. Сулышыннан, мөгаен, чәчләрем кыймылдап куйгандыр. Арбада сул кулына дилбегә тотып һәм бөгелә төшеп Галимҗан абзый утыра иде. Киң, ябык яңаклар, кысык күз, калын маңгай, нәрсәдәндер өркеп, шомланып йөргәнгә башын яка эченә яшерергә тырышкандай — кыска муен...

— Ә-ә-ә! Рахман! Корреспондэт! Тпрру-у-у, шайтан алгыры!

— Мин. Ничек таныдың?

— Ә кәк же. Киендем-ясандым да танымаслар дисеңме? — Бераз тузан кунарга өлгергән модный туфлиләрем, киң галстук белән ап-ак күлмәгем өчен оялып куйгандай булдым. — Кемне пешекләргә? Минем хат буенча түгелдер ич?

— Нинди хат? — дидем мин утырудан баш тартырга базмыйча, чемоданымны урнаштыргач.

— Гәҗитегезгә колхоз рәисен яман да каты пешекләп хат язган идем. Ул, үзбелдекклеләнеп, ферма төзетәсе кирпечтән Мәркәгә йорт салып бирде. Бер аягы күптән гүрдәге карчыкка дворис шикелле яңа йорт... Бу бит колхоз милкенә көпә-көндез кул салу. Тәк? Тәк...

— Ул Мәркә апаның...

— Апа! Бөрешеп беткән карчык диген.

— Ире бар ич, Гимай абзый.

— Үлде. Ел ярым инде — үлде. Көтү көткәндә яшен бәргән.

— Колхоз көтүедер ич?

— Колхоз... — Галимҗан абзый, төбәлеп, миңа карады. Ә мин тыштан тыныч идем. Эчтәге утны сизмәде. — Сарык көтүе.

Мин арбага утыруыма үкенеп бетә алмадым. Туры килүен кара! Төшеп калсаң, әллә ничек. Ни әйтсәң дә авылдаш һәм... Менә бу «һәм» минем сабырлыгымны үзенә буйсындырды.

— Минем ялга кайтып барыш. Отпускка. Пешекләү... Үзе дә, ире дә гомер буе колхозда эшләгән әбигә йорт салып бирү... Бөтен җирдә шулай булса иде, Галимҗан абзый! Аннан мин корреспондент түгел шул инде. Башка эштә.

— Нужели чыгардылар? Хәзер кем?

Эчтән көлеп куйдым.

— Беркем дә түгел. Китап язам... кайда нәрсә...

— Китап диген, ә? Әйе, әйе, авылда сөйләштергәлиләр. Ишеттерешкәлим. Китап язу да — ничего — эш... Корреспондэт... шәбрәк иде. Безнең заманда киләләр иде — калтырый идең. Тавыгын суйдырасың, теге, бу... Ну, малай, ул язучы дигәннәре шытырдатып алдый инде бер карасаң! Кайда ялганлый, кайда күпертә, кайда су куша, чүпрә өсти... И тутырып — акча!

Ул, менә мин ничаклы беләм дигән сыман, торналар кыйгачлап очып барган аяз күккә таба имән бармагын тырпайтты.

— Ну, бармы берәр чын китап?

— Яхшы китапларның барысы да чын.

— Без, әллә нидә бер китап тоткан гади бәндәләргә яхшысы ни, начары ни. Минем үз гомеремдә бер чыңкый чын китап укыйсым килә. Понимаешь?

— Аңлыйм, аңлыйм... Бик шәп! — дидем мин, эчке бер үтә канәгатьләнү хисе сизүдән рәхәтләнеп, пиджакның куен кесәсеннән кара тышлы кечкенә бер китап чыгардым. — Менә, Галимҗан абзый, син укырга теләгән «чыңкый чын» китап. Берәүнең канаты каерылган тормышы турында.

Ул китапны кытыршы учларына алды. Күзләренә якын ук китереп һәм юка иреннәрен метмелдәтеп аның исемен, авторын укыды һәм, сәерсенеп, миңа карады:

— Синекемени? Кызыклымы соң?

— Кемгә ничек. Сиңа кызыклы булырга тиештер.

— Ничек алай?

— Анда синең хакта да бар.

— Минем хакта?! Хе-хе... Хе-хе-хе. — Ул, ышанмыйча, кеткелдәп көлде. — Шутник син, малай, ә? Атаң да бу хәтле булмагандыр. Тәки ышандырырсың, шайтан. Прәме шутник...

— Ә син укы, укы, менә бусын.

— Кайткач... мин ятып укырга яратам. Йокы алдыннан.

Ат, ара-тирә пошкыргалап һәм авызлыгын күңелле чылтыратып, тауга түбән ялкау гына юырта. Атлаган көйгә аның корсагында су шапылдавы ишетелә, көпчәк астында коры ботаклар чатный, чыртлап имән чикләвекләре ярыла. Агачлар арасында кояш нурлары чагыла. Коелган яфрак, юеш җир, соңга калып аткан чәчәк исе аңкый.

Яңа ыштан кигән вакытымнан хәзергәчә Галимҗан Сираевка бәйле хатирәләр, каен тузындагы каралып, яшьләнеп торган пәке ярасы кебек, минем җанда тирән, төзәлмәс эз калдырган. Мин аның яңадан саркый башлавын тоям. Ап-ак каен тузы өстендә юеш яра — яшьле күз?

— Хәзер аттамыни, Галимҗан абый?

Ул уңайсызланып китте. Соравымның аны ни дәрәҗә телгәләвен мин үзем генә беләм.

— Пука атта...

Сираев бу сүзләрне үзенә бер төрле итеп әйтте. Колхоз рәисе булып йөргән чагында, бераз салып җибәрсә, шул ук интонация белән, тик күкрәген киереп һәм әллә шаярып, әллә чынлап:

— Пука председатель. Иллә мин бер дә бер көнне... белмим, кем булырмын икән? Министр ук булмасам да, яныма рөхсәтсез үткәрмәсләр. Пешеклисе кешеләр бар әле минем, бар! — дия торган иде. Аның кечкенә күзләре авызына бал капкан шикелле ләззәтләнеп кысыла, буынтыклы озын бармагы, кемгәдер зәһәр янап, һава айкый. Андый чакта без, малайлар, аннан ераграк торуны хәерле күрәбез. Бәладән башаяк. Пешеклисе кешеләре — без әбер-чебер булмагае.

Белмим. Янына рөхсәтсез үткәрмәслек кәнәфигә утырырга аңа нәрсә комачаулагандыр. Без туа-тумыштан колхоз башында торган Сираевны башта бригадир, аннан ягулык складында май-бензин биреп торучы иттеләр. Һәм менә — «пука атта».

Галимҗан абзыйның шул заманнардан калган кушаматы бар — Тозлы Прәннек. Бу кушамат кайчан ябыштырылгандыр, белмим. «Тозлы Прәннек». Исеме үк авызда эрергә торган шундый тәмле, баллы нәрсәнең тозлысы да була микәнни?

Озак еллар үткәч кенә бу кушаматны дөньяга биргән авыл халкының тапкырлыгына, сәләтенә шаккатып башымны игән идем. Исеме җисеменә шулкадәр тәңгәл килгән кушаматны мин башка беркайчан да очратканым булмады.

Туй-фәлән, кунак-мазар җыясы кеше бер-ике көн кала председательне искәртеп, чакырып куярга ашыга иде. Ашыкмас иде — икенче көнне Тозлы Прәннек кунак уздыручыны идарәгә чакырта. Эш вакытында колхозчылар вакытын бүлүнең зарарлы нәтиҗәләре турында ярты сәгатьлек лекция тыңлап пешекләнү белән генә котылсаң, Тәңреңә рәхмәт укы. Бәладән башаяк, биш-алты стакан җәл түгел. «Рәхим ит, Галимҗан олан, керми калма, көтәбез».

Галимҗан һич тартынусыз килә, табынның иң түреннән урын ала, яңа өйләнешкәннәрне котлау өчен сүз сорый. А-а! Тәмен белә иде ул шундый чыгышларның!

— Иптәшләр, — дип башлый иде ул, халыкның тәмам тынып бетүен сабыр гына көтеп алгач, — җыелышны... туй мәҗлесен ачык дип белдерәм. Мин шәхси үз исемемнән яшьләрне котлауны кирәк санап, чебен дә сыймас тыгыз вакытымны һич җәлләми-нитми бирегә килүне неотлагательно кирәк дип таптым, һәм үкенмим, иптәшләр! Әле кырда колхозның бәрәңгесе алынып бетмәгән бетүен, тик шулай да безнең асыл яшьләребез күмәк тормыш башлап җибәрергә үйлаганнар икән, мин моны хуплыйм гына. Димәк ки, алар башкача булдыра алмаганнар. Бу үзе генә дә аларның бер-берсен сөюләрен дәлилләүче фактор. Ник дисәң, мәхәббәт колхоз бәрәңгесен көтеп тора аламыни, иптәшләр? Мәхәббәт колхоз бәрәңгесе дип тормый, ашыга... Әйеме, яшьләр? Кызардылар, димәк ки, шулай... Алар үрлисе үрләр, таулар шома булсын өчен эчәм... эчик, җәмәгать! Һәм дә шулай ук алынасы бәрәңге мул булсын өчен күтәрик стаканнарны, иптәш колхозчы-крестьяннар!..

Председатель алдына тәлинкә тулы прәннек утыртыла.

— Менә, Галимҗан кордаш, — дип куя аны кызның әтисе. — Сиңа. Шәхсән ублюдкы...

— Ублюдкы түгел, блюдо. Блюдо, — дип төчеләнеп төзәтә Сираев.

Эчкән саен табын хуҗасының (ул, чыннан да, үзен шулай дип хис итә иде) йөзе прәннек шикелле тимгел-тимгел булып кызара, тәлинкәдәге прәннекләр күзгә күренеп кими. Бераздан «хуҗа» тәмам мәлҗери.

Председательне тизрәк эчертеп исертү алдан килешү буенча кайсыдыр бер кунакка йөкләтелә. Вазифасын никадәр оста һәм җитезрәк башкарса, ул шулкадәр мактаулы. Чөнки Тозлы Прәннектән котылу уе белән бөтен табын яна иде. Шуңа күрә Сираев стаканыннан сары болганчык бал бушанып тормый.

Бераздан аны озаталар. Ул туктаусыз күкрәк кага, кемнедер «пешекләп» бармак яный һәм кесәсенә салып чыккан прәннекләрен безгә өләшә. Тик алар тешләнгән була иде.

Тешләнгән булганга, мин аның прәннекләрен беркайчан да алмый идем. Алар тоз шикелле әче булырлар, тамак төбенә утырырлар кебек тоела иде. Бала чакта мине тешләнгән прәннекләрдән дә рәнҗеткән гаделсезлек булмагандыр. Кояш кебек көләч прәннекләрнең тешләнеп бирелүе мине ярсыта, гарьләндерә иде. Үсә төшкәч, һәр гаделсезлек, усаллык минем күз алдыма тешләп бирелгән прәннек рәвешендә килеп баса торган иде.

Галимҗан абзыйның тирле кулларыннан мин беркайчан да прәннек алмадым, һәм дөрес эшләгәнмен. Моңа мин соңыннан гына төшендем.

— Тар-рантас! — дип боера Галимҗан абзый болдырдан.

Кече капка ачылып, бала-чага тулы ишегалдына кәҗә сакаллы Мәүләви карт керә.

— Әзер, әзер, — ди ул, кабаланган булып.

— Иртәнге якта кереп чык, Галимҗан кордаш, — ди туй уздыручы. — Баш авырта-нитә калса...

— Авыртыр, авыртыр инде ул бераз...

— Авыртсын, бер сүзем юк... Төзәтербез иртәнчәк. Әйе, иртәгә сугыл... Аннары суң, кордаш, берсекөнгә урманга утынга бармакчы булып тора ием әле...

— Иртәгә... сөйләшербез...

— Әйе, иртәгә... Иртәгә, димәк...

Галимҗан абзый тарантаска менеп утыра да, Чегән кинәт алдырып киткәнгә ыкылдап, башын артка ташлый.

— Әкертенрәк бул инде... Мәүләви. Утын агачы илтмисең ич... мине! Картайдың... Сеңерләреңнең җегәре беткән... Мич башына бер менеп киткән идең ич инде... Ниме дип төштең дә, ниме дип мин сине алдым әле, панимаешь!

Галимҗан абзыйның хатыны укытучы Вәзирә апа кунакка йөрми иде. Күрәсең, ул яшьләр «үрлисе үрләр, тауларның шома булуын» теләмәгән...

**IV**

— ...Значитсы, минем хат белән түгел инде, ә?

— Значитсы, түгел, — дидем мин, аныңчарак сөйләшергә тырышып.

— Жә-ә-әл!..

— Нигә жәл?

— Ә кәк же?! Мин тагын икәү бергә тегеләрне мунча кертербез дип өметләнгән идем.

— Пешекләргәме?

— Во! Имынны пешекләргә! Ату, малай, соңгы вакытларда гупчым санга сукмый башладылар. Гупчым, кая карама — башбаштаклык. Идарәгә кереп тулган анда җыен... маңка! Син гафу ит, кәнишне. Үзләренең авыз кырыйлары сап-сары... Дөньяны кире борып булмый, янәмәсе заманалар башка. Панимаешь?

Ул, кесәсеннән таушалган, керләнгән кап чыгарып, ашыкмыйча гына папирос кабызды, бөтен күкрәге белән тирән суырып, аннан борын тишекләреннән көдрәләнеп чыккан аксыл төтенгә уралды.

— Заманалар башка шу-у-ул... Кайчандыр абруй бар иде. Кулда дилбегә. Бөтен колхоз, менә шушы ат шикелле, синең кулда иде. Кая тартсаң, шунда борасың. Эхе-хе...

Ул хыялына чумып барган көйгә туктаусыз көйрәтә бирде. Бер ноктага төбәлеп кысылган күзләренә, җыерчыклы сулган йөзенә, кайчандыр үз-үзеннән бик тә канәгать төстә кәпрәеп йөргән, ә хәзер шактый иңгән гәүдәсенә, папирос кыскан сөякчел бармакларына карагач, мин бу бәндәне ирексездән кызганып куйдым. Үткәнебезнең кайбер ялгыш тайпылышлары тудырган кайбер «пешекләүче» җитәкчеләрнең берсе булуына ул үзе генә гаепleme соң әле? Күрәсең, Тозлы Прәннек һәм аңа охшаган адәмнәр инде артта калган заман юлының читләтеп үтелгән гади бер каткагы булгандыр. Йөрергә, алга үтәргә комачаулавында үзсүзле кире каткакны гына гаепләп буламыни? Салкын көзләр бар иде ич...

Аннан соң яз килде. Галимҗан абзыйның шул, яз кояшы эреткән каткак шикелле, тормыш юлыннан югалуын күреп тору, ничектер, кызганычрак шул. Кешеләргә чәчәр өчен яз, алга барырга такыр юл кирәк. «Кая тартсаң, шунда борыла торган» заман... Әйе, хәзер заманалар башка... Картайган Мәркә әбкәйгә яңа кирпеч йорт салып бирәләр...

Тик каткаклар эзсез эремәде. Аларга сөртенүдән күпләр күңелендә инде онытыла барган, дөресрәге, гафу ителә, ә бәлки соңгы сулышкача кичерелмәслек тирән эзләр калган.

Тозлы Прәннектән калган эзләр дә шундый. Аларның иң җәрәхәтлесе — әткәй йөрәгенә тырналганыдыр. Хәзер үзем белгән, үзем үткән хатирәләрне, әтинең кайчандыр миңа сөйләгән, йә булмаса башка кешеләрдән үзем сорашып белгән хәлләрне яңадан искә төшереп, ат атлаган көйгә салмак чайкала-чайкала

Галимҗан Сираев арбасында утырып барганда, мин шул эзне буйлыйм, аның һәр бөртек тузанын, һәрбер ташын уйларым белән капшыйм һәм хәтеремнең йөрәгемне сызлатуын, чиркандыруын, җирәндерүен кичерәм төсле тоела. Күкрәгемдә йөрәгем түгел, прәннек сулкылдап тибәдер, сулкылдап елыйдыр... Тозлы прәннекләр...

Ат пошкырды, Галимҗан абзыйның төпсез чоңгылдан ишетелгән күк тоник саңгырау тавышы мине уятып җибәргәндәй булды.

— ...озаккамы, дим?

— Күңел туйганчы. Нәфес күпме куша...

— Да-а-а!.. Нәфес күпме куша диген, ә? Рәхәт шәһәр халкына. Чемоданың авыр күренә шул, озаккадыр.

Галимҗан пәрәвез ятьмәсе кунган кепкасын маңгаена төшереп арттан башын кашып алгач, колгалар өстендә яткан чемоданны иснәгәндәй, очлы борынын тартып-тартып куйды:

— Күчтәнәчләр?

— Төрлесе.

Чемоданымдагы прәннекләрне ачып күрсәтсәм һәм кайткач аларны тешләми-нитми генә бала-чагага өләшәчәгемне белдерсәм, ни дияр идең икән?!

— Бәлкем, синең тегесе дә бардыр әле, Рахман туган?

«Һе, инде туган дамыни?!»

— Кайсысы — «тегесе»?

Юлдашым, башын сулга янтайтып, урта бармагы белән ике тапкыр бугазына чиртеп алды. Тел төбен сизеп, теләген шаяруга борып карасам да булмады.

— Кунакка да — балсыз? Шалишь, егет! — Галимҗан абзый кеткелдәп куйды.

Котылыр әмәл калмагач, чемоданны ачып, бер шешә чыгардым. Үземнең дә киеренкелектән беразарынасы килгән иде, бөкесен ачып шешәсеннән генә бер-ике йотым эчмичә булдыра алмадым.

— Мә... Кабарга менә... прәннек...

Күршем кыстатып торуны кирәк дип тапмады.

Кайчандыр гарьлегемнән җиргә ятып еларга мәҗбүр иткән кеше белән бер арбага утырырмын, җитмәсә аны аракы һәм прәннек белән сыйлармын дип кем уйлаган? Тау белән тау гына очрашмый дигәне дә шушы микән?

Минем, ундүрт яшьлек малайның, киптереп, чүмәләгә өйгән печәнемә ут төртеп яндырганда, Галимҗан абзый «кая тартсаң, шунда бора» торган дилбегәсен кулыннан ычкындырган, бригадир булып эшли иде инде.

— Башкалар янып кырда эшләгәндә Булатныкылар печән җыйсынмы? Хосусый милек? Шалишь! Юл куймыйбыз, әйе!

— Абый, тимә инде, бу чокырны барыбер кеше чапмый. Әти бүлнистә ич безнең, бүтән хәстәрләүче юк, — дип, бригадирның шырпы тоткан кулына килеп асылынгач, ул мине этеп кенә җибәрде:

— Бу хәтле дә атаңа охшарсың икән, маңка малай!

Мин, ялынуның файдасызлыгын күреп, читкә тайпылдым. Кояш кыздыра. Битемнән бөрчек-бөрчек тир тама. Күз ачылмый: чагыла. Мин сипкелле битемнең уттай кызаруын сизәм. Бәләкәй йөрәгем көчсезлектән сыкрый. Үз-үземнән оялам. Гарьләнәм.

— Ә син... син... фашистка охшаган. Фашистка... охшаган, белдеңме?

— Нәрсә, нәрсә дисең? Пионер башың белән җитәкче органдагы кешене ничек дип атыйсың син? Кабатла әле?

Мин, аның күзендә иман заты юклыгын шәйләгәч, энемне җитәкләп, елый-елый авылга таба элдердем. Беркадәр ара үткәч, артка борылып карадым. Анда кечкенә чүмәлә ялкынлана, рәшә дулкынлана иде. Мин, сулкылдап, үлән өстенә капландым. Энекәшем майкамнан тарткалады:

— Тол, тол инде, абый. Кайтыйк тизеләк. Су эчәсем килә...

— ...Ну вот, Рахман туган, шәп үк булып китте әле бу, каһәр! Безгә мондый нәрсәләр гупчым тәтеми. — Кая инде безгә, авыл кешесенә. Нәфсесе килгәндә чүпрәле балы булгалап торса, шөкер дисең. Ә бу... Шешәсе матур. Искусство! Шәһәрнекеләр яши белә! Безнең ише түгел. Сездән кай төшебез ким, кай? Менә сез, яшьләр! Ни күргән дә, ни нужа кичергән? Ә бит, уйлап карасаң, без үстергән җимешләрне татыйсыз, безнең... Муллык, җәннәт!.. Ә без? Җәһәннәмне кичкән! Күпме кан түктек — орденнар тактылар! Заман башка иде, заман...

## V

— Сагынасың мәллә, Галимҗан абзый?

— Нәрсәне?

— Шул, бая үзең әйткән дилбегәле заманнарны.

— Ә, Рахман энем. Тормыш ат түгел ул. Без — аның аты. Ә камчыбыз — яшәү. Шул куа, шул. Сагынырга ара тар.

— Ара тармы, әллә күңел тартмыймы?

— Үткән-беткән. Безнең күңелләр елак хатын түгел, сагына алмый. Сагынсаң да — үкенечкәме?

Үзенекен уйлап, Галимҗан абзый тынып кала. Мин сигарет кабызам. Югары карыйм. Зәңгәр күктә ваемсыз ак болыт йөзә. Әйтерсең лә диңгез уртасында адашып калган җансыз җилкән.

Галимҗан абзый карлыккан тавыш белән борын эченнән генә җыр сузарга азаплана. Карашы кая төбәлгәндер — билгесез.

> Үткәндәгенә-ә-әй гомер, калган хәтер
> Сатып алыйм дисәң табылма-а-асс...

— Их-х! Җырлыйм дисәң җыры юк, мырлыйм дисәң — зары. Җырлый идем мин заманында! Җырлый иде-ем... Менә шулай, сузы-ы-ып алып китә идем...

> Шәм-Шәрифкәй дигән шәһәрләрдә-ә
> Кич ахшамсыз капка ябылма-асс...

— Галимҗан абзый, кире кайтыр идеңме?

— Кая?

— Үткән гомергә, дим.

— Ә син судан сора. Инештән, әйтик. Кире агарга кодрәтеннән килә икән — мин дә риза, кайтам! Билләһи газыйм.

Аның күзе очкынланып киткәндәй булды. Кепкасын салып, кул арты белән маңгаен сөртте: гүя тир белән бергә тирән-тирән буразналарны да сыпырып төшерергә теләде. «Без дә менә шулай яшәрбез-яшәрбез дә вакыт арбасын кире тартып алып китәргә теләп хыялланырбыз микән? Инде гомернең яртысы узып бара түгелме соң? Өлгерербезме, өлгерербезме?» — дип уйлап куйдым. Кая өлгерербезме — бусының уема ничек килеп керүен дә сизми калдым. Кызык бу уйлар. Миңа калса, аларның безнең халәткә буйсынмаган чаклары бик күп.

— Юл озын әле, Галимҗан абзый. Әйдә, үткәнеңә алып кайтам. Мә, кабыз тагын берне.

— Ә син ничек алып кайтмак буласың?

Сүзен әйтеп бетерергә ирек бирмәдем. Кемдер бик зарури фикеремне бүлдергәндәй, ашыгып әйтеп салдым:

— Юл — сүз белән кыска... Бир әле баягы китапны, укыйм әле кычкырып үзеңә.

— Сүз — зур юаныч анасы. Юаныч кына микән?

Солдат каешы белән буган телогрейкасы кесәсеннән китапны алып, Галимҗан абзый миңа сузды.

— Көлкеле урыннары булмасмы шунда. Ату сез маһир инде аңа... Н-но, сәрхуш!

Галимҗан абзый минем ни эшләргә җыенуымны онытты ук кебек. Ара-тирә атына эндәшкәләп, «Карурман»ны сызгыра башлады. Онытмаган икән. Беркавым баргач, борылып:

— Соң, укы инде, — диде.

Мине ашыктырган кебек, урман буйлап җил уйнаклап узды. Тезимә бер яфрак төшеп кунды да кышкы йокыга талган күбәләк шикелле тынып калды. Шундый «күбәләк» юлдашымның иңбашында да, минем чемодан өстендә дә пәйда булды... Яңадан скрипка сызлануын ишеттем. Нинди моң соң бу? Кая дәшә ул мине? Нидән кисәтә? Нигә үгетли? Әллә кулымдагы китапны укыргамы? Бәлки, укымаскадыр? Юк, мин укырга тиеш. Тик йөрәгемдә ачу, хәтта үч аласы килү тойгысы булса да, жәллим ич мин Галимҗан абзыйны, кызганам. Шул хис мәллә соң син, сүзсез моң?!

— Тыңла, Галимҗан абзый. Сагындырмаса да, искә төшерү — үзе бер дәва. Хәер, бу юлы... дәва микән?

## VI

«Бакый белән Гарифҗан бер чишмә суын эчеп, бер болын печәнен чабып үстеләр. Үсмер чакның чабатасын салганнан соң, елкылдап торган кунычлы хром итек киделәр дә, берсе тальяны, икенчесе гайрәтле тавышы белән карт-корыны сагышландырып, яшь-җилкенчәкне җилкендереп язгы-җәйге кичләрдә Урсай чишмәсе таллыгына җыелучы кыз-кыркын күңелен чиртә башладылар. Әмма уйнаудан ары узмадылар: башкалар таллыкта биеп-җырлаганнан соң беренче әтәч кычкыруын аулак почмакларда пышын-пышын көлешеп-серләшеп каршылаганда, Бакый да, Гарифҗан да, кеше күзенә чалынудан шүрләп, бакча артларыннан гына үр өстендәге мәктәпнең җиде төн уртасына чаклы сүндерелмәгән тонык сары яктысына тар-

тылдылар һәм, икесе ике яктан, укытучы кыз Вәсимә бүлмәсенең тәрәзәләренә чиерттеләр. Бер көн шулай булды, ике көн, ә өченче көнне мәхәббәткә сусаган егетләрнең сукмаклары кисеште.

— Син нишлисең монда, Гариф?

— Ә син нишлисең?

— Ы-ы... Кайтып барышые, уеннан...

— Минем дәген...

— Юлың әйләнгечтән икә-ә-ән... Алай...

— Әйләнгечтән шәп ич.

— Вәсимә кебек чибәрләр булганда шулайдыр шул, ахир. Тик син кеше бакчасына кермә инде. Бу юл миңа җайлырак бит, кайтыр якта.

— Һәр кешегә — үз сукмагы. Бәлкем, минем сукмак турырактыр?

— Такыр юл өстенә сукмак салмыйларые мыңынчы...

— Синең юл кай ара такыраеп өлгергән соң әле, Бакый малай, ә?

Шул рәвешчә ярым шаярып, ярым чын күпме тарткалашканнардыр, билгесез. Тар басмада очрашкан кәҗә тәкәләре кебек аларның берсе дә икенчесенә юл куярга уйламады, һәм, күрәсең, күңелләре төшкән Вәсимәне алай җиңел генә бер-берсенә калдырырга теләмәде.

Вәсимә тын табигатьле, унсигезне яңа тутырып килгән зифа буйлы кыз иде. Әтисе ниндидер күкрәк чиреннән сырхаулап китеп, тиз арада гүр иясе булгач, күз яшьләренең кибеп җитүен дә көтмәстән, салкын кыш уртасында укытучысыз калып таралышкан балаларны өйдән өйгә йөреп яңадан җыйды да үзе укыта башлады. Яшьтәшләре кебек, кышкы аулак өйләргә йөреп үзен күрсәтергә дә, егетләр йөрәген яулап алырга да аның вакыты да, теләге дә булмады шул. Чөнки көз башында егерме-утыз булып та, кыш уртасында таралып бетә язган балаларны өй борынча җыеп кара әле син?!

— Нишләмәк кирәк, Вәсимә сеңел, өчесенә бер кыска бишмәт ләбаса, берсе йөреп торса да рәхмәт диярсең...

— Сабакка барырга ни атлыгып тора да бит кана, чабатасы туздны шул, чабатасы... Шушы арада үрелер, боерган булса.

— Менә ни, мөгаллимә туташ! Мәптек — шайтан оясы. Варис хуҗа каласы баламны денсезләргә ияртеп station аздырасым җук! Акча санарга шайтан сабагы нигә хаҗәт? Йөрмә буталып, йөрмә. Иртәгә базарга барасы...

Аннары уен кайгысымыни? Вәсимәнең җилкәсендә — комсомол ячейкасын җитәкләү бурычы. Кышка әнә авылда колхоз оештырасы бар. Кайда ул уенлык, кайда ул егетләр?

Ә егетләр күмәкләшү шаукымы дип тормадылар — ут эленү белән, шул ук аулак өйләргә таралдылар, шул ук каеш салышны уйнадылар, шул ук таллыкта такмак әйтештеләр. Шул арада берсе хәтта Вәсимәгә яучы да җибәреп өлгерде.

Вәсимә, чынны уенга алып:

— Вакытым тар шул менәтерә. Көндезен мәктәптә, кичләрен җыелышларда. Ачка үләр ул минем белән, — дип җавап кайтарды.

Сукса тимер өзәрлек ике егетнең үзен күзләп һәм башка егетләр күзеннән саклап тәрәзә төбен каравыллавын ул каян белсен? Дөрес, күп тапкырлар инде ул стена артында кыштырдаган, тәрәзәгә чиерткән авазлар ишеткәләде. Ләкин анда йөрүчене йөрәк дәшүе белән килгән дип уйламады да.

— Апа, кемдер бар... дошманнар булмагае...

Үзе белән бергә торучы җыештыручы һәм каравылчы апа, караңгы тәрәзәгә капланып:

— Кем бар анда? — дип кычкырды да тизрәк кызны тынычландырды. — Беркем йөрми. Тоеладыр, кызым. Өшәнгәнгәдер...

Тоелгандыр... Яшь кыз күңеле җиңел генә тынычлана алмады. Ул кулак Сәхипнең олы малае Бәдринең үзенә күптән теш кайрап йөргәнен дә сизә. Күптән үч тотып йөри бит инде ул кулак сыныгы аңа.

— Камсамулка түгел син, комсыз маңка син, кызыкай. Әйе, комсыз маңка! Безнең келәтләрдә... ниең калганмы әллә? Хәзергә, Алла куәте белән, йозаклары нык әле аларның. Сез ач танауларның тешләрен генә сындырырлык. Кара аны!.. Җыелышларыңда безнең нәсел-нәсәп эшенә тыкшынып, тагын тел-теш тидерә калсаң... Телең — әллүр... — дип, Вәсимәнең каршына бер чыкты бит инде ул. Шул сагалый микәнни? Кичә тагын:

— Значица, энекәшне кызыл ясадыгыз? Гарифҗанны әйтәм. Ладно! Карарбыз кемнеке басканны!..

«Әллә шул Гарифҗан абыймы? Очраган саен кичен килсәм чыгарсыңмы дип шаярта. Тәмам йөдәтеп бетерде инде...»

Ике егет бер дә бер көнне мәктәп тәрәзәсе төбендә кабат очрашты. Тик бу юлы сәламләшеп, барны юкка алыштырып, шаярып маташмадылар инде. Әле кайчан гына кочаклашып гармун һәм җыр белән урам әйләнгән егетләр арасында кара мәче пәйда булды.

— Син, Гариф малай, бу тирәдә буталып йөрмә инде. Бүләр нәрсәбез юк!

— Һе, буталма, имеш! Бәлки мин, комсомолец Гарифҗан Сахипов, ячейка секретаре Вәсимә Ишмурзинаны сезнең ише... ялгызак элементлардан саклап сугышчан постта торамындыр?!

— Син! Танавыңны үлчәп ач! Югыйсә шундый элимет күрсәтермен, кырыкка мәтәлерсең! Тездән түбән җиргә иңәрсең, аңладыңмы? — дип, Бакый тегенең бугаз төбеннән эләктереп тә алды.

— Кытыклама! Сабый түгел... Шундый итеп сылармын, кубарып ала алмаслар. Комсомолга кул тидергән өчен...

— Янамасана, кулак сыныгы... Комсомол, имеш! Белми дип уйлыйсыңмы әллә? Корт син. Чикләвек эченә оялагач та... төшкә әйләндең мәллә? Май чүлмәге тышыннан билгеле.

— Ә син бар да әйт. Шулай-шулай диң. Иртәгә үк. Ни кырырсың икән. Бүгенгә — көш! Тай!

Үз гомерләрендә бер-берсе белән беренче кат якага яка килгәнгә уңайсызланыпмы, көчләренең тигез икәнлеген белгәнгәме, кичәге җан дуслар сугышмадылар. Йодрыкларын кесәләренә яшереп, ачудан калтырана-калтырана, икесе ике якка, төнге караңгылык эченә кереп киттеләр.

— Төнлә очрашырга язмасын, Гариф!

— Янама, Бакый, мин ялгыз йөрмим!

— Беләбез! Төнлә абыеңнар белән, көндез комсомоллар белән...

— Малай!! Шушы сүзләреңне көндез ишетим! Билләһи газыйм... Ә Вәсимә синең мал түгел. Чабатага — чүәкме? Ха, ишнең ише бар!

Икенче көнне үк карт сыеры белән бозавын яңа укмашкан «Кызыл таң» колхоз абзарына калдырып кайтышлый Бакый урамда Вәсимәгә юлыкты да кыймый гына сүз катты:

— Сүзем бар иде, Вәсимә...

— Ә, Бакый абый! Исәнме! Каян болай?

— Колхозга кердек... Сыерны, бозауны, сука белән ызбыруйларны төшергән ием.

— Чынлапмы?! Тик... күршеләрегез күптән...

— Сразы ничек хәл итмәк кирәк? Соң булса да уң булыр аның каравы.

— Шулай булсын инде.

— Ни, минем, Вәсимә... Кһы-кһы... бер үтенечем бар иде.

— Тыңлыйм, Бакый абый.

— Менә шул... үз арагызга алмассыз микән диюем иде. Комсомол итеп. Кансиртларда гармун уйный алам, бии... Әтү, әнә такмакка биеп йөрисез...

Унбишләп комсомол җыелган ячейка утырышыннан алар бергә кайтырга чыктылар.

— Менә, Бакый абый, котларга рөхсәт ит.

— Рәхмәт инде, Вәсимә. Син булмасаң, Гарифҗан гел каршые.

— Минем эш кечкенә, Бакый абый. Син үзеңне макта. Колхозга кердегез. Чәчүлеккә күпме арыш төшердегез...

— Соң бит бу комсомолга керер өчен түгел!

— Беләм, беләм, бетте. Без барын да үлчәдек. Рәүф абый безгә, шикләнмәгез, диде ич. Ишеттеңме, нәрсә диде? Тракторга укытырга яшьләр кирәк, диде. Көчлеләрне, тазаларны. Ә син... әнә нинди!

— Нинди?

— Ма-мату-ур... Әй, көчле!

— ...

— Йә, бүгенгә хуш иттек, Бакый абый. Сезнең өй турысы.

— Мин ашыкмыйм әле, Вәсимә. Төн матур... Йолдызлар. Ялгыз йөрергә курыкмыйсыңмыни?

— Күнегелгән.

— Бәдри синең хакта әнә ни дип әйтә ди ич. «Себергә китсәм дә, шул имансызның башына җитеп китәм»,— дип төкерек чәчә, ди.

— Гарифҗан абый безгә кушылганга шулай ул.

— Ә Гарифҗан... чын йөрәктән микән? Тиктормастан комсомолга.

— Атасы белән әрләшеп ич. Өйләреннән үк чыгып китте.

— Анысы бер хәл. Бәдри белән очратканым бар мин аны. Ике тапкыр.

— Бәлки... Бәдри аңа да яныйдыр? Ачуланышмыйлар идедер ич?

— Болай... сизелмәде... Белмим. Ярар, кадалсын. Вәсимә, әйдә... озатып куйыйм. Мәктәп әнә генә.

— Юкка... мәшәкатьләнәсеңдер лә...

— Мәшәкать дип...

Көннәр узды. Бакый белән Вәсимә әнә шулай эшләре белән дә, тора-бара күңелләре белән дә кыяр-кыймас аралашып, аннан сөешеп тә киттеләр.

— Өйләнәсе иде сиңа, Бакый. Картайдым бит. Күрәсең, инештән бер көянтә су алып менүе дә мең газап. Тегеләр атаңны үтергән елдан бирле йөрәгем калтырый, — дип сукранды аңа әнисе, яшьләр күңелен сиземләп алгач.

...Бакыйның әтисен, Рәхимне, буранлы бер төндә сәнәк белән чәнчеп үтерделәр. «Кызыл таң»ның председателе егермебишмеңче Рәүф Исламов белән район үзәгеннән кайтышлый аларны күрше авыл кулаклары сагалап торган. Чанада — колхоз акчасы. Урман буйлап сузылган юлда — кара шәүләләр.

— Бүреләр мәллә, Рәхим абзый?

— Бүреләргә охшаган шул, Рәүф туган. Болары ике аяклылар.

— Кешеләр?.. Болай итик: син капчыкны ал да — урманга! Тиз!.. Минем — револьвер.

— «Рибулбир»... Алар, күрәсең, өчәү... Миңа тимәсләр. Миндә ни үчләре бар? Әйдә, син. Сизеп алмас борын бар. Без — кара халык. Миңа тимәсләр.

Шулай дигән дә Рәхим карт, Исламовны чанадан төртеп төшергән һәм атын шәүләләргә каршы куган...

Өйләнергә утыз җиденең көзендә генә җай чыкты. Бу вакытта Бакый инде МТСта бригадир булып күтәрелде. Әле һаман да Вәсимәдән өметен өзмичә буйдак булып кала биргән Гарифҗан исә күптән инде кибеттә сатучы булып эшли башлады.

Күрәсең, сүзләре нык иде: Бакый чын-чынлап туйга әзерләнергә, кирәк-яракны булдырырга кереште.

— Туйларга исәп, дисең инде, Бакый? — дип, мыек астыннан елмайды Гарифҗан, аны урамда очратып. — Туй көнендә кунакка көт.

— Бусагамнан үткәрәмме соң!..

— Ә без җаен табарбыз.

— Җай табарга сиңа куш. Башың — тегермән ташы. Шәп әйләнә.

Гарифҗанның кем икәнен, әлеге сүзләрнең ни аңлатканын Бакый соңыннан, туй көнендә генә төшенде. Туйның иң кызган чагында, капканы киң ачып, ишегалдына Гарифҗан килеп керде. Үзе генә дә түгел, ике милиционер белән.

— Рөхсәттер ич, хуҗалар?

Яшь кияү, иңеннән гармунын сала-сала, алга чыкты.

— Бер-бер нәрсә бармы?

— Каян беләсең барын? Хәзер тикшерәбез, ни бар да ни юк... — диде Гарифҗан, итек кунычын чыбык белән чәпәли-чәпәли. — Күрәзәлегең шәп. Кичә кибетемне басканнар. Акча, бер ящик аракыдан җилләр искән. Сине күргәннәр.

— Ничек... ничек мине?! Гариф, шаяртма!

— Шаяртмыйм. Халык сөйли.

— Нинди халык? Беркем берни ишетмәгән, ә син — халык дисең... Без Бакыйны яхшы беләбез. Чебенне дә рәнҗетмәс кеше...

— Шулай да... Ну-ка, җәмәгать, без кайбер нәрсәләрне карыйк әле.

Озак эзләмәделәр, Гарифҗан мунча туфраксасыннан бер әрҗә аракы күтәреп төште.

— Йә Алла диң, ә?

— Кем уйлар...

— Ходай күрсәтмәсен.

— Дәүләт милкенә кул салган кеше — халык дошманы. Тикшерерләр.

Арбага утыртып, милиция сагы астында Бакыйны район үзәгенә алып киттеләр.

Артта туй калды. Бәгыре өзгәләнеп яшь кәләш калды.

Кибет баскан өчен аны өч елга хөкем иттеләр.

Хөкем карары укылган көнне ул төнлә район КПЗсыннан качты да, Вәсимә белән саубуллашырга дип, авылга кайтты. Бәлки, бөтен гомере эчендә бу төн бәхетнең аңа елмайган бердәнбер мизгеле булгандыр.

— Бакый!.. Бакый! Син минеке генә, Бакый...

— Өч ел — күбәләк гомере. Көтәрсең ич, якыным?

— Сорап торасың... Гарифны әйтәм, ничек кулы барган. Теле дә тартышмый.

— Усал яхшыдан яман ясый. Саклан аннан, Вәсимә. Котырган эттән ерак торганың яхшы. Сиңа сүз катар әле ул, берүк саклан...

— Бакый!..

Таң беленү белән, ул районга юлга чыкты. Томанлы көз иртәсе. Кибет турысыннан узганда, ачык ишектән Гарифҗан күренде.

— Бик тиз, бик тиз, — дип кычкырды ул ишек караңгылыгыннан.

— Шулай итеп халык сөйли диген, ә? Чиста кыландырдың, аракыны әйтәм.

— Ә мин сине өч елдан гына күрергә исәпләгән идем тагын. Ни ара әйләндең алай? Үч алырга уйлыйсыңмы? — Гарифҗан артка яшергән кулы белән капшанып чүкеч алды. — Якын килмә, гөнаһлы итмә!

— Гөнаһың гарык, буа буарлык. Ух-х, көчек! Әйткән идем, чикләвек эченә поскан корт, дип. Тәки... Өлгермәдем. Эзеңә төшәм дигәндә... Хәзергә тимим. Кайтырмын, боерган булса, эти канын төкертермен, имансыз булыйм... Теге чакта, урман буенда, Бәдри дә булган, эт! Сөрелеп котылды. Кем хәбәр иткән Рәүф абыйның акчага киткәнен? Син, кулак сыныгы. Ну, ничава! Кайтырмын... Тфү, җирбит!

Гарифҗан җиңе белән битен сөртте.

— Их син!

Чүкеч һавада айкалып алды.

— Бусы ник, Гариф...

Аңына килеп башын күтәргәндә, ул яткан җирне халык уратып алган иде инде. Ут, төтен бии. Үзенең ни хәлдә калганын ул бераздан гына, халыкны ерып уртага корымга буялып беткән Гарифҗан килеп кергәч кенә аңлады.

— Менә, җәмәгать!.. Магазин янына килсәм, ут төртеп маташа. Мине күргәч, үтерәм, дип, миңа ташланды. Шушы чуерташ белән башына орып өлгермәсәм, белмим, нишләтерие. Бәлкем, чытыр-чытыр килеп янып ятар идем! Ул арада ут та үрләп өлгерде. Нихәтле тырыштым, сүндерә алмадым. Шаһит булыгыз...

— Их, Бакый!.. Шуның өчен кайттыңмыни?..

— Елама, Вәсимә. Ышанмагыз, җәмә...

«Милиция бүлегеннән качып кайтып үч алу нияте белән ут төрткәне өчен» Бакыйга тагын биш ел өстәделәр. Булды сигез ел.

Кеше язмышы көпчәк шикелле тәгәри икән. Бүген син өстә, иртәгә аста. Гарифҗан Сәхипов корган тозак шапылдап ябылды да Бакыйның язмышын хаксызлык йозагына бикләп тә куйды. Ул утырган тормыш арбасы күрер күзгә очы-кырые булмаган сазлыкка кереп батты. Баткаклык аны көннән-көн көчлерәк, тирәнгәрәк суыра барды. Ә баш очында — йолдызсыз-нисез, ышаныч балкышы чагылмаган караңгы язмыш күге...»

## VII

— Трр!

Көчле тавыштан сискәнеп киттем. Арбаның кинәт туктавыннан авып китә яздым. Китап тоткан кулым белән Галимҗан абзыйның иңбашына таянып калдым.

— Син укыйсыңмы, әллә укыган булып сөйләнәсеңме? — диде Галимҗан, коры тавыш белән.

— Укыйм.

— Укыйсың. — Ул башын түбән иде. — Күрәм, мактанып әйтмәгәнсең икән. Ышандырдың.

— Нәрсәгә?

— Әнә шуңа. — Юлдашым китапка ымлады. — Насыйп булды. Штож. Башың йомры икән.

— Бусы да мактау.

— Шушымыни мине үткәнемә апкайтуың?

— Шушы.

— Исәбең төгәл... Кучтәнәчең йомшартты. Вәт, мин әйтәм, ешрак булсае! Панимаешь, көнозын берүзем. Каядыр барасы килеп атлыктыра. Кая?.. Йөрәк сулка. Йолкып ташлыйсыңмыни? Йолкысаң да тамыры кала.

Мин аны игътибар белән тыңларга тырышсам да, уйларымның агышы мине читкә кага. Ник дип бүген кайтасы иттем соң әле? Алай дисәң, без Галимҗан абзый белән барыбер очрашмас идекмени? Тормышның үз юлы булган кебек, көрәшнең дә үз законы бар. Чишелеше.

— Укы, Рахман. Дәвам ит. Син дәвам ит... Әмма ләкин — Вәзирә дип, пыжалысты. Чын исемнәре белән. Шулай телим. Син аңламыйсың. Шулай телим.

— Һәм — Булат дип, әти дип, Галимҗан дип...

— Аңлыйсың тәки... Риза... — Ул бөгелә төште, уң кулын куенына тыкты, йөзен чытты. — Йөрәк тузды. Үткәннең бөтенесе йөрәккә төенләнә икән, йөрәккә.

— Әйе, Галимҗан абзый. Әнә, көпчәк үткәч, юл да уелып кала. Маңгайдагы җыерчыклар кебек.

— Уелып кала шул.

«Ә мин сиңа таза-сау дип карап барам тагын, Галимҗан абзый. Эчтән тузгансың икән ләбаса. Шулай булгач, ник сине азаплап кайтам соң әле мин? Ник?.. Ә-ә! «Тол, тол инде, абый! Кайтыйк тизеләк. Су эчәсем киләә...»

### VIII

Ник болай бу дөнья?!

Туганда бөтен кеше дә тигез. Шәрә. Ике куллы, ике аяклы, бер башлы, бер йөрәкле. Әмма язмыш дигән бер көч туганда ук кешеләрнең иңнәренә кырыкмаса кырык төрле тормыш йөген мөһерләп куя. Язмыш, ялагай эт шикелле, берәүләргә койрыгын болгый. Икенчеләрнең баш очына очлы хәнҗәр асып куя. Кеше үскән саен шул хәнҗәргә якыная. Тутыккан хәнҗәр чәнчә башлагач кына ул, җавап эзләп, югарыга карый. Салкын йолдызлар дәшми...

Әйтегез, йолдызлар! Ник бәхет тигез түгел? Ник язмышлар йә ак, йә кара: йә ана кулыдай назлы, йә үги ана карашыдай кырыс. Әйтегез, әйт?!

...Мең тугыз йөз кырык сигезенче елның җәе.

Ул авылын, дөньяга килгән нигезен, анасын, Вәзирәсен сагынып кайтты. Урманны чыгып, соңгы кашлак өстенә күтәрелгәч, аның йөрәген сөенечтән бигрәк курку биләде.

Аста авыл. Кулыңны сузсаң, морҗаларга кагылырсың сыман. Борынга тупыл әчесе дә бәрелгән кук. «Нәрсә анда, кемнәр анда, нишлиләр?» Тәрәзәләренә тонык лампа яктысы сарган йортларның кайсысында кайгы, кайсысында шөкрана, ризалык, кайсысында шатлык, бәрәкәт? Ул караңгылык эченнән карт тупыллар шәүләсен, алар астындагы йортны эзләп бакты. «Ун ел. Ун ел. Ун ел — колак төбендә сызгырган җил. Күз йомылган да ачылган. Кайда соң безнең йорт? Әһә, буа! Ун ел элек кайда булса — шунда. Әз генә астарак — тегермән. Ерактан караганда түбәнең уң кыегына орынып күренгән йорт — безнеке. Караңгы, күренми. Ник ут кабызмадылар икән? Этләр өрә... Җырлыйлар! Гаҗәп, җырлыйлар! Нинди гү? Кешеләрме? Гаҗәп. Нидән? Июнь... Июнь — сабан туе... Сабан туе!.. Авылы аны сабан туе җыры белән каршылый!..»

Эчкә җылы йөгерә. Ниндидер авыр мәсьәлә җиңел генә хәл итеп куелган да, тәмәке көйрәтеп алгач, тыныч йокыга китәргә мөмкинчелек туган. «Нигә безнең тәрәзәдә ут юк? Ә, алар сабан туендадыр. Әнкәй карчык, Вәзирә, тагын... Тагын... Аңа ничә яшь инде? Ун ел... Тугыз. Тугыз яшь! Сөбханалла! Кызмы икән, улмы? Ул кирәк, малай! Булачак хуҗа!.. Миннән ниткән рәт? Тишек үпкә. Таланган йөрәк. Ырматызлы аяк... Әйе, ул кирәк, ул! И-эх, рәхмәт төшкере! Гел бирмәсә, бер бирә. Тормышка каһәр укырлыкмы соң? Ул әнә дәвам итә, җырлыйлар, әкәмәт... Кайчан да булса аңа да елмаерга язгандыр ич. Тамак төбенә каткан үпкә, рәнҗүгә буылып өстерәлергә димәгән. И-эх!»

Авыл утлары. Тирән чоңгыл төбеннән күренгән ак ташлар. Ул сагаеп алга атлый. Тиз-тиз атлап китсә, авыл куркып аннан кача башлар төсле. Саксыз хәрәкәт һәм, чоңгылның төнбоеклы тын суы җыерчыкланып, ак ташлар юкка чыгар. Теге вакыттагыча...

...Башта әсирләрнең бер төркемен бәреп яуган салкын яңгыр астында җәйге сугышлар вакытында миналанган кырдан бәрәңге алдырттылар. Кыр тирәли — овчаркалар, автоматлы сакчылар...

Булат күрде: лагерьда танышкан дусты Табейкинның аяк астында җир убылды. Гүя удмурт текә ярдан су өстенә сикерде дә, тамчыларда кояш фонтаны кубарып, төпкә китте. Җиңелчә пар күтәрелгән мина чокырчыгы кырыенда ертык пилотка гына калды. Әллә мина ялкыны чагылудан, әллә Ишпайның каны кушылудан яңгыр тамчыларында кызгылт төс уйнаклап алды...

Әсирләр, яңгыр тамчылары белән бергә яшьләрен йота-йота, күшегеп каткан бармаклары белән пычрак җирдә казыналар. Бер әсир көрәк белән актарына, икенчесе кәрҗиненә пычрак бәрәңге тутыра. Үзәкләргә үтеп салкын җил исә. Карлы яңгыр камчылары битне, тәнне телгәли. Ул ачудан, көчсезлектән кайный. Бөтен тән җылысын нәфрәт ялкыны белән тулы күзләр суырган...

Ул шушы кичне качты. Төн караңгы. Авыл. «Безнең авыл кебек: үр астында». Кырый өйдә ут. Шунда какты. Таза йөзен кара сакал баскан крестьян тасма телләнеп, кайнар чәй эчертте. Толыпка төреп җылы мич башына яткырды. Җылылык аны каймак кебек эретте. Эссе. Имеш, янгын. «Тор, тор!» Табейкин аны торгызмакчы итә, өстен ача. Ул тартыша. Толыпны яңадан башына каплый. Сүгенә. Ут. Матча сынып иңбашына төшкәндәй була. Авырту. «Әнисенең мич башындамыни, ә?» Көлү. Кемдер аны сөйрәп төшерә. Упкын. Йокылы күзен ачканда — сукыр лампа яктысында баягы кара сакал. «Кунарга керт, ди, Крупяненко әфәнде...» — ди йорт хуҗасы. — «Шәп иткәнсең. Иртәгә килерсең. Закуска ала кил!» — ди Булатны сөйрәп төшергәне. — «Бик шатланып, бик шатланып...» Полицай! Юеш шинель җиңендә керләнгән ак тасмага «Р» дип язылган. Ерткыч авызына үз аягы белән килеп капкан лабаса!.. «Рәхмәт чәй өчен, кара сакал! Минем тән аны сиңа иртәгә самогон итеп эшләп чыгарыр. Кружкаңны тотарсың, шарлап тулар. Закусканы ала

кил. И-эх! Киттек, Крупяненко әфәнде. Сезнеке басты». — «Басармын мин сиңа!» Һәм полицай, кинәт селтәнеп, Булатның авызына йонлач йодрыгы белән суга.

...Туган авыл качмады. Украина авылындагыча, ут сыңар тәрәзәдә генә түгел. Мондагы тәрәзәләр — күктәге йолдызлар: чакырып җемелдиләр. Туган авыл... Киң урамнары белән кочты да тәмле исләре белән назлап сөйде. Катырак кыскандыр: тын бетте, колаклар чыңлады, йөрәк атылып чыгардай булып типте, маңгайга тир бәреп чыкты. Ул изүен чиште. Тыкрыктан күтәрелеп сулга борылгач, өченче йорт — аның йорты. Үз кулы белән салды. Өйләнер алдыннан. Юл капчыгын җиргә куеп читәнгә сөялде. Читән шыгырдады, абзар артында һаударланып эт өреп алды да тынды. Җылы тирес исе, яңа сауган сөт исе. «Эт — Карабаймы? Юк, ул мин барында ук карт иде инде. Гыймадетдин абыйлар абзар-курасы. Хуҗалыгы таза иде. Исән-сау кайтты микән? Кайткандыр. Юкса тол хатынга эт нәрсәгә?»

Гармун өздерә. Өздерми, сызлана. Сабан туеның кечке уены аръяк болында. Шунда булмый кайда булсын?.. Буа өстеннән чыгып колхозның яшелчә бакчасын ураган читән буйлап баргач — иңкү болын... Тормыш дәвам итә. Булат, аның кебек йөзләр кайтмады димиләр, бәйрәм итәләр. Менә шулай, кешеләр үлә — җәмгыять яши, буыннар алмашына — бәйрәмнәр кала... Беренче йорт. Йолдызлы күктә каралып, кайчандыр бабасы утырткан таллар шәйләнә. Икенче йорт. Шомырт агачы. «Картайгандыр инде». Менә минем йорт. Төн йокламый диярлек маңгай тирен агызып салынган йорт. Мал-туар юктыр шул инде: аяк астында элеккечә каты җир түгел, тапталмаган. Йомшак, димәк, капка төбен чирәм баскан. И-эх! Ничего! Такыраер, Алла теләсә...

Капка йозаклы иде. Такта эскәмиягә утырды. «Таган астыннан кайтканнарын көтәсе булыр инде». (Кызык сүз — таган асты. Сабан туеның кичке мәйданын бездә шулай атыйлар.) Йолдыз атылды: ул шырпы сызды. Папирос кабызды. Хәзер эш тә эш инде. Бөтенесен рәткә китерәсе. Әнкәй карчык та, Вәзирә дә — аларның кулы барысына да җитмәгәндер шул. Ничего! Булышырлык ул бар. (Булырга язсын.)... Билгесез кеше. Нинди икән син?

Урамнан, сөйләшеп, кешеләр үтте. Тавышларын танымады. Онытылган. Күрмәсеннәр дип папиросын учына яшерде... «И-эх, озак болар! Вәзирәгә килешә микән? Хуҗа өйдә юк чакта шулай озак кайтмау буламы? Хәер, әз булса да ялгызлыктан арынырга телидер. Кеше арасында чүтеки җиңел була. Укыта микән? Балаларны ярата иде...»

Күңелне тынычсызлык борчый башлады. Эш юктан эш булсын дип, түр бакчага узды. «Эш күп. Рәшәткәләр черегән. Ну ничего!» Караңгы өй эченә күз салыйм дип, тәрәзәгә үрелде. Маңгае аркылы тактага терәлде. «Кадакланган», әйтерсең йөрәккә чүкеч белән кадак кактылар. Икенче тәрәзәгә ташланды. Такта! Өченчесенә капланды. Такта! Ташландык өй. Буш өй! Әллә ялгыштымы? Юк. Тупыллар. Чия ботакларына битен тырната-тырната, үрсәләнеп, капка төбенә йөгереп чыкты. Капка өстеннән үрмәләп, ишегалдына сикереп төште, болдырга күтәрелде һәм, кечкенә йозакны каерып, эчкә узды. Борынга кеше күптән тереклек итми торган торакларда гына була торган коры тузан исе ярып керде. Шырпы яктысы чаршау-кашагасыз шәрә өй эчен беркавым үзенең калтыравык нурына манчыган булды да, караңгылыкны җиңә алмаячагына ышанып, сүнәргә ашыкты. Булат мич гәрничендә сукыр лампа күреп алды, селкетеп карады. Аның төбендә генә керосин чупылдады. Филтәгә ут эленгәч, ул агач караватны, түрдәге сандыкны, җиз герләре идәнгә тиеп туктап калган борынгыдан күчә килгән сәгатьне, лампа күләгәсе төшкән җиз самоварны күздән кичерде. Ялгыз чикерткә чыңы ишетелде. Киерелеп тыңлаган иде — колак үзе шулай чыңлый икән. Бу чың шушында үткәрелгән төннәр, чикерткәнең нәзек сайравын искә төшерә. Тынлыктан котылыр өчен ул, герләрен күтәреп, сак кына сәгать теленә кагылды. Йөрәк — тук-тук, сәгать — тек-тек. Аркасында кемнеңдер карашын тойган шикелле, ул артка борылды. Стенада — карточкалар рамы. Сынаулы карашлар. Гаепле карашлар. Шатлыклы карашлар. Басынкы карашлар. Аның ялгызлыгын бүлешә алмаганга уңайсызлангандай, тын калганнар. Түбәтәйле һәм камзуллы атасы. Чигүле алъяпкычлы һәм шәльяулыклы әнкәсе. Тормыштан иртә киткән абыйлары. Бердәнбер апасы. Ничек яши икән? Тәрәзәгә кадакланган такта ярыгыннан бер йолдыз күренә. Гүя аңа иптәшлеккә кул сузган. Тәне буйлап кайнар кичереш дулкыны чемердәп уза. Ул — шул йолдыз. Кешеләрдән, Җирдән аерылган япа-ялгыз йолдыз. «Нәрсә соң бу, нәрсә? Нәрсә? Үлделәр... микәнни?..» Җавап эзләп, Булат әнкәсенең уңган рәсеменә текәлде. «Тырыштым, улым. Әрләмә инде, кичер. Хәлемнән килмәде», — дия сымак. Алъяпкычлы сурәт чигүле яулык почмагын күзенә китерә. «Насыйп булмады».

Ул карават читенә утырды. Капчыгыннан, капшанып, шешә алды. Калай кружкасын мулкытып спирт салып эчте. Ирен читләре белән мыек очын чәйнәп тын калды. «И-эх, едрит-вертит, ә?» Җиделе сукыр лампаның кызгылт ялкыны өстендә күбәләк җилпенде. Булат: «Кем җаны?» — дип куарга өлгерми калды. Ак күбәләк, канатларына ут кабып, егылып төште. «Кем җаны?» Әтисе мәрхүм дөнья куйгач, өй эчендә күбәләк күргән саен, әнисе һаман: «Атаң... җаны кайта, үзе юк», — дип көрсенеп куя торган иде. Хәзер, күрәсең, үзе. Улын каршыларга килгәнме? Чытырдатып күзләрен йомды. Бала итәкле алъяпкычка гөлт итеп ут

кабынды. Юк! Юк! Күзен ачканда, лампа уты үзе дә, филтәдән аерылып очарга теләгәндәй, әлеге күбәләк шикелле талпынып-талпынып куйды да кинәт сүнде. Янган чүпрәк исе чыкты. Булатка лампа белән бергә тормыш та сүнгән кебек тоелды. Тоелды түгел, ул моны үзе теләде. Концлагерьда йөзләгән әсирләрне бер рәткә тезеп, немецлар мәйдан уртасында бер токтынның өстенә бензин сибеп ут төрткәндә, аны шушы ук тойгы алдаган иде. Ул чагында да сүнгән филтәдән чыккан ис кебек каршы җил әсирләргә чүпрәк исе, куырылган ит исе китергән иде. Тормыштан гарык булу теләге Булатны илертә-илертә эсэсчыларның автомат көпшәләренә каршы куды. Озын муенлы, җирән чәчле, зәңгәр күзле, бик нечкә табигатьле комендант атмаска кушып кул изәде. Боз өстенә кулларын як-якка җәеп йөзтүбән капланган Булатны торгызырга кушты да ысылдап: «Леһко умерайт һотель? Найн, найн, живьи, живьи!» — дип җирәнгән сыман, ирен почмагы белән генә елмайган иде. Комендантның мактанычы һәм куанычы булган музыка командасы ниндидер тинтәк бию көе башлады. Әсирләр аумас өчен бер-берсенә ябышып, кара кисәүгә әверелгән кеше гәүдәсе тирәли «кыргыйлар балеты»н башладылар. «Живьи, живьи, живьи...»

Булат, тән чираткан күренештән арынырга теләп, чигәләрен кысты. «Леһко умерайт һотель? Живьи, живьи...» Сукыр лампа сүнде. Мең газап кичергән аның тормышы сүнмәде... Урамнан «Урам көе»н җырлап уздылар. Тормыш бәйрәм итә. Бәйрәмнәр сүнми. Тормышның мәңге сүнмәс татлы бәйрәмнәре күп. Ярыктагы йолдыз югалды. Булат ирексездән сытылып чыккан яшьләрен, җиң очы белән сөртеп, ястыкка капланды. Ул янтайгач, әллә тәрәзә ярыгында, әллә аның күңелендә яңадан йолдыз балкыды. Ул, хыялындагы улын баш очына күтәреп, йолдызга сузды: «Ал, ал, улым! Минем йолдыз. Сиңа булсын...»

Йокыга китә алмыйча контузияләнгән кеше кебек миңгерәп бераз аунагач, кеше-кара күзенә чалынмаска тырышып, түбән очка, апасы янына төшеп китте.

## IX

— Әни кайда?

— И Булат, Булат. Көтте, өзелепләр көтте. Күрәсең, язганы шул булгандыр... Гүр иясе әнкәй. Узган җәйне. Алданрак кайта алмадыңмыни соң?!

— Ә Вәзирә?

— Кияүгә чыкты...

«Сугыш ярасы... Әле син тәнне генә түгел, йөрәкне, җанны да телгәлисеңмени? Тупларың тынып, крематорийларың сүнсә дә, син черек тешләрең белән кешеләр тормышына авыр яралар ясыйсың».

— Кемгә?

— Галимҗанга. Ул хәзер колхоз председателе.

«Бар нәрсә утка әйләнә, һава җитми. Күкрәкне нәрсә кыса? Кач! Вәзирәне дошман ярата... И язмыш!.. Син — авызы канга буялган немец овчаркасы. Бер корбаныңны ничә кат талый аласың син?!»

— Көтмәгән дә илаһым.

— Көтте. Галимҗан аның артыннан калмый йөрде. «Үз күзем белән күрдем, үлде. Гәүдәсен җирләгән кулларым чересен алдасам» дип... очраган саен... Шуның өстенә тагын әнкәй вафат булып... Хатын-кыз, ялгыз калудан куркып... Беркеме юк бит. Миннән киңәш сорады... Ни дим? Теләгең кушып, кайтмаслыгына ышансаң... чык, дидем. Мин гаепле, мин...

«Тормыш өчен теш-тырнак белән тартышу нигә кирәк булган? Мәсхәрәләнгән, яраланган җирдә Вәзирәне хыялымда кочып күзләремне йомсам ни булган?!»

— Йөрәгеңә алма. Хәзер йорт саен тол хатын. Баш исән-имин кайтканга шөкер диген.

— Әй, апа, каһәрләсәң дә таман...

— Алай димә. Онытылыр, Алла теләсә. Исәннәргә бер җүн кылыр. Кайтмаганнарга ясин чыгыйк та... Амин. Сабан туе бүген. Кайтышлый күргәнсеңдер...

— Туры сиңа чаптым. Өй бикле. Тәрәзәләр кадакланган. Сабан туе сөлгеләре минем кайту шатлыгына түгел, кәфенлеккә булган шул... Сабан туена терәлгәнме? Их Вәзирә!.. Башымны кая орырга соң? Безнең баш органга түзәрлек таш калды микән дөньяда?

— Алай димә, Булат. Болынга чык. Кешеләр белән сөйләш. Йөрәгеңне йомшат. Безнең башлар да әз күрмәде. Түздек. Кичерә алырдаен кичердек.

«Ике шатлыгым бар иде: әнкәй карчык та Вәзирә якыным. Аларны да тартып алдың, тәкъдир. Берсен җир куенына яшердең. Икенчесен, дошманым куенына...»

Булат ай яктырткан урам буйлап үтте. Гаҗәп, аръяк болында кызлар җырлый, гармун өзгәләнә: кичке уен. Ун ел элек тә шулай иде. Йөз ел элек тә шулай бәйрәм иткән җир кешесе. Йөз елдан соң да шулай булыр. Туендырган сабанына мәдхия итеп, кояш яргалаган ләм шикелле кытыршы, имән тамырларыдай бүртенгән кан юллары белән телгәләнгән хезмәтчел кулларын ял иттерә җир кешесе. Сабан туе...

«Сау бул, сугыш еллары! Каһәр төшсен сиңа, адәм ите белән тамагың аркылган утлы мичләр! Исәнме, михнәт! Якыным хыянәте, исәнме?!»

Урам буйлап бераз баргач, ул мәктәп үренә күтәрелде. Кырга чыгып, сабакланып килгән арыш тавышын тыңлады. Терекөмеш шикелле ялтыраган буага гаҗәпләнеп күз атты. Аннан тагын кырга, кырга!.. Җирнең түренә! Чөнки Җир, — арымас Ана, — миллион язмышлар йөген күтәргән Җир генә аны аңлый ала! Мең михнәтне тәненә һәм хәтеренә җыеп кайткан Булат өчен бары ул гына бишек булып калган. Шуның өчен сыйпагандыр ул аның арыш чәчләреннән, шуның өчен кайнар күкрәгенә ятып елагандыр, шуның өчен, пулялардан саклангандай, җиргә сыенгандыр. Колакка тыгылган мамык аша саркыгандай, тонык булып моңсу җыр, көлү авазы ишетелә. Бар дөньяны шул көлү баса. Тешләр кысыла, бармаклар туфракка батып керә. Туфракка гүя электр тогы җибәрәләр: бөтен тән калтырый, бөгәрләнә... Төшме, өнме? Ха-ха-ха!.. Кем көлә? Галимҗанмы? Кара томшыгын тутыккан хәнҗәр итеп, Булатның йөрәгенә төбәгән язмыш козгыны. «Исән-имин кайтканымны белгәч ничек каркылдар икән ул? Әсирлектә гарык булганчы газап әчесен татыганда, кызышып, салкын үлем белән тартышып, кара кан түкереп ятканда, лагерьдан беренче кат качкач өч тәүлек буе тездән бозлы суда торганда, икенчесендә, билдән җиргә күмелеп ач эттән таланганда аның күз алдында өрәк булып гел Галимҗан биеде. «Яшә, яшә, — дип пышылдады ул, — дөньяда син татымаган күпме газап бар әле, яшә!»

## X

Төне буе уяулы-йокылы саташып чыккач, Булат, таң белән торып, папирос кабызды. Өй эчендә эңгермеңгер иде. Беркавым аңышмыйча торды: «Ник караңгы?» Тәрәзәләргә карагач, кичәге такталарны исенә төшерде. Кайбер тәрәзә өлгеләренең пыялалары ватылган иде. «Пыяла җүнәтеп куясы булыр». Бу уй аны айнытып җибәрде. Умарта күчедәй өерелешеп, башына кичәге уйлар өермәсе кереп тулды. Капылт кына эрактагы җәй иртәләре исенә төште... Өйдә рәхәт салкынлык. Яңа сауган сөт исе. Көтү күтәргән урам тузаны, кояшның кыйгач нурларыннан алсуланып, бәрәңге сабакларына, кура җиләге, карлыган куакларына, тупыл яфракларына, салам түбәләргә куна. Яңа уянган аңына ерактан әнисенең ягымлы тавышы ишетелә.

— Тордыңмыни? Җылы сөт эч әүвәл...

Үлеп-үлеп шул тавышны яңадан тыңлыйсы, йөз кат, мең кат ишетәсе килүдән Булат вәсвәсәләнеп күзләрен йомды, һәр җәһәт аңа тынлык һәм урамнан килгән яңгыравык авазлар белән генә җавап бирде. Әнисенең вафат булганлыгына ул котылгысыз рәвештә ышанып өлгерде инде — «Әллә соң читкә чыгып китсенме?» Әнисенең каберенә барып баш та имичәме? Такта ишекне шыгырдатып ул чоланга керде. Бик пөхтә итеп чөйгә элеп куелган теге ямаулы («Әни мәрхүм эше») чалбарын һәм аркасына астар тегелгән («бусы арка тире белән тозланып тиз тузмаска. Вәзирә») күлмәгенең тузанын кагып әкрен генә киенде. Әле чәче үсеп җитмәгән. Шунда ук эленеп торган майлы кепкасын (тракторда эшләгән чак истәлеге) башына бастырып әвеслеккә үтте. Ышкылар, пычкылар, өтергеләр, бораулар, хәтта чабата үрә торган шөшлесенә хәтле — һәркайсы үз урынында иде. Боларның барысына әнисе кулы тиюенә шикләнмәде. Бармак очларын эш коралларына тидереп алганда аның кул җылысын тойгандай булды. Кирәкле ике генә нәрсә күренмәде — балта да багай*. Балта — иске дугалар, үгез камыты, киезе төшкән ыңгырчак, коргаксыган арба көпчәкләре һәм авыр үлчәү көянтәсе аунаган киң синнектә, багай келәттәге иске-москы тутырылган лар өстендә булып чыкты.

Булат илле пот сыешлы ларны карап торды. Кайчандыр аның гәрәбәдәй сары бодай белән тулы чагын искә төшереп уфтанып куйды. Соңгы мәртәбә кайчан тулган иде әле бу лар? Өйләнәсе елны. Җитмәсә бүселергә торган ничәмә арыш капчыгы. Бөтенесе тулы. Өч кешегә ике елга җитә дә җитә иде. И-эх! Насыйп булмады... Ну ничего!»

Кояшның беренче нурлары тал очларын, калкулыктагы зират каеннарын алтынга манчыды. Булат башта әнкәсенең каберенә бармак булса да, җиңнәрен сызганып, ясканып-ясканып тәрәзәгә кадакланган такталарны каерырга кереште. «Ник какканнар? Ир кулы. Озакка исәпләп. Кем эше икән?» Тутыккан кадаклар туйра бүрәнәләрдән тешләргә үтәрлек чыгырдау белән суырылды. Салам түбәле өй, каш сикерткәндәй, әүвәл сыңар күзе, аннан ике тәрәзәсе белән каршыдагы шомыртка, зәңгәр күккә карады. Өченче тәрәзәсен дә такта зынҗырдан азат иткәч, өй бөтен йөзенә елмаеп җибәрде: гүяки тирән сулыш алып бөтен буыннары иркенәеп, җәелеп китте. Күрше йортларда капка келәләре шакылдады. Атка чөңгергән авазлар, арба тәгәрмәче, тавык кытаклаган тавышлар, авыл өстенә җәелә барып, яңа көн, яңа мәшәкатьләр килүен хәбәр итте.

Эшен бетереп, кул сырты белән маңгай тирен сөрткәч кенә, Булат, кеше карашын сизеп, артка борылды. Рәшәткәдән әз генә калкып, аңа зәңгәр яулыклы утыз яшьләрдәге бер хатын карап тора иде.

— Исәнмесез, — диде ул. Нindидер җинаять өстендә тотылгандай, аның йөзенә кызыллык йөгерде, һәм ул, шуны яшерергә теләгәндәй, башын аска иеп алды. — Кем дип әйтергә дә белмим.

Булат үзе дә нихәл итәргә белми аптырап калды. Хатынның йөзенә карады һәм Вәзирәсен күргәндәй булды.

— Кара, Булат абый, син түгелме соң? Галәмәт, танымый торам.

Вәзирә юкка чыкты. Рәшәткә артыннан аңа чит кеше эндәшә.

— Син таныдың, ә мин таный алмыйм... Кем соң син?

— Рәсимә мин. Хисами Вәлиханы кызы.

— Кит аннан! — дигән булды Булат гаҗәпләнмәсә дә. Аның йөрәге тагын кыбырҗый башлады. Вәзирә хакында төпченебрәк сорашмакчы иде дә тыелып калды. — Кая болай иртәләп?

Аның күзе әлеге хатынның рәшәткә арасына туры килеп юка ситсы күлмәк аркылы сизелеп торган калку күкрәгенә төште. Булат якынрак килде. Озын ак муен, кан тамырының сулык-сулык тибүенә хәтле күренә. Исендә тагын Вәзирә калыкты.

— Идарәгә.

«Китмә, китмә, Вәзирәкәй».

— Йомыш юллапмы?

— Безнең көн дә йомыш, көн дә әҗәт. Бәйрәм дип тормыйсың... Кайчан кайттың, Булат абый?

— Кичәгенәк.

— Сине көтмәс булган идек бит инде. Кайберәүләрне әле дә көтәбез, сине юк.

— Әйе, әйе, ишеттем.

Рәсимә, уңайсызланып, рәшәткәдән аерылды. Нечкә бил. Таза киң ботлар.

— Ярый хәзергә, Булат абый. Эшләр ашыгыч. Барып бригадирны шатландырыйм әле.

— Йөрмә, Рәсимә... Кирәге юк әлегә, әйтмә мин кайтканны.

— Ник алай дисең, Булат абый! Берсекөнгә Атау эченә печәнгә төшәбез. Үтенсәң дә болай булмас, ихлас. Ирләр... Күктән төшкән кебек хәзер сез... тансыкка гына. Эшкә дигәндә — бәһасез.

— Шулайга охшага-ан! И-эх, Рәсимә сеңел! Ну, кайттым, ну шуннан? Ниле булдым, йә, йә? — Булат, башына яуган бөтен бәласе өчен шушы үзенә беренче булып сүз каткан хатыннан үч алган сыман, балтасын җиргә бәрде. Күңел түрендә капма-каршы хис тә өлгереп җитте. Аның Рәсимәгә эч серләрен сөйләп бушанасы, йөрәгенә утлы пычак кадаган Вәзирәсен эт итеп сүгәсе, агач корты шикелле ничә ел үзен эчтән кимереп черетүче, бәгырь тамырларын корытучы Галимҗанны дөнья ишетмәгән каһәрләр белән каргыйсы килде. Ни дә эшли алмады. Рәсимәгә күз яшьләрен күрсәтмәс өчен, балтасына иелде, астан гына күзләрен сөртте. Йөрәге җиңеләйгәндәй тоелгач:

— Юк, Рәсимә, идарәдә минем турыда хәзергә ләм-мим. Мин үзем, үз вакытым белән, үзем барып чыгармын, — диде тешләрен кысып. — Синең соң, ирең бар идеме, кайттымы?

— Бар иде, Булат абый. Укытучы Хәмит. Белмисеңдер. Сине алып киткәч, сугыш алдыннан гына безнең мәктәпкә җибәргәннәр иде. — Хатынның йөзен моң басты. Аңа аркан борылды. — Егерме беренче июньдә туебыз булды... Кайтмады. Көтәм. Юанычым бар: малаебыз...

— И-эх! Ну ничего! Бирешмә. Көт. Менә ич, мин дә кайттым. Колхозда кем булып эшлисең соң?

Рәсимә җавап бирмәде. Яулыгын төзәтте. Шул нечкә биле һәм ак муены белән борылды да:

— Бераз эшем кимегәч килеп чыгармын. Сине күргәч, бер уй туды әле миндә, — диде.

— Ярый соң. Соравыма җавап бир инде?

Рәсимә, әкрен генә:

— Парторг мин, — диде дә китеп барды.

## XI

Булат дөньясына сул кулын селтәп, урамга тиз генә чыгарга ашыкмады. Тезмәдә сакланып калган коры такталардан урам як тәрәзәләренә сырлап-бизәкләп яңабаштан яңаклар ясады, ватык пыялаларны алыштырды. Өй тирәсенә бераз җан кергәндәй булгач, кычыткан, кура баскан алма бакчасына тотынды. Туфраксадан алып төшкән чалгысын сугып кычыткан, әрем, тигәнәк, алабута, артык үрчегән кура җиләге кураларын кырып ташлады. Кинәнеп, вакыт агышын сизмичә эшләде. Тәнен ерттыра-ерттыра корыган чия, алма агачларын кисеп ыргытты. Чия бихисап күп булачак иде. Алма агачларының күбесе эштән чыккан, әмма биш-алтысы юньле күренә. Бакча яшәреп, киңәеп киткәч, эш инеш ярындагы кара мунчага терәлде. Миче җимерелеп, ләүкәләре кыйшайган, түбәсендәге юкә кабыклары череп, сыгылып төшкән, мунча эчендә нинди эссе көндә дә салкынча. Ул иртәгә нишләрмен дип үзе турында уйламаска тырышты. Шуңа күрә җенләнеп, хәлдән тайганчы эшләде. Печәннән кайтып, терлек-малын абзар-курасына урнаштырган хатыннар басмага суга, кер чайкарга төшкән саен, кайсы кызганулы, хәсрәтле, кайсы сагышлы, басынкы, кайсы шаярулы тавыш белән сүз ката. Әмма ул: «Ару гына әле», «Биргәненә шөкер», «Зарланмыйбыз, башка вакытта»,— дигәннән гайре җавап кайтармый.

Кичкырын, эңгер-меңгердә күз камаша башлаганда, ишелгән мич салынып, түбә нык кабык белән ябылып бетте. Ул, папиросын көйрәтә-көйрәтә, балыкларның буа өстен җыерчыклап чәпчүләрен күзәтте. Басмага сак кына чиләк куйган авазга борылды. Аркасы чемердәп, тәненә кайнарлык йөгерде. Көянтәсенә чиләк элеп, чүп-чар эләкмәсен өчен чиләген як-якка чайпап су алучы хатын аның Вәзирәсе иде. Булат казыкка таянып шыпырт кына читән аркылы сикереп төште, аяк очына басып басмага керде. Вәзирә, чиләкләрен тутырып, көянтәсен иңенә алды һәм, Булатны шәйләгәч, сискәнеп, чайкалып куйды, артка чикте.

— Менә очраштык та, Вәзирә. — Булат тавышының карлыгып чыгуына колак салды. — Көтмәгән идеңме?

— Булат...

Вәзирәнең кара керфекләре гаҗәпләнүдән карлыгач канатларыдай талпынып куйдылар. Булат аның күзләрендә өркү билгеләрен чамалады. Йөзе сулган, моңлы. («Үкенәме?») Чиләк-көянтә гәүдәсен сыгып аска тарткан. («Чиләкләреме, әллә тормыш йөге басамы?») Иреннәре чак кыймылдап елмаюга охшаш хәрәкәт ясый. Күзе Булатка түгел, гүя аның эченә, җанына текәлгән. Нидер әйтергә яскана, теле әйләнмәүдән интегә. Аңа авыр, ләкин түзә. Булатка хатынның эчке халәтен, аны төшенкелек, барысына да кул селтәү һәм, иң авыры, аны үткәненә кире кайта алмау үкенече басып киткәнен сизү кыен булмады. Аның күңеленә Вәзирә үз богавын үзе сала алмас, ялгышларыннан үзе арына алмас дигән шик килде. Вәзирәне бүгенге бәласеннән (аның Галимҗан белән бер куышта яшәвен ул шулай гына бәяли алды) ничек булса да йолып калырга, коткарырга, ярдәм итеп калыргамы әллә? Аны көтмичә дошманына кияүгә чыгуы хатынның гаебе түгел, бәласе ич? Хатын салкын кое төбенә егылган икән, моңа ник Галимҗан түгел, Вәзирә гаепле? Үз язмышының шундый ук кое төбенә тәгәрәвенә Булат үзен гаепләми ич? Шулай да ул Вәзирәгә карата үч ялкыны йотып йөрде. Урамга чыгып кешеләр белән аралашмавы да аны ялгыш очратырмын, кызган баштан бер-бер хәл кылып ташлармын дип куркудан иде. Үзенең яшь гомерен кискәләгән явызлык йөген ул үз иңенә генә салырга булды. Хәзергә онытылырга. Соңыннан бер җае чыгар дип, Вәзирәне күңеленнән чыгарып атарга хәл итте. Тизрәк онытыр өчен, аны эчтән эт итеп сүкте, үзен аны күралмаска өндәде.

— Ник дәшмисең, Вәзирә?..

— Ни дим соң?..

— Булмаса, «нихәл» диген, ичмасам!

— Нихәл...

Көтелмәгән очрашу Вәзирәне эчтән телгәли иде. Ул туры карарга базмый, карашын гел яшерә. Булат якын килеп йөзенә кулын тидергәч, «кирәкмәс» диде. Элек тә Булат сүзсез иркәләгәндә, Вәзирә пышылдап «кирәкмәс» дия иде. Әмма язгы сафлыкта, кышкы айлы төннәрдә, көзгә сагышлы кичләрдә бу «кирәкмәс» Булаттан битәр аның үзе өчен әйтелә иде. Менә хәзер шул сүз Булатның эченнән төртә башлаган бар ачуын юып төшерде. Бәгырьгә тамыр җәя башлаган тозлы нәфрәтне кинәт кенә кызгану җиңде. Үзенә хыянәт иткән хатынны кызганса, аңа үзен дә кызганырга туры киләчәк. Ә бусы тагын да кыенрак. Кызганыч. Бәлагә тарыган Вәзирә Булатка тагын да кадерлерәк, якынрак булып тоелды. Күрәсең, бу хис аның йөзенә дә бәреп чыккан булгандыр: хатынның тутырып караган күзләрендә ул кимсенү, бу газаптан тизрәк котылу теләген укыды. Аның да җанын ут көйдерә иде.

Булат чыдый алмады, Вәзирәнең чиләк-көянтә авырлыгыннан сыгылган иңнәренә кулын салып:

— Китик моннан, Вәзирә, ерак китик! — диде.

— Юк, юк, Булат... Рәхмәт! Башка сүз көтмә... Син намуслы кеше. Син гел шулай булып калган. Вөҗданың... шушы инеш суы күк саф...

— Вәзирә, мин — гап-гади кеше.

— Гап-гади шул, гап-гади!

— Вәзирә...

— Үтенмә! Түбәнчелеккә төшмә. Минем аннан кызым бар инде.

— Бусын белмәдем.

— Белмисеңдер шул.

— Курыкма! Кызыңны да үзебез белән апкитик...

Вәзирә сулышын чыгарган кебек кенә «аһ» итеп куйды.

Бала сүзен ишеткәч, Булатның бөтен тәне хәлсезләнгән шикелле булды. Ул карашы белән Вәзирәнең тар иңбашларын, ябыгып калган муенын, тулы салмак кулын айкап алды. Кызгануы тагын да артты, каршында торган хатынны юатасы, ничектер назлыйсы, иркәлисе килде. Тамак төбенә утырган тозлы төерне йотып:

— Ә безнеке... кайда? — диде.

Хатын куырылып, тагын да кечерәеп калды, башын түбән иде, озын бармаклары белән яулык очын бөтерде.

— Саклый алмадым, Булат...

— Кем иде?

— Малай... диделәр.

— Димәк, ул...

— Йөрәгем астында сигез ай йөрткәч... саклый алмадым. Март кичендә мәктәптә дәфтәрләр тикшереп утыра идем. Җыештыручы Мәгъсүмә апа кереп өстәлгә капланды да «Тизрәк, бүлнискә!» диде. Завхоз юк. Мәктәп атын җигеп Ак Елгага кудым. Буран чыкты. Бүреләр иярде. Шырпы алып чанадагы бер кочак саламга ут төрттем дә юлга аттым. Ат шәп иде, калдырдык... Мәгъсүмә апа бәбиен чанада тапты. Нарасыйны үземнең пальтома төрдем. Курыкканым өстенә туңганмындыр да. Больницада искә килдем. Кешенекен коткарганмын. Ә үземнеке... үле туды.

Вәзирә туктады.

— И-эх! Ничә ел улым белән хыялланып йөрдем. Ел саен бер яшь өстәп буен үстердем, башыннан сыйпадым...

— Җитте!.. Ичмаса, хет ачулан, сүк, ахыр чиктә!

— Ни өчен, ни өчен, и-эх!

— Син мине әүвәлгечә итеп күрәсең. Ә мин синең элекке Вәзирәң түгел инде. Бүтән миңа сүз катма! Кайта алмыйм артка. Юлыма киртә үскән. Кимсенмә минем янда, яме? Хәтеремдә горур булып кал!

— Вәзирә!

— Юк! Үгетләмә бернигә дә. Читләр без, читләр!..

**XII**

Өйдә, нәни кызын коендырып йоклаткач, Вәзирә чиккән сөлге эленгән көзге каршына килеп басты. Басмадагы дулкынлану, үз-үзе белән эчтән көрәшү билгеләре йөзеннән качарга өлгермәгән, битләре яна, күзләре тынгысыз иде әле. Кызын коендырганда юешләнгән чәчен тарады, толымнарының рәхәт авырлыгын тойды.

Үзен көзгедән күзәткән чагында, яңадан берсеннән-берсе чуалчык уйларга чумды. Галимҗан ник алдаган? Ни булган анда, фронтта? Булат ник шулай соңарып кайтты? Нидер өзелде. Бу «нидер»нең иң фаҗигалесе — бүгенгенең үткәннәрдән аерылуы, Булат белән булган якынлыкның мәңгегә өзелүе иде.

Һәм ул, күз яшьләренә буыла-буыла, ике толымын да муен турысыннан кайчы белән кисеп төшерде. Яңадан көзгегә карау белән хәлсезләнеп сыгылып төште. Булат белән очрашудан соң тыеп торган күз яшьләренә буыла-буыла еларга кереште.

Өй эчен калтыравык зәңгәрлеккә манчып яшен яшьнәде. Күк күкрәде һәм үзе белән Вәзирәнең үксүен еракларга таратты. Тагын мең тармаклы яшен чаткысы чәчрәде, күк гөрселдәде һәм яңгыр коярга кереште. Юеш пыялада чит кеше чагылышы күреп, Вәзирә сискәнеп китте, бер адым артка чикте. Кыска чәч һәм гаҗәп тә таныш йөз! «Чү, мин үзем ич?!» Ул пыяладан яңгыр тамчылары юган чагылышына карап торды. Пыяла түгел, аның шәүләсе елый. «Мине кызганасыңмы? Юк, кирәкми! Елама, шәүлә...» Кая кунар урын тапмагандай, өй эчендә тагын яшен яктысы айкалды һәм нәкъ баш очында гына тау-таш җимерелде. Вәзирә чытырдатып күзен йомды, кыска чәчле боек чагылыш аның миендә кайнаган кебек зырылдап әйләнергә кереште. Күкрәкне кыскан бөркүлектән һәм баш әйләндергеч күренештән арынырга теләп, тәрәзәне ачып җибәрде. Шуны гына көткән кебек, тагын күк күкрәде, пәрдәләр, яңа яшен чаткысыннан өреккән төсле, җилпенеп, кагынып алдылар. Бишектә нәни Миләүшә аваз салды.

— Бетте, бетте, газизем. Тынычлан. Әлли-бәү, бәлли-бәү. Барысы да артта...

Яңгыр әз-мәз сибәли иде әле.

Төнге сәгать уникеләрдә, манма су булып, Галимҗан кайтып керде. Вәзирә утны сүндереп яткан гына иде. Торасы килмәде. Теләсә дә, тора алмаган, авыз ачып тел тибрәтә алмаган булыр иде. Ире дә соң, арып кайткан чагында, аны артык борчымыйча, үзе кармаланып йөрергә күнеккән. Ачыкса ашын үзе генә салып ашый иде. Бүген дә шулай итте.

— Йоклыйсыңмы? — дип, хатынына да эндәшеп бакты. Ләкин төпченеп җавап көтеп тормады, шапоршопыр килеп, өйалдында брезент кожанын, итеген салды. Ыштан-күлмәктән генә калып чишенгәч, караватка килде. Хатынының кайнар иңбашына кулын салып, үз урынына ятты. Бераздан, хатынының йокламаганын сизенепме, аны үзенә таба тартты.

— Кирәкмәс, — диде Вәзирә, йокы аралаш сөйләшкән булып.

— Беләм бит, йокламыйсың. Нәрсәгә яшерергә?

— Син тагын эчкәнсең...

— Районда үзебездә төзеләчәк электр станциясенә машиналар кайтарту турында килештем. Моны да юмагач!..

— Ә кичә?

— Кичә дә сәбәбе булды. Иртәгә печәнгә төшәсе... Яңгыр гына аркылы килде менә. Ну иртәгә тиз кип-терәчәк. Игеннәргә шәп булды.

— Өченче көн?

— Мало ли ни өчен салгалый председатель. Син прәме ирең өстеннән ревизия уткәрәсең.

Вәзирәнең төпченүенә шулай түземле генә җавап бирүе тикмәгә түгел. Галимҗан хатынын үзенчә хөрмәт итә, аңа нинди кызган чакта да дорфа сүз әйтми, гомумән, аны ярата алганчы ярата, бөтен күңеле, уе, тәне белән аңа бирелгән иде. Фронттан беренчеләрдән булып орден һәм медальләр тагып кайтканга, аны чулак Гайфи урынына председатель итеп куйдылар. Исән-имин кайткан дәртле солдат, бигрәк тә ул солдатның баш кеше булуы кайбер чая хатын-кызның күңелендә вәсвәсә уятмады түгел. Ләкин аларның нинди чибәрләренә дә аның күңеле ятмады, ничәмә-ничә очрактан, хатыннарның хәтерен калдырмаска тырышып, баш-аягы белән качты, шулай була торып беренче хатыны Мәүлиянең куралмас дәрәҗәдә үзеннән көнләшүен, төннәрен арык тәне белән яфрактай үзенә ябышуын Вәзирәгә булган тойгылары белән янәшә озак яшәтә алмады. Бер низаг вакытында тәмам ярсып, хатынының төянеп күрше Кашкай авылына кайтып китүенә ирешге. Бар сәләтен биреп яшьлек мәхәббәте Вәзирә тирәсендә чын-чынлап бөтерелә, сайрый башлады. Озак тартыша торгач, бер челләдә теләгенә ирешге һәм шул кичтән соң аның күңелен күрү өчен мөмкин булганнарның ниен генә эшләмәде? Күңеленә беркемне дә кертмәде, сөюе белән Вәзирәгә турылыклы килеш кала алды: авыр сүз әйтмәде, аның үткәне хакында ләм-мим тын чыгармады. Бүген, гадәттәгегә каршы, Булат өчен яралы күңеленә (ул моның шиксез шулай икәненә шикләнмәде) тоз салырга бик теләгән һәм шуның өчен махсус эчеп тә кайткан иде. Дөрес, эчүенең сәбәбе күбрәк Булатның көтмәгән-нитмәгәндә кайтып, аның тыныч төбәгендә кыямәт уйнатуына күбрәк бәйле иде. Иртәгесе көннең үз абруе һәм тормышы умырткасына кай яктан кусәк төшерүен көтү аны бизгәк тоткандагы кебек калтырата иде. Ул көн саен, һәр минут саен Булат белән очрашуны көтеп яшәде.

— Бүген менмәгәндер ич? — диде ул, ниһаять.

— Кем?

— Булат.

— Юк.

— Очратмадың дамы? — Ул Вәзирәнең караңгыда елтыраган күзенә карар өчен башыннан тотып йөзен үзенә якынайтты.

— Чәчең... кайда?

— Кистем.

— Ничек... Тиктомалданмы?

— Тиктомалдан... — Вәзирәнең тавышы әллә ничек үзгәреп, коры яңгырады. Галимҗан моны аермачык сизде һәм чак-чак башын күтәреп, пышылдап сорау бирде:

— Булат... Димәк, очраштыгыз тәки... — Аның сүзләрендә сораудан бигрәк курку чагылды. Вәзирә дәшмәде. Мендәргә йөзтүбән капланып ыңгырашып куйды. Галимҗанның эченә, пычак кадагандай, кайнарлык йөгерде.

— Курыкма! Сиңа берни янамый. Ышандыра алам. Синең үчтеки-үчтеки иткән кадерле Вәзирәң үлгәнче сиңа кала!.. Тәмәке кабызып торма, болай да тынычлана аласың. Мин үткәнемә кире кайта алмыйм, араны өздем... Толымнарым шуның билгесе... Әйе, очраштык... — Аның тормышын агулаган бу кешенең үзәгенә үтәрдәй каты сүз әйтәсе килеп, Вәзирә тезләренә калыкты: — Әйе, очраштык. Шуннан ни булган?.. — диде.

— Кычкырма, баланы уятасың, — диде Галимҗан.

Вәзирә иренең куырылып авыр ыңгырашуын, сугып җибәрүен теләде. Әмма Галимҗан кыймылдамады да, авыр йөктән котылгандай, җиңел сулап кына куйды.

— Барып җитәме, юкмы сиңа, очраштык, — диде ул, гарьлегеннән ярсып. — Бу синең өчен барыбермени соң?

— Сөяк күрмәгән эт кебек, үзең йөгердеңмени?

— Бусы инде сиңа барыбердер, — диде ул, ачу белән.

Әмма Галимҗан яткан урыныннан кузгалмады. Кулларын җәеп җибәрде. Хатынының юри ялганлавыннан түгел, иртәгесе өчен күңеле тынычланудан. «Иснәшеп өлгергәннәр, елки-моталки. Шулай булыр дип һич көтмәгән идем. Вәзирә миннән китмәячәк, димәк. Әмма тегесе очрашмый түзмәс дип уйларга кирәк. Димәк, Вәзирәдә тынычлыгын тапкач, Булат мине күрмәмешкә салыначак. Шайтан! Вәзирәне бүлешәсе

килми дә бит... Бичарадан ни чара... Аның каравы тора-бара сүнәр, сүрелер. Вакыт әллә нинди җәрәхәтне дә төзәтә. Рус әйтмешли, «поживем — увидим». Бу уйлары аның күңеленә җылылык өргән шикелле итте.

— Әгәренки мин, сине ташлап, кире аның йортына күчсәм?

— Ничек, Миләүшәне калдырыпмы?

— Икәүләп.

— Юкны сөйләмә...

— Ышанып әйтәсеңме?

— Ышанып.

— Йа Хода!.. Ник?! Ник...

Һәм күзен томалаган яшь пәрдәсе аша Вәзирә нигәдер әллә кайчангы бер кичне искә төшерде.

...Берчак Вәзирә район үзәгенә барды. Йомыш юллап йөри торгач, райком янында Галимҗанга тап булды.

— Нишләп йөреш? — диде Галимҗан, хәл-әхвәл сорашып тормастан.

— Ронога, вак-төяк йомышлар белән йөрим.

— Әйдә, апкайтам.

Вәзирә, аның гаҗәпләнүенә каршы, карышып тормады, сусыл клевер түшәлгән тарантаска җиңелчә генә менеп утырды да:

— Соңга калабыз. Бераз кауласаңчы. Караңгы төшеп килә, — диде.

Галимҗан каты итеп айгырга чөңгергән булса да, дилбегәне аз гына да бушатмады. Үз кырларына җитеп, арыш эченнән сузылган тузанлы юлга килеп кергәч, атын тагын да тыя төште һәм, бераз эчтәрәк утырган ялгыз карама турысына җиткәч, бөтенләй туктатты, көпчәкне караган шикелле бераз маташкач, Вәзирә янына килде.

— Мәүлия киткәнгә өч ай. Аш пешерер дә кешем юк. Мәүләви абзыйларда ашап йөрим... Галимҗан Вәзирәнең кояшта каралган сыйрагына, беләкләренә күз төшереп алды. — Синең турындагы уйларым сөлек булып канымны суыра, аңлыйсыңмы син?!

— Уйлама, суырмас.

— Суырмас? Миннән торса иде!

— Миңа нишләргә кирәк соң суырмас өчен? — диде Вәзирә, тыныч кына. Әйтерсең сүз аның хакында түгел, ә ниндидер әйбер турында иде.

— Минеке бул. Минеке бул! Гомер буе тол яшәрсеңме?

— Миннән сөяркә ясамакчы итәсеңме? Гөнаһ сүз сөйлисең, председатель. Хатының кайтыр, ашарга пешерүчең булыр.

— Хатыным... — Галимҗан тузанга төкерде. — Колга! Безнең хәтта балабыз да булмады. Мин бит аны Булат белән сиңа үч итеп күрше авылдан алып кайттым, сөйрәлчек эт ул...

— Мине дә шул хәлгә төшермәкчеме?

— Беләсең ич, беләсең, яратам!

— Ә Булат? Кайтыр, бәлки...

— Үлде ул, үлде! Танк таптады. Үзем җирләдем. Ничә әйтергә? Үлде! Аңлыйсыңмы, үлде!!!

Кичке бөркү һавада Галимҗанның сүзләре Вәзирәгә баздан ишетелгән күк тоныгаеп, әмма аермачык барып җитте. Дөнья (инде ничәнче кат) сүнде. Элек председатель күпме кабатласа да, күңеленең кай җирендәдер бер ышаныч кала торган иде. Бүген аның соңгы мыскалы да юкка чыкты. Күзен томан каплады. Кызарып, дөньяны чит бер манзарага күмеп батып барган кояшны ниндидер җанварга охшаган болыт каплады...

...Шушы күренешне исенә төшереп, Вәзирә калтыранып куйды.

— Әшәке син. Туймас тәнеңдәге сөлегеңне минем йөрәккә каптырдың, — диде һәм ыңгырашып ястыкка капланды.

— Йоклыйк әйдә. Иртүк торасы бар. Яңгыр туктады, иртәгә печәнгә төшелер, — диде Галимҗан һәм стенага таба әйләнеп ятты.

Узып киткән яңгырның ерак аҗаганнары кабынгалады. Алар Вәзирәнең ачык күзләрендә озак чагылдылар әле...

**XIII**

Вәзирә белән хушлашкач, башында кайнаган уйларын юарга теләгәндәй, Булат озаклап су коенды. Кызган тәне суынып, гәүдәсе җиңеләеп калды. Өйгә кайткач, спирт эчеп, әзрәк капкалап алгач, апасы җәеп киткән чиста урын-җиргә сузылып ятты. Үз өенә кайтып, йомшак һәм җылы урында ятуы әле дә сәер

сыман. Ялгызлык. Тынлык. Күңел ышанмый. Күңел янәшәдә, такта сәндерәләрдә саташкан, буылып йөткергән, сүгенгән, пышылдашкан меңләгән арык, ач гәүдәләр кыймылдавын ишетеп ята кебек. Барак ишекләре, тупсалары каерылыр чиктә ачылыр да, этләр җитәкләп эсэсчылар өере кереп, типкәли-төртә лагерь артындагы упкынга куарлар, һәм алар, аяк астындагы бозлы таш кисәкләре шикелле, тавыш-тынсыз түбән коелышыр яисә нәкъ аңа, Булатка, җирән комендант чишенергә кушар. Аннан кемдер аның башына канистрдан бензин агызыр һәм читкәрәк китеп шырпы сызар. Комендант перчаткасы белән ябыклыктан күзләре генә чекерәеп калган оркестрантларга изәр: «Балет дикарей!» Булат чәбәләнеп боз өстендә аунар, чытырдап тәне янар, ул акырыр, акырыр...

Төш. Өн түгел, төш!.. Мамык ястык та, түшәк тә юк. Ул кеше гәүдәләре ышкылудан ялтыраганчы шомарган такта сәндерәдә ята. Комендант керә һәм спирт тулы калай кружка суза: «Пэй, пэй! У нас много, пэй!.. Кончил? Молодец!.. А теперь это пэй!» — Һәм ул шул ук кружкага бензин салып бирә...

Кинәт яшен чатнап уйнаклый. «Инде янам дамыни?» Күк күкри. «Оркестр»... Тәрәзәләрдә яңгыр тамчылары шакылдый. «Бии дә башладылар. Йөзләгән агач башмаклар шакылдый, сәләмә киемнәр кыштырдый, әсирләр гыжылдап сулыш алалар. Бииләр, бииләр, ул уртада, яна... Аның ялкыныннан бөтен күк зәңгәрсу ут булып калтырый». Чатырдап күк чатный. «Егылганнарны аталар...»

Бер сәгатьләп койгач, яшенле яңгыр ашыкмый гына узып китте. Тын өй эчен ялгыз чикерткә сайравы күмде. «Һе, чикерткә! Тургаймыни? Кай ара?» дип шатланды Булат. Бая эчкәнгә җиңелчә башы әйләнде. Тамагы чатнады. Торып су эчте. Белә иде: спирттан соң су эчкәч исертә. Исерәсе килде. Ялгызлыктан котылу чарасы. Дөресрәге — качу. Ул спиртны кирәге чыгар дип биш бәясенә Казан базарында бер карт чегән хатыныннан сатып алган иде. Күптән эчкәне булмаганга, аракы аны тиз баса. Иялэшергә язмасын. Полковник чамалап кисәткәндер.

Полковник Григорьев — аның лагерьдагы иптәше иде. Керәшен. Татарстанда булмаган, Себердә үскән. Ул аны ике мәртәбә үлемнән йолып калды. Беренче тапкыр әсирлектә. Бер яктан төпсез упкын, икенче яктан текә таулар тезмәсе белән кысрыкланган лагерьны бер кичне Англия самолетлары бомбага тота башлагач, әсирләр тау-таш арасына таралышып качып беттеләр. Булат та шашкан кешеләргә иярмәкче иде, Григорьев туктатты.

— Ник? — диде Булат.

— Иртәгә күрерсең әле.

Иртәгесен таң белән лагерьны саклаучы эсэсчылар батальоны качкыннарга ау оештырды.

— Лагерьга керү юлы берәү генә, — дип аңлатты Григорьев. — Чыгу юлы икәү. Берсе кергән юлдан. Тик аннан мәче дә үтә алмый. Тарлавык очында пулеметлар, чәнечкеле тимерчыбык. Кергәндә күрмәдегезмени?

— Бөркәүле машина белән китерделәр.

— Сезнең бәхет чирткән. Без җәяүләп килдек. Килә-килешкә үк колоннадан биш кешене аттылар. Икесе упкынга очты. Үзләре... Мәйтәм, икенче юл... үзең беләсең: «Кыргыйлар балеты». Аннан туп-туры җәннәткә, бәхетебез басса, безгә багышланган догалар хәерле булса, әйе. Ә болай... Кая качма — упкын, кыя. Җан әсәре очратырмын димә. Лагерь урыны — табигый тозак. Җаныңны язмышыңа ышанып тапшыр да көт.

Кыялар өстендә көне буе автоматтан атулар, этләр өрүе, әсирләрнең этләр талаганда ачыргаланып кычкырулары кайтаваз булып адашып йөрде. Лагерьда калганнар пулемет сагы астында кызганып һәм нәфрәтләнеп шул авазларны тыңлады. Төркемләп-төркемләп тоткыннарны кире лагерьга алып кайттылар. Комендантның ак перчаткасы упкынга таба изәде. Кичен, вышкаларда прожекторлар кабынгач, куркышып бер-берсенә елышкан соңгы төркем янына ул спирт салынган калай кружка тотып килде... Оркестр күңелле, мәзәк көй уйнап җибәрде. Лагерь ишегалды яктырып китте. Бу юлы әсирләр «балет»ка катнашмадылар. Алар комендант һәм автоматлы сакчылар белән бергә үзләре тамаша кылдылар. Бүген качкыннар гына биеде. Мәйданны ит исе, атылганнарның кан исе тутырды.

— Кара, Рәхимов, син сөйләгән авылдашыңның әлеге этлеге болар алдында чүп, әйе. Шунысы бар: йөрәгең ташка әйләнмәсен. Безне яратып туймаган хатыннарыбыз көтә. Таш йөрәк ничек сөйсен, әйе.

Озакламый аларны инглизләр азат итте. Ашык-пошык тикшергән, сорашкан итеп кылангач, өр-яңа совет формасы кидереп, аларны Англиягә үк алып киттеләр. Павел Юрьевич полковник формасыннан иде. Англичаннар ак чәчле совет полковнигы тирәсендә бик нәзакәтле бөтерелделәр. Диңгез ярында урнашкан күңелсез бер шәһәрдә аларны сугымга әзерләгән кебек ашаттылар, эчерттеләр. Инглиз сержантлары кичләрен шәһәргә чыгарырга да бик теләп риза булалар иде.

— Җәннәт ич бу, җәмәгать! Хет өйләнеп җибәр, ә, егетләр?

— Өйлән, үрчерсең, — диде полковник, чая кыяфәтле бер адәмнең әйләнә-тирәдәгеләргә шәһәрдә күргәннәрен сөйләп утырганда. — Оныттың дамыни, хәшәрәт?

Берничә кат Булатны үзләре яши торган ак җәймәле караватлар тезгән барактан лагерь түрендәге кечерәк йортка чакырып алдылар. Монда күпләр булган иде инде. Кайберәүләр, кабат-кабат шунда чакырыла торгач, башка күренмәс булдылар. Тик андыйлар бармак белән генә санарлык шул. Булат инглизләрнең кая каеруларын тиз төшенде. Григорьев аны кисәтеп өлгергән иде инде. Шуңа күрә гаиләсен, тормышын кайгырткан булып төчеләнгән майорга туп-туры әйтте:

— Куркытмагыз. Әсирлеккә үзем теләп төшмәдем. Аңларлар. Сездә калу — туган илгә хыянәт итү, — диде.

— Юк, юк, без кал дип әйтмәдек, дөрес аңлагыз.

— Кыек сүзнең исе яман. Гомумән, языгыз. Ватаныннан түбәнчелек белән кичерүне үтенеп, кайтаруларын таләп итте, диегез.

Тылмач, яшь лейтенант, майорның колагына иелеп, үзенчә нидер бытылдап алды.

— Шулай да уйларга киңәш итәр идем. — Майор бер папка ачты. — Сез — штрафник, гаиләгез күптән Себердә. Минемчә, өмет күгегез караңгы.

— Мин өзеп әйттем. Өстәр сүзем юк.

Икәүләп шәһәргә чыгып киткән иделәр. Гади генә бер ресторанга керделәр. Бераз утыргач, Павел Юрьевич каядыр чыгып торды. Ул китүгә, ачык күкрәкле бер хатын килеп утырды. Ханым, мөмкинме дигән караш белән озын сигарет кабызды, төтенен аның йөзенә өреп:

— Сезне дустыгыз көтә, — диде.

— Павел Юрьевичмы? Кайда ул?

— Тегендә, — диде хатын һәм икенче катка менә торган борылмалы текә баскычка ымлады. — Әйдәгез, озатам.

Булат, шикле бер тойгы кире өндәсә дә, кыймый гына әлеге хатын артыннан өскә күтәрелде. Хатын әллә юри, әллә чынлап кара челтәрдән тегелгән күлмәген артык югары күтәреп аның артыннан атлады.

Икенче катта коридор башындагы якты бүлмәгә керделәр. Бүлмә уртасында берничә шешә эчемлек һәм алма тезелгән түгәрәк өстәл. Шактый ук киң диван. Каршы якта чаршау белән генә корылган икенче бүлмә ишеге иде булса кирәк.

— Полковник кайда?

— Ә-ә! Ул хәзер керер. Нинди сабырсыз! Мин полковниктан ким мәллә? Әллә сез, руслар, безгә караганда... ирләрне өстенрәк күрәсезме? — дип тәтелдәде хатын туктаусыз һәм, терәткечкә таянып, диванга җәелде. Утырганда сиздерми генә тезләрен ялангачландырырга онытмады.

— Утырыгыз.

Булат үзенең башы әйләнә башлавын сизде. Чыгып китәсе килде. Әмма үзен биләгән кызыксынудан арына алмыйча, моның ахырын көтте.

— Хәзергә... эчемлекләр белән... юана торыгыз, — диде хатын, елык-елык атлап өстәл янына килгәч. — Сез... син нәрсә телисең: вискимы? Аракымы? А, конечно, аракы! — Һәм ул озын бер бокалга аракы салып Булатка сузды. — Җиңү котлы булсын!

Хатын уймак хәтле генә рюмканы авызына каплады. Булат үз тәненең уйнак дулкын белән тулуыннан эсселе-суыклы булып аракы эчте. Инде ни гомер күрелмәгән ал битле алманы авызын тутырып умырып тешләп алды.

«Пал Юрьич, ә? Һәрвакыттагыча, үткен, каһәр. Нинди табын әзерләткән», — дип уйлап алды.

— Син русча авырсынып сөйләшәсең...

— Мин — татар.

— Татар? Кызык! Тере татар. Мин аларны гел дәү авызлы, дәү тырнаклы итеп күрә идем.

— Ничек алай?

— Әти сөйли иде. Унҗиденче елда әнине алар үтергән. Безнең усадьбага ут төрткәннәр. Әни шунда янган... Татар... Ә син... Ничего: озын... кара күзле... Эч тагын, эч... Ә хәзер кил монда, монда, диванга... утыр...

Бүлмә әйләнә, ул әйләнә, челтәрле кара күлмәк аша ак тәне чакырып торган эмигрант хатын әйләнә. Җанга үтеп керә торган сагынулы пышылдау әйләнә. «Вәзирә, Вәзирә!! Синме бу, синең иреннәреңме бу? Сагынган мин сине, сагынган».

Булатны ниндидер чит аваз айнытты. Капыл гына күтәрелсә, чаршау җан кергәндәй селкенеп куйды, йомшак аяк тавышы ишетелде. Ул, сикереп торып, шунда ташланды, ләкин хатын ирек бирмәде.

— Ни булды, ни бар?

— Анда — кеше!

— Күзеңә күренәдер, син исерек.

— Исерек, пычагым! Кы-ыш...

Чаршауны ике якка ачып эчтәге бүлмәдән ике кеше чыкты. Булат тәрҗемәче лейтенантны шундук танып алды.

— Менә нәрсә, солдат, без монда... син маташкан арада бер-ике кадр төшереп алырга өлгердек. Иртәгә аларны синең шәхси кәгазьләрең белән Лондондагы совет илчелегенә тапшырачаклар. Сез кәҗәләнүегездән туктамасагыз, билгеле. Бәхәсне иртәгә дәвам итәрбез. Хәзергә... Хэм, кунакны түбән залга озатып куй. Киттек, тутый кош, — диде ул һәм ханымны кочаклап ишеккә юнәлде. Булат, мәче шикелле, аларның юлына аркылы төште. Кизәнеп тә тормастан лейтенантның боксчыныкы кебек нык, итләч ияк астына сукты. Моны көтмәгән лейтенант үзе артыннан «тутый кош»ны да ияртеп арты белән өстәлгә капланды һәм шешәләр, алмалар белән бергә идәнгә ауды. Икенчесе шул ук секундта сул кулының кыры белән Булатның янтыгына сыдырып алды, уң йодрыгы сугарга өлгермичә һавада айкалып калды, ә үзе артка атылды.

Булат тын ала алмый бөгелеп торган арада, кемдер аның кулыннан эләктереп ишеккә сөйрәде.

— Йөгер!

Булат, Григорьевның дулкынланган тавышына буйсынып, бормалы баскычтан түбән ташланды.

— Тизрәк, тизрәк лагерьга, мәми авыз! Түтәйләр шулай алар, сыйлары — ике яклы пычак, әйе!

Куа килүчеләр күренмәде. Ниндидер караңгы урамнар, ишек аллары, утын әрдәнәләре арасыннан лагерь урнашкан елга буена якынлаштылар. Күпергә кергәч, Павел Юрьевич култыкса аркылы түбәнгә бер нәрсә ташлады.

— Ни ул, Пал Юрьич?

— Ни, ни! Тегеләрнең фотоаппараты, менә ни! Көчкә эләктердем.

— Менә эт, ә? — дип сөйләнде Булат, кайтып яткач. — С-сучка!

— Ярар, бу юлы, бәхетеңә каршы имин котылдың. Әйе!

— Үзем дә сизми калдым, Пал Юрьич!

— Әзрәк эчәргә кирәк. Кисәттем. Аракы ул — эч кенә. Дөньяңны ал да гөл итә. Ияләш кенә...

Корабльгә төялеп туган ил ягына юл алгач, Булатның шатлыгы эченә сыймады.

— Пал Юрьич! Әйдә хәзер туп-туры минем авылга кунакка! Кая барасың? Беркемең юк. Ял итәрсең, билләһи.

— Ашыкма... — диде полковник боек кына, ак ефәк чәчен җилгә куеп. Булат аның күзләрендә яшь күрде.

Томанга уралган Англия яры күренмәс булгач, озатучы совет капитаны, әсирләрне тезеп, формаларны салырга боерды.

— Тикшерелгәнчегә хәтле әнә тегеләрен кияргә, — диде капитан.

— Менә шулай, — диде Григорьев. — Кунак-төшем кичектерелә, әйе...

Мурманскига кайткач, аларны аердылар.

— Йөрәгең ташка әйләнмәсен, Рәхимов. Язмыш шундый ул. Әйе, — диде Григорьев хушлашканда. — Иң әһәмиятлесе — без Туган илдә. Аңаябыш!..

Булат изрәп йокыга киткәнен сизми дә калды.

## XIV

Иртән торганда яңгырның эзе дә калмаган иде инде. Дымга сусаган җир күлдәвекләрдәге болганчык суның соңгы тамчыларына хәтле суырып бетергән иде. Яфракларында, кәүсәләрендә яңгыр тамчылары җемелдәшкән каеннар, тупыллар, бармак калынлыгы тузаны басылып, шадраланып калган юл — кичәге яңгырның телсез шаһитлары — тирә-юньгә сафлык бөркәләр сыман. Кояшның кыйгач нурлары шул сафлыкта коенып, оеган тәнгә рәхәт бер йомшак сулышын өрә. Ләкин Булат үзен чәйнәлеп ташланган сагыз хәлендә итеп тойды. Соңгы якыны Вәзирә дә аннан йөз чөерде. Дөрес, яратмаудан, туюдан түгел. Аны гына гаепләп тә булмый. «Күрәсең, минем дөньяга хаҗәтем юктыр. Менә бу җиһанга... И-эх!» Булат кинәт күңелендә төпсез бушлык сизде. Йөрәге кысып, чеметеп, бермәл сулыш ала алмый торды. Хәлсезләнеп, эскәмиягә утырды. Күкрәген эчтән йөзләгән энә чәнечте. Ул табигатькә, буа аръягындагы киң болынга, яшел кырларга, ерак урманга сагышланып карады. Тын калган авыл урамында үзен шундый ялгыз итеп тойды, — күзенә яшь килде, тамак төбенә төер утырды. Чигәсенә кемдер кургаш чүкеч белән «Хаҗәтең юк, хаҗәтең юк» дип сукты да сукты. «Шушында тудым, үстем, сөйдем, әче тир түктем. Тормышымны җәрәхәтләп шушында тоз сиптеләр. Кан койдым. Күпме мәсхәрәләргә түздем. Ничек каршылыйсың, туган җир, куган җир, торган җир? И-эх! Мине бөтенесе оныткан. Мин — ник туганга үкенгән сукбай. Чит мин. Вәзирәгә чит. Рәсимәгә... чит. Бер апа калган. Бөтен дөньяда — бер апа! Хәер, аның үз хәсрәте дә ургыган. Чит! Чит! Чит!!!»

Хәтеренә Григорьевның: «Иң әһәмиятлесе — без Туган илдә. Аңа ябыш!» — дигән сүзләре килде. «Кайда син, Пал Юрьич? Мин әнә туган илгә кайткач та өч ел нужа чиктем әле. Күпме урман кистем. Ышанмадылар. Ябышырга ирек булмады. И-эх! Тукта! Ә хәзер? Ник ябышмыйсың хәзер? Үпкәләдеңме? Идарәдән килеп, ачык чырай, такта чәй белән чакыруларын көтәсеңме? Син бар, картларга сәламеңне җиткер, аңламасలармыни? Ихтирам итәләр иде ич?! Син, сабый!..» — «Дөрес, Рәхимов, язмыштан узмыш юк». — «И-эх! Пал Юрьич...»

Булат уйлары бөтерчегендә ярты көн әйләнде, тугланды. Эсселектән әлсерәгәч, салкынча һавалы келәткә кереп аунады, ни кылырга белмәүдән аптырап, читән аша кереп, Гайшәбикә карчыкның бәрәңге буразналары арасындагы түтәлләреннән бер уч суган кыягы өзеп керде дә спиртка ябышты. Эсселек тиз мәлҗерәтте. «Рәсимә дә килмәде. Онытканддыр». Ачык ишек яңагына сөялгән кешене шәйләп, аңа текәлде.

— Син кем? Хәтерләмим.

— Кунак. Кунакка, чакырылмаган булса да, хөрмәт кирәк.

— Кер. Ризыгың — суган, эчкәнең хәмер булыр.

— Рәхмәт, эссе бит.

— Ә менә миңа салкын. Күрәсең, җылынам.

— Йә, сөйлә, — диде «чакырылмаган кунак», сәкедән урын алды. — Ни белән кайттың?

— Ни белән кайттым? И-эх! Ни белән озатсалар — шуның белән.

— Ачыграк сөйлә.

— Ачыграк тек ачыграк. Яшерен-батырын серләребез юк: күңел тулы таш белән. Үпкә һәм... усаллык өрәкне шулай таш иткән. Шуларны бүләк иткән кешенең танавына төясе генә калды. («Йөрәгең ташка әйләнмәсен, Рәхимов».) Калтырасын бераз. Ләззәтләнеп каласым килә.

— Кы-зы-ык, — диде кунак һәм, суган кыягын ярып төргәч, керт итеп тешләп алды.

— Әх, кыз-ы-ык?! Бер карасаң, тамаша! Бер сәхнәдә дә уйналмаган кәмит! Әкәмәт!

— Димәк, үпкә һәм куеныңа таш йомарлап кайттың?

Булат, башын күтәреп, ирексез әңгәмәдәшенә беренче кат карады. Чәчләре, хәтта кашлары да агарган ач яңаклы йөз. Тирән моң яшеренгән кара күзләр, тирләгән җыерчыклы муенында ал яра җөе. Әз генә чалшайган борын...

— Тукта, тукта... Кем дип әйтим... Рәүф абый, синме дим? Мин киткәндә, дөресрәге, мине алып киткәндә, МТСта директор идең. Яраңның, нидән икәнен беләм: Шахновода, утызынчы елгы сәнәкче кулаклар бунты истәлеге, шулай, ахры? И-эх! Мать честная! Соң, исәнме, Рәүф абый!

— Таныдың тәки. Исәнме, исәнме, туган!

— Каян җил ташлады мин ялгызак янына?

— Ишетеп кердем. Колхозның, аннан МТСның иң яхшы бригадиры... Элеккеге... Печән өстендә аракы чөмерә... Бәлки, фронтовиктыр...

— Булды. Анысы да. Менә монда, — Булат уң күкрәген кысты, — фашист пулясы. Ә син хәзер кем?

— Әүвәл кем булсам, бүген дә шул. МТСта директор...

— Минем янга... ни йомыш белән?

— Болай гына. Хәл белеп кенә керүем. Танышлар, дуслар ич чүтеки.

— Бар иде заманалар! Берчакны рөхсәтсез-нисез үзебезнең колхозның байтак җирен сөреп ташладым да, ай буе сүктең.

— Әйе, истә... үзсүзле мужик идең. Хәзер дә шулай булып калгансың, күрәм.

— Ничек — хәзер дә?

— Кайтканыңа биш көн, күзгә-башка чалынмыйсың, диләр.

— Кемнәр ул? Инде сөйли дә башлаган. Галимҗанны әйтәм.

— Председательме?

— Әйе.

— Бүген очрашсак та, синең хакта аны-моны әйтмәде. Мәүләви ага сөйләде. Үз урынына сине бригадир итеп куярга да ул тәкъдим итте.

— Минеме? Бригадир итепме? — Булат көлеп куйды. — Ун ел төрмәдә яткан уголовникнымы?

— Тәкъдим итеп кенә калмады. Тагын кайбер нәрсәләрне дә ачыклады ул.

— Анысы ни тагы?

— Синең нинди «уголовник» икәнеңне аңлатты.

— Тагын шул балык башы! Кайда мин — тегермән ташындамы? Әйләнәм дә әйләнәм. Мать честная! Тормыш — тегермән ташы. Ялгыш атладыңмы — он итә, тузан ясый синнән!

— Кызма! Менә шул: мин утыз сигезенче елда үтә шаккаткан идем сиңа. Ышанмаган идем. Атасы колхоз өчен җанын фида иткән комсомолец — халык дошманы!

— Кем соң мин, Рәүф абый, ә? Дошман түгелмени? Совет суды ялгышмастыр.

Син спирт белән суны бутама. Совет суды һәм вакыт — икесе ике нәрсә. Кибеткә ут төрткән өчен генә түгел, әйтелмәгән сүз өчен дә синеке ише генә иза чикмәделәр.

— Аңламыйм, аңларга да теләмим. Син... директор кеше... Мин... яңа төрмәдән кайткан. Яңадан... китәсе килми. Шушы җиргә тырмашып үләсе килә!

— Миннән шикләнәсеңмени?

— Анысы да бардыр. Хәер, синнән битәр үземнәндер.

— Юкка!.. Дуслар идек ич. Синең атаң, Рәхим абзый булмаса, бу яра белән генә калыр идеммени? Директор муенындагы җөйгә кагылып алды. Мине ул коткарды ич — мәрхүм. Шулай булгач, әйдә, эш хакында сөйләшик. Кыскасы, Мәүләви карт яңадан мич башына ашыга. «Ырматыз аякларымнан сугыш кына сөйрәп төшергән ие», — ди. «Кызыл таң»да синнән гайре кандидат юк. Хәзергә бер-ике ай монда, аннан, әйдә, элекке урынга, МТСка. Ә кибет яндыру... Мәүләви карт иртүк ат абзарына төшешли барысын да күреп, ишетеп торган. «Бу көенчә тынычлап үлә алмыйм, бу йөкне каберемә алып китәр хәлем юк», — дип зар елады.

Булат стаканга текәлгән күзләрен Рәүфкә төбәде. Бармаклары агарганчы папиросын кысып өстәл тактасына кадады.

— Ышанмыйм! — дип кычкырды ул, яртылаш тулы стаканны авызына бушатты. Басынкы, көчсез тавыш белән дәвам иттерде. — Соң... Ник әйтмәгән шул чакта, ә? Рәүф абый...

— Син ул вакыт ни өчен КПЗ дан качкан идең? — дип сорады Рәүф аның сораулы карашына җавап бирмәстән.

— И-эх! Уйлап кара, Рәүф абый! Өйләнгән хатыныңны кыз килеш ничек тол калдырасың? Мине туемнан алып киттеләр ич.

— Шула-ай... Аракыны, беләсеңме, кем куйган сезнең мунча туфраксасына?

— Кем булсын! Ул, Галимҗан, Сирай мөртәте. Ул хәшәрәт! Үч итеп... Вәзирәгә авыз суын корытып йөргән иде. Кайтсам — морадына ирешкән. Минем генә түгел, бәхетсез хатынның аяк-кулын гына түгел, җанын да тышаулап куйган.

— Ул түгел шул.

— Кем... тагын?!

— Мәүләви. Галимҗан кушуы белән. Нәрсәгәдер сатылган. Шуның өчен әйтмәгән дә. Ике ут уртасында. Галимҗанны тоттырыр иде — таякның икенче очы аның башына да төшәсе. Кичә мин аларда кундым. Яңгыр. Төне буе сөйләп чыкты. Үкенә. «Әҗәл килүен сизәм, шуңа сөйлим», — ди. Дөрестән дә, бик бетәшкән. Искитмәле. Шушыңынчы ничек бригадир хезмәтен үтәп йөргәндер. Сугыш инде... Бөтен нәрсәне башаягы белән әйләндереп куйды. Картлар мич башыннан төшеп яшәрмәсә, яшь хатыннар ирләрен чаларып каршыларлык дәрәҗәдә эшләмәсә, яшүсмерләр ир була белмәсә, җиңәр идекме? Син тимә. Вөҗдан газабы утында янсыннар, тимә. Аннан... болай да азны күрдемени безнең халык?

Булат эндәшмәде. Тырнаклары белән стаканга чирткәләп, ниндидер көй көйләде.

— Хәзер нишләргә соң? — диде ул көчсез. — И-эх! Бер нәрсәгә төшендердең син мине, Рәүф абый. Әйтәм ич, тормыш — тегермән. Тик аңа суны без үзебез коябыз икән ич. Мин, Галимҗан, Мәүләви, Вәзирә... Аннары син. Ә син бөтенләй икенче якка коясың. Аңла шуннан: кайда ул дөреслек, и-эх! Күрәм, мин күптәннән нәкъ синеңчә уйлап йөргәнмен икән. Әле генә мин сиңа күңелем тулы таш дигән идем... Дөресен әйткәндә, берни юк анда! Көзге ялан шикелле буш. Усаллык та юк, үпкә дә. Шул бушлыкны менә аракы белән тутырмакчы булам да... Сагыш ул — мичкә белән бер. Бер төбе төшсә, тутырам димә. Әллә, мәйтәм, китәргәме соң?

— Кая?

— Кем белә... Ә? Юк шул, җибәрми мине бу җир. Минем бер дус бар иде, полковник. «Туган илгә ябыш», — дия торган иде.

— Хак әйткән.

— Хагын хак та бит... Ничек соң мин шул Галимҗан белән рәттән...

— Мин җәллим аны. Бер ялгышкан да шуның шулпасын бөтен гомер буе эчә инде. Ул да бит, атасыннан аерылып, беренчеләрдән колхозга керде. Ярыйсы гына иңләде. Шул чагында — ышанычсыз мәхәббәт. Бәлки, ул да сөйгәндер Вәзирәне, ә? Сугыш... Биш ел ут эчендә. Аның да гомере бер генә. Күрәсең, шыр җибәрмәгән — орден, медальләр. Коммунист булып кайтты. Колхозы районда алдынгылардан. Дөрес, бераз каты куллырак. Бүгенге колхозчыны арттан куалап торсаң да бик таман. Аякка басканчы бөтенесе белән килешергә туры килә.

Директор сөйләп бетермәстән, Булат ястыкка капланды. Баш очыннан гүя пулялар сызгырып үтте. Эчтән тагын нидер чәнчеп алды.

— Нәрсә, нәрсә булды? — Рәүф, иңбашыннан тотып, аны торгызмакчы итте. — Син нәрсәдер яшерәсең бугай, Булат?

— Әй, — дип кул селтәде Булат. — Булмыйм мин бригадир!

— Тукта, тукта, ник алай?

— Хакыйкать — тирән. Төбенә төшәрлек түгел. Шуңа булмыйм.

— «И-эх! И-эх!».. Уфтанасың, көрсенәсең, үкенәсең. Бәгырьгә тия.

— Сугыштан соң... Тәмугтан чыгып тагын тимерчыбык киртә эченә куып кертсеннәр әле. Өч ел тикшерделәр: ничек, ни өчен әсир төшкән... Ышандылар ди! Җитмәсә минем ише штрафникка. Штрафной батальонда идем мин. Исбатла! Яралар — телсез. Менә шулар бер йөрәккә сыярга тиеш. Бүре булып уларсың, бүре. Аннан... Галимҗан... Сөйләрмен әле бер. Хәзер — юк. Без бит аның белән фронтта да очраштык. Тәкъдир диген. Яралы килеш мине ташлап качты. Ә каршыга — немец танклары.

— Әйе-е... Булат дус, кара әле, сәгать ярым серләшәбез. Сүзнең ахыры бетмәс. Әйдә кырга. Кешеләргә күнегергә кирәк сиңа.

— Хак. Күнегергә кирәк. Эшенә дә.

— Бәлки, минем белән печәнчеләр янына төшәрсең? Минем сугыласы бар иде.

— Йөз грамм тотыйк та...

— Синең исәнлеккә дисәң генә.

— И-эх!

— Бусы, ичмаса, шәп, и-эх! Җегәрле!

## XV

Кояш шактый күтәрелгән иде инде. Ул рәхимсез кыздыра. Җил юк. Нигез буендагы тузан чокырчаларында тавыклар кызына. Авызларын ачар дәрәҗәдә әлсерәсәләр дә, ышыкка качмыйлар. Бер-ике карчык тау астына арканлаган бозауларны эчерә. Буш урам буйлап МТС директоры тарантасына утырып бару һәм ачык тәрәзәләрдән карап калган карт-корының карашын сизү Булатны уңайсызлый. Ул, дилбегәне үз кулына алды, биеп барган атка ирек бирде. Чем-кара айгыр урыны-урыны белән кипшенеп җитмәгән авыл урамы буйлап җиңел генә җилдерә башлады. Булат күп өйләрнең кыйшайганын, берничәсенең сипләтергә исәплләп, тәрәзә асты бүрәнәләре сүтелгәнен күреп узды. Ара-тирә тәрәзәләре кадакланган йортлар, түбәләренә хәтле алабута әрекмән басып киткән каралты-куралар каралып калды. Колхоз амбарлары, авыл читендәге мал абзарлары тирәсеннән узганда, Булат яңа салынган каралты-куралрга игътибар итте. Аның карашын Ислам күреп алды.

— Сираев — молодец. Байтак нәрсә корыштырып куйды. Быел электростанция төзергә ясканып йөри. Тегермән, аның янына йон тетү машинасы. Авылга электр кертмәкче. Хуҗалык җанлы.

— Кем белә кешене, — дип мыгырданды авыз эченнән Булат. — Районда яхшы исәптә алайса?

— Зарланмыйбыз дияр идем... Чәчүгә дә беренче булып ул төшә. Икмәкне дә алдан тапшырганын беләм.

Ике-өч чакрым юырта торгач, кашлакка күтәрелделәр. Үзәнлеккә тышаулап җибәрелгән атлар, хатыннарның чуар яулыклары, билгә тикле чишенгән ир-атларның рәткә тезелеп печән чабулары күренде.

Булат әүвәлгечә көр тавыш белән болынны яңгыратып, халык белән исәнләшергә, хәл-әхвәл белешкәч, җиңел бер чалгыны эләктереп, кәс-кәс печән чабарга теләде. Аннан, арыш умачы салып пешерелгән аш ашап, бер кружка мәтрүшкәле чәй эчкәч, кулын баш артына салып чалкан ятасы, кыз-ыркын һәм җилкенчәк егетләрнең төн уртасына хәтле тынмыйча көлүләренә изрәп яшьлеген уйлыйсы, бөтенләйгә кайтуын җаны-тәне белән тоясы, хәтерне богаулап торган ун еллык газапны шушы бер кичтә онытасы килде.

Кичәге яңгыр чылатып үткән покосларны әйләндерүгә карчыклар, бала-чагалар, яшь кызлар, аргы башта чалгы селтәүче хатыннар, ирләр, тир ялтыраган маңгайларына учларын куеп, бер мәлгә аларга текәлделәр. Ят кешеләрдән читенсенепме, хатыннар кыстырган итәкләрен ычкындырып, аякларын капларга ашыктылар. Арадан берсе алар янына ашыкты. Борын өстенә яфрак ябыштырган.

— Рәүф абый, — диде ул, килә-килешкә кулын сузып. — Хуш иттек. Ничек киләсе иттегез? Саумы, Булат абый! Син дә кузгалдыңмыни? — диде ул, Булатка да ике кулын сузып.

— Саумысез, — дип елмайды директор. — Буламы, апалар? Апалар, сәлам биргәч, үз эшләренә керештеләр.

— Менә яңа көч алып килдем. Шаять, кире какмассыз.

— Мин тагын үзе килгәндер дип торам, — диде Рәсимә.

— Бер сүз бар иде, — диде директор Рәсимәгә һәм читкәрәк чакырып ым какты.

Булат аларның карашларыннан сүзнең үзе хакында икәнен аңлады. Болын исе һәм иркенлек хисеннән башы әйләнде. Кыргый яшьлек нуры калыккан күзләре үзләреннән-үзләре елмаеп, җыерчыклы йөзенә яңа бер төс таратты. Кырынмаган йөзе ачылып, анда ниндидер дәрт уянды.

— Мин дә шулай дип уйлап торам, Рәүф абый. Мәүләви ага ике көн инде идарәгә дә төшми. Бүген идарәдә хәл итәрбез. Бәлки, шулай яхшырак та булыр. Идарә членнары ни әйтер тагын, — диде Рәсимә, директор белән хушлашып. — Ә сезгә... ихтимал, җибәрмәбез.

— Ә Сираевка мин тәкъдим итте диярсең.

— Ну, әйдә! — диде Исламов, Булатның җилкәсеннән җиңелчә этәреп. — Иртәгә үзең карарсың. Бүгенгә нишлисен Рәсимә әйтер. Ярый, мин «Тукай»га ашыгам. Сау булып тор! — Ул Булатка һәм Рәсимәгә кулын биреп, тарантаска менеп утырды да атына чөңгерде.

— Рас килгәнсең икән, мә! — диде Рәсимә, күзләрен кысып, һәм Булатка үзенең чалгысын сузды. — Бөгәлҗәсен таманла. Ирләр янына бар. Озакламый әбәт.

Шушы гади сүзләр, чалгы янаган чың, чикерткә черелдәве, халыкның кичә генә аерылгандай, аны сүзсез кабул итүе Булатны ничә ел киеренкелектә тоткан тозлы төенне көтмәгәндә эретте дә җибәрде. Әйтерсең аның кайнар каны, кинәт көч алып киң болынга җәелгән кар суы шикелле, бөтен гәүдәсенә тарала, ун ел сыкрап торган иң туң хисләрен дә эретә иде. Тормыш аңа иң риясыз, гөнаһсыз ягы белән борылган, мәрхәмәтлек күрсәтеп, ничә ел төшкә кереп изалаган иң гүзәл кочагын ачып елмайган кебек тоелды.

Ирләр янына килеп сүз каткач, гадәттәгечә, тартырга утырдылар. Булатның яңа ачылган папирос кабы минут ара бушап, текә ярдан тын инеш өстенә очты.

— Значитсы, кайттың, — диде солдат чалбарыннан гына калган Гимай, калын мыегы астыннан ике төтен көлтәсе чыгарды. — Кай тирәдәрәк сугыштың?

— Каян беләсең минем фронтта булганны?

— Ә Галимҗан сөйләде ич!

— Ә-ә!.. Гомель янында. Кырык бердә... Ә син?

— Сталинградта...

— Афзал әнә туже Гомель янында булган ич. Шулаймы, Афзал? Ничек очрашасы итмәдегез? Бергә-бергә күңеллерәк тәпәләр идегез фрицны.

— Мин сугышып йөргәндә, Булат кордаш хур кызлары белән ике ел кети-кети уйнап яткан инде, пәрәми. Теге ярчык өч-дүрт илле уңгарак эләккән булса, теге дөньяда очрашасы икәнбез дәген бит. Икәү рәдем җатып ширбәт җылгасыннан пуф иткәнче чөмерер иек тә мич башына кырын ятыр иек теге хур кызлары белән...

— Ничек чыгасы иттең суң аннан, Булат малай, ә? Галимҗан яшь имән төбенә ләхетләп күмдем дигән ие ич!

— Шул хәл дөресмени, Булат малай, ә?

Ирләр дәррәү көлешеп алдылар.

— Дөрес, авылдашлар. Чолганышка эләктек. Ул мине, җәннәткә булмаса да, тәмугка ташлап китте. Ике төштән яралы идем. Бер удмурт егетенә ташлап качты. Шәп егет иде Табейкин. Ялгызы ничек күтәреп йөртсен. Бер урманда урманчы йортына тап булдык. Икенче көнне үк немец килеп басты. Урманчының хатыны белән кызын шундук аттылар. Күз алдында. Ә безне — әсирлеккә озаттылар.

— Ышанычлы кабергә күмгән икән шул, Галимҗан абыйны әйтәм.

— Хәзер... ни кылмак буласың? — диде Гимай, тирән сулап.

— Ни кылмак!.. Яшәмәк булам! Дошман үлгән дип хәбәр салганга үлеп булмас бит инде.

— Бусы тәгаен! Мин Галимҗанны диюем. Хатыныңны нишләтмәкче...

— Яшәсеннәр...

— Дөрес. Хатын беткәнмени, пәрәми!

Кичкырын печәнчеләр арасыннан аны Рәсимә эзләп тапты.

— Булат абый, йомыш бар иде.

— Тыңлыйм.

— Бүген идарәгә кереп чык әле. Сәгать тугызларда.

— Керә алмыйм.

— Кара инде…

— Мине Галимҗан белән бер өстәл тирәли утыртмакчы буласыңмыни?

— Анда ул гынамыни? Бөтен бригадирлар, коммунистлар, мин дә... Өченче көн әйткән идем ич бер сүзем бар дип. Кичен тагын күрмәкче идем дә Рәүф абый белән киңәшләшим дисәм, үзем, диде.

— Сез тагын шул, Мәүләви карт урынын дисезме?

— Шунда.

— Итәк чабуыннан гөнаһлар җибәрми бит.

— Нинди гөнаһ, Булат абый? Киңәшелгән, сөйләшенгән.

— Шулаен шулай да...

— Белдем инде ник төшмәячәгеңне.

Рәсимә кырт борылып китеп барды.

Булатның көндез аяз күк кебек ачылган кәефен кич- кырын болыт басты. Бүген ул печәнне бөтенесенә караганда да күбрәк егып атты. Ирләр бер покос чыкканда, ул бер ярымны чыгып өлгерә иде. Шаярткан булып ул аларны каулап та карады. Ирләр дә, хатыннар да, нигәдер артык көчәнмичә, чалгыларын үз көй-ләренә генә селтәнүгә караганда, су мичкәсе янында озаклап сөйләшергә ашыгалар сыман күренде. Җи-деләр тирәсендә үк кайтырга җыена башладылар. Булат печәнне куна-төнә чабуларын искә төшерде. Элек, атларны да, үзләрен дә өшәндерүдән куркып, шушында, болын куенындагы шалашларда гына йок-ларга авалар иде. Шуңа күрә кешеләрнең җиде чакрымдагы авылга кайтырга җыенуларын күргәч гаҗәпкә калды, кашлары җыерыла барды.

— Гимай абзый! Бәлки, кунарга гынадыр? Печән шәп. Көннәр барында... Сугыш алды елларны кунып ята идек бит.

— Ул сугышка хәтле бит...

— Хәзер ни аерма?

— Аерма шунда, Булат. Сугышка хәтле бәрән дә тук, сыер да тук була торган иде. Печәнне үзебезгә дә бүлә идек, хәтерлимсең?

— Соң?

— Хәзер бөтен печән колхоз богылына кала. Шәхси хуҗалыкка сыңар курпы да юк. Әүвәле кем күпме чаба, шуңа карап учын суза ие. Бушка без үзебез дә тук. Ә син кунып ятмакчы. Синнән ким эшләр иек дип беләсеңме әллә?

— Җыелып сөйләшегез соң...

— Былтыр сөйләшкән идек тә кана! Ни файда. Сөмсергән арыш саламы бүлделәр. Аның белән сыер асрап булмый шул. Хәзер аннан бер кочак, моннан бер көлтә... Мәтәшәбез шулай. Менә кайтышлый арба астында кайта әзме-күпме. Барлы-юклы булса да, тамчыдан күл җыела.

— Хәлне ничек җиңеләйтергә булыр күк соң?

— Гап-гади итеп. Аннан-моннан учлап печән хәстәрләгәнче, бүлсен дә бирсен иде идарә. Фәлән срукта фәлән хәтле печәнне киптереп чүмәләгә куйсагыз, фәлән хәтлесе үзеңә. Эленке-салынкы йөрер идек дип беләсеңме? Бер печән белән генә булса бу хәл — бер хәер. Юкса авызның икмәккә туйганы юк лабаса.

— Ничек алай? Колхоз алдынгылардан ди ич?

— Кай яктан карыйсың бит...

— Башка колхозларга үрнәк, янәсе! Төкереп тора акыллы башлар синең үрнәгеңә! Әнә күршеләрне ге-нә ал — «Тукай»ны.

Булат ни дип тә җавап кайтара алмады. Шушы хакта сүз куертырга исәпләп Рәсимәне эзләп караган иде дә кайтып киткән булып чыкты. Җитмәсә хатыннар теленә ризык булып керде.

— Тикмәгә генә булмастыр ла, — диде ире сугыштан кайтмаган Тәзкирә исемлесе, каш-күз сикертеп. — Баштан тегесе моны болын айкап эзләде, хәзер инде бусы тегене әлсерәп куып йөри.

— Хи-хи-хи! — дип элеп алды хатыннар.

— Куарсың, кумый ни, икесе дә... сагынганнардыр?

Тәзкирәсе, өенә алып кайтырга дип печән бәйләгән җиреннән туктап, кеше-кара күрмәгәндә, Булат ал-дында уйнаклап та алды:

— Күктән торна эзлисең, Булат. Торна белән гади чыпчык арасында ни аерма? Тәтемәгәндәйгә үрелгән тәтердәенә сүрелгән... Печән бәйләргә булышмассыңмы диюем ие... Булышканга буш булмас.

Аптырап калган Булат:

— Хәзер! — дигән булды һәм читкә китеп барды.

## XVI

Рәсимәгә идарәгә төшмим дип әйтсә дә, Гимай абзый зарыннан соң, Булатта кемгәдер нәрсәдер җит-керәсе килү теләге уянды. Апасы Газимә кертеп калдырган җылы сөтне эчеп, бөтенләтә пешерелгән бә-рәңге белән тамак ялгап алгач, капка төбендәге эскәмиягә чыгып утырды. Папиросын кабызгач, көндезге вакыйгаларны, Исламовны, Рәсимәне, Гимай абзыйның бая әйткән сүзләрен хәтеренә төшерде. Әңгер-меңгердә нигәдер Павел Юрьевич гәүдәләнде, ул тагын: «Туган илгә ябыш, ишетәсеңме», — диде. «Ничек ябышасың аңа, Пал Юрьич? Кем уйлаган әнкәй гүр иясенә әйләнер, өйдән Вәзирә китәр дип?! Ничек ябы-

шасың, кай җиренә? Бирче бер киңәш?» Миен мең сорау миңгерәтә. «Җиргә ябыш, җиргә ябыш... Бәлки, син, Пал Юрьич, башка мәгънә җиткерәсең килгәндер? Теш-тырнагың белән җиргә ябыш, явыз уйлар, усал кешеләр куса да, җиргә ябыш... Көрәш, тартыш!» Бу уйлары Булатның күңеленә шәфәкъ яктысы алып килде. «Димәк, көрәшергә? Минем бәхет минем үткәнемдә. Ә аны Галимҗан урлады. Аның белән көрәшер өчен кайтты түгелме соң ул? Булатны салкынча һава агымы чиркандырып алды. Әллә дошманы белән күзгә-күз очрашачак минутларны күзаллау шулай тәэсир иттеме? Рәүф абый. Галимҗан. «Күрәсең, шыр җибәрмәгән — орден, медальләр алып кайтты. Колхозы районда алдынгылардан...» Кайтырмын да, колагыңнан тартып, хөкем залына алып керермен, имеш. Исбатлап бак. Вәзирәсен тагын. Барыр да кире алып кайтыр шикелле иде. Ә ул: «Читләр без, читләр!», «И тормыш — очсыз йомгак. И язмыш — караңгы төн... Нишләргә, нишләргә??» Булат сүнгән папирос төпчеген аяк астына ташлады да торып басты. «Бәлки, хаклыдыр син, Рәсимә, куркамындыр мин. Пал Юрьич, син нишләр идең?.. Ә-ә, күрсәттең бит... Инглиз солдатлары лагерьга бәреп керер алдыннан син меңләгән әсирләр кебек капкага ташланмадың, бараклар артындагы таш йортка таба йөгердең. Мин дә синнән калмадым. Сине беркем тоткарламады. Лагерьны саклаучы солдатлар, инглизләр ультиматумына буйсынып, лагерьны калдырып чыгып киттеләр. Алар арасында җирән комендант Генрих Крюгер гына юк иде. Син аны үз бүлмәсендә таптың. Ул, тонган күзләрен соры болытларга текәп, тимер рәшәткәле тәрәзә каршында кара өрәктәй катып калган иде.

— Гутен морген, герр комендант! — дидең син, ишекне киң ачып.

— А, готт! — дип бакырды комендант. — Вег! — Һәм пистолетын синә төбәде.

— Һерайн! — дидең син, елмаеп. — Бирегез монда. Сезгә кирәкмәс дип уйлыйм. — Син курыкмадың. Фашистның йөзенә туп-туры карап, алга атладың да аның кулыннан пистолетын каерып алдың.

— Алла безнең белән, — диде Крюгер, елмаерга тырышып. Имеш, ул үлгәндә дә елмаячак.

— Юк, Крюгер! — дидең син. — Әгәр дә хакыйкать алла икән, ул безнең белән.

Син, үз-үзеңне онытып, комендантка пистолеттагы бөтен пуляны атып бетердең.

Миңа таба борылганда, синең маңгаеңда тир бөртекләре ялтырый иде. Мине кочаклап үкси-үкси елаганда, мин учым белән сөрттем аларны. Салкын иделәр. Син еладың. Беренче кат. Йөзеңдә елмаюга охшаш сызыклар калыкса да, син еладың...

Мин дә нәкъ синең шикелле, һәр уенның ахыры бар. Галимҗан алдында да хаклык пәрдәсе ябылыр. Минем өчен борчылма. Мин ул хәтле үк көчсез түгел. Син әйткән хакыйкать алласы минем белән. Союзникларым да, шаять, табылыр. Шул ук Рәүф абый, Рәсимә, Гимай абый... Мин идарәгә киттем. Бәлки, син дә?.. Әх, әйе, син еракта...»

«Кеше дөньяга ничә кат килә дә ничә кат яши башлый? — дип уйлады ул. — Ничә гомере бар кешенең? Минем менә икәү!..»

## XVII

Уйларым башта мине бик дулкынландырса да, ахыр килеп, мин тынычлана төштем.

Инде авылга якынлашып та киләбез. Соңгы уйсулыкка төшеп, соңгы сыртка күтәреләбез. Авыл үзе шушы үр артында, күренми.

Әмма мин аның сулышын күптән тоям инде.

Кеше яшәешенең асылы нидән гыйбарәт? Мин нишләргә тиеш хәзер? Иртәгә? Берсекөнгә? Галимҗан абзыйдан үч алыргамы? Ничек итеп? Ни өчен мин? Нигә эти үзе алмаган ул үчне? Кешенең кеше һәм мохит алдындагы иң изге әҗәте явызлыкка каршы көрәш икән, ул нигә көрәшмәгән? Ни өчен яшәгән? Ул үзенең әҗерле яхшылыгы, гаделлеге белән күптән кабердә, ә Галимҗан — менә ул.

Сораулар, сораулар... Озын юл кебек очсыз-кырыйсыз сораулар...

Тукта! Әти көрәшмәгәнмени? Юк, көрәшкән. Тик үзенчә. Явызлыкка яманлык кылу белән түгел. Явызлыкка яхшылык белән. Бөек фәлсәфә.

Кешегә иң авыр җәза бирәм дисәң, аны үзе белән ялгыз калдыр. Озакка. Берзаман мин төш күрдем: имеш, мине авыш көзге стеналы алты кырлы бүлмә уртасына богаулап куйганнар. Минем җаныма алты яктан йөзәрләгән күз текәлгән. Уңга борылам, сулга, алга карыйм, артка... һәр тарафта мин. Түшәм дә өчпочмаклы көзгеләрдән эшләнгән. Анда да йөзләгән күз. Минем үз күземә текәлгән күз. Газап бер кичереш: мин үземне үзем хөкем итәм...

Әти дә Галимҗанны шулай иткән. Аны үз-үзе белән ялгыз калдырган. Үз вөҗданы белән күзгә-күз. Гадел, искитмәле гадел хөкемдар булган ул әти. Кешене үз намусы (әгәр дә ул булса, билгеле!) хөкеменнән дә гаделрәк хөкемгә, җәзага тартып буламы? Әйе, буламы?..

— Галимҗан абзый, синең каян кайтып килешең соң әле? Районнан-мазардан түгелдер ич?

— Юк ла! Моннан гына, аермадан. Автобус каршына чыккан идем. Кайтышлый менә урманга кереп, бер-ике юкә чабып алдым. Җепсәгә. Юкса, шушында хәтле килеп, бушка ат изалау була ич.

— Ә!.. Автобуста берәр кемең кайтасы идемени?

— Ие лә! Кызым кайтасы иде.

Күкрәгемдә өзелергә әзерләнгән төсле нидер тартылып куйды. Мин хәтта аның зыңгылдаганын да ишеткән күк булдым. Төпсез бер ышаныч белән сорау бирдем:

— Кайсысы?

— Бу юлы — олысы. Иртәгә тагын кечесе булыр инде, каһәр.

— Кайда соң ул, Миләүшәне әйтәм?

— Кайда булсын. Билгеле инде, калада. Бүгенге яшьләрне кайда дип белмәк кирәк. Сөтләре кибеп бетми — күзләре кала ягын бораулый. Йөриләр аннары соң чегән шикелле. Әле монда, әле тегендә. Чистый нужа. Кайтмасларые — туган нигез, картаешкан ата-ана...

— Әйе...

Димәк, Миләүшә кайтасы. Ә мин әле күп нәрсәне хәл итеп бетермәгән, ачыкламаган. Бу юлы ышандыра алырмынмы мин сине? Көчем, дәлилләрем җитәрме? Кем белә, бәлки, соңдыр инде...

### XVIII

— Тр-р-р, мур булгыры! Трр, дим, үләт! Та-ак, Рахман туган, кайтып җиттек без. Дальше — һәркемгә үз сукмагы. Мин моннан, бераз әйләнечтән. Син инде ни, бигайбә. Үз җаеңны үзең. Якын инде... Барлы-юклы бер чакрым, — дип сөйләнде Галимҗан абзый, атының бушаган аркалыгын күтәреп бәйли-бәйли. — Бигайбә, мәйтәм. Жирдалар. Чутеки — рөхсәтсез. Күргәннән күрмәгән яхшы. Шулай ич?

— Шулай, шулай.

— Иртәгә кереп чык. Гупчым, кер, утырырбыз. Менә ич ару гына кайттык. Сыйладың, рәхмәт.

— Кая инде, Галимҗан абзый...

— Хәзер минем нәүбәт. Брашка бар минем. Тондырылган. Зәһ-һәр!

— Ярый, керермен!

— Әйдә, алаша! Н-но!

Атын юырттырып, Галимҗан абзый үрдән төшеп китте һәм эңгер-меңгердә күздән югалды.

### XIX

Үргә күтәрелдем. Алдымда күренмәс кояшның нурлары кызарткан офык. Матур офык. Киң. Аста авыл утлары. Иркенлек, сафлык. Авыл!

Иртәгә Миләүшә дә кайтасы ич әле! Миләүшә — зәңгәр исем...

### XX

Биш көннән соң Галимҗан Сираевны җирләрмен, каберенә бер уч туфрак салырмын дигән уй бу минутта башыма да килмәгән иде. Юк, укыйсы, монда язылмый калганнарын үзең белерсең дип, китапны бирәсе калмаган аңа. Анда мин Галимҗан абзый кулына ау мылтыгы тоттырганмын ич.

«Яңа йомшак кар түшәлгән кыр, ерак-ерак китеп, офык белән тоташкан һәм иксез-чиксез булып күренә иде. Ул чаңгыларын салып читкә атты да беравык шул чиксезлеккә карап торды. Меңнәрчә көмеш бөртек җемелдәгән кар өсте ниндидер көмеш моң белән тулган да аны үз учында йоклатырга теләп көйли сыман иде...

Мылтык гөрселдәде. Бик тирәннән әче бер үкенеч тойгысы китереп бәрде. Канга буялган кулын ак кар белән юып чистартасы килде. Тик өлгерми калды…»

Җиңел булмагандыр үз үлемең хакында уку. Бәлки, шуңа да авырып киткәндер. Гүргә илтәсе чир — иң газабы. Шул газапка минем сүзләр өстәлгән... Үкенеч — вөҗданның авыруы. Хәзер үземне дә шул телгәли.

Нишлим соң: хәзер бик үкенсәм дә, авылга кайткан көнне җаным шулай теләгән иде ич. Кайчандыр нәни Мефистофельнең хакыйкать хакына сай сулы буада кузгалган давыл кебек кечкенә көрәш ачуы ни белән дә булса очланырга, төгәлләнергә тиеш түгел идемени? Тиеш иде. Тик мин хаклы идемме? Онытылган иде ич инде тән ярасы, онытылган иде!

«Мин аңладым сине, Рахман. Бигайбә, яме!»

Галимҗан абзый миңа шундый язу калдырган.

Мин теләмәдем моны, теләмәдем!.. Шулай да сине мин үтергән кебек, Галимҗан абзый.

Галимҗан абзыйны җирләгәч, әткәй кабере янында шушы язуны кабаттан укып чыктым. Ниндидер эчке бер тылсым, мин төшенеп җитә алмаслык эчке бер фикер бар иде Галимҗан абзыйның миңа аталган соңгы сүзләрендә.

Учымны ачтым. Көзге җил, кош теле хәтле генә кәгазь кисәген элеп алды да, саргайган каен яфраклары белән бергә сикертә-очырта зират буенча очыртып китте. Кайсы тарафтандыр шул ук скрипка моңы ишетелгән сыман булды. Кемдер мине ерак-еракларлан кычкырып чакырадыр кебек иде.

Койманың теге ягыннан Вәзирә апа чакырып торса да, Миләүшә әтисе кабере яныннан озак китә алмады.

Тынлык дөньяны тагын да киңәйтә төсле. Бары тик трактор гөрелтесе генә аны ни беләндер чикли, тотып тора иде.

Сары каен яфраклары арасында Миләүшәнең зәңгәр күзен күрәм.

Җир ярасы нинди була? Ялгыз калган хатын-кыз күзләре кебек мәллә?

Әйе, снаряд чокырлары, җимерек шәһәрләр, яндырылган авыллар, туганнар каберлеге генә түгел. Җирнең җәрәхәте — ялгыз калган хатын-кыз күзләре.

Исәннәргә шуны күрүе авыр.

Күп еллар әүвәл мин дә сугыш ачтым. Миләүшәнең күңелемә текәлгән яшьле күзе шуның ярасы булды. Юеш яфраклар, яшьле күз...

Үз җаныма менә шундый тирән яра салдым.

*1968–1973 еллар,*
*Олы Әшнәк — Казан.*

## СИРТМӘЛЕ БИШЕК

### Беренче бүлек

Тыныч кына итеп Җир шары әйләнә. Йокысыннан уянып килүче мәк чәчәге шикелле кызарып һәм зураеп кояш байый, күкнең шәмәхә ягында сизелер-сизелмәс кенә зәңгәрсу ай калка, ә минем дустым Нурисламның киң ачылган бәләкәй кочагына таба ярык туп оча иде.

Туп эченә мин кырлы-мырлы бер таш тыгып куйган идем. Хәзер Нурисламның ябык тәненә эссе һәм кисәк авырту таралып китәр, аның күзен каплаячак яшь элпәсе аша кояш белән ай да, минем сипкелле йөзем, сары чәчле башым да, эчендә таш сурәтендә хыянәт һәм мәкер посып яткан туп та — һәммәсе кара булып күренер. Урман аланындагы черек төпкә җылынырга дип чыгып, бөгәрләнеп яткан елан йомгагы шикелле кара булып.

Минем нечкә, ләкин тыгыз җепселләрдән торган итле, җитез, көне буе кояшта йөрүдән һәм су коенудан тиресе кызару гына түгел, ә каушакланып торган кулым көченә буйсынып, ташы белән бергә Нурисламга таба ярык туп очып китте. Безнең икебез арасындагы уен тәртибе буенча, ул аны һичшиксез тотып алырга, радио баганасы белән бакча коймасы арасыннан ничек тә уздырмаска тиеш. Тупны хәзер бер нәрсә дә туктата яки юкка чыгара алмый иде инде. Ул, офыкка яңа орынган кояш кебек авыраеп, Нурисламның кочагына килеп керер дә...

Колагыма буш мичкәгә таш белән органдагы ише тавыш килеп бәрелгәндәй булды — аның арык күкрәк тавышы. Мин: «Тотма!» — дип кычкырып җибәрдем. Әмма үз тавышымны үзем дә ишетмәдем. Күрәсең, тупны тоттырасым килмәве шултикле көчле булгандыр ки, минем тавышым шул теләгемнән ары узмыйча, эчендә генә тыелып калды.

Мәкер һәм хыянәт, авырту һәм күз яше белән тулы ярык туп дустымның бәләкәй йөрәге типкән кочагына килеп керде. Хәзер аңа ике якка җәеп җибәргән кулын тиз генә җыеп, тупны күкрәгенә кысасы гына калды.

Ул кичне кояш белән ай түгәрәк иде. Туп та. Без уйнап йөргән Җир шары да түгәрәк. Шул түгәрәкләр тирәли карлыгачлар тузгып оча иде. Мөгаен, төнләме, әллә таң алдыннанмы яңгыр явар. Ә аныңчы җиргә Нурисламның күз яшьләре тамачак. Тәгаен тамачак. Төнләме, әллә таң алдыннанмы явасы яңгыр һәм Нурисламның күз яше тамчылары, теләсә кайсы сугышта су белән кан кушылган шикелле бер үк җир туфрагында очрашып, бергә катнашыр.

Кырлы-мырлы таш тыгып куелган ярык туп, радио баганасы белән бакча коймасы арасына ялан аякларны киң җәеп баскан Нурислам һәм аның тупка каршы ачып куелган кочагы. Мең тугыз йөз илле дүртенче елның җәе.

Грек сугышчылары кереп поскан гәләмәт зур агач ат. Грекларның хәйләсен белмичә, Троя капкаларын киң ачып, шәһәргә агач ат тартып кереп баручы Троя сугышчылары. Греклар төнлә агач атларыннан чыгар да шәһәрне камаган үз гаскәрләренә капкаларны ачып бирер. Кан коелыр. Безнең эрага кадәр мең ике йөз алтмышынчы ел.

Кырлы-мырлы таш яшерелгән ярык туп белән греклар поскан галәмәт зур агач ат.

Мәкер һәм хыянәт.

Күз яше һәм кан.

Җир йөзендә яңгыр тамчылары белән Нурисламның күз яшьләре генә түгел, ярык туплар белән Троя атлары да очрашырга мөмкин икән.

Әйе, ул туп тишек иде.

Яңа чакта аның ярты ягы кызыл, ярты ягы зәңгәр, ә урталай өч юл ак кыршау төшерелгән иде. Аның төсләре уңып, кырылып беткәч, әти берзаманны тәрәзә йөзлекләрен буяганда аны акка, аннары түбә калаен буяган чагында яшелгә буяп бирде. Ул буяулар үз чиратында куба барды һәм тупның йөзе без ябынып ята торган корама юрганга охшап калды. Кайбер урынында кызыл балчыклы җир кисәге, кайбер урынында зәңгәр диңгез ертыгы, шул зәңгәр су уртасында яшел утраулар. Нәкъ мәктәптәге глобус. Ихтимал, бик югарыдан караганда, Җир шары безнең иске туп шикелле чуар булып күренә торгандыр.

Яз башында туп берара югалып торган иде. Аны су тегермәне чокырындагы кычыткан арасыннан әни табып менде. Тик ул тишек иде инде, әнинең чалгысы тигән. Сагындырган, күрәсең, без аның белән шул килеш тә байтак юандык әле — футбол тибәргә бик ярады. Типкәли торгач, аның тишеге мин таш тыгып куярлык булып зурайган икән инде.

Ә беркөнне без аны күрше малае Нурислам белән бер-беребезгә каршы ыргытып уйнадык. Туп ерганакка төшеп китте. Ә анда ташның ниндие генә юк — тулып ята... Йөгереп мендем дә тупны бөтен көчем белән селтәнеп торып алга ыргыттым. Ул, авыздан ычкынган яман сүз кебек томырылып, минем киләчәк хәтеремә таба очып китте. Дустымның ябык (кая инде ул елларны авыл җирендә таза булу!) күкрәгенә томырылып бәреп керәчәк Троя аты...

Җир кешеләре үзләре җимереп киткән Трояларга археологлар булып әйләнеп кайталар.

Аит үзен кайтарып куйган зур йөк машинасын («ЗИЛ-555») капка төбеннән озатып калды да, ишегалдына кереп, урта бер җиргә килеп басты. Аның әкрен генә җиргә сузылып ятасы, битен кояш җылыткан яссы ак ташка куеп торасы килә иде. Кайчандыр үзе, апалары белән абыйлары, энекәшләре, атасы белән әнкәсе яланаяк та, чабата, резин калуш, туфли-ботинка, күнитек белән дә шомартып бетергән яссы ак ташлар. Шуларга колагыңны куеп тыңласаң, кайчандыр бу йортта яшәгән, кайсы бакыйлыкка күчкән, ә кайсы читкә китеп исән булсалар бер кайтып керәчәк кешеләрнең аяк тавышлары ишетелер микән, әллә йөрәк тибешләреме? Аитның тамак төбенә кайнар төер килеп тыгылды.

Эссе ишегалды бушлыгын фәкать чикерткәләр зыңы гына тутырып тора иде. Ул бушлыкны Аит төяп кайткан әйберләр дә тутыра алмаган. Киресенчә, алар ул бушлыкны тагын да сиздеребрәк торалар бугай.

Хәер, биредә инә төртерлек тә буш җир юк икән. Бердәнбер буш урын — Аитның башы түгелме соң? Аның бер генә уе да юк. Бу мәлдә аңа уй кирәкми дә. Ул басып тора һәм күзәтә генә. Әйтерсең лә карлы тау түбәсенә менеп баскан да үзеннән түбәндәге дөньяга карап тора. Ишегалды һәм андагы әйберләр аның үзенең бер өлеше мәллә? Хәер, юк. Киресенчә. Ул үзе ишегалдындагы һәрнәрсәнең бер кисәге бугай. Ишегалдындагы һәрнәрсә — алюмин буявы уңып, кубып бетә язган калай түбәле карт йорт (иске түгел, нәкъ менә карт йорт), дүрт баганалы урыс капка, үләре алдыннан гына атасы яңадан корып йә сипләп куйган абзар-кура, кыл урталай ярылган бүрәнәләрдән буралган келәт, карлыган бакчасының арасыз коймасы, зәңгәргә буялган болдыр, кайчандыр эшлеккә исәпләп утынга киселми калган, хәзер инде яргаланып бетү генә түгел, эчтән чери үк башлаган бүрәнәләр өеме, күпсанлы келәләр һәм төрле бикләр, болдыр баскычы төбендәге тегермән ташы китеге, кече капкага, абзар һәм келәт ишекләренә таба салынган яссы ташлар, өй кәрнизе буйлый сузылган яңгыр аккыч калай юллык, аның астындагы тузган тимер мичкә, болдыр тәрәзәсе төбенә эчтән тезеп куелган эреле-ваклы дистәләгән үлчәү герләре, утын кискеч «кәҗә»... Алда-артта, уңда-сулда, якын һәм ерак.

Аит сагынып кайтты. Ул үзенең күз карашы төшкән һәрнәрсәнең күңелендә терелә, җанлана, хәрәкәтләнә барганын тоеп алды. Гүя бу әйберләр, һәрбер нәрсә ниндидер тылсым белән кайчандыр тораташтай катып калганнар да аның җылы карашы төшкәнгә уянып, тирән итеп сулап җибәрделәр кебек. Ул туган йортын кирәгеннән артык тыныч күңел белән барлап торуына гаҗәпсенеп куйды. Тамак төбендәге кайнар төер эреп югалды, күзен чылаткан яшь элпәсе кипте. Шушы урында ул хуҗасыз, хәтта ташландык йортҗирне битараф төстә күзәтүенең уйлар һәм хәтер белән алмашына баруын тоеп алды. Һәммә нәрсә аның күз алдында җанланып, әүвәлгечә, үзе белгәнчә терелеп китте. Алар хакындагы уе, күз алдына китергән күренешләр кыска, кырыс, тик искиткеч, аларга сыенасыны китерердәй кадерле иде. Ул иң кирәген генә хәтерләргә тырышты. Иң кирәген, иң кадерлесен. Калганнарының әһәмияте юк. Тау башына менеп җиткәч, күтәрелгән вакыттагы һәммә авырлыклар, үлем куркынычының әһәмиятсез, вак нәрсәләрдәй генә булып калуы кебек. Хәер, аек акыл белән уйлаганда, хәтердәге нәрсәләрнең вагы-төяге дә, иң зур истәлеге дә вакытлар узгач бердәй кадерле була бугай.

Хәтер археологы ярык тупны да, Трояны казып чыгаргандай, җанның һич көтелмәгән ярасы итә ала икән ләбаса.

Менә капка. (Мин аның ачык калганын исемә төшереп, ябып куярга ниятләп барган идем.) Әйе, менә капка. Дүрт имән баганалы. Баганалары җир турысыннан череп чыгарга җиткән икән инде. «Катырак бер җилләсә»... — дип уйлап бетермәдем, капка, терәлеп калырга теләгәндәй, миңа таба авыша башлады. Такта ярыгыннан кояшның нечкә генә бер нуры килеп керде дә, көзгедәге кебек минем хәтеремдә чагылып, уйнаклап алды. Бер генә мизгелгә сукыраеп калгандай булдым. Һәм мин шул ялкынлы караңгылыктан үземә таба йөзеп килгән җигүле күк биягә каршы йөгердем. Табанымны урамдагы калын чирәмнең салкынча сулышы кытыклый, күкрәгемне эчемә сыймаган шатлыгым кыса.

— Капка ауды, әти! Сөенчегә нәстә бирәсең?

Капка ауганга сөенче! Ул заманнарда капка аву крестьян гаиләсе өчен сыер үлү белән бер үк төсле афәт. Күп балалы гаилә өчен бигрәк тә. Бала күңеле моны аңламый, аларга һәр яңалык — сөенче алырлык куаныч. Һәр афәт ата-анага килә.

— Капка ауды, әти!

— Өстегезгә аумадымы? — дип арбадан сикереп төшкән әти мине күтәреп алмакчы була, тик «сөенче» хәбәр аны шул кадәр куркыткан — аның мине калтыраган тезенә кысарга гына хәленнән килә. — Өстегезгә аумадымы?

— Юк. Әни...

— Нәрсә булды әниегезгә?

— Юк, әти. Әни булмаса...

— Шул шул менә — ул булмаса! Ә ул бар, улым. — Әти, күтәреп алып, мине арбасына утырта, үзе дә үрәчәдән аягын салындырып утыра, күк атка (мин ул атның Күгәрчен кушаматлы булганын исемә төшереп уздым) чөңгерә дә күчтәнәч капчыгының бавын чишә башлый — райүзәктән кайтышы, буш кул белән түгел. (Ул колхозның хуҗалык мөдире иде.)

Капка ауганга сөенче!

Тычканга үлем, мәчегә көлке.

Җәй башы. Көн кояшлы, ләкин бик җилле. Ишегалды янып торган учак янындагы шикелле җылы. Өй нигезе буендагы чокырлар тузанында тавыклар коеныша. Тыныч, рәхәт. Әни кер уды да, инештә чайкап менгәч, капка җепсәсеннән лапас баганаларына тартылган юкә бауга элеп куйды, ә безне — өч-дүрт бала-чаганы — керләрен орынып пычратмасыннар дип, урамга чыгарып җибәрде. Кече капкадан тышка атлавыбызга, безнең тын юлларыбызга урамны бетереп тузгып килгән «шайтан туе» өермәсенең эссе, тыгыз сулышы кереп тыгылды...

Ә капка әкрен генә итеп, күрше Хафиз бабай биленә таянып, урыныннан торгандагыча бер-ике мәртәбә ыңгырашып кына авып төште.

— Башлары исән булсын, карчык, — диде әти. — Яңага вакыт иде инде. Аны сүтүе дә чыгым ич әле. — Сүзен ул: — Берүк ут-күздән саклана күр! — дип тәмамлады.

Яңа капкага иске капка келәсен куйдылар. Келә яссы тимер тасмасын матурлап бөгеп ясалган, баш бармак астан, ә калганнары өстән бик җайлы гына ятып, бәләкәй генә көч салу белән келт итеп ачылып китә, әйтерсең лә фотоэлементы бар. Безнең ата-бабаларыбыз белән әни-әтиләребез матурлыкка үтә сизгер булганнар шул. Фотоэлемент ише генәме соң!

Аит түзмәде, барыбер түзмәде, башта кинәт чүкте дә аннары әкрен генә алга иелеп, учларына таянды һәм битен яссы ак ташка куеп ятты.

Аның ирене, ирексездән:

— Бигайбә, — дип кыймылдады. Тагын әле йөгерек, әле әкрен, әле сулышын бүлеп, әле иркенләп тын ала-ала: — Бишегем, кайнар бишегем минем, — дип пышылдый башлады. — Тик син каты бәгырьле булма... зинһар, — дип дәвам итте ул һәм: — Мин йомшардым инде, бигайбә, — дип пышылдады ул. — Дөнья... дөнья зур, аның миңа биргән бәхете үзеннән дә зур булып чыкты, ахрысы... Барысын да аңа кире бирдем. Кирәкмәс. Кирәкмәс!.. Бишегем, — дип, яңагын таштан алды ул. — Кайнар бишегем, — дип тураеп тезенә калыкты һәм, торып, тирән бер үкенеч хисе белән: — Бигайбә, — дип кабатлады.

Беркавым кулы белән битен каплап торды, ниндидер тавышлар ишетелгәндәгечә, сагаеп, нәрсәгәдер колак салып торды. Нинди тавышлар бу? Әллә тавышлар, әллә тау кыялары шикелле төпсез тынлыкмы? Бәлки, шушы иске йортның кайнап торган чакларындагы көндәлек тормыш итү тавышыдыр, бәлки, кайбер бәйрәм көннәренә туры китереп, сирәк-мирәк җыелгалый торган кунак-төшем, тыйнак мәҗлес шавыдыр? Әллә бала-чага көлүе яисә елавы микән? Һәрхәлдә Аит өчен кадерле, изге, юанычлы һәм юксынулы

авазлар. Югыйсә ул аларны шулкадәр дә гаҗиз калып тыңлап тормас иде. Әнә ич аңа әнкәсе белән атасы эндәшкән кебек булып китте. Тик каян? Күктәнме, әллә кое төбеннәнме?

Әнкәсе: «Кайттыңмы, бәбкәм?» — дип сорады. Аит: «Кайттым», — дип җавап бирде. «Ашарыңа җиттеме?» — «Җитте». — «Кара, чабатаң тәмам тузган лабаса!» — «Чабатаң? Мин хәзер чабата кимим инде, әни. Ә менә йөрәк тузды бугай». — «Солтан авылы белән безнең авыл арасы җиңел юл түгел шу-ул... Унбиш чакырым. Түз, түз. Мәктәп юлы картайган көннәрең юлларын җиңеләйтер». — «Иң җиңеле язгы ташуларда чабата киеп узган шул унбиш чакрым юл икәнен белсәң иде син, әни! Анда чабата гына туза иде. Ә дөнья гизгәндә йөрәк туза икән»... — «Әйдәле, Аит! Малларга печән салып керик әле, улым. Бүген-иртәгә сыер бозауларга тора, Алла теләсә!..»

Бу тавыш атасыныкы иде. Аит аны мең кеше берьюлы сөйләшкән җирдә дә танып алыр иде.

«Әти...» — дип уйлады ул. Уйлады гына, күз алдына берни килмәде. Атасы белән әнкәсенең тавышлары аның күңеленә үтеп киткән җил кебек кенә орынып узды. Ул бер нәрсәгә текәлеп торды да ирексездән шунда таба атлап китте һәм, иелеп, кулына балта алды. Күгәрек балта коргаксыган сабында буш утыра иде. Ул тирән сулап, аны гайрәт белән яргаланып беткән бүкәнгә каптырмакчы булып кизәнде. Ләкин балта күтәргән кулы астыннан өйләренең аркылы-торкылы такта кагылган өч тәрәзәсен күреп, шуларның уртадагысы каршысына барып басты. Ниндидер ирексез гайрәтле хәрәкәт белән кубарылып ташланган такталар каз каурыйлары сыман тавышсыз-нисез генә ян-якка очып китте. Ул тәрәзәгә кунган тузанны уңлысуллы сөрткәләде дә, якты көнне еракка карагандагыча кулын каш өстенә куеп, өй эченә карады. Һәм караңгы пыялада атасының ап-ак йөзе белән маңгайга-маңгай, күзгә-күз очрашкандай булды.

«Ир-егет, шулай, бишегенә әйләнеп кайта ул, улым».

Аит артка сикерде. Янтаеп, кырый тәрәзәгә ташланды һәм аның да такталарын кубарып ыргыткач, тәрәзәнең пәрәвезле өлгесе аша үзенә карап торган әнисенең йөзен күргәндәй булды.

«Рәхмәт, улым, йортны ятим итмәдең».

Аит балта тоткан кулының беләге белән маңгай тирен сөртеп алды. Йөзенә әкренләп елмаю чаткысы тарала башлады һәм ул эчтән генә көлеп куйды. (Яхшы хуҗасы тавышына күкрәк эченнән генә кешнәп җавап биргән тук атмыни!)

— Кайттым әле, мать честна!..

«Менә хәзер чүмеч белән генә чөмереп алып, әчегән бал эчеп җип-пәр идең ул, брат!» — диде ул үз-үзенә.

Ул атасының: «Әчегән бал! Җитмәсә чөмереп!.. Мин сугыштан кайтып кергән мәлне борыныңнан агып төшкәнне иренең белән суырып торганыңны онытма, малай актыгы», — дигән тавышын ишеткәндәй һәм тәмәке тартудан тырнагы саргайган буынтыклы бармагын янавын күргәндәй булды.

Тын иде. Әле һаман тын иде. Чикерткәләр сайравыннан ул тынлык зыңлап тора кебек. Җиләс. Хәер, ара-тирә шоссе юлдан узучы машиналар тавышы ишетелә, күршедә генә тавык кытаклап җибәрә, урам буенча бер эт өреп уза.

Аит бүкәнгә барып утырды. Әле генә ташып торган хисләре сүрелергә дә өлгерде. Ул нидер югалткан һәм шуны эзләгән кеше сыман төрле якка карангалап, тик берни күрмичә болдырга менде, кулы үзеннәнүзе баскычка сөялеп торган гитарасына үрелде. Ул чәнти бармагының тырнак очы белән аның иң аскы кылына чиртеп куйды, аннары кочагына җайлап, бер аккорд сугып алды — ля бемоль.

> Тормышның... текә... тавында
> Баусыз калдым ялгыз... —

дип, хәтерләгән кебек кенә итеп көйләде ул һәм кинәт җырлый алу сәләтенең бөтен мөмкинлеге белән:

> Әллә шулай язган язмыш,
> Әллә минем ялгыш! —

дип тәмамлады. Җырның

> Бөркетләрнең ояларын
> ташлар иште түбән.
> Кайда син?
> Ишетәсеңме:
> Бу — минем тәүбәм... —

дигән өлешен ул күңеленнән генә җырлап бетерде. Җыр матур иде. Ул аны үзе чыгарды. Памирда. Ярты чакрымлы текә бер кыяны үткән чакта. Ул — иң алда. Аңа орынып диярлек болытлар агыла иде. Кайчагында аның ярты гәүдәсе болыт мендәренә чума, аяклары гына чыгып кала. Көн кояшлы, болытлар, кошлар көтүе шикелле яннан гына уздылар да киттеләр. Бу җырны көйләп-эзләп күтәрелүе аңа игътибарын тупларга булыша кебек иде. Ул көнне аны баш түбәсеннән өстәрәк ниндидер ярыкта җил сызгыруы ты-

нычсызлап торган иде. Хәер, ул сызгыру җил тынгач та бетмәде. Ул сызгыру да түгел бугай, ә тауның, кыяның тартылып, киерелеп торган кылы, эчке резонансы. Сызгыру аның кәефенә кире тәэсир итә, аны узып китәргә ашыктыра, бармакларын кабаландыра һәм бер дә бер мәлне шул кабалану белән сызгыруның резонанслары бергә туры килеп һәм бер-берсенә ярашып, Аитны күтәрелгән кыясы-ние белән җимереп ташлар кебек тоелган иде.

Ул чакта бу җыр һәм аңа сүзләр уйлау аның кәефен бер тигезләнештә, бер яссылыкта тотып торган иде. Хәзер исә ул җырның кинәт кенә үзенә теге кыя сызгыруы кебек кире тәэсир итә башлаганын тоеп алды. Шуңа күрә аннан котылу өчен хәтерендә яңарып җиткән һәм инде теленә, бармаклары очыннан гитарага күчәргә торган өлешен җырлап бетерергә ашыкты:

Югарыга менгән саен
Җилләр дә зәһәр.
Түбәннән югары менү
хәтәр, ай, хәтәр...

Хәтәр... Ә тагын да хәтәррәге — югарыдан түбән төшү. Менгәндә күз һәм бармаклар белән капшап менәсең, ә төшкәндә — аяк очы белән капшанып. Ничә елларга сузылган шәһәр тормышыннан соң авылга торырга дип кайтуын ул аяк очлары белән капшанып, кыядан түбән төшүгә тиңләштереп карады. Ни көтә аны монда? Билгесезлек.

Төшкән чакта ул иң артта булырга ярата иде. Кыядан төшкәндә артта булу менгәндә иң алдан булу белән берүк.

## Икенче бүлек

Җырның дәвамы бар иде әле. Ул өлеше, чыннан да, аңа тау сызгыруына охшаш төстә тәэсир итәчәк. Чөнки анысы — Аитка үз җанының резонансы кебек.

«Әгәр хәзер сиңа ирек бирсәм, син минем кәефемне җимерелеп төшкән кыя шикелле итәчәксең! — дип уйлады Аит. — Кит, онытыл!»

Ул гитарасын өеп куйган әйберләренең теге ягына шудырып төшереп җибәрде. Гитара бөтен кыллары белән зыңлап торды да тынып калды.

Бая үзен кайтарып куйган шоферны сыйламакчы булып, ул бер рюмка чыгарып куйган иде — шул күзенә ташланды.

Аитның: «Әче бал безнең үзебез белән, эти!» — дип, җырның үзен биләп алган киеренкелегеннән котыласы килә иде. Ул бөтен җире дип әйтерлек чит ил күренешләре этикеткалары белән чуарланып беткән сумкасының (спорттан киткәндә дуслары бүләк иткән истәлек) замогын ачып җибәрде дә бер эчемлек шешәсе суырып чыгарды. Тик аның, рюмкадан эчмичә, үзенең иң соңгы җиңүе өчен бирелгән бәллүр кубоктан эчәсе килеп китте. Туган нигезендә яшәргә (ә бәлки, үләргә дәдер), төялеп кайтуы да аның соңгы җиңүе түгелме соң? Соңгы җиңүе ләбаса! Ул савыт-саба әрҗәсеннән сары күлмәгенә төреп салган кубокны ашыга-ашыга эзләп тапты да, шул ук күлмәгенең җиңе белән эчен сөртеп алгач, шаулатып эчемлек салды. «Сезнең исәнлегегез өчен, эти-әни!» — диясе килде, тик сүзсез генә эчеп куйды. «Инде исәнлек өчен түгел, истәлек өчен генә», — дип уйлады ул, кул сырты белән авызын сөрткән чагында. Аскы иренен тешләп һәм күзен кыса төшеп, ул, өнсез калгандай булып, бер читкә карап алды. Башында һичнинди уй калмады, күзе берни күрмәс булды... Ниндидер котылу чарасы эзләп, ул кулын алга сузды да әйберләр арасыннан шпагасын суырып чыгарды. Нигә икәнен уйлап тормастан, ул аның салкынча корычына иренен тидереп алды да баскычка утырды. Һаман да шулай өнсез калган рәвештә шпаганы идәнгә суккалый башлады. Бертөрле тизлектә генә, әмма торган саен ярсурак.

Урамнан сөйләшә-сөйләшә бер төркем кешеләр узып китте. Аларның тавышлары аңа шпага белән бәргән арада гына өзек-өзек булып ишетелеп алды. Тик Аит ачык кече капкага күтәрелеп карамады. Югыйсә капка баганасына сөялеп торганнан соң үзенә таба якынлашучы бер туташнымы, ханымнымы күрер иде. Ул фәкать кемнеңдер шпага очын тотып алуын гына искәрде. Шпага очында ике тамчы кан пәйда булуына игътибар итте. Җентекләбрәк караса, кан тамчылары түгел, бәлки кызылга буялган ике тырнак икән. Ул карашын ялтырап торган тырнаклардан ак, озынча һәм шома бармакларга күчерде, ул бармаклардагы ташлы һәм ташсыз алтын йөзекләрне күрде, нечкә генә зәңгәрсу һәм алсу кан тамырлары сизелеп торган кул буенча төссез дип әйтерлек төкләр җемелдәшкән беләк буенча шудыра башлады... Тик түзмәде, башын кисәк күтәреп, алдында торган хатынга бөтен барлыгы белән күрердәй итеп карап куйды. Аның каршысында кайчандыр чәчен сарыга буяган, ул сарылык бөдрәләтеп, колагы тирәсенә җыйнап куйган чәченең түбән яртысында гына калган ак йөзле, шул аклыкта учактан кар өстенә чәчрәгән утлы күмер-

не хәтерләтеп янып торган иренле һәм яшел күзле, яше утызга якынаеп килүгә карамастан, сыгылмалы билле һәм җиңел сөякле, кызыл кофта белән ак вельвет чалбар кигән бер хатын-кыз басып тора иде.

Аит авылга кайту юлында уйлап кайткан теге ярык туп вакыйгасын исенә төшерде дә каршысында торган зат турында: «Троя аты», — дип уйлап куйды. «Нигә Троя аты?» — дип сорады ул үз-үзеннән.

**Өченче бүлек**

Аит аның башта иреннәре кыймылдый башлавын күреп алды, аннары:

— Кирәкми, — дигән тыныч тавышын ишетте.

Аит:

— Нәрсә кирәкми? — дип кайтарып сорарга мәҗбүр булды.

Ханым ни әйтергә белмичәрәк торды.

— Ялгыз эчәргә кирәкми, — диде ул, шешәгә ымлап.

Аит ханымның шпага белән бәргәләү кирәкми дип әйтергә теләгәнен төшенеп алды. Чит кешенең үзен борчылган кыяфәттә күргәнлеге аның кәефен тагын да кырып җибәрде.

— Әлегә монда син кирәкмисең, — диде ул хатынга, каш астыннан туп-туры карап.

— Ялгыз эчү ярамый, — диде хатын, кабатлап.

Алар әле һаман берсе шпаганың сабыннан, икенчесе очыннан тоткан килеш торалар иде.

Аит, юри тупас итеп:

— Кушыласың килә, ахрысы, — диде.

Хатын шпага очын ычкындырды, иелеп шешәне алды һәм әйләндерә-әйләндерә аның язуын карап чыкты.

— А-а-а! «Камю!» — диде ул, телен шартлатып. Аит аның вак кына тигез тешләрен күреп калырга өлгерде. Хәер, хатын тешләрен яшермичә, җае чыккан саен ешрак күрсәтергә күнеккән булса кирәк. — Бик илаһи утырасыз. Алламыни!

— Аллага «сез» дип эндәшмиләр. Аллага якынрак булыйм дисәң, аңа «син» дип эндәшү мәгъкульрәк.

— Ярый, килешәм... Әй, син, Алла! Монда ошый миңа!

Хатынның уйный башлаганын тоеп, Аит, кырыс кына:

— Миңа ошамый, — дип куйды.

— Алайса ник күктән җиргә төштең, Алла?

— «Төштең» дип каян алып әйтәсең? Бәлки, мин менә китәргә җыенганмын гынадыр әле?

— Мал-мөлкәтеңә караганда, син күктән төшкән булырга тиеш. — Хатын, матур бер хәрәкәт белән бер борылып ишегалды уртасында торган йомшак, коңгырт төстәге эре чәчәкләр төшерелгән кәнәфигә борылып утырды. — Ә миңа монда ошый! — диде ул, тешләрен күрсәтеп. Аның чак ачылган тешләре арасында кызыл тел очы күренеп калды. Бу хәлендә ул мәчене хәтерләтеп куйды. Күзе дәү, ләкин күз алмасы ничектер мәченеке кебек аркылыга кысылып тора иде шикелле. Аит монысының да искиткеч яхшы үзләштерелгән бер гадәт икәнен чамалап алды.

— Миңа ошамый, — диде Аит, юри. Әгәр дә «миңа ошый» дисә, алар арасындагы сүз өзелеп торачак, чөнки чит кеше белән яңа сүз башлавы һәрчак җиңел түгел. Хатын да нәкъ аның «ошамый» диюенә ябышты лабаса. Әнә:

— Ник ошамый? Тәхетеңә ярашып җитми мәллә? — диде ул һәм аягын аягына куйды да бик җайлап ияге белән учына таянды.

— Миңа син ошамыйсың! — диде Аит. Хатынның бу сүзеннән соң чыгып китәсенә икеләнмәгән иде, тик ул тыныч кына, тавышын һич үзгәртмәстән:

— Алай артык борчылма: ошаган чаклар да булыр әле, — диде. Әйтерсең лә алар әллә ни гомердән килгән таныш-белешләр.

— Телеңә карап фараз кылганда, син бик күпләргә ошамыйсың булса кирәк, — диде Аит, шул ук «ошамый» сүзен дәвам иттереп.

— Әйе, мин сине шатландыра алам: шул телем аркасында мин хәтта иремнән дә котыла алдым.

Туры һәм кыю сүзләренә гаҗәпсенеп, Аит аны баштанаяк карап чыкты.

— Син ул ирне бик бәхетле иткәнсең. Инде мине бәхетсез итәргә чамалагансың икән, әйт: минем сиңа ни зыяным тигәне бар?

— Каян беләсең: бәлки, бәхетле итәрмендер әле. — Хатынның күз карасы тагын баягыча аркылыга кысылып куйды.

— Рәхмәтләр яусын инде, бик нык куандырдың, — диде Аит, хатынның тел төбендәге шаяртып сөйләгәнен аңлавын, хәтта ошатуын ук белгертергә теләп.

Дөрестән дә: болай шаярып сөйләшү аларның икесенә дә ошады булса кирәк. Ул аларның кәефләрен күтәреп җибәрде бугай, ул гына да түгел, ул аларның икесе арасына күзгә пәрәвезләр сыман җиңел һәм матур бер бәйләнеш җебе сузып куйды. Әлегә исә аларның һәр икесе өчен бер-берсенең шаярып сөйләшкәнен аңлавы рәхәт иде.

— Миңа ошый монда, — дип кабатлады хатын һәм кәнәфигә бөтен гәүдәсе белән чумып, аркасын терәп утырды. — Кайдадыр рестораннар, коктейль-барлар... Ә монда... — Ул әйтеп җиткермәде, кулын җәеп җибәрде дә як-ягына каранып алды.

— Иске-москымы? Кайда кыйшык, кайда җимерек, кайда черек...

Хатын сүзен әйтер алдыннан, көлеп:

— Сиңа бик килешеп тора! — диде.

— Мондый сүзең өчен куалап чыгарыр дип шикләнмисеңме?

— Һич. Сиңа бүген әңгәмәдәш кирәк.

— Психолог икәнсең син. — Аит чиста нур белән тулып торган кубокка коньяк салды.

Хатын аның һәр хәрәкәтен, һәр карашын күзәтеп тора иде. Аит кубокны югары күтәреп аңа сузды:

— Эчкерсезлегең өчен!

Савытның түбәнге бер өлешендә ачык көрән нур ноктасы җемелдәп тора иде. Аңа хатынның да күзе төште, ләкин ул, карашын ул ноктадан бармагындагы якут кашлы йөзегенә күчереп карады: кайсы нурлырак? Тәгаен чагыштырырга теләгәндәй, ул кубокны үрелеп алды.

«Бу дөньяда һәрнәрсәне чагыштырып була шул, — дип уйлады Аит. — Син хәзер, ханым, коньяклы бәллүр савыт нуры белән алтын йөзегең кашын чагыштырып утырасың. Ә шул ук вакытта минем үзеңне кем беләндер чагыштырып утыруыңны башыңа да китермисең.» Тик ул бу хатынны кем белән чагыштырганын хәтерли алмады.

Аның каравы ул инде хатынның йөзеге һәм коньяклы бәллүр җемелдәвеннән дә балкышлырак бер нурны исенә төшерә алды. Ул нур, күктәге йолдызларның нуры җиргә миллиард еллар аша килеп җиткәне кебек, Аитның хәтеренә таба ерак үткәннән — бала чагыннан ук юл алмады микән?

Авылыбыздан ярты чакрымнар тирәсе түбәнрәк инештә бик яхшы, җигүле ат йөрер өчен димсең, машина-трактор өчен димсең, гаять җайлы бер кичү бар иде. Инешебез күп сулы түгел, ләкин ярлары тирән. Ә кичү яры ике яктан да сөзәк, җитмәсә юлы тау юллары кебек бормаланып менә — йөк йөртер өчен үтә дә кулай. Шуның өстенә кичү тирәсендә елга төбе ап-ак ташлы, юри түшәсәң дә алай тигез һәм каты булмас. Ә монда авыл көтүе төшлеккә туктый торган иде. Сыерлар җәйге челләдә суга ук кереп ята, сарыклар да, башларын үз күләгәләренә төртеп, суда төркем-төркем басып тора.

Шул кичүгә җитәрәк, инеш текә борылыш ясап ага иде. Биек-кызыл яр. Ярда катлам-катлам токымнар чиратлаша: иң түбәндә ак таш, аннан соң кызыл ком, аннан кызыл балчык, аннан ары торф, иң соңынтын кара туфрак. (Кызыл ком арасыннан без нигәдер алтын бөртекләре эзли идек. Берәрсе котыртканмы, хыялыбыз кушканмы... Безнең авылыбыз тирәсендәге җир астында алтын бар икән дигән сүз йөргәләсә дә, ул, йодрык-йодрык булып, нәкъ шул кызыл ком арасында ятадыр шикелле иде.) Язгы ташулар белән тегермән буасы бозлары ярны туктаусыз ашый, яңартып тора, ком белән ташларны кичүгә тигезләп таратып сала. Ә яр астындагы тобага ике дилбегә дә төшеп җитми диләр иде.

Бер елгы ташудан соң инеш суы ниндидер кодрәт белән текә борылышка орынмас хәлдә калды. Тоба урынында түгәрәк, тирән күл хасил булды. Суы гадәти чишмә хәтле генә булып агып тора иде. Мин Байкал күле дип менә шул күлне атаган идем. Ул халык теленә дә күчте.

Башта аннан язып торып калган зур-зур балыклар сөзеп алдылар. Бәртәс, чуртан, табан, җәен...

Вакыт үтү белән, суның төсе күзгә күренеп үзгәрә башлады. Башта ул зәңгәр, җылы иде. Аннары яшел төскә керде. Һәр ике төсе дә матур иде. Аннары ул төссезләнә башлады, суы салкынайды, төбендәге балыклар ап-ачык күренеп йөзә, тик тоттырмыйлар, ә үзләре кимегәннән-кими. Берзаманны тәмам юкка да чыктылар. Бу — без — малай-шалай өчен моңарчы күрелмәгән, җавабын хәтта дөньядагы бөтен нәрсәне белеп бетергән әти-әниләребез дә тапмаган тылсымга әйләнде.

Бактың исә, балыклар төннәрен җылы инеш суына күчеп беткәннәр икән.

Аның каравы күлнең төссез суына әллә кайдан гына көмештәй нур иңә башлады. Ул көндезләрен балкып тора иде. Төбенә ярдан ишелеп төшкән кызыл ком җәюле алтын табакмыни! Берәүләр ул балкышны чишмәләр белән җир астыннан килә дип сөйләделәр, хыялга баераклары... күлгә төннәрен көянтәле Ай кызы суга төшә икән, төшкән уңайдан бер коенып та ала икән дип чыгарды. Имеш, ул көмеш нур күл суына сылу кызның таза тәненнән юылып кала икән. Авыл кешеләренең хыялыйраклары ул нурны Ай кызының төнге күз яшьләреннән күрде. Ике дилбегә җитмәслек шундый тирән күлне көмеш нур белән тутырыр өчен ялгыз Ай кызына күпме күз яше түгәргә кирәк булды икән соң?

Авылыбыз кешеләренең хыялга моннан да баераклары көн саен айдан төшкән сылу кызга уллары сугыштан кайтмый калган аналар, ирләре сугышта үлеп калган хатыннар, сөйгән егетләре сугышта ятып калган кызлар килеп булыша икән дип тә тараткан.

Чынын бер кем белмәгән.

Бары тик гашыйклар гына...

Дөньяда гашыйклар белмәгән сер була димени?! Алар бүтән кешеләр күз белән күрмәгәнне кайнар йөрәкләре белән сизә ләбаса.

Бер егет сөйгән кызына Искәндәр кашлы көмеш йөзек бүләк иткән, ди. Кызы ямьсез дип алмаган бит. Авылымдагы Байкал күлнең төссезләнеп калган бер мәле бар иде ич әле? Ул көмеш йөзекнең Искәндәр кашы менә шундый төстә булган, ди, имеш.

«Көмеш нурлы күл буена кил, ул йөзеккә шунда йөрәгебез төсен иңдерербез», — дигән ни чарадан бичара егет.

Кызы ышанмаса да, күнгән тагы. Тулган ай чыгып, айдагы көянтәле сылу кыз бөтен йөзенә елмаеп җибәргәндә, җитәкләшеп күл буена килгәннәр. Егете төссез кашлы көмеш йөзеген учына яшереп, ялганы фаш булу оятыннан курка-курка гына суга манчып чыгарса, ни күрсеннәр: йөзек кашы кызлар бите сыман алсуланып яна ди!

Кыз мәхәббәтеннән тилереп, егет сөюеннән шашып, текә яр башына менгәннәр дә Ай кызына рәхмәтләрен кабул кылуны сорап кулларын сузганнар. Ай кызы көянтәсенә сарылып яткан кулы белән чиләгенең берсен янтайткан да егет белән кызның аяк астында яткан күлгә тәңкә-тәңкә су тамчылары коеп җибәргән вә юкка чыккан. Яшьләр аны күлгә төште мәллә дип аркан борылып карасалар!..

Көндезләрен ай шикелле көмеш нур белән тулып торган төнге күл итәге Кояш сыман алсуланып аларның каршысында җәйрәп ята икән. Бусын әле минем авылымдагы бер кешенең дә күргәне булмаган.

Шуннан соң мин Байкал күле дип атаган күлне Искәндәр күле дип йөртә башладылар. Кояшлы көннәрдә ул ай шикелле көмеш нур белән балкый, ә айлы төннәрдә кояш сыман алсу төс белән җемелди иде шул. Үзем күрдем. Үз күзләрем белән күргәнне үз йөрәгемә салып куйдым. Ул йөрәктә генә калды инде — алдагы елны язгы ташу Искәндәр күлен ком белән күмеп китте. Аның урынында тирән күзле, йөгерек сүзле салкын чишмә генә торып калды. Хәзер анда авыл көтүен көтүчеләр көндезге ашка дип алып килгән сөтле шешәләрен батырып куя...

Ә бу тылсымның сере нибарысы күл төбенә ярдан ишелеп җәелгән кызыл ком да саф чишмә суы. Алтын табакка салынган чишмә суын күргәнегез бармы сезнең? Ул шул Искәндәр күле була инде. Балачагымның йөзек кашы.

Бу дөньяда Аитка әнә шул Искәндәр күленең үз йөрәгендәге нуры бернинди балкыш белән дә чагыштыргысыз кадерле иде.

Шушыны тоеп алган кебек яисә коньяктагы ачык көрән нур бөртеген үзенең рубин кашлы алтын йөзегеннән көнләгән һәм аны тизрәк юкка чыгарырга теләгән шикелле микән, хатын бәллүр кубоктагы сыекчаны сөзеп кенә эчеп җибәрде.

— Өч йөз генә торадыр бу бәллүр, — диде ул, иренен кызыл тел очы белән ялап алгач. Аксыл көрән нур юк иде инде, ул хатынның алсу канына тарала башлагандыр.

— Алай бәллүр саный башласаң, әллүр моннан!

— Алай да шәп мал икәнен әйтеп каласым килә. Үзеңнекеме?

— Атаң башыныкы булсынмы тагын! — дип кычкырды Аит.

Хатын тагын берни булмагандай тыныч калды.

— Бая син мине психолог дип атадың. Ә син үзең псих икәнсең. Син нәрсә?

— Кәбестә, — дип пышылдады Аит.

Икесе дә көлеп җибәрделәр.

— Үземне бәхетсез дип йөри идем. Моңа кадәр синең ише пычак теллеләргә юлыкмавым белән бәхетле икәнмен әле мин.

— Кызганычка каршы, инде менә юлыктың.

— Зарланмыйм. Монда миңа, ни әйтсәң дә, ачык чырай, такта чәй ич әле! — диде хатын, кубогын күтәреп. — Хан кызлары кебек, бәллүр кубоктан затлы коньяк авыз итеп утырган көнем!

— Хан кызлары күз яшьләре генә эчкән.

— Бәхетсезләр.

— Ханнарның бар эчкәннәре кан да күз яше генә. Ә синең кулыңда... — Аит аның кулындагы савытка коньяк өстәргә ниятләп үрелде.

— Юк, юк, рәхмәт. Инде болай да... нинди оятсыз хатын бу дип уйлый торгансыңдыр.

— Ә синең кулыңда җиңүчеләр кубогы. Бу мизгелдә синең бәхетеңә көнләшергә була.

— Нигә бу мизгелдә генә?

— Чөнки бу мизгелдән соң син чыгып китәрсең инде, яме?

— Әйбәт тост! — Хатынның тавышы калтыранган шикелле булды бугай. Ул җайсыз кузгалып куйды, артыгы белән кыюсыз, тыйнак кунактай, уңайсыз утырган килеш калды. — Шушы тостыңа үзең дә тот инде. Югыйсә мин генә талымсызланган булып чыгам.

— Кәефеңне кырдым, ахрысы... Син дөрес әйтәсең: бүген миңа әңгәмәдәш кирәк. Ничек кирәк икәнлеген белсәң иде син!.. Тик бүген миңа ни синең, ни башкаларның хаҗәте юк. Миңа бүген бер генә әңгәмәдәш кирәк — ул да булса үзем. Кешегә үзе генә кирәклегенең ни икәнен беләсеңме син? Хәер, моны һәркем бары тик үзе генә белә... Үз-үзеңә генә кирәк булган чак — кешенең иң бәхетсез чагы ул, ханым... Күп сөйләнеп ташладым. Йә, танышыйк соң...

— Таныш булмаганнар белән яхшырак. Андыйлар үзара эчкерсез сөйләшә. Тәүбә кылгандагы кебек, ихлас итеп. Ярып салып. Эч серләреңне яшермичә. Аннары сөйләгән сүзләрең өчен бер-берең алдында тамчы да оялмыйча аерылышасың.

— Алай да кем атлы соң син?

— Әй, нәрсәгә соң ул?

— Синең исәнлегең өчен бер эчәсем килә, туташ, — диде Аит.

Хатын, үзалдына елмаеп:

— Туташ түгел, — диде якты, аяз күккә карап.

— Туташ дияргә дә бик була, ханым. Ә кем атлы ханым?

Хатын, алга иелеп, аңа ак кулын сузды.

— Сөмбел атлы ханым, — диде ул. — Сөмбел генә дисәң, яхшырак.

— Сөмбел, — дип кабатлады Аит.

— Бер шагыйрь кисәге Гиацинт дип йөргән иде.

— Охшамагансың түгел, — диде Аит, аңа тутырып карап.

— Комплиментлар яратмыйм.

— Ялгышмасам, Сөмбел — төнлә ачыла торган чәчәк булса кирәк.

— Син беркадәр хаклысың. Артист халкы кешеләр өчен төнлә ачыла.

— Син артистмыни?

— Без авылларга гастрольгә чыктык.

Сөмбел күчмә театр артисткасы иде. Бу авылның кунак йортына килеп урнашкач, кибет карап кайтырга дип чыктылар. Чир диярсең: алар иң әүвәл авыл кибетләрен карап чыгалар. Алырга теләгән нәрсәләре дә юк, шулай да тыелып кала алмыйлар. Бәлки, бу озын көнне уткәреп җибәрүнең инде гадәткә кергән бер чарасыдыр? Аннары тәэсирләргә бай кичне хезмәт, сәнгать таләп итә торган киеренкелек, сәхнә зәвыгы, алар гел кабатларга тиеш булган матур идеяләр артист халкын көндезге тормышында кайчак беркадәр күңел күнекмәгәндәй тоелган кире чагылышлары белән дә гаҗәпләндергәли. Ниндидер бәйсезлек, беренче карашка тупасрак кабул ителергә ихтимал булган мәзәкләр, гадәти кешегә көлкеле күренгән атлы кыланып, шаярып алулар... Ә асылына төшебрәк карасаң, артистның җаны мәңге ачык килеш торган тирән җәрәхәт сыман ул. Тормышта тагын кемнәр шулай һич икейөзлеләнмичә үз-үзләре булып кала белә икән?

Сөмбел дә менә шундый җаннарның берсе иде.

Бая кибеткә барышлый гитара тавышына сагая калды да, кызыксынып, яшел чирәм белән капланган капка төбенә таба атлап китте. Авыл җирендә шулай җиткезеп гитара чиртүчегә карап узарга теләү табигый лабаса. Моннан да битәр бөтен кыяфәте белән иясез икәнлеге беленеп торган йортның ниндидер бер тылсымы, сере бардыр кебек иде. Ул берәр эшсез студент затын очратасына һич шикләнмәде. Гитара тынып калды, ә ул капкага таба нибарысы бер-ике адым атларга өлгерде. Ул кыймыйча тукталып калды, узып киткән хезмәттәшләре аңа, борылып, кайсы чакырып кул изәде, кайсы көлде, кайсы «Кыюрак!» дигән ишарә бирде.

Ә капка төбенең чирәме калын, йомшак паласка баскандагыча, аякка рәхәт иде. Ул бары тик шул рәхәтлекне татып карар өчен генә тагын ике-өч адым атлады. Кемнедер йокысыннан уятмаска теләгәндәй тын гына, салкын суга кергәндәгечә сагаеп кына, караңгы бүлмәдә капшанып баргандагыча куркып кына. Андый чакта колак үтә сизгер, итәгең кузгаткан җил дә ишетелә, аяк басуың да каты кебек, йөрәгең дә бөтен кешегә ишетелерлек булып тибә бит ул.

Менә хәзер дә һәр атлаганы саен тук та тук аваз килә башлады. Ирексездән ул үз адымнарын шул тавышка көйләп басты.

Башта ул аяк астындагы чирәмне карап, аның яшеллегенә, үрмә сабакларының япон рәсемнәрендәгечә ассимметриясенә, чәчәкләренең он бөртеге хәтле генә таҗларына сокланып барды. Аннары ачык кап-

кага сузылып кергән җиләс һава агымын тоеп алып, карашын шунда күчерде. Карашы белән кече капканың кеше колагын хәтерләтеп бөгелгән keләсен искәртеп узды. «Нинди гармония: келә, чыннан да, капканың һәр аяк тавышын сагаеп тыңлаучы колагы лабаса!»

Шунда ук табак-табак ак ташларны күреп алды. Аралары чирәмле. Ул аларны яшел белән каймаланган сатин кулъяулыкларга охшатты. Басып керер өчен аяк астына кулъяулыклар салып куйган кебек. «Мондый җирне кайда күрер идең?» — дип уйлады ул. Басып йөрер юлыңа шундый мәгънә салып кую өчен йорт хуҗасына нинди акыл иясе булу кирәктер! «Йа Хода! Монда гаҗәп матур һәм тату торганнардыр!» Ә хәзер абзарның арык сыер тиресе шикелле эленке-салынкы салам түбәсендә эсселектән шәлперәйгән алабуталар моңаеп утыра.

Тимер белән суккан тавышны эзли-эзли, Сөмбел ишегалдының кече капкадан күренеп торган бар нәрсәсен күзе белән капшап чыкты. Коргаксып беткән арба тәгәрмәче, стенадагы чөйгә эленгән йөгән авызлыгы, ыргак, ишегалды уртасына өеп куелган кәнәфи, сүтелгән өстәл, кибеттән алынганнан бирле ачылмаган яссы әрҗәләр, берсе яңа, берсе таушалган чемодан, тагын әллә нәрсәләр өеме, келәт почмагына кыстырылган урак, төпсез чиләк, болдыр баскычындагы кыйммәтле магнитофон («Сони»?) Әлеге тавышны җиләс һава селкетеп торган чыбык очы чыгара бугай... юк, чыбык очы түгел, ялтырап торган нечкә тимер. Янтая төшеп, эчкәрәк сузылып караган иде, болдыр баскычында утырган бер ирне күрде. Ул баскыч тактасына шпага белән суккалап утыра икән. Аның йөнтәс беләгендә браслетлы сәгать, күлмәк җиңен сызганган. Нык муенга утырган, аеры иякле, ач яңаклы, кысыграк күзле, калын кашлы һәм кара чәчләре артка таралган.

Һәм Сөмбел аны таныды. Әлбәттә, таныды. Әйе, әйе, таныды...

**Дүртенче бүлек**

Бигрәк тә ул аның сәҗдә кылган картныкыдай тирән, моңсу күзләренә игътибар итте. Әллә үкенеч, әллә кайгысы бар, әллә аек, әллә исерек, әллә киеренкелек, әллә битарафлык... Әллә бөтенләйгә өеннән чыгып китәргә җыенган, әллә төялеп бөтенләйгә кайтып төшкән. Әмма чыгып китәсе кешенең йорты бу хәлгә үк төшмәс.

Ниндидер бер тылсымлы пышылдау чакыруына ияргән сыман, ул капкадан эчкә узды. Бөтен җаны-тәне белән бу серле ир заты бәргәләгән шпаганы очыннан эләктереп туктатырга теләде. Ул, кемнедер юаткан сыман: «Хәзер, хәзер», — дип уйлады. Шулай дип үз-үзен юатмады микән?

Ул бу йортның шаулап-гөрләп торган чагын да бик яхшы хәтерли иде.

— Бая, беренче күрүгә мин сине китәргә җыенгансыңдыр дип торам. Ишегалдыгызда алабута үсә, каралты-курагыз ишелергә тора... Ишегалды уртасында мал-мөлкәт... Димәк, күрергә генә түгел, торырга дип кайткансың. Мондый хәлдә кешегә авыр.

— Җиңеләйтергә теләгән идеңмени? Җиңелгәннең хәлен җиңеләйтеп булмый, ханым.

— Җиңелгәннең?

— Минем кем икәнемне беләсеңме?

Сөмбелнең «Беләм!» дип кычкырасы килде. Сикереп торып: «Беләм, Аит абый!» — дип кычкырасы. Шушыныңчы аның үзен танымавы гына тыеп калды. «Танымады. Күңеле белән карамыйча, узгынчы дип кенә кабул иткәнгә күрәдер. Әллә ул шулай танымаслык булып үзгәргәнме дисә... яисә картайган укмы?»

— Мин...

— Кирәкми, әйтмә, — диде Сөмбел.

Аит, аннан күзен алмастан, кубокка бер-ике йотым коньяк агызып алды.

— Шулай. Узгынчыга мине белү нигә хаҗәт... Элек мин мондый кубоклардан бары тик җиңүләрем өчен генә эчә идем...

— Ә хәзер?

— Җиңелүем өчен.

— Анысы да булгалый торган эш. Тагын җиңәрсең әле.

«Болар бергә түгел инде, ахрысы, — дип уйлады Сөмбел. Үзен ышандырыр өчен, ул үзен болай уйларга этәргән сәбәпне дә эзләп тапты: Аит әле бер генә мәртәбә дә «без» димәде, гел «мин» дә «мин».

— Спортчы гомерендә һәммә җиңүләр дә артта кала торган бер чик була. — Аит бер йотып куйды да коньякның тәмен татыгандай тынып калды. — Бу яктан сез, артистлар, бәхетлесездер. Сезнең халык сиксән яшьтә дә унөч яшьлек Джульеттаны уйнар идем дип дәгъвалыйдыр, — диде Аит.

— Кайбер чакны минем шикелле утыз яшьтә дә хәзрәтнең карт хатынын уйнарга туры килә. Бигрәк тә син режиссер белән килешә алмаган ялгыз, өстәвенә шактый чибәр бер хатын да булсаң. — Сөмбел бармак очлары белән генә үзен баштанаяк сыпырып үткәндәй бер хәрәкәт ясап алды.

«Анысы хак, чибәр», — дип уйлады Аит.

— Академия театрыннанмы син? — дип сорады ул.

— Юк, күчмәдән. Хәзер күчмә дип аталмый, исемен үзгәрттеләр. Тик җиселе шул көенчә калды. Тоташы белән чегән тормышы — гомер буе көпчәк өстендә.

Аит, чак кына салып, кубокны аңа сузды.

Сөмбел алмады.

— Рәхмәт.

— Кире какканны яратмыйм, ханым.

— Мин нигәдер кире кагарга яратам шул. Югыйсә карт хәзрәтнең иң карт хатынын уйнап йөрер идеммени? Үзең эч. Син матур итеп эчә беләсең икән: назланып, тәмен татып.

— Йә, алайса ни өчен эчим?

— Киләчәктәге җиңүләрең өчен.

— «Киләчәктәге җиңүләрең»... Барысы да артта калды.

— Үткән җиңүләр — иң җиңелләре алар. Кешенең иң авыр җиңүләре алда... Кешенең мондый хәрабәләр арасына кайтып төшүе зур бер җиңүдер ул.

— Җиңелдем дигәч тә, үземне тормыштан соңгы уколны алган кеше дип уйламыйм әле мин. «Әйе, минем әле үземне җиңәргә теләгән язмышның үзенә кадап күрсәтәсем бар, үзенә! Иң татлы җиңү — соңгы очко», — дип уйлады Аит. Аның шпагасы белән һаваны чәнчеп-чәнчеп аласы килде.

Бу йортны — үзенең туган бишеген — ул җәннәт итәргә уйлап кайтты. Аның анлык кына байлыгы бар. Яшәп күрсәтәсе килә иде. Аңа үч итеп, аңа!

Ул эчеп җибәрде.

— Менә монда румын гарнитуры, — диде ул, кубогы белән әрҗәләргә ишарәләп. — Ә менә монда... — Ул кулын селтәп алды.

— Нигә элегрәк кайтмадың? Нигезегез тәмам тузган. Ә кайчандыр бу йорт авылда иң тазалардан, матурлардан иде.

— Күргәнегез бар идемени? — диде Аит, аңа карамыйча гына.

Сөмбел кузгалып куйды.

— Бәй, моны күрү кирәкмени? Бар нәрсә монда кайчандыр зур тәртип булганын сөйләп тора. Иске йорт булса да, берни аунап ятмый.

— Аунаганнарын ташып бетергәнгә күрә ул.

— Ташып бетергәнче кайт идең.

— Батырлык җитмәгәндер.

— Батырлык? — Сөмбел тынып торды. Каршысында утырган иргә авыр бер сүз әйтүен аңласа да, ул: — Мин... хатының риза булмагангадыр дип торам, — диде.

«Кызык бу хатын-кыз логикасы, — дип уйлады Аит. — Бөтен нәрсәне хатын-кызга гына бәйле дип белә».

Хәер, хатыны белән аерылмаса, ул бирегә торырга дип кайткан булыр иде микән? «Батырлыгым җитмәс иде», — дип килеште ул. Хәзер үз нигезенә кайтыр өчен дә батырлык кирәк шул. Бүгенге дөнья әллә нишләде. Ә бәлки, бернишләмәгәндер? Батырлык ул элек кайда һәм кайчан кирәк булса, бүген дә шунда һәм шул вакытта кирәк. Аның бары тик төсе генә үзгәрде. «Төсе?» — дип сорады ул үз-үзеннән. Батырлык һичшиксез кан төсендә — кызыл гына булырга димәгән. Хәер, тыныч көннәр батырлыгы күбесенчә яшерен. Бүгенге көн батырлыгы үтә шәхси эш. Беркем артыңнан куып тормый. Шуңа күрә аны эшләве дә кыенрак. Аның бүген син читләтеп үтәргә һәм үзеңне акларга мөмкинчелек биргән бик күп сәбәпләре бар. Әйтергә кирәк, җитди сәбәпләре!.. Менә шул сәбәпләрне җиңә, шәхси читлегеннән чыга алган кеше — каһарман ул. Ә ул, Аит, каһарманмы? Ул туган нигезен җимерелүдән, бетүдән саклап калыр өчен бар дәрәҗәмнән, ирешкән биеклегемнән ваз кичеп кайттым дип әйтә аламы? «Кыргансың икән! — дип көлде ул үз-үзеннән. — Моны гап-гади бурыч дип тә атарга була лабаса! Туган бишекне саклау бурычы. Тик һәр бурычны үтәү каһарманлык түгел».

Аннары соң ул монда үз киләчәгеннән ваз кичеп түгел, ә бәлки үткәненнән качып, җимерелгән үз язмышын төзәтү исәбе белән кайтмады микән? «Юк! Мин монда дөньяны тагын бер мәртәбә җиңәр өчен кайттым».

Әйе, ул бу йортны җәннәт итәчәк әле! Иске булса да, бүрәнәләрен чыкылдап торган нарат такта белән тышлап җибәрсәң, ике гомергә чыдарлык. Ишегалдына гына кара — үзе бер сабан туе мәйданы хәтле бар. Аның әтисе белән әнисе яши белгәннәр дә соң! Кешеләрнең ишегаллары уч төбе хәтле генә. Аит нигә шулай икәнен чамалый. Җәен себерергә, кышын карын көрәргә иренүдән шулай кечкенә, тотып алыр өчен такта кызганудан, күңел тарлыгыннан. Ә аларның нәселе иренүнең, ялкаулыкның ни икәнен белмәгән дип

сөйлиләр. Ләкин менә балалар гына кайткалап, төзәткәләп тора алмадылар. Менә иртәгә, менә иртәгә дип, тыныч кына яши бирделәр. Йортны сатып җибәрергә дә кызгандылар. Ә тормыш гел бүген бит ул, каһәр! «Иртәгә» дигәнең үлгәч кенә килеп җитә... Йә, ярый, кем әйтмешли, Алла Аитка мәдәт бирсен...

Бу хакта Аит әллә кайчан уйлап куйган иде инде. Сөмбелнең «элек хатының риза булмаганга кайтмагансың дип торам» дигән фикеренә җавап кайтарыр өчен генә кабатлап торуны кирәксенмәде. Бу нәрсә аны һич кызыксындырмаган һәм борчымаган кыяфәт белән ул магнитофонының ике төймәсенә басып алды.

Аит таянмый-нитмичә һәм көч кертмичә, мәченеке кебек сыгылмалы гына бер талпыну белән урыныннан торып басты. Әгәр бу хәрәкәтне ни беләндер чагыштыру кирәк булса, Сөмбел аны оста артистның яхшы куелган сыгылмалы, йөгерек, көйле тавышына тиңләр иде. Артист үз тавышы белән идарә итә белгән кебек үк, спортчы да үз тәнен, мускулларын да үзе дә сизмәстәй дәрәҗәдә хәрәкәтләндерә ала икән.

— Рөхсәт итмәссез микән, Сөмбел ханым? — диде Аит. Шуннан соң капканы ябып килде дә аның каршысына килеп басты.

Аның гәүдәсе, торышы, кыяфәте, йөзенең тыныч, үз-үзенә ышанган төсмере матур иде. Сөмбел беренче һәм инде кайчан икәнлеге дә онытылган беренче күргән Аит башлыча уенчак тайга тартым иде. Хәзер ул уенчаклыкны акыл һәм тәҗрибә буйсындырган. Ә Сөмбелне ничек танымый соң ул? Сөмбел, бәлки, таныгандыр, тик нигәдер белгертергә теләмидер яисә базмыйдыр дигән өмет белән:

— Мин үземә таныш булмаган ир-ат белән биемим шул, — дигән булды.

— Алайса таныш булыйк: Аит.

«Юк, танымаган».

— Кызык исем, — диде Сөмбел һәм, аның үзенә таба сузылган учына таянып, урыныннан торды. — Кызыклы исем, сирәк. Дөнья чемпионымы әле?

— Элеккеге.

— Медальләрегез күпме?

— Алар хәзер истәлеккә генә ярый инде... Бал-маскарад телисезме?

Рәсемнәр белән чуарланып беткән шул ук сумкасыннан шпагачы битлеге һәм медальләр тасмасы алып, Аит Сөмбелгә кигезеп куйды, ә үзе шпага такты. Яссы ташлардан төшеп, вальс бии башлаганда гына, Сөмбел алабуталарга абынып китте.

— Монда бик онытылып әйләнермен димә шул.

— Әйе, сәхнә түгел.

— Син дөнья буйлап чемпион титуллары яулап йөргән арада, нигезегезне алабута басып киткән!

Аит кисәк туктап калды. Аның күгелҗем мәрмәрдән уеп ясалгандай ияге Сөмбелнең күзе турысында иде, һәм хатын аермачык итеп ул нык иякнең тетрәп куйганын күреп алды.

— Пәрдә, ханым, — диде Аит. — Спектакль тәмам.

Һәм ул тыелгысыз ярсу төстә шпагасы белән алабуталарны уңлы-суллы туракларга кереште. Ул селтәнгәндә, корыч чыбыкның чажлавы музыканы да басып китә иде. Кайдадыр каргалар каркылдашып алды.

Сөмбел, бая биредә пәйда булгандагыча тыныч кына:

— Кирәкми, Аит, — дип караган иде, тәэсире булмады. — Аит! — диде ул, тавышын күтәрә төшеп. — Тынычлан, Аит! — һәм шпагасын югары күтәргән бер мизгелендә аның күкрәгенә ташланды.

Мөгаен, көтмәгәндә юлга йөгереп чыккан һәм өстенә килгән машинадан куркып калган баланы коткарырга да шулай ташланалардыр.

**Бишенче бүлек**

Аит гаҗәпсенүдән зур ачылган күзләре белән аңа текәлде. Сак кына итеп, икеләнеп, аның иңбашына орынды. Уч төбенә аның җиңелчә генә калтырану дулкыны таралды.

— Кирәкми, — дип пышылдады Сөмбел.

Аит үз муенына аның битлек челтәреннән чыккан кайнар сулышның күбәләк канатыдай җилпенүен тоеп алды.

— Ирләргә килешми, — диде Сөмбел.

Текә борылышка җиткән елга кебек, Сөмбел читкә тайпылды. Аңа аркан торган килеш башындагы битлекне, иңбашына кыйгачлап салган медальләр тасмасын салып, бер әрҗә өстенә куйды.

— Монда теләсә нинди күңел ачу маскарад кына, ханым. Гафу ит.

— Спектакльгә чаклы минем вакытым бар әле. Әйдә әйберләреңне өйгә ташып куябыз! Төнгә монда калмаслар лабаса. Мин кермәсәм, инде шактыен ташып бетерер идең.

— Рәхмәт. Башта эчтәге иске-москыны чыгарып ташлыйсы бар әле. Бераз төзәтәсе, юасы, җайлыйсы...

— Иске-москы? Кирәге чыкмас дисеңме?

— Эш анда түгел. Искә төшереп тормасыннар.

— Ихтыярың... — Сөмбел башын гына борып аңа карады.

Аит аның үзен кызгануын тойды.

— Син чыннан да бөтенләйгә кайткансың.

— Бөтенләйгә.

— Ә... хатының... балаларың? — диде Сөмбел, өзек-өзек итеп. Моның белән ул соравының җитдилеген белгертергә теләгән иде. Ә Аит Сөмбелнең бу сорауны үзенә күптән ачыклап куйганына шикләнми иде инде. Сүз ни хакында гына кузгалмасын, ул әле бер генә мәртәбә дә «сез» дип авыз ачмады ич. Ул: «Син чыннан да бөтенләйгә кайткансың», — димичә, «Сез чыннан да бөтенләйгә кайтырга карар кылгансыз икән», — дия ала идеме? Болай әйтсә, сүз, әлбәттә, гаилә хакында дип аңлашылыр иде. Димәк, аның «хатының, балаларың» дию е бары тик тел төбе яшерәсе килүдән генә. Мәче-тычкан уйнау яки бу ханым алдында үрнәк кеше сурәтендә күренәсе килү ялган да, мәгънәсез дә.

Шуңа күрә ул, кырт кисеп:

— Аерылыштык, — диде.

Әмма аның бу сүзеннән соң ханым башын чак кына артка ташлый төшеп, елмаеп куйды түгелме соң? Башын артка ташлавы аны биегәйтеп тә җибәрде бугай. Кешене шатлык, тантана, горурлык йә мактану хисе генә биегәйтә. Башка бөтен хисләр дә аның буен кечерәйтеп җибәрә. Аның елмаюын күрмәмешкә салышу, хәтта җәзасыз ук калдыру да мәгънәсезлек булыр иде. Хис яшермәү ирләргә дә кирәк сыйфат.

— Мин синең елмаюыңны күрәм, ханым, — диде ул, фикерен бөтенләе белән үз иркенә җибәреп. Әмма бу сүзләрне әйткәндә, ул үзе дә күңелсез йөз белән елмаеп тора иде.

— Ни сөйлисең син? — диде Сөмбел һәм, башын алга иеп, кулы белән йөзен каплады, гәүдәсе шундук кечерәеп, мескенәеп калды.

— Әйе, әйе! Үзең кебекләр үзең генә булмавы кайвакытта куандыра да ул!

Аит аны башта җавап кайтарып тормастан чыгып китәр дип көткән һәм туры бәреп әйтүенә үкенгән дә иде инде. Сөйләшеп утыруы, яшерен ымнар белән сынашу ярый иде ич әле. Шул ук вакытта ул Сөмбелнең чыгып китмәячәгенә дә төшенде: ул җиңелергә ярата торган хатын-кыз затыннан булырга охшамаган.

Әнә ич кулы белән битен яртылаш каплаган килеш (әллә кофтасының күкрәгендәге тирән уентыгын каплавы микән?), кисәк кенә аңа таба омтылды. Күзе ачылган, еш-еш сулу ала.

— Мине үзеңнең яңагыңа сугып җибәрде дип бел!.. Яки йөгереп чыгып китте дип... Гарьләндердең һәм үпкәләттең... Мин үземне бәхетсезләрдән санамыйм, тик кеше бәхетсезлегенә куана торган бәхетсез түгел әле мин... тәкъсир!

— Алайса ник елмайдың соң?

— Сине уйлаганнан түгел. Була бит шундый мәгънәсез уйлар: мин үземне син ташлаган хатын итеп күзалладым... Ә ул хатынны — үзем итеп.

— Моңа еларга кирәк, елмаерга түгел.

— Фаҗигаләрнең елмайтырдайлары фаҗигалерәк.

— Гафу ит. Соң... сук һәм ташлап чыгып кит.

— Боларның икесе дә бик җиңел юл. Кайчагында калуы авыррак була. Кайчагында түзү һәм калу кирәк. Бәлки, сиңа да хатының белән калу кирәк булгандыр.

— Безне бу хакта уйланмаган ахмаклар дип беләсең мәллә?

Аит магнитофонны сүндерде. Тагын зыңлап торган тынлык урнашты. Һаман да шул чикерткәләр генә әле озын, әле өзек-өзек итеп аваз сала.

Аларның икесе арасындагы күренмәс җеп тә шулай киеренке зыңлап торадыр шикелле. Кайдадыр биектә, нәкъ аларның баш өстендә эленеп торган зур кургаш шарның җебе өзелгән дә шул шар сызгырып аларга төшеп килә сыман. Шуны тоеп, ләкин качарга һичнинди талпыныш ясамыйча, алар бер-берсенә сүзсез карап тордылар. Карашлары гүя торган саен үзләренә якынлашып килгән кургаш шар кебек авыр иде, тик алар бер-берсен котылгысыз читләшүдән коткарырга ашыкмады. Әгәр дә Сөмбелнең иренenә иннек сөртелмәгән булса, Аит аның агарып калуын күрер иде. Хәзер исә ул аның күзенә игътибар итте. Сөмбелнең күзе яшькелт төстә һәм ул яшеллек аңа тау башыннан күренгән түгәрәк үзәнне хәтерләтте: әйтерсең лә пыяла астына велюр җәеп калдырганнар.

— Сау бул, — диде Аит һәм килеп гитарасын алды да, болдыр култыксасына, аның ачык ишегенә каршы барып утырды. Бернинди дә уе булмаганга, бармаклары үзләреннән-үзләре гитара кылларын чиртә-ли башлады.

— Гитараң яхшы. Зыңлап тора. Яңгыравыклы.

— Болдыр шулай ишеттерә, такталары нарат, шуңа яңгырый... Тавыш, кеше тавышы сагынган бу йорт... Корридадан соңгы стадион кебек буш, ташландык, сагышлы.

— Коррида... Испаниядә булганың бармыни?

— Юк. Мексикада күрсәттеләр... Бөтен дөньяны айкадым-айкадым да чыгып киткән бишегемә әйләнеп кайттым... Әле дә ярый хәлдән тайгач кайтып егылыр өчен ата-ана нигезе бар. Без аларга үзебезне дөньяга китергәннәре өчен генә түгел, безгә теләсә кайчан кайтып егылырга мәңгелек бишек калдырганнары өчен дә бурычлы, — диде Аит, йорт-җиргә ишарәләп. — Әти белән әни корган бишек... Моннан якты дөньяга җиде бала канат ныгытып очкан.

— Берегез-бер авылда түгелме?

— Укыдык без.

— Сатасыгыз калган. Йортыгызны диюем.

— Арып, хәлдән таеп егылган атны атып йә бәреп үтергән шикеллеме?

— Атларны шулай үтерәләрмени? Сугышта гынадыр. Шуны әйтәсеңме?

Безнең авылдан түбәнрәк, үр өстенә утырган кечерәк бер рус авылы белән ике арада үләксә киртәсе бар иде. Анда үлгән малларны илтеп ташлыйлар иде. Үләксә дигәне болай да аңлашыла, тик без үзебезне белә башлаганда анда бернинди дә киртә юк иде инде. Күрәсең, мал-туар зиратының кайчандыр киртәсе дә булган. Ә хәзер юк, тирәләп казылган һәм кычыткannan гайре берни үсми торган канау гына бар. Безнең авыл зираты тирәли дә шундый ук канау казылган, тик анда кычытканнан кала мәтрүшкәләр, әрем, ут чәчәкләре, кылган, исле чәчәкләр дә үсә иде. Авыл халкы үз зиратын да, мал зиратын да бертөрле үк итеп ясаган, күрәсең, үлгән мал-туарны да якын иткән, хөрмәтләргә тырышып күмгән. Һәр ике зираттан да бер үк дәрәҗәдә шикләнү, курку бар иде. Имеш, кешеләр зиратында да, мал-туар зиратында да бер үк җенпәриләр, өрәкләр, албастылар тора. Мал зиратына каршы, инешнең бу ягында, колхозның печән болыны, бер читендә биек камыш-җикәнле һәм куе кыяклы түгәрәк күл җәйрәп ята, анда көне-төне бака тавышы, карп-кәрәкә, бака челәне, кыр үрдәкләре (гаҗәп, ул үрдәкләрне атучы юк иде). Болында билдән чумып печән чабалар, ә үләксә киртәсе бүленеп алынган болында мал яратмыйча гына ашый, ашаса да, күзләрен кызартып чыгара, йоннарын койдырта торган куе сазлык үләннәре белән аксыргак кына үсә. Шундый үле болын булганга, үләксә киртәсе иткәннәрдер дә инде. Дөрес, җәй көне ул тирәгә авыл көтүе кертеп чыккалыйлар.

Печән чабучылар, шул тирәгә төнлә килеп эләккән көтүчеләр (болын печәнен чабып алгач, болынга колхоз көтүен тешерәләр) үләксә киртәсе өстендә көлтә-көлтә зәңгәр ут күреп кайталар. Ул ут шарлары якын-тирәдә торган чагың булса, артыңнан куа чыга, имеш. Аның ни икәнен аңлаткан укытучыларга ышанмыйчарак калалар, халык маҗаралар ярата. Сугыштан кайтканнарга гына ышандылар. Ул көлтә-көлтә ут мәетләр күп күмелгән җирдән чыга икән — газ. Фосфор газы. Монда да малларны күмәк чокырга ташлыйлар да өстән юка гына итеп күмәләр ич.

Ә бездә картайган яки хәлдән таеп, бүтән тормаска яткан атларны чалалар иде.

Ризван абый амбар хәтле Владимир токымлы «Килен» кушаматлы атны шулай чалды.

Мәһабәт һәм яшь баладай тупырдап торган ат иде ул! Аны Ризван абыйга Кенигсбергны алгандагы батырлыгы өчен сугыш беткәч биргәннәр. Авылда күрше авылның Гриша атлы кешесе йөртә торган бер машина, ике «ДТ» тракторыннан гайре бар ышаныч атларга багланган еллар иде. Ул Владимир токымлы атны ат җигеп эшләүче егетләр кызларга гашыйк булганнан да болайрак яраттылар. Соң! Көрән төсле, төн кебек зәңгәрсу-кара ял белән биеп кенә йөргән табак-табак тояклар, сыйрагындагы ул елларны хатын-кыз Сабан туйларына чигүле чүәк белән киеп чыга торган оекларга тиң ак җире, тутырып ачылган шәмәхә күзләр, киң маңгаеның урта бер җирендә йолдызларга биргесез матур янып торган кашка, өстәл кадәрле түш, дугаланып килгән муен (кыл тарттырып,ук сал да Ай кызының чиләк бавына төбәп атып җибәр инде менә — суы чайкалып, шыбыр-шыбыр җиргә агачак!) — гашыйк булу гына түгел, саргайтып киптерерлек ат иде ул! Кушаматы да нинди диген — «Килен»! Колхозның мактанычы иде ул ат. Арба гына чыдасын, ни салсаң да тарта, ни таксаң да өстери, сөйри. Кырмыска кебек фидакарь, бал кортыдай башын эшкә биргән зат. Аны сугышта ат белән туплар сөйрәтеп орден алган шул Ризван абзый җигә иде. Колхоз җыелышы җыеп карар чыгарганнар. Ризван абыйның ул атны алып кайтуы гына җитмәгән, күз карасы кебек сакларга сүз бирдерткәннәр, ант иттерткәннәр.

Антын ул изгеләрчә бирелеп тота иде: Киленне мунчага гына кертеп чабындырмый, кунактан кунакка гына йөртми инде менә!

Ризван абыйларның балалары булмаган. Ә бер җәйне, ниһаять, ни гомердән соң, инде өметләре өзелде дигәндә генә бәбәй көткәннәр.

Сабан туе көне була. Берничә авыл җыелып бәйрәм итә торган соңгы җыеннан кайтышлый, Ризванның хатыны, бөтен гәүдәсен бер йодрыкка җыеп кыскандай авыртуга сулышы кысылып, иренең колагына иелә дә ояла-ояла гына пышылдый:

— Инде ку!

Ризван абый бар халыкны юып кына төшергәндәй арбасыннан бушата да Киленне өч чакрымдагы больницага таба куа. Барышлый әллә ни түгел. Ә менә игезәк уллары дөньяга килү сөенчесен авылга җиткерү теләге аның бар вәгъдәсен иманыннан җил итеп очырта да биргән антын борчак итеп чәчеп калдыра. Үзенең башын күккә тигезгән шатлыгын кайтарып җиткерә ул җиткерүен. Әмма басу капкасын узып, авылга килеп керүенә, Килен аяклары тотмыйча гөрселдәп чирәмгә ава.

Алай итеп карыйлар, болай итеп — юк, тормый. Төн уртасы җитүгә карамастан, халык киму түгел, арта гына бара. Фельдшер да шунда, ветлечебницадан иң баш белгеч тә килеп җитә, участок милиционеры Ризван абыйны кулга алу белән яный, идарә бухгалтеры йортыңны сатсаң да түләп җиткезә алмыйсың дип куркыта, кайсысы юата, кемдер шатлыгы хакына кичерүне, шәфкатьне онытмауны дәгъвалый...

Ризван абый бу сүзләрдән шүрләү түгел, ишетми дә!

Ул бөтен авыл халкының уртак мәхәббәтен, бөтен авылның күңеленә мәңгелек килен булып төшкән, үзе белән бергә утны-суны кичкән сугышчан дусты янында төн кунарга кала, икенче көнне көне буе утыра да таң алдыннан аның муенына пычак сала...

Ул көнне Ризван абыйның солдат гимнастеркасы, үзе яралангандай, канга буялып бетә. Шуннан соң аны гимнастеркасын һәм галифесын кигән килеш күрмәделәр. Ул аларны сугыштан кайтканнар арасыннан беренче булып салып ташлады.

Киленне бөтен авыл ирләре, егетләре мал зиратына үзенә аерым чокыр казып күмделәр.

Шуннан соң Ризван абыйларның бүтән балалары булмады инде.

Хәлдән таеп, бүтән тормаска егылган атны чалырга чын ирләрнең генә йөрәге җитә. Шуңа күрә без атны чиксез куып яндырудан үз җаныбызны яндырудан курыккандай сакланып үстек.

— Әйе, безнең бу ятим йортны сатарга кулыбыз күтәрелмәде. Хыянәт кылырбыздыр кебек тоелды... Тик вакытында ирләр булып калу кирәк икән! Кызганыч... — диде Аит.

— Кызганып кайттыңмыни?

— Нәрсәмнедер югалттым, Сөмбел. Ни эзләп кайттым, белмим... Бәлки, алтындыр? — диде ул, кинәт кенә Сөмбелгә борылып һәм шаян елмаерга тырышып. Аннары, нидер исенә төшереп, мыек астыннан гына елмаеп та җибәрде.

Сөмбел көтелмәгән бу күчешкә аптырап китте.

— Алтын? — диде ул, Аитның сүзләрен ни уенга, ни чынга алырга белмичә. — Нинди алтын?!

— Белмим... Безнең өйнең кайсыдыр бер төшендә алтын бар дигән сүз йөрде. Бабайга тегермәнче бай сезгә яшердем дип әйткән, имеш. Колхозлашу башлангач алып киткәннәр дә шуннан кайтмаган инде ул.

— Алтын эзләүче... Сиңа алтын бик кирәк, Аит. Ләкин бәхет алтыны... Мин дә кире какмас идем.

— Бәхет үк булмаса да, бүген минем бу авылда беркемдә дә юк нәрсәм бар ич әле — «Камю» коньягы! Һәм...

— Баш очында түбәме? — дип бүлдерде аны Сөмбел.

Аит ташка сикереп төште.

— Һәм син, — диде ул. — Яхшы әңгәмәдәш.

Сөмбел читкә борылды.

— Ни югалтса да, ир-ат бер генә нәрсә эзли шул — хатын-кызларны.

— Дөнья шулай яратылган ич, Сөмбел: кешеләр үз-үзләрен күп очракта башкаларда таба.

— Бәла дә шунда шул — таба. Ирләр үз-үзләрен очраган бер хатын-кызда табарга риза.

Аит аның каршысына килеп басты.

— Хәзер бу гади эшләнә, шулаймы? — диде ул һәм Сөмбелнең күкрәгенә кушырып куйган кулларын түбән шудырып төшерде.

— Ничек була инде ул гади диюең?

— Менә болай, — диде Аит һәм җитез бер хәрәкәт белән аны үзенә таба тартып китерде дә иреннәреннән суырып үпте.

Сөмбел тынсыз калды. Коньяк йотымы аның кәефен күтәреп җибәргән иде, гадәти булмаган бу очрашу һәм сөйләшү мавыктыргыч, Аитның кыюлыгы бик гади, Сөмбел кайбер кунак-мәҗлесләрендә моның ишене генә күрмәде түгел, хәзер дә аның тәне оеп киткәндәй булды, юк, моны ул үз-үзеннән яшерми, юк! Ләкин ул күңелендәге кайсыдыр бер кылның үз кәефенә буйсынырга теләмәгәнен дә тоя иде. Нәкъ менә гадәти булмаган бу очрашу һәм сөйләшүнең шулай гади бер хәрәкәткә килеп терәлүе белән килешә алма-

ды. Башка чакны үзен мәҗбүр итеп булса да, артык игътибар итмәгән атлы гына кыланып, уздырып та җибәрер иде...

— Яхшы аңлаттың, — диде ул, хәзер нишләргә тиешлеген уйлый-уйлый. — Ә җавабы тагын да гадирәк аның.

— Нинди? — Әллә уңайсызланып, әллә ничек Аит башын түбән иде, ә Сөмбел, изүен капларга үзеннән-үзе күтәрелгән кулы белән киң селтәнеп, аның яңагына сугып җибәрде.

— Аңлашылгандыр дип уйлыйм!

Ә Аит аның кечкенә кулыннан яңагын сакларга уйламады да ичмаса!

Сөмбел капкага таба китте.

— Капкаңны ач әле, — диде ул, башын горур тотып.

Аит аңа аркан баскан килеш, борылмыйча гына:

— Кулың шактый озын һәм дәрманлы — ач та чык, — диде.

— Мин монда ачык капкадан кердем.

Аит салмак адымнар белән, таштан-ташка басып кына килде дә капканы тупсасыннан каерылып чыгарлык итеп ачып куйды.

— Юлыңа ак җәймә, — диде ул, тыныч кына.

— Сиең өчен рәхмәт, чемпион!

Сөмбел чыгып китте. Аит аны борылып карар дип көткән иде. Юк, карамады. Китте. «Кирәкмәс иде», — дип уйлады Аит һәм, капканы ябып, баскычка килеп утырды. Ашыйсы килә иде. Әллә эче поша микән?

«Сөмбел», — дип уйлады ул, буш кәнәфигә карап, һәм аны шунда утырган итеп күз алдына китерде дә:

— Сөмбел, — дип пышылдады.

## Алтынчы бүлек

Кич җитеп, ни ара караңгы төште. Өйләрдә ут алынды, ә кайберләрендә бер кабынып, инде сүнәргә дә өлгерде: авылда иртә яталар, иртә торалар. Авыл кешесе көндәлек тормышын, кояш белән табигатькә һәм мал-туар мәшәкатенә, бала-чага мазасына көйләп кора. Аның йокларга һәм авырырга вакыты юк. Иркенләп йоклый икән — кеше арасында саны юк, чынлап авырый икән — инде җаны гына калган була.

Аит үзенең авылга кайтып төшүенә әллә ни ис киткән кешене очратмады. Кичә иртән күрше Мөкатдис кенә кереп чыккан иде.

Аның беренче сүзе Аитны сискәндереп җибәрде. Исәнлек-саулык сорашкач, ул:

— Үләргә кайттыңмыни? — дип салды.

— Ник алай дисең, Мөкатдис абый?..

— Авылда торырга шәһәрдә сансыз, кеше чутында йөрмәгән булдыксызлар йә терелергә иманы калмаган авырулар гына кайта, парин. Башында акылы, тәнендә сау җаны булганнар кире кайтамы соң?

— Юньле мал ашаган урынына кайта, диләр ич әле.

— Җүнле малны ашап симерә торгач тотып суялар аны, парин... Һәй! Теге чакны геройны ычкындырмасаммы? Калыр идем мин авылда, бар! Берәр базага директор итмәсләр идемени?

Кайчан гына очрашсаң да, Мөкатдис моны искә алмыйча калмый. Берзаманны, шәһәрдә больницада икәнен ишетеп, Аит аның янына хәл белешергә барды. Ята, күңеле көр, зурлап килгәне өчен рәхмәт әйтә-әйтә күреште, хәл-әхвәл белештеләр, сөйләштеләр, искә алдылар... Һәм ахырда, Аитның ничек карыйлар, зарың юкмы дигәненә каршы тагын шул ук сүз:

— Җүнлерәк карый торган урыннар да бардыр, монда да зарланырлык түгел... тик, парин, теге чакны геройны ычкындырмасаммы?..

Ул чакта аны өчме-дүртме ай яткырдылар да чыгардылар. Операция җиңел үткән. Операция дип әйтерлек тә түгел — эчен ачканнар да япканнар гына. Солтания шуннан соң ике ай авылга кайткалап йөрде, кайткан саен елап килә иде. Врачлар Мөкатдиснең туганнарын чакыртып алып, аны ике ай гомере калган дип җибәргәннәр. Аннан соң инде ике ел узды, ул вакыт эчендә Аитның үз гаиләсендә күпме борчу, мәхшәр булып узды, Солтаниянең авыр фаҗигасе бүтән бөтен нәрсәләрне калын битарафлык туфрагына күмеп калдырды.

Ә Мөкатдис исән-сау, тик ябык, күз төпләре капчыкланып тора, ә күз алмасының агы, акчарлак йомыркасыдай, сары һәм көрән таплар белән чуарланып беткән. Башында ямьшәйгән һәм таплы эшләпә, өстендә соргылт пинҗәк һәм кыек якалы көлсу күлмәк, күкрәк кесәсенә күгәрек тимер каптырмага кидерелгән кызыл карандаш белән бөгелмәле калай линейка тыккан.

«Теге чакны геройны ычкындырмаса» ни буласын ул әйтеп бетерми, анысын тел очында гына калдыра, анысын гәптәше үзе күз алдына китереп бетерергә тиеш; һәрхәлдә, теге чакны геройны ычкындырмаса, Мөкатдиснең хәле хәзергедән шөкрана яхшырак, җиңелрәк, мәртәбәлерәк булырга тиешлеген күңеле-

ңә салып куярга мәҗбүрсең. Иң кимендә кемнеңдер, кайчандыр, кайдадыр, ни өчендер Мөкатдискә карата гаделсезлеккә юл куйганлыгын искәреп куясың, үз күңелеңдә аңа теләктәшлек, аны кызгану хисе уяна.

Ә «теге чакны геройны ычкындырмау» ихтималы дөрес булганмы, юкмы, күпләр аның җае чыккан саен моны кабатлаудан тартынмавын дөреслеккә юрый иде.

— Разведканың ни икәнен беләсеңме син, парин? — дип сорар иде ул сүз башлаудан әүвәл. — Ул, парин, кыш көне Иделгә бәке уеп су астында йөрү белән бер. Яңадан шул бәкеңә килеп чыга алсаң, якты дөньяда ашар ризыгың бетмәгәненә шөкер кыласың инде. Юкса, син әйләнеп менгәнче, бәкең шыкыраеп катуы да ихтимал. Иң мәсьүле шул: разведчикның үләргә хакы юк. Ә изге бер сәгатьтә үлеп калуның яшәүдән җиңелрәк тоелган вакытлары барые аның, парин!

Мөкатдиснең иске, мәгънәлерәк гыйбарәләр кулланырга, шуның белән сөйләгәненә серле төсмер бирергә ярата торган гадәте бар иде.

Разведчикның үләргә хакы юклыгын Аит бик яхшы белә. Үзе шаһит. Үзе һәм хатыны Солтания. Хәер, хәер!.. Бу — авыр яра. «Кагылмый тор, кагылмый тор», — диде ул үз-үзенә. Аннары соң... ул аның хатыны да түгел инде.

Ә менә бу ни, бу?

Бик түбән очкан реактив самолетны хәтерләтеп, күл турысында ялгыз үрдәк пәйда булды. Һаваны кисеп, күлне узып китә дә, кире әйләнгән чакта җилнең кайсы яктан искәнен чамалап алгач, шуңа каршы юнәлештән суга төшеп утыра. Кыр үрдәге суга һәрчак җилгә каршы куна. Җил исмәгән шаттә җылы яисә салкын һава агымына каршы. Очып киткәндә дә шулай.

Ялгыз үрдәк ул әле кайсы да булса бер көтүнең эзтабары гына. Үрдәк көтүе аңа карап кунačак.

Шырпыны сызмас борын, ут кабынмый. Ә ут бар, ул синең учыңдагы кап эчендә шылтырый, әйеме? Аның ялкыны син теләгән мизгелдә үк пәйда булачак.

Мәче башлы ябалаклар да күл турысында шулайрак — кисәктән пәйда булдылар. Аксыл ябалаклар. Һавада башта берсе күренде, әйтерсең лә ул көне буена шул ноктада күзгә күренмичә эленеп торган да кинәт хәрәкәткә килгән. Аннары соң, ул күл өсли бер кат әйләнеп килгәч, кисәктән тагын өчесе килеп чыкты, бераздан аларга тагын берсе килеп өстәлде. Барысы бишкә җыелды.

Алар мине шул ук мәлне күреп алдылар. Гүя мин камышлар арасында качып утырган ноктаны аларга алдан ук хәбәр итеп куйганнар. Икесе чиратлашып минем турыдан очып узды. Үтеп киткәч тә аларның башлары гел миңа таба борылган көенчә кала бирде әле. Ябалаклар башларын артка да кырт борып карый ала икән.

Һәм ау башланды! Биш ябалак чиратлашып, төрле яктан күл уртасындагы кыр үрдәгенә ташлана. Өнтавышсыз гына якынаялар да кисәк түбәнәяләр.

«Бак!» — дип кычкырып җибәрә үрдәк. Һәм, суны аягы белән ургытып, суга чума. Ябалаклар, чаңгычылар сыман, суга орыныр-орынмас шуып үтәләр дә югарыга күтәреләләр. Шул рәвешчә, алар җиде-сигез һөҗүм оештырдылар.

Ә кыр үрдәге пылт итеп калкып чыга да, башын янтайтып, җәһәт кенә күзләп ала, чираттагы һөҗүмне кире кайтарырга әзерләнә.

Һава сугышы ярсу, кызганусыз, килешүсез дәвам итте. Үрдәкнең бар максаты — исән калу, аның үләргә хакы юк иде ләбаса! Разведчикларның үз бурычларын үтәми торып үләргә хаклары юк ич! Ул үз көтүе җибәргән эзтабар, хәзер аның ыруы очып килеп җитәчәк, ул аларны каршы алырга һәм, кунарга ярыймы-юкмы икәнлеген белгертеп, хәбәр салырга тиеш иде.

Үрдәкләр «эскадрильясы» күренде. Тик эзтабарның «Бак!» дигән хәвефле авазы аларны, мылтыктан аткан вакыттагыча, кисәк селкетеп алды да читкә этәреп җибәрде. Тузгымады-таркалмадылар, тигез генә янтаеп, моннан биш-алты чакрымда көмештәй агарып яткан Кама киңлегенә юл алдылар.

«Разведчик» үрдәк үзенең сугышчан бурычын уңышлы үтәп чыкты.

Бу да шул ук разведка һәм Мөкатдиснең үләргә хакы булмаган чакларын сөйләвенә Аитның үзе күреп ышанган бер үрнәк иде.

Үрдәк — үрнәк кенә. Чынын Аит үзе дә кичерде. «Кагылмый тор, кагылмый тор», — дип, аның йөрәге тагын чәнчеп, кисәтеп куйды.

Юк, Мөкатдис зыянлы кеше түгел ул. Дөнья тормышка ризасыз кешеләр арасыннан хәтта тарих булып тарихка да файда китергән бик күпләрне белә.

Юк, Аит Мөкатдисне теге чакны геройны ничек ычкындырганын сөйләүдән мәхрүм итәргә кыймады. Бәлки, кеше шуның өчен кергәндер дә. Бәлки, кеше шуның өчен яшидер!

Аит салып бирде. Матур, бәллүр рюмкага. Мөкатдис аның һәр хәрәкәтен күзәтеп торды, эчәр алдыннан коньяк шешәсенә бик хикмәтле нәрсә күргәндәй, күзен тал яфрагыдай кысып, сәерсенеп карап торды, кулына алырга үрелгән иде, кире уйлады һәм рюмканы гади стаканга бушатты да тары бөртеге йоткандай гына итеп эчеп җибәрде.

— Синең урынга теге... кем әле...

Мөкатдис аның ни хакында сүз кузгатканын ирене кыймылдавыннан да белер иде. Ул бу сорауны ирkенләбрәк сөйләшергә мөмкинлеге булган һәрбер очракта теләсә кемнән көтә иде, ахрысы.

— Әйе, Шамякинга, — дип җөпләргә ашыга ул. Хәзер инде вакытка ул хуҗа. Вакытка гынамы? Хәзер инде ул хикмәтле, корсагында балавыз шикелле саллы печать бүлтәеп торган яшел шешәдән ятсынмый, кулына ала, мөһерен иренен түгәрәкләндереп өреп карый да, стаканны читкәрәк этәреп, алдына рюмка куя. Үзе салмый, ул әрсезлеккә караганда хөрмәтләүне яратарак төшә.

Аит тутырып салып куйды.

— Шул белорус Шамякинга бирделәр, — дип кабатлый Мөкатдис һәм: — Без аны Хомякин дип йөртә идек, — дип өсти. — Авызыннан ризык өзелмәс иде шул әрләннең, кайчан карама, ни дә булса чәйнәр иде. Ни эләкте шуны җыюын әйтмим дә инде. Ни эләкте дип... сугышта ни эләксен инде? Җыюы да ни инде — артык чолгау, запас кашык, тәмәке дә кәгазь. Сугышта тагын йокы туйсын да, тамак тук, өс коры булсын, кем әйткәндәй, Аллаһы Тәгалә рәхмәтеннән ташламасын... Әрлән... шул, Шамякинның инде, йокыга исе китмәс иде. Шуның аркасында геройны эләктерде дә.

Шушы урында Мөкатдис һәрвакыт тәмәке кабыза иде. Бүген дә тынып, кесәләрен капшап алды. Аит тартмый, ләкин аның үзе белән тәмәке йөртә торган гадәте бар. Эзләп табып, Мөкатдис алдына «Аврора» китереп куйды — теләсә кайда һәм теләсә кемгә үтемле сигарет.

— Ташладым мин, парин, — диде Мөкатдис. — Әйе, Хрущевның йокламаска кирәк дигән сүзен хәтерлисеңдер ич? Хомякин да йоклауны өнәми иде. Йоклаганда басып кереп үтерүләреннән җә өстенә бомба төшүдән куркып. Шунысы бар, разведка немецның йоклаган чагын ярата иде. Тегеләрнең дә разведка зәһәр, Шамякин аларның да йокы сәгатьләрендә йөрүне хәерлерәк санаганын яхшы белә, командир гел сакка куя торганые... Шулай немецның блиндажын капладык. Керә-керешкә өч-дүрт гранат томырдык, автоматларны чалгы урынына гына селтәнәбез, безнең пуля турамаган кыл да калмагандыр. Бәреп керсәк, җан әсәре калмаган, кайсы кая өч немец чәчелеп ята, ә безгә җансыз тел кирәкмәс, итекләр генә пычранып бетте. Сөртим дип бер чүпрәк эләктергән идем, тышта атыш китте, чәчрәп чыктык та караңгылыкка чумдык, ә караңгыда без чәйдә эрегән шикәр белән бер... Теге чүпрәкне ташлап калдырмаганмын, парин. Итектәге немец канын бик сөртәсе килгән иде шул, күңегелсә дә җирәндерә. Кайткач карасам, чыклы үлән итекне гөлт иттергән, куенга кыстырган чүпрәк тә кулга затлы нәрсә күк тоелды. Үзебез йокыга түндек, Шамякин аягын юарга чыгып китте... Разведкадан кайткач, аягын юа бу... Мә, мәйтәм, һәркайсыбызга берәр чолгау чыксын, дим, теге чүпрәкне почмакка томырдым да бөгәрләнеп яттым...

Бу урынга җиткәч, Мөкатдис эчеп куймый булдыра алмый иде инде. Аның «теге чакны геройны ычкындыруы»ның бөтен хикмәте шушында ята иде.

— Иртән уянып китсәм, чолгау да юк, Шамякинның да тыны ишетелми. Тыштан да эзләп карадык — юк. Эчләр жу итеп китте, парин! Чишмәгә төшкән җиреннән немец чәлгән дибез инде. Тегеннән-моннан сорашабыз, берәү әйтте: таң алдыннан сак астында батальон штабына алып киткәннәр моны. Эчләр тагын жу — кичә разведка алдыннан бер консерва ялмап куйган иде бу. Барып чыккан, мәйтәбез, кухнядан суккан. Шуннан югалды бу. Командирлар да аны-моны белгертми. Сорарга дисәң, шикләндерә... Кичкә кайтып төште бу! Пилотка кыңгыр моның, авыз ерык, бер көтү офицер иярткән. Кай төшедер чит кебек. Баксак, парин, күкрәгендә чабата хәтле Алтын Йолдыз! Моны Герой итеп кайтарганнар! Акыл ышанмый, күз күрә! Безне моның каршысына тезеп бастырдылар да, берәм-берәм кулыбызны кысып, Кызыл Йолдыз биреп чыктылар. Теге чүпрәк хикмәте икән. Немецның дивизия штандарты булып чыккан ул, каһәр!.. Миңа, җүләргә, аяк сөртеп кенә ташлыйсы калган... Исеме генә дә ни диген бит — штандарт. Дөнья булгач, шундый-шундый штаннар да була икән ул.

— Ә Шамякин? — дип сорады Аит.

— Хомякинны әйтәсеңме? — Кем белә инде аны? Озакламый яраландым мин, аерылыштык.

Мөкатдиснең бөтен сөйләгәне бүтән бер ягы белән кызыклы иде: Аит студент чагында ук Шамякин дигән геройның дөньяда юклыгын сорашып белде. «Теге чакны геройны ычкындырган» Мөкатдиснең хикәясе авылга бик кирәк булганын белгәнгә күрә генә бу серен ачарга базмады. Кайчагында тормышта начар дөреслеккә караганда яхшы ялганнар да кирәк бит. Мөкатдис елга бер-ике мәртәбә Кызыл Йолдыз орденын тагып чыга — тагын ни кирәк? Нидер булган лабаса, нидер булган!

— Бу нәрсәң бушагач, шешәсенә керермен әле, Аит, — диде ул, ухылдап урыныннан торгач. — Кырачин тотарга ыңгай.

— Көнбагыш маендыр, Мөкатдис абый.

— Анысына минем шәбрәге бар, парин! — диде ул. Анда да сынатмый кала беләэ иде.

Мөкатдис: «Бозауга су эчертәсе бар», — дип чыгып китте. Ул рәхмәт әйтүне кирәк санамый иде: әллә анлык кына сөйләмиме? Кайвакытны ул «Тагын керермен әле» дип чыгып китә. Ә беркайчан да үзе чакырмый иде.

Аның тагын бер темасы бар. Җае киләме, юкмы, «Синең атаң яхшы кеше иде, мәрхүм» дип башлый да, «Минем балаларым игелекле» дип тәмамлый. Теләсәң ничек аңла! «Синең атаң яхшы кеше, ә мин андый ук булмасам да, минем балаларым сезнең ише игелексез түгел», — шулай дипме? Ихтыярың. Ул кешене үпкәләтүдән курыкмый, уен эчендә саклап тотмый торган кеше — бары тик шул гына. Аның артыннан Аит: «Үзеңнән башка сине беркем дә хөкем итә алмый», — дип уйлап калды.

### Җиденче бүлек

Аит яңгыр тиеп чылатырдай нәрсәләрен болдырга ташып бетерде.

Әкрен генә итеп радиоалгыч сөйләп тора иде.

Хәзер инде төн, уты янып торган һәм ишеге ачык болдырда ул иске китап-журналлар, дәфтәр-кәгазьләр актарып утыра. Йончып бетсә дә, моның үз тәме бар иде. Бер ишесен пөхтәләп өеп бара, күбесен ишегалдындагы өемгә атып бара. Болдырга, болдырдан өйалдына, ә аннан өйгә чебен, төрле күбәләкләр кереп тулды. Һәр җир ачык иде: Аитның күптән инде кеше тормаган өйнең үзенә генә хас ят коры тузан һәм тычкан исләрен җилгәреп бетерәсе килә. Кичәле-бүгенле ул моңаияләшеп бетте инде. Япа-ялгыз гына тормый ич, кергән-чыккан кеше борынына әллә каян бәреп торачак.

Кәгазьләр арасыннан яньчелеп, яссы хәлгә килгән конфет кабы кулына эләкте. «Берәребез әнигә алып кайткан булган, күрәсең». Шундук өемгә ташларга уйлаган иде дә, нинди конфет салынган булганын беләсе килеп, әйләндереп карады. «Йа, ни җитте кап күренми түгелме соң бу?» Конфет кабының тапланып беткән аскы ягына җыр юллары төшкән иде. «Ак Иделгә басма салдым басып су алганым җук сезнең яктан кошлар сайрый җыламый калганым җук. Ага сулар ага сулар ага сулар ник болай. Аккан сулар кире кайтмый яшь гумерләр дә шолай. Ак иделдә юа алмадым ак кына беләгемне, хәсрәт урап алган яшьтән үк җөрәгемне. Ак идел сулары кебек тар сулар булмас инде минем җөрәккәем кебек ярсулар булмас инде».

Аит бу язуны нәкъ шушының ише мең язу арасыннан да танып алыр иде. Кулыннан гына түгел. Сүзләреннән. Моңы белән хәсрәтеннән. «Агыйделгә басма салдым — сезне дөньяга китердем», «басып су алганым юк — рәхәтегезне күрә алмадым», дип укыды Аит. «Сезнең яктан хәбәр килә — еламый калганым җук»... Нинди хәбәрләр? «Ул кайгыга караганда шатлыктан күбрәк елый иде», — дип исенә төшерде Аит. Шулай микән, шулай микән соң? Әй, шулай булсачы, шулай булсачы соң! Юк бит, юк. Юк лабаса! «Безнең әниләр дөньяга транзит пассажирлары булып кына килгәннәр шул».

Ул конфет кабын үзенә аеры алып куйды.

Күк йөзен тутырып, аҗаган күбәләкләре канат кагына башлады. Үткән сугышның бу йортка орынып үткән кайтавазы шикелле тонык кына булып, Кама ягыннан күк күкрәгәне ишетелә иде.

Ачык ишектән бөтерелә-бөтерелә күбәләкләр керә. Һәм утка елышалар.

Аларның берсе — иң зурысы һәм зәңгәр күлмәклесе болдыр баскычына килеп кунгандай булды — Сөмбел.

— Аҗаган уйный... Бөркү — яңгыр явар, ахры, — диде Сөмбел, әкрен генә.

Аит радиоалгыч боргычына үрелде. Аңа бу мизгелдә ят, ә истә-оста гаять таныш аһәңле тавыш шуннан киләдер кебек тоелды. Аннары баскыч төбендә газ ялкыны булып утырган Сөмбелгә күзе төште.

— Кеше бар дип торам, сез икәнсез, — диде ул.

— Мин кеше түгелмени?

— Безнең авылда шулай сөйләшәләр, — дип аңлатты Аит. — Чит кеше — кеше түгел ул, ә кунак.

Сөмбел рәхәтләнеп көнбагыш яра иде.

— Театрыгыз бүген дә китмәдемени әле? Бүген дә уйныйсызмыни?

— Башкаларыбыз китте.

— Ә син?

— Калдым әле.

— Спектаклегез?

— Бүген ишанның хатыны бергә ким булыр. Аңа һәр көн саен биш хатын димәгән. Менә синең берәү дә юк. Гаделлек кайда? — дип көлде Сөмбел.

Алар тагын кичәгечә уен-көлкедән, бер-берсен аңлап шаярудан башладылар.

— Миңа кияүгә чыгарга дип калмагансыңдыр ич?

— Көтмәдеңмени?.. Җүләрме мин? — диде Сөмбел, бераз тын торгач.

— Түгел.
— Нинди?
— Акыллы. Мин көттем сине.
— Тагын бер килеп чыгасымны белдеңме соң?
— Белдем.
— Кайдан?
— Безнең кичәге сөйләшүебезнең дәвамы булырга тиеш ич инде?
— Кичә син үпкәләдеңме? — диде Сөмбел, караңгылыкка борылып.
— Юк. Кыйммәт түләп алган нәрсә кадерле була ул... Шундый бәягә торган үбү беләсеңме нинди татлы булды?
Сөмбел, дога кылгандагыча, кушырып, кулларын йөзенә куйды да:
— Китеп барган булсам, артымнан эзли чыгар идеңме соң? — дип сорады.
Ишектән җиргә төшкән сары яктылык рамында ул борынгы рәсем кебек күренә иде. Баскыч төбенә һәм бакча ишегенә таба сузылып җәелгән ташлар ул картинаның күп вакыт үтүдән яргаланган буявын хәтерләтәләр. Һәм бу күренешнең картинага охшавын тагын да арттыра төшәләр иде.
Аит беравык уйланып торды, аның үзен ихлас тоткан хатынга дөресен генә әйтергә хакы бар. Аннан соң сөйләшүнең көтелмәгәнчә башланып китүенә, шуңа өстәп, көтелмәгәнчә борылыш алуына ялган җавап ябышмый, туфли табаныннан килеп чыккан кадак очы кебек, шундук фаш булыр иде.
— Юк.
Сөмбел кисәк аңа борылып карады. Аның ирене үпкәләгән балаларныкы шикелле бүлтәеп тора, менәменә елап җибәрер сыман иде.
— Ник? — дип сорады ул.
— Сине эзләп китсәм, син миңа ияреп кайтмас идең.
— Парадокс. Үз аягым белән килгәнне, берәү үтенеп йә ялынып килсә, ничек кайтмас идем икән?
— Хатын-кыз ялынганны яратмый. Алар үзләренең тәэсиренә буйсынырга теләмәгән ирләрне артыграк күрә. Чөнки сораганны, бигрәк тә ялынганны кире кагу тоз булып аларның канына сеңгән.
— Үзең дә ышанмаганны сөйлисең. Яки үзең шулай теләгәнне. Әллә... — Сөмбелнең борын яфраклары дерелдәп куйды, үзен-үзе тынычландырырга теләгәндәй, ул учларын кулбашларына куйды да каты итеп кысты, ахрысы, киерелгән бармакларының ак эзләре бетми торды, беткәч, тимгел-тимгел кызарып чыкты. — Әллә, — дип дәвам итте ул өзелеп калган сүзен, — мине монда кичәге «юлыңа ак җәймә» диюеңә каршы әйләнеп килде дип уйлыйсыңмы?
— Мин әйтеп бетермәдем, — диде Аит. — Сезнең халыкның, ягъни хатын-кызның, беренче максаты үзенә игътибар итмәгән ирне яратудан элек үзенә буйсындырудан гыйбарәт. — Аит аны тыңлаттырып тынычландырыр өчен юри озаклап сөйләргә чамалаган иде дә, буталып калудан курыкты, ә һәр буталу иң элек ялганлауга якын. Шуңа күрә, сүзе бетүен белдереп, тамагын кырып куйды.
— Тик шунысы бар: безнең үзебез яраткан кешене генә буйсындырасыбыз килә шул, — диде Сөмбел.
— Ирләр моны тиешенчә бәяли белә дип уйлыйсыңмы?
— Бер нәрсә сөйлим, тыңлыйсыңмы? — диде Сөмбел.
— Кинәнеп тыңлыйм, — диде Аит. Ул Сөмбелнең иңенә көрән куртка китереп япты, алдына термостан агызып чәй куйды. Болдырга кереп утырырга кыстамады. Ләкин Сөмбел идәндәге чынаякны алды да, аны учларына кысып, баскычка менеп, иске патефонга утырды.
— Бер табышмак әйтәм: җавабын мин теләгәнчә дөрес бирсәң, мин синең яратам дигәнеңә ышанырмын.
Аит аптырап китте: нинди «ярату»? Аның моңа бернинди сәбәп биргәне юк лабаса әле. «Шаярта», — дип уйлады ул. Һәм ул, Сөмбелнең шаяртуын аңлаган һәм кабул иткән атлы кыланып:
— Нинди җавап бирим соң: син теләгәннеме, әллә үзем дөрес дип тапканнымы? — диде.
— Минем өчен үзем теләгәне дөрес, — диде Сөмбел. — Тыңла, Аит.
Бөтен күк йөзен аҗаган яктыртып алды. Аның зәңгәрсу балкышы Сөмбелнең йөзен күлмәге белән бер төскә манчып алды. Өй артындагы тупыл башларыннан җил шаулап узды. Беренче сыек болытлар йолдызларны хәрәкәткә китерде, алар текә елга ярындагы ояларына кереп китүче керәшәләр кебек берәмберәм караңгы болыт кыясына чума башладылар.
— Яңгыр килә, — диде Аит.
— Тыңла әле, Аит... Бер Роза чәчәге Океанга гашыйк булган да, ди, аңа кадәр барып җитеп, бөтенләйгә аныкы буласы килгән, ди.
— Ах мут чәчәк!.. Син уңайсыз утырасың, Сөмбел. Күч монда. — Аит толып җәелгән иске диванда утыра иде, читкәрәк шуышып, урын күрсәтте.

— Бүлдермә... Һәм Роза чәчәге бер елгага төшкән дә юлга чыккан. Бара торгач, бер чоңгылга килеп җиткән бу. Әйләнеп йөри дә йөри икән, тик юлын дәвам итә алмый интегә икән. «Чоңгыл, кадерлем, мине чыгарып җибәр әле», — дип үтенгән бу. «Бер таҗыңны бирсәң, чыгарам», — дигән чоңгыл. «Юк!» — дип кире каккан Роза чәчәге, чоңгылга таҗын бирмәгән. Ничек итсә иткән, әйләнә торгач, бер җаен туры китергән дә чоңгыл кочагыннан исән-имин ычкына алган... Ага икән, ага икән — елгага аркылы ауган бер агачка килеп төртелгән. «Агач, кадерлем, мине тизрәк үзең аша чыгарып җибәр әле, мин инде барасы җиремә болай да тоткарландым, шиңә башладым», — дип ялварган Роза чәчәге. «Бер таҗыңны бирсәң, чыгарам», — дигән агач. «Юк!» — дигән Роза чәчәге һәм су кимегәч кенә агач астыннан чыгып китә алган. Шулай итеп, ул, ниһаять, Океанга барып җиткән. «Мин килеп җиттем», — дигән ул аңа. Һәм үзенең гыйшкын сөйләп биргән. «Күрәм», — дигән Океан, — тик син миңа кирәкмисең». — «Нигә?» — дип сораган Роза. — Мин сиңа бер таҗымны да югалтмыйча, саф килеш килеп җиттем». — «Саф. Ләкин син шиңгәнсең инде», — дигән Океан һәм Розаны үзенә алмаган. Дулкыннары белән яр читенә кагып чыгарган да ташлаган.

— Бичара Роза чәчәге! — диде Аит.

— Мәхәббәтен саклап шиңгән Роза чәчәге бичара була микән?.. Ә Океан? Дөрес иткәнме ул?

— Океан яшь, дәртле, көчле булгандыр. Ә Роза чәчәге шиңгән ләбаса!

— Ярый. Синеңчә — шулай булсын. Тик әле мин җавап сорамыйм, ашыкма. Мин дәвам итәм әле...

Икенче бер Роза чәчәгенең дә Океанныкы буласы килгән. Елга буенча аккан да киткән. Ә елгаларның күбесе океаннарга кадәр җитә... Тик бусы чоңгылга да, агачларга да таҗларын кызганмаган... Аның каравы Океанга шиңгәнче үк барып җиткән. Һәм Океан аны үзенә алырга риза булган, ди...

— Син ул роза чәчәкләренең кайсысын сайлар идең икән, Аит? Йә? Менә хәзер җавап бир инде.

Ул сөйли башлауга, Аит розаларның берсе Сөмбелнең үзе булып чыгарга тиешлеген искәреп куйган иде инде. Моны аның икенче Роза хакында сөйләгәндә матур сүзләр эзләп тормавы, йөз хәрәкәтләренең хиссезлеге, ишарәләренең саранлыгы үк әйтеп торды бугай. Икенче роза, һичшиксез, ул үзе иде, чөнки нәкъ шул салкын һәм битараф сөйләве белән ул Аитның игътибарын җәлеп итәргә теләде дә. Икенче Роза турында сөйләгәндә, аның үз эчендәге ниндидер бер истәлектән арынасы килгәнлеге сизелеп тора иде. Шуңа күрә ул Сөмбелнең «Роза чәчәкләре арасыннан кайсын сайлар идең?» дигән соравына:

— Икенчесен, — диде.

— Нигә анысын?

— Син аларның икенчесе бит. Һәм син минем үзеңне сайлавымны телисең.

Сөмбел аның иң җиңел юлны сайлап алуына гаҗәпләнмәде. Бүгенге заманда кайсы гына ир затына шиңгән гөл чәчәге кирәк булсын соң?! Барысы да ашыга, кабалана, барысына да бүген кирәк! Хәзер үк кирәк. Сайлап торырга берәүнең дә тәкате җитми. Бер-ике яисә ике-өч таҗ яфрагы гына югалту нәрсә соң ул? Күпме ир-ат шушылай уйлый. Шиңмәгән генә булсын!.. Ә шулай да ул Аит белән килеште, чөнки Сөмбел өчен үзе теләгән җавап кына дөрес, һәм ул үзен сайлауларын тели! Моны кайсы хатын-кыз теләмәс икән? Әйе, Сөмбел үзе теләгән җавап — ул үзе иде.

— Син мине аңладың һәм... мине сайладың. Тик кызганып. Әллә кызыгыпмы?.. Хәер, ни аерма?!

Сөмбел урыныннан торды да үзен бөрешеп утырып тыңлаган Аитка таба китте. Менә ул аның янәшәсендә үк инде, кулын сузып, бармак битләре белән генә аның чәченә кагылып ала һәм, аның учы белән сихерләнгәндәй, Аит диваннан күтәрелә башлый.

Аның йөзе якын гына булса да, Сөмбелгә курчакныкы шикелле кечерәеп күренә, аларның йөзләре бер-берсенә якынайган саен, Сөмбел Аиттан ераклашканнан-ераклаша бара кебек. Нәкъ теге чактагы сыман!

**Сигезенче бүлек**

— Иисус воскрес!

— Воистину воскрес!

— Иисус воскрес!

— Воистину воскрес...

— Иисус воскрес...

— Воист...

Чиркәү эче көндезге кебек яп-якты, электр лампочкалары яна, нечкә шәм очларында хәнҗәр очлары булып утлар калтырана, яшь кенә поп үз алдында ярсу-ярсу селеккәләгән чылбырлы савыттан борынны кытыкларлык тәмле исләр таралып тора, шул ис кешеләр җылысы һәм шәмнәр кайнарлыгы, алтын белән каймаланган сурәтләрнең зур ачылган күзләре, йөзләгән кеше үз җаннары төбеннән алып кабатлаган сүз-

ләрнең елга дулкыннары шикелле баш очында чайкалып торган моңы — барысы да изрәтә: әллә талгын гына тирбәтә, әллә ак болытларга күтәреп оета, әллә су астындагы кебек тоеп булмастай бер тынлыкта йоклата иде.

Балкып торган утлардан аяз күктәге йолдызлар күренмәс була, аларның һәммәсе, күбәләкләр сыман, шәм очларына төшеп кунганнар да эрегәннәр, ахрысы. Бөркет томшыгына охшаган кәкре борынлы, күзе белән дугаланып торган каш арасы гадәттәгедән киңрәк булгангамы, йөзе нәрсәгәдер гаҗәпләнгән баланы хәтерләткән яшь поп үзенең биек һәм иркен мәйданында халыкка әле аркан, әле кырын, әле әйләнгәләп йөренә, ул да булмый, бераз вакытка югала да берсеннән-берсе затлырак тоелган япанчаларын алыштырып тора, шуңа күрә модельләр йортындагы халыкка сезон модаларын күрсәтүчеләрне искә төшерә. Халык инә дә төшмәслек күп, шуңа карамастан, кешеләрнең йөзләре әллә ничек һәркайсы зураеп, аермачык күренеп тора, шунлыктан һәркем үзе генә аеры торган шикелле.

Ә алар өчәү иде: Сөмбел, Аит, Солтания.

Бирегә аларны Аит алып керде.

Ул елны Сөмбел беренче мәртәбә авылга кунакка кайткан иде. Яңа гына өйләнешкән апасы белән җизнәсенә ияреп. Солтания белән Аит авылларыннан унбиш чакрымдагы урта мәктәптә укыйлар, тулай торакта торалар, дуслашып алгач, Солтания Сөмбелне үзе белән мәктәбенә алып китте, ә ялга үз авылларына кайтышлый Аит аларны юл өстендә утырган рус авылының чиркәвенә алып керде.

Юл өзек, пычрак, су, кичкә кырын гына чыгып киткәннәр иде, соңардылар.

Ләкин биредән аларның үз авылларына хәтле нибарысы ике чакрым гына, шунлыктан курыкмадылар, инде төн уртасы якынлашуга карамастан, гомерләрендә дә күрелмәгән тамашага исләре китеп торганда, әллә ничек кенә бирелеп китеп, халыкка иярделәр.

Солтания Сөмбелнең колагына:

— Белгән догаларыңны укы, безгә чиркәүгә керү гөнаһ, — дип пышылдады.

Сөмбел үзенең пырхылдап көлеп җибәрүен сизми дә калды.

— Ник? — диде ул. — Мин бернинди дога да белмим! Мине беркем...

Һәм ярты сүзендә киселеп калды: янында торган яланбаш җыерчыкланып торган нечкә генә озын муенлы, кагылсаң, һәркайсы чыңлап җибәрердәй тоелган күперенке чәче белән тузганакны хәтерләткән бер картның керфексез зәп-зәңгәр күзләреннән очкыннар чәчрәде кебек. Сөмбел аннан күзен ала алмыйча, үзе белән янәшә торган Аитка елышты, бар көче белән аның кулына чытырдапябышты.

Карт читкә борылды, Сөмбелнең чит милләт кешесе икәнен сизеп, ниндидер бер тирән ярсу белән карап куйган күзләреннән котылгач та, ул Аитның кулын үз учларыннан ычкындырырга кыймаган иде әле: шултикле курыккан иде, күрәсең! Ә аннары... йөзләгән халык арасында Аитның тирләгән кулын яшертен генә тоткан килеш басып торуы әллә ничек рәхәт, кызык, романтикалы иде! Ә нигә, нигә! Аит... Аит матур иде! Хәер, эш аның матурлыгында гына да түгел иде, ахрысы. Ул беренче тапкыр үз йөрәгенең шәм сыман эреп, бөтен тәненә таралып бетүен тойды. Тойды гынамы соң? Күрде!

Аңа тагын кемдер карап тора иде. Шул карашны маңгае белән тойды диярсең. Очлы иде ул караш, үчле иде! Баягы тузганак бабай дип белеп, ул астыртын гына аңа карап куйды, тик бабай авызын көнбагыш яргандагы шикелле тиз-тиз кыймылдатып, барысыннан да алдан һәм катырак итеп:

— Воистину воскрес! — дип кычкырып ята иде.

Шунда ул Солтаниянең:

— Син белгән догаларыңны укы, чиркәүгә керү гөнаһыңны юарлык булмаса да, кеше егетен тартып алмакчы булуыңны... Солтания астан гына аның кулыннан тотты да дүрт бармагы белән берьюлы тырнап җибәрде.

Сөмбел «аһ!» итеп куйды.

Ә Солтаниянең күзе... Янып тора иде! Тузганак башлы картның зәңгәр күзләре ише генә идеме соң! Мәхәббәткә кагылышлы нәфрәт диннәр каршылыгы нәфрәтеннән аяусызрак икән.

Ә Сөмбел Аитның кулын аның саен катырак кысты. Солтаниягә үч итеп. Ә ул?

— Уйнап тормагыз әле, кызлар, — дип кенә куйды.

Бер заманны, әллә инде шунда эчтә үк, әллә инде тышка, саф һавага чыккач, кешеләр берсенә-берсе:

— Христос воскрес!

— Воистину воскрес... — дип үбешергә тотындылар. Һич тартынмыйча. Күрше күршесе белән, танышлар дус-ишләре белән, һәм, билгеле инде, туганнар туганнары беләндер.

Көтмәгән-нитмәгәндә Сөмбел Аитны үбеп алды. Башта бит алмасыннан, аннары, ул нишләрен белмичә аптырап торган арада иреннәннән дә. Аит иренен — корт чакканмыни! — кул сырты белән сөртеп ташлады. Солтания караңгылыкка кереп югалды. Аит, «Җүләр!» дип, Сөмбелнең кулыннан эләктереп алды да

өстерәп диярлек аның артыннан йөгерде. Авылга кадәр шулай җитәкләшеп кайттылар, чөнки Сөмбел дөм караңгыда бөтенләй бара алмый иде.

Икенче көнне Солтания аның белән сөйләшмәде. Ә клубтан кайтканда, Сөмбел аларны бергә күрде. Аҗаган уйный иде, аның бөтен нәрсәне су астындагыча яшькелт күрсәткән яктысында рәшәткә буендагы бүрәнәдә Аит белән Солтания утыра. Аит нидер сөйли, Солтания чың-чың итеп көлеп куя. Сөмбел, аркасы белән рәшәткәгә сөялеп, шул бәхетле көлүне тыңлады, күз яшенең иң тозлысын беренче мәртәбә ул шунда татыды. Көнләште ул әлеге көлүдән! Бөтен гомеренә җитәрлек итеп көнләште. Әйе, кичә Аит аерылдык дигәч, ул көнләшү тагын уянып, аның йөзенә елмаю булып таралды да бөтенләйгә, инде мәңгегә сүнде — аерылганнар!

Ә бүген инде нигәдер Сөмбелнең елыйсы килә. Әгәр язмыш аны Аит белән кабат очраштырган икән, кемнедер көнләштерерлек матур язмыш туган инде бу! Әнә ич танымады да! Ул аның янына мәхәббәтенә ашыккан, тик инде күп нәрсәсен югалткан икенче Роза чәчәге булып әйләнеп кайтты. Бәлки, бусы да язмышка язылгандыр? Язмыштан узмыш юк, диләр. Бәлки, узмаскадыр? Калыргадыр? Бәлки, ул Аитка кирәктер? Ни уйлап кабат килде соң әле Сөмбел бирегә? Икенче Роза чәчәгенең язмышы бүтәнчә тәгалләнә ләбаса. Әгәр аныкы да — Сөмбелнеке дә шулай бетсә?

— Икенче Роза чәчәге белән Океанның мәхәббәте ни белән беткәнен беләсең киләме? — диде ул.

— Күзалларга була, — диде Аит. Һәм аның биленнән кочып алды.

— Юк шул, болай түгел, — дип көлде Сөмбел һәм аннан этелеп: — Хәер, соңыннан... Соңыннан әйтермен, — диде дә патефонга барып утырды.

— Кайчан — соңыннан?

— Белмим. Аннары.

— Табышмак, — диде Аит. — Инде минекен дә тыңлап кара.

Ул диван пружиналарын шыгырдатып торды да стена буена өч өемгә тезеп куйган китап-дәфтәрләр янәшәсендә үзенә аерым торган яшел тышлы калын бер китапны кулына алды.

— Мең дә бер кичәме әле ул?

— Коръән.

— Минем Розаларыма сабак укытырга җыенасың дисәм... Ул Розалар шәригатькә сыймыйлардыр шул... Мәхәббәт гомумән шәригатькә сыймый торгандыр инде ул.

— Коръәннән дә олырак сөюләр булган икән, Сөмбел.

— Көфер сүз сөйләмә, тәкъсир.

— Табынып, алдында сәҗдә кылырлык олы сөюләр булган!

— «Булган» дисең... Булган гынамыни? Инде юкмыни?

— Бардыр. Булырдыр да. Менә моның ише изгеләре... — Аит Коръән тышлыгын ачты да сырын сырга туры китереп, өчпочмаклап бөкләнгән ике кәгазь алды. — Көндез мин бу Коръәннән этинең фронттан язган ике хатын табып алдым. Табып дип... Ихтимал алар үзләре мине тапкандыр.

— Бөти шикеллеләр, — диде Сөмбел. — Укыганым бар, элек балаларга шундый өчпочмаклы бөтиләр такканнар.

— Әйе, Сөмбел. Болар — картайгач та бөти итәрлек хатлар. Хәтер бөтиләре... Тыңлыйсыңмы, укыйм.

### Тугызынчы бүлек

— Фронт хатларында ни язылганын күзаллавы читен түгел, — диде Сөмбел. — Сагынудыр инде... Сагыштыр... «Жди меня, и я вернусь, только очень жди»... Шушының бер төредер.

— Алай булса да начар түгелдер. Тик болар икенчерәк. Көчлерәк.

— Шигырьдән дә көчлерәкме?

— Чын тормыш шигырьдән көчлерәк. — Сак кына бер хатны ачып, Аит, үзенә укыган кебек тын гына: — «Сезгә сагынып», — дип башлады. Баскычка утырды. Чиксез караңгылыкка карап, дога әйткәндәй: — «Якыным Гайшә!» — дип пышылдады.

Сөмбел сигарета кабызды. Каршысындагы күренеш илаһи иде. «Давид?» «Матисс?» «Рембранд?» Алдындагы күренешне кем дә булса ясады микән? Кайчан да булса ясар микән? Ачык ишек караңгылыгында үткән сугыш эченнән телгә килгән һәм мәңге тынмас бу хат иясенең үзе утыра мәллә? Кем ясаган һәм кем ясаячак мәшһүр картина соң бу? «Карагыз!» — дигән төсле, аҗаган кабынып ала, һәм караңгы күк гөмбәзенә кулына хат тотып утырган Аитның күләгәсе йогып кала кебек. Помпей һәм Хиросима кешеләренең стеналарга, урам ташларына, күпер такталарына төшеп калган җансыз күләгәләре сыман, ишегалды ташларына да Аитның тере күләгәсе сузылган. Аит, хатлы кулларын сузарак биреп, утка кырынрак утырган, аның ишегалдына төшкән шәүләсе тезләнеп күктән нидер ялварган төсле булып күренә. Тавышы гел бер

көе, битараф, хиссез. Ә хаттагы сүзләрнең тәэсире аның саен көчлерәк, чыннан да, ниндидер ялварулы догага тартым, борынгы язулардагыча тыныч, мәңгелек иде. Әнә ич: «хатыным» димәгән, «якыным» дигән. «Яратам» яки «мәхәббәт» дигән сүзләр хәзер генә китте ул. Шуның белән бөтен телебез тулган, китаплар. Матур сүзләр. Тик тапталып, шомарып беткән, көчсез, телсез, мәгънәләрен җуйган сүзләр. Ә тормышта әнә ничек булган: гадирәк, нәфисрәк, ялкынлырак!.. Ахыр килер, тыйнаграк — «якыным»... Монда ни генә юк: хатыным, иң якын кешем дию дә бар бу сүздә... Шушы ук сүздә тагын ялкыным, якынлык та бар... Хат әллә барып җитә, әллә юк... Ара чиксез ерак... Юл ераклыгы, вакыт ераклыгы... Ләкин хис, тою якын... Сагыну көчле, сагыш зур, наз бөек — «якыным!..» «Яратам» дигән сүзләрне хәзер ничек җиңел әйтәбез без! «Син миңа ошыйсың», «Мин сине якын күрәм» диюләр тәмам онытылды, төссезләнде, уңды, тәме китте... Шушыннан соң гына лабаса әле ул сөю, мәхәббәт, ә иң соңынтын — ярату!..

**Унынчы бүлек**

*«Сезгә сагынып.*

*Якыным Гайшә! Сиңа, матурым Әлфиягә вә иң матурым Наиләгә, шулай ук миннән соң булган кечкенә бәбигә, кыскасы, барыгызга да сәлам...»*

— Кечкенә бәби дигәне мин булганмын, — диде Аит, бүленеп һәм дәвам итте:

*«Туганнардан якын туганым Гайшә апаларның һәрберсенә, Солтан авылы туганнарымның һәрберсенә, Хафиз абыйларның һәрберсенә, калган башка туганнарның һәрберсенә миннән сәлам тапшыр. Күршеләрдән Бәдигол апаларның һәрберсенә, Хәйрулла абыйларның һәрберсенә, шулай ук язылмый калганнарның да һәрберсенә сәлам. Кыскасы, мине сораганнарның һәрберсенә миннән сәлам әйтерсез! Ярый... Якыным Гайшә! Нихәл суң? Үзеңнең саулыгың бармы? Бәгырьләрем Әлфия, Наилә һәм кечкенә бәби саулармы? Мине, ягъни әтиләрен искә алалармы? Башка хәвеф-хәтәр юкмы? Адашың Гайшә апалар ни хәлдә суң? Үзе һәм балалар саумы суң? Бигрәк тә якын җизнәмнең хәбәре бармы? Ул бәгърем дөньяда бу көндә тере микән, юк микән? Хәвеф-хәтәр юкмы? Бәдретдин абый үзе һәм Билал абый өйдәләрме? Минем уйлавым буенча, өйдә түгелләр булырга кирәк. Хәерле булсын... Ярый, Хафиз абыйлары һәм Бәдигол апалары ни хәлдә торалар? Минем уйлавым буенча, алар искечә торалар булса кирәк. Ярый... Якыным Гайшә, нихәл? Суң, ризык мәсьәләсендә аптырамыйсызмы? Ә инде минем уйлавым буенча, аптырый торгансыз булырга кирәк. Беләмен, бәгырьләрем, көн уздыруларыгыз ансат түгелдер. Ә инде ягу өчен утын мәсьәләгез, анысы, минемчә, юк инде. Нишлик суң, бер без генә түгел. Беләсең, хәтереңдәдер: безнең тормышның шөкер, бик рәхәт вакытлары бар иде. Беләсең, безнең бар нәрсә җитеш иде. Ул бергә-бергә балалар белән уйнашып, рәхәт гомер иткән вакытлар минем бер дә исләремнән чыкмыйлар. Ә инде минем белән бергә гомер иткән вакытларың, минемчә, синең дә исләреңнән чыкмый торгандыр булырга кирәк. Ярый, нишлик суң, бәгырьләрем, бер без генә түгел, сабыр итик. Ул рәхәт гомерләр, исән булсак, тагын да булырлар әле. Ул рәхәт гомерләрне булдыру өчен иң элек безнең нәүбәтебез безнең туган илебезнең бераз өлешен вакытлы рәвештә сиздермәстән яулап алган кабахәт, ерткыч, тыныч халыкны тынычсыз иткән һәм халык талаучы дуңгыз борын Германия фашизмын штыкка күтәреп, калганнарын туган илебездән куып чыгарып, ул кабахәт ерткычлардан чистарткаsuccessнан суң, исән булсак, сезнең янга кайтып, яңадан рәхәт һәм шатлыклы гомер итәрбез... Ярый, якыным Гайшә! Нигә суң сез миңа хат язмыйсыз икән? Менә мин 6 нчы аемны хәрби госпитальдә ятам. Сезгә ничә мәртәбәләр хат яздырып салдым. Ә сездән бер хат та алганым юк. Менә шул мәсьәлә минем өчен бик күңелсез. Әллә бертөрле хәл булдымы икән дип борчылам. Әллә мин язган хатларны сез ала алмыйсыз микән? Шулай ук сез язган хатларны мин ала алмыйм микән? Минем өчен бик читене шул. Әнә үзең беләсең: бервакыт Мәфтуха артыннан язып җибәргән хатыңны Казанда вакытта алып укыган идем, менә шул көннән бу көнгә кадәр сезнең хәлегезне белгәнем юк. Ә инде бу көн 3 март көне. Димәк, 6 ай хәлегезне белгәнем юк дигән сүз. Ә инде сез минем хатларымны ала алмаенчы бу көнгә кадәр минем хәлемне белмәгәнсез. Түбәндә сезгә үзем хакында язып аңлатам. Мин сугыш кырыннан ранный булып чыктым, 29 сентябрь көнне кич белән. Бу көн, 3 март көне, минем ранный булганыма 156 көн, ягъни 5 ай да 6 көн, 6 нчы аем дигән сүз. Менә шул көннән бу көнгә кадәр җитәкчебез һәм атабыз иптәш Сталинның бигрәк тә илне саклау өчен сугыш кырында ранный булган авыруларга нык тәрбия бирергә дигән мәкаләсе аркасында шундый рәхәттә яшибез ки, язып түгел, сөйләп бетерә торган түгел».*

Сөмбел «яратам» дигән сүзнең хатта бөтенләй булмавына игътибар итте. Ләкин андагы һәр сүздә шул мәгънә балкып, зиһеннең бар җирен тутырып, мәк чәчәге кебек ялкынланып сизелеп тора иде. Табигатьтәгечә, нәфис һәм серле итеп, чәчтән сыйпаган шикелле юатып һәм үпкәндәге сыман назлап. Монда — икәүнең бөтен дөнья күз алдында җәйрәп яткан газиз, илаһи бер бәхетле тормышы. Монда — мәхәббәтнең чиста дәрьясы. Өстә генә йөзеп йөргән буш сүзләр юк, хис тирән, сагыну тыелгысыз, киләчәккә өмет

ышанычлы, нык... Эчкерсезлек, гадилек... Исбатлаулар кирәкмәс, аерылышуга зарланып шыңшу чит, төшенкелек ят нәрсә монда!..

— Чагыштырып утырам да... Без яшәмибез, ә бәлки йоклыйбыз гына икән, — диде Сөмбел, Аит тынып калгач. Ул аны хисләнеп туктады дип уйлаган иде, уйларын таратам дип эндәште: — Укы, укы.

— Бетте. Бу хатның ахыры сакланмаган.

— Ә кулыңдагысы?

— Анысы бүтәне.

— Әнкәңнең җавап хатымы?

— Юк. Мин укыган хатны алганчы, юлга әни хаты чыгып киткән була. Бу — шуңа җавап...

*«Кайгылы хатым.*

*Якыным Гайшә! Сиңа, әгәр дә үлеп бетмәсәләр, матурым Әлфиягә, һәм — иң матурым иде — Наиләгә, бәлкем, бу көндә юктыр да, шулай да, нәни улым Аитка, барыгызга сәлам... Шулай ук элек мин яза торган туганнарга, ике яктагы һәммә күршеләргә вә мине сораган абый, эне, апа, сеңел, дус-ишләргә сәлам. Ярый... Әй, якыным Гайшә! Синең 15 февральдә язган хатыңны алып укыдым, мәсьәләне төшендем. Эшләр шулаймыни? Ә укыгач нишләдем суң, — караватыма ятып аунап еладым, ризык ашамадым. 11 март өйлә вакытында алып укыдым. (Ягъни хатың 25 көн килгән.) Бер мәртәбә укып кына калмадым, 2 укыдым, 3 укыдым. Әле мин бик рәхәт идем, бик тәме белән ризык ашый идем, бик тыныч йоклый идем, — кулым гына төзәлеп бетмәгән, хәзер инде сызламый, бик матурайган идем. Кыскасы, 18 яшьлек егетләр кебек булган идем, дөрестән дә шулай диләр иде. Шулай итеп, синең кайгылы хатыңны алып укуы минем өчен җиңел булмады. Һәм минем дә сиңа каршы кайгылы хат язуым җиңел булмады. Минем бу минутларым ничек суң, — яза торган кулым калтырый, ике күземнән канлы яшь ага. Үзебезне тәрбияли торган сестра, сиңа хат бар, Җаббаров, йә, тансавайт ит, юкса хатыңны бирмим, диеп, шул арада мин сөенечемнән сикерә-сикерә биегән булып, бөтен иптәшләр көлешеп карап торып, суңра сестра маладис, Җаббаров дип, синең кулъязмаңны биреп, мин сөенә-сөенә укый башлаган идем, чишмә кебек, ике күземнән яшь ага башлады. Шуннан караватка ятып, одеал белән бөркәнеп бик озак еладым. Әй... Гайшә! Шулай ук, шулай ук ул безнең матурларыбыз әрәм булырлармыни? Һәм булырлар микәнни?.. Әлфиям һәм Наиләмне күргән идем, әнә шул минсез булган кечкенә йөрәк бәгърем — 2 нче Аитны күрми калам микәнни?»...*

— Минем Аит атлы абыем булган, — дип аңлатты Аит, бүленеп торып. — Әни миңа да аның исемен кушкан... Мин дә чак кына үлми калганмын. Яңа туган балага үлгән бала исемен куймый торган булганнар...

*«Әй, бәгырьләрем, әй... матурларым... Бервакытта да хәтеремнән чыкмый шул ук Әлфия белән матурым Наиләнең кыланышлары. Матурым Наиләнең, конфет бирәм дигәч, минем ике битемне үбүләре һәм шуның өстенә әтием, конфет бирсәң, әлһәмдел өйрәтәм диюләре... Шулай ук матурым Әлфиянең матур көйләр белән зурлар кебек матур итеп җырлаулары һәм аның идәндә матур итеп биюләре. Шулай ук 2 нче Аитым (гәрчә күрмәсәм дә), менә шулай ящикта утырадыр, менә шулай көләдер, менә шулай үрмәлидер, менә аны әнисе шулай биләгәндер, суңра кочагына алып, матурым, ичмаса әтиең өйдә юк диеп сөйгәнсең, шулай сөя торгансың дип, йокыга яткач һәр көн сәгать 2 гә, 3 кә кадәр йоклый алмый ятам. Яткач, әнә минем күз алларыма түбәндәгеләр киләләр. Кайсыдыр минем узган гомеремдә сезнең, ягъни синең белән, матурларым Әлфия һәм Наилә шулай итеп сезнең белән бергә уйнап-көлеп һәм бергә-бергә син әзерләгән ризыкларны ашап-эчеп, көлешә-көлешә матурларымның кыланышларын карап утырулар, — әнә ул вакытлар минем һәр кичне күз алларыма киләләр. Ә инде миннән суң сезнең матурларым белән ашап-эчәргә өстәлгә утырып, шунда, минем уйлавым буенча, матурларым белән мине юксынып сөйләүләрегез, син аны коендырганда синең тирәңдә матурларым Әлфия белән Наиләнең и матур бәби, матур бәби дип йөрүләре син аны коендырып биләгәч, алар аны әле берсе, әле икенчесе алып сөюләре, суңра синең аны кочагыңа алып, әтиең өйдә булса, ул да сине безнең кебек сөяр иде диеп, синең аңарга күкрәк сөтеңне бирүләрең, шуннан соң сикертә-сикертә сөюләрең — менә шулар һәммәсе минем күз алдыма киләләр. Җылыйм, әгәр дә өйдә булсам, мин дә, сезнең кебек, шул яшь бәбине сөяр идем дим. Ярый, сез бергәләшеп сөйгәнсез, ә мин суң күрми дә калам микәнни һәм калдым микәнни? Мин әле бу көнгә кадәр сөенеп йөри идем, кайтып, шул баланың кечкенә кулларын кечкенә аякларын тотып, кулыма алып, сикертә-сикертә сөймәкче идем. Шулай ук күрми калам һәм калдым микәнни?.. Әй... Әлфиям, әй... Наиләм... әй... 2 нче Аит...»*

— Тукта, Аит! — дип кычкырды Сөмбел.

— Инде бөтенләй дә тәмам, — дип пышылдады Аит. — Гадәттә хатларның ахыры югала бит.

**Унберенче бүлек**

— Елыйсы килә!! Нинди ярату, йә Тәңре! Шекспир, билләһи газим Шекспир хисләре!.. Мин сәхнәдә шушы хатларны алып укыган бәхетле хатын ролендә уйнар идем.

— Сәхнәдә... Ә тормышта яшәр идеңме соң? Сәхнәдә мәхәббәт уйнамыйча, тормышта шул хатын булып яшәр идеңме, Сөмбел?

Аит хатларны үзе дә нигә икәнен белмичә Коръән эченә тыгып куйды. Ул хатлар хәзер өзелеп төшкән ике яфракны хәтерләтә иде инде. Истәлеккә дип, китап эченә тыгып куйган сары яфраклар. Сөмбел моңсу гына елмаеп куйды.

— Мондый хатларны язу да, уку бәхетенә ирешү дә бүгенге ирләр һәм хатыннар кулыннан килә торган эш түгел шул инде. Заманасы әллә нинди китте: тутык хисләр, ә йөрәкләр әйтерсең лә сүнгән мичләр!..

Юк, Сөмбелгә кушылып, Аит заманany гаепләргә җыенмый иде. Сугыш, ачлык, мәхрүмлекләр вакытында шундый сөю булганны бүген ник булмаска тиеш ул? Ул кайдадыр укыган «Бу дөньяда нидер тиешенчә түгел икән, моңа бары тик кешеләр үзләре генә гаепле», дигән сүзләрне исенә төшерде. Ул үзе — Аит нишләде соң? Бер селтәнү белән хатынын ташлады да китте. Дөрес, моны ул үзе теләмәде, моны Солтания теләде. Ялварырдай булып теләде, мине азатлыкта калдыр, үзеңне миннән азат ит дип сорады.

Һәм Аит азатлыкка таба чыгып китте. Ул үзен дә, Солтанияне дә гаепләргә базмады. Әйтмәде түгел ич, әйтте, бергә яшик, берни булмагандай яшик, диде. Язмышка язмагач, бәхеткә килмәгәч, ни хәл итәсең соң?

— Әйт әле, Сөмбел: үзеңә атап шушындый хатларны язардай кешең булсын өчен ни бирер идең икән син бүген?

Сөмбел җавап бирмәде.

— Фәкыйрьләр без. Нинди фәкыйрьләр! — диде ул. — Ә соң синең үзеңнең шушындый хатлар язып җибәрерлек кемең бар соң, кемең бар?

Аит дәшмәде. Әйе, аның андый кешесе юк иде инде.

Караңгы төн уртасында яшенле яңгыр алар йокларга яткан карт өй турысына килеп җитте. Пружиналары уңайсыз төртеп торган иске диванда түзган толып ябынып яткан Аит уеннан берөзлексез Сөмбелнең соңгы сүзләрен кичереп ятты. Әйе, аның йөрәге көзен буш калган бәләкәй кош оясы кебек салкын иде. Аның йөрәгендә дөньяда кая сугылып бәрелергә белмәгән яшен белән Сөмбел соравы гына торып калган кебек.

Яңгыр шавына ниндидер кыштырдау авазы килеп кушылганын ишетеп, Аит сагая калды. Кайдадыр эре-эре тамчылар тамганы ишетелә. Йөрәк тибеше кебек сак кына итеп, кемнеңдер аяк атлавы сизелеп китте. Билгеле, Сөмбел. Аит аны өйдәге тимер караватка яткырган иде. Ул башын күтәреп караганда, болдыр ишеге ачылып китте һәм ул яшен яктысында ишек яңагына сөялеп торучы Сөмбелне күреп алды. Ул өстенә ак җәймә бөркәнгән, төрле яктылыктагы яшен яктысында бер мәрмәр сынныммы, бер өрәкнеме, бер ниндидер кошныммы хәтерләтеп басып тора. Аит торып аңа якынлашканда, ул баскычтан түбән төшеп китте дә, кулын җәеп, торган саен кызурак итеп әйләнергә кереште.

— Сәхнәдә дә шушындый матурмы син? — диде Аит, тамашадан ни көләргә, ни сокланырга белмичә. — Хәер, син ишанның карт хатынын уйныйсың бит әле, кайда анда матур күренү...

— Ялгышасың... — Сөмбел туктап калды, йөзен яңгырга каршы куйды да иренәнә тәгәрәп төшкән яңгыр тамчыларын тел очы белән ялап торды. — Ишан хәтле ишан буласы ир беренче хатынлыкка иң асыл затларның берсен сайлап никах укыткандыр. Сәхнәдә мин карт, ләкин гүзәл бер шайтанны уйныйм.

— Ә тормышта син гүзәл бер... фәрештәсең...

— Юк, Аит. Күрмисеңмени? Суга төшкән тавык мин. Гап-гади мескен тавык.

Караңгыда Сөмбел ачык күренмичә, сизелеп кенә тора иде. Бары тик яшеннең калтыранган яктысында гына Аит аның ак җәймәсе чыланып, тәненә ябышып беткәнен шәйләп алды. Кулы салынып төшкәч, чәченнән, җәймә очларыннан, күкрәк аермасыннан йөгерек яңгыр ага. Яшен дә яп-якын булып, тәненең һәр сызыгы яшен уты белән каймаланып күренә. Яшен яктысы сүнеп, ишегалды караңгыда калганда, ул беравык Аитның күз алдында ялкыннан ясалгандай чагылып торды әле. Күзен йомып кояшка карагандагы шикелле. Аннары аның шәүләсе томандагы әйбер төсле соры булып кына төсмерләнә, ераклаша, ләкин аннан берөзлексез эсселек бәреп тора шикелле. Ул, еракта җемелдәгән учак кебек, Аитны үзенә дәшә сыман иде.

— Миңа... ошый монда... — диде Сөмбел, каядыр өскә карап. Нәкъ кичә әйткәненчә. Кичә ул бу сүзләрне Аитны үзе белән сөйләштерергә теләп әйткән иде. Ә бүген, хәзер? Алар әз сөйләшмәделәр ич инде, бу хәлдә сөйләшү мәгънәсез булыр иде. Аит кичәгечә: «Ә миңа ошамый», — дип бәхәсләшеп тормас ич инде? Һәм ул, һавадан аның чакыруын эзләгән шикелле, кулын сузып, бармакларын тырпайтты да, баскычның ике басмасын атлап, түбән төште.

Яңгырның салкын сулышы йөрәгеН куырып алды шикелле, бөтен тәнен инәдәй чирканчык чәнчеп узды.

— Туңмыйсыңмыни? — диде ул.

— Юк.

— Юк? Суык ич.

— Ялгызлык суыгы хәтәррәк.

Алга сузылган кулының бармак битләре белән генә ул караңгылык томанында эрер-эремәс кенә төсмерләнгән хатынның кулбашына орынды, аның салкыннан калтырануын тояр шикелле иде, тик юеш җәймә җылы иде, парланып торамыни!

Аитның тыны киселеп калды. Мондый тойгыны күптән кичергәне юк иде аның. Аңа хәзер беренче кат күзе төшкән кызны — Солтанияне озаткандагы хисенә, беренче кат яраткан кызы — Солтаниянең куенына кергән кичерешенә кире әйләнеп кайткан шикелле булды. Тик хәзерге мизгелдә аның каршында ул хис, ул тойгы, ул кичерешнең кайсысы басып торганына Аит һич кенә дә төшенә алмады. Күзең төшкән беренче кызны ни өчен озатканыңны, ни өчен үпкәнеңне, ахыр килеп, аңа ни өчен өйләнгәнеңне күңелеңнең һәм тәнеңнең нинди беренче боеруына буйсынып эшлисең — кем белә икән соң? Кайсысы көчлерәк икән — хис, тойгы, кичерешләрме, әллә шул боерумы?

Ә хәзер кем көчлерәк — Сөмбелме, әллә улмы? Язгы су ургымы астыннан калкып чыккан боз шикелле булып, ул боерыкка Сөмбел буйсыныр микән? Әллә соң Аит әкренләп Сөмбел хисләренең боерыгына буйсындымы? Югыйсә карышуы мәгънәсез булачак көч белән аны Сөмбелгә ни тартып тора соң?

Солтания, Солтания! Солтания...

Хәзер Сөмбел якынрак иде. Иң мөһиме — Солтания хәзер инде Аит беркайчан да якыная алмый торган ераклык иде. Алда торган ераклык түгел, артта калган ераклык. Артта калган ераклык — үткән вакыт. Ә Сөмбел йөрәкне эретердәй учак булып, ак кайнарлыгы белән бөтен ишегалдын тутырып басып тора. Юк, ул учак кына микән? Үзе басып торган ишегалды ташы белән болытлар арасында балкыган яшен. Теләсә, ул хәзер Аитны боз хәленә калдыра ала, теләсә, кан юлларына терекөмеш йөгертә алырлык зат иде.

— Икенче Роза чәчәге белән океанның мәхәббәт тарихының ахыры нинди икәнен беләсең киләме синең, Аит? — дип пышылдады Сөмбел.

Бая, шушылай дигәч, Аит үзенең Сөмбелне кочаклап алганын күзаллап куйды.

— Бәлки, соңыннан... аннары?.. — диде Аит.

— Ә хәзер нәрсә? Йә, нәрсә? Нәрсә, Аит? Аит...

Сөмбел Аитка таба борылды. Шул мәлне бар дөньяны мәченең караңгылыкта ялтырап киткән яшел күз нурлары кебек фосфор утына күмеп яшен яшьнәде, чатнап һәм чытырдап күк күкрәде. Сөмбел, өреккән тай сыман сискәнеп, Аитның кочагына ауды. Учына кунган күбәләкне икенче учы белән каплагандай гына итеп, Аит Сөмбелне кочып алды да күкрәгенә кысты.

— Шушылай җиңел очрашкач, ничек авыр аерылышыйк ди инде без, Аит? Җиңел акыллы Роза белән ахмак Океан очрашуы!

Аит үзенең иңбашына тамган дистәләгән яңгыр тамчысы арасында Сөмбелнең ике-өч бөртек кайнар күз яшен тоеп алды. Алар, кайнар ташкын булып, аның тәне буенча түбәнгә, аска тәгәрәштеләр.

— Аит, кадерлем... берәр төрле эчемлек алып чык әле, җаным... — дип, Сөмбел әллә елаудан, әллә туңудан калтыранды.

Аитка аны кочагыннан ычкындыру авыр иде. Ул, баштан-аяк чыланып беткән Сөмбелне өстенә бөркәнгән ак җәймәсе белән бергә сыгарга теләгәндәй, аның кулбашыннан башлап бөтен гәүдәсен сыйпап төште һәм, аның бармак очларына җиткәч, тотыныр урын таба алмыйча, кулы белән караңгылыкны кыскалап торды. Ә Сөмбел, башын артка ташлап, суга сусаган кеше шикелле, ирен читләренә агып төшкән яңгыр тамчыларын тел очы белән ялап тора иде.

— Сөмбел... сусагансың.

— Әле син биредәмени? Минем синең берәр бәллүр фужерыңны ташка бәреп ватасым килә... Кызганмыйсыңдыр ич?

Аит аңа караган килеш кенә чигенә башлады, аркан килеш кенә юеш баскычтан болдырга күтәрелде. Өйдәге әйберләрнең кайда икәнлеген кулы онытмаган, бизмәгән икән әле, болдыр ишегенең яңагыннан әз генә читкә кагылган иде, кулы үзеннән-үзе электр боргычына туры килде дә, ник икәнен абайлап тор-

мастан, ул утны кабызып җибәрде. Сөмбелне яктылыктан читкә, караңгылыкка тайпылыр дип көткән иде, ә ул баскан урынында кала бирде. Бары тик әллә аннан ятсыныпмы, әллә үз-үзеннән оялыпмы, әллә соң туп-туры яуган яңгырдан туңа башлапмы, бөрешәрәк төште, әмма башын имәде, муенын сузып, йөзен югары тоткан килеш гел шул ирен читләрендәге яңгыр тамчыларын ялаштыргалап алды.

— Беләсеңме син кем? — дип эндәште Аит.

— Кем? Кем?

— Искәндәр ташы син.

— Александритмы? Бик матур түгелмен икән. Александрит — нурсыз таш.

— Көндез төссез, салкынча. Аның караvы төнге ут яктысында... кайнар шикелле, якын.

Сөмбел эченнән генә көлеп куйды. Ә Аит болдырдагы кәгазь әрҗәдән шәраб сайлап алды да, ике фужер эләктереп, аның янына ашыкты. Баскычның беренче басмасына басар алдыннан шешәле кулы белән тагын электр боргычына таянды. Ишегалды тагын төн канаты астына сыенды. Яшеннәр баштагы шикелле чатнамыйча, ана казларың канат кагынуы сыман авыраеп, күк күкрәүләре бар көченә йөгереп барган, торган саен ераклашкан ат көтүе тоякларының җирне шаулатканы шикелле тоныкланып калдылар. Яңгырның тигез шавына төрле җирдән тәртипсез тамган су тамчылары тавышы килеп кушылды. Күрше йорт ишегалдында каз каңгылдап куйды, Аитларның коймасы башында ике яшел-зәңгәр ут уйнаклап алды. Аны Сөмбел дә күргән.

— Ни ул? — дип сорады ул. Үзе үк көлеп җавап та бирде: — Мәче дисәм...

— Мәче.

Аит шешәнең укасын ертып, авызын аска каратып тотты да төбенә учы белән китереп сукты. Мәче калын тавышы белән аваз салды да ашыкмыйча гына, сузылып, койма буенча китеп барды — чите ачыклана башлаган күк яктылыгында ул кара шәүлә булып кына күренә иде. Яшен яшьнәп җибәрде, һәм мәче зәңгәр нур белән каймаланып, ап-ак булып күренеп калды.

— Йә! — диде Аит һәм Сөмбел тотып торган фужерларга шаулатып шәраб агызды да шешәсен аяк астына, ташка бастырып куйды.

— Йә? — диде Сөмбел. Ул, фужерын күзе турысына китереп, эчемлек аркылы яшен чаткысы уйнаклавын карап торды.

— Чиста... Хисләр дә шундый чиста булсын иде ул, Аит, — диде ул. — Ул хисләр... шушылай үтә күренмәле булса иде.

— Алайса хисләр чисталыгы өчен, Сөмбел! — Аит ашыгып эчеп куйды. Аңа бу төн тиздән бетәчәк бер уен гынадыр кебек тоелып алды. Каядыр, нәрсәгәдер өлгермәс шикелле булып китте.

Ә Сөмбел ашыкмады. Ул үз фужерын иреннәннән аермыйча гына вак-вак йотымнар белән эчеп бетерде дә, — чираттагы яшен яктысы чагылышыннанмы соң, — күзен йомды да, фужер тоткан кулын йөзенә якынайтып алгач, кискен селтәнеп җибәрде. Күк күкрәгән калын авазга чәлпәрәмә килгән бәллүр пыяланың нечкә чыңы килеп кушылды. Аның хәтерендә теге пасха көнендәге чиркәү кыңгырауларының төрле төстәге авазлары биешеп алды. Аның каядыр очып китәсе килеп китте. Күзен ачканда, ул үзенең, чыннан да, Аит кочагында әйләнүен күреп алды. Бераздан ишегалды һәм аның тирәли үскән карт тупыл ябалдашлары, колгадагы ватык сыерчык оясы, абзарның салам түбәсендәге бастырыкларның тырпаешкан очлары әйләнүдән туктадылар да... барысы да артта калдылар. Ул бая үзе йоклап чыккан өйнең ят исен сизеп алды.

Аитның Сөмбелгә Искәндәр күле турында сөйлисе килә иде. Ләкин... Солтания ишетеп торыр кебек тоелды. Ул үз-үзенә: «Түбән карама!» — дип боерды. Түбән карама... Бу — тауларга менүчеләр законы. Хәзер исә ул Аит күңелендә «Үткәннәргә карама!» дип боеру булып калыкты. Үткәннәргә карама, анда — Солтания. Әмма алда Сөмбел булыр микән соң?

Аларның икесе дә тышта яңгырның туктавын ишетеп ятты.

**Уникенче бүлек**

Ә Җиргә әкрен генә яктылык иңгәнен аларның берсе дә күрми калды. Яңгырдан соңгы тыныч төннең серле авазлары аларны бик ерактан гына әйләнеп үтте.

Кояш мул иде.

Урам буенча язгы ташудай шаулап узган көтү дә аларның йокы ярларына орынмыйча узып китте. Аннары соң авыл тагын тынычлана калды. Иртәнге мәшәкатьләрен бер кат үткәреп җибәргәч, кешеләр, кулбит юып, ашап-эчеп алыр өчен, өйләрендә югалып тордылар.

Бакчаларда ара-тирә тәмам өлгергән алмалар коелыша иде. Тыңлап торсаң, аларның җиргә орынуларын балаларның беренче кат тәпи басып китү тавышына охшатып булыр шикелле.

Алдан Аит уянып китте. Озаклап түшәмнең куна тактасыдай тигез һәм киң такталарын карап ятты, матчага кыстырылган ниндидер кәгазьләрне күзеннән кичерә башлады. Страховой белешмәләре, төрле квитанцияләр.

Ул аягын идәнгә төшереп, торып утырды. Сөмбел стенага таба борылып ята иде. «Мин аңа беркем түгел шул, — дип уйлады ул. — Югыйсә читкә карап ятмас иде дер. Иренә сыенмаган, таянмаган, ышыкланмаган хатын үзен-үзе чикли, читләштерә, кадерсезгә әйләнә, тупаслана... — Ул, уеннан бүленеп, усал итеп, мыскыллы көлеп куйды. — Ир!.. Хатын!.. Кайчаннан бирле? Аның ир булудан туктавына ничә ай бит инде! Хәзер кем соң ул? Ир-ат, бары тик ир-ат кына! Дөньядагы бөтен хатыннарга ул бары тик ир-ат кына, беркемгә дә сыенырлык, таянырлык, терәк булырлык ир түгел икән ич инде... — Ул үзен әллә кызгана, әллә әрли иде, хәер, нишләсә дә барыбер түгелмени? Ул беренче тапкыр үзе турында «мин» димичә, өченче заттан уйлавына сәерсенеп игътибар итте. Беркемгә дә ир булмаган ир-ат үз-үзенә «мин» дип эндәшүдән дә мәхрүм каламы әллә? Ә нигә «мәхрүм»? Нидән мәхрүм? Кемнеңдер үзенә сыенуыннан, таянуыннан, ышыклануыннанмы? Үзеңнең кемгәдер терәк булуыңнанмы? Бу нәрсә, ахыр килеп, азатлык дип атала бугай ич әле! Ә азатлык татлы нәрсә ул, каһәр! Менә ич, ята, аныкы булып ята... Сөмбел аңа бөтен азатлыктан да бише белән татлырак төн бүләк итте. Бише белән татлырак, биш тапкыр татлырак, биш мәртәбә...»

Ул Сөмбелнең өстенә җәймә ябып куйды. Уянмады. Кояш нуры төшеп җылыткан мендәрне ирене белән юешләп йоклап калды, ә Аит плавкидан килеш кенә ишегалдына чыгып басты. Баскыч такталары җылынып беткән, ә ташлар кап-кайнар булган инде.

Аның кәефе төшеп китте. Солтаниянең шушы ташларга яланаяк баса-баса иртәләрен бала керләрен уып йөрүләре, көндезләрен ишегалдына киптерергә җәеп куелган печәннәрне ике япьле агач сәнәк белән әйләндерүләре, кичләрен, аякларын тезләренә кадәр җылы туфракка буяп бетереп, яшелчәләргә су сибеп йөрүләре — кайда болар? Аяклары... Иң аянычы шул: аяклары, Солтаниянең аяклары... Алар хәзер юк иде инде. Үзе бар, ә аяклары... Аитка аның үзе дә юк иде инде. Әллә Солтаниягә Аитмы? Кайсысы кайсысына юк?

Ул тагын күңеленнән генә үз-үзенә: «Аска карама!» — дип боерырга мәҗбүр булды.

Ул, кое янында юынып алгач, өч кирпечне бер-берсенә мич шикелле итеп терәп куйды да, өстенә ике тимер кисәге куеп ут тергезгәч, чәйнек утыртты.

Болдыр ишегендә Сөмбел күренде. Кай ара киенергә-ясанырга өлгергән. Ләкин чәче тарау.

— Ах, нинди тәмле озон исе, — диде ул.

— Озон? Ялгышмасам, моны бездә саф һава диләр.

— Иртүк бәхәсләшәсем килми.

— Алайса хәерле иртә.

— Хәерле иртә, Аит. Нишлисең?

— Ат дагалыйм.

Сөмбел эндәшмичә генә баскычтан төште дә ялтырап яткан бәллүр китекләрен учына җыеп, чыңлатып карады.

— Боз кисәкләре шикелле... Мин сиңа кыйммәткә төштем бугай, ахрысы.

— Сатулашма.

Чәйнең капкачы тишегеннән пар бөркеп чыга башлады. Аит ике чокыр белән кофе савыты алып чыкты.

— Төрекчә ясалган кофе рәхим ит, ханым, — диде ул һәм, чынаяк куеп эчәр өчен болдырдагы патефонны алып чыгарга ниятләп, эчкә керде. Күтәрәм дигәндә, аның капкачы ачылды. Патефонның кәкре муенлы уйнаткычы тутыкмаган, ялтырап тора, капкачына эчке яктан боргыч белән инәләр кабы беркетелгән. Тәлинкәсе дә бар. Ул аны бармагы белән әйләндереп карады. Һәм шунда гүя патефон телгә килде — Аит әнкәсенең тавышын ишетте: хәтерендә аның шушы патефон турында сөйләгәне калыкты.

Балам! Атагыз сугыш кырыннан яраланып чыгып госпитальдә ята ые әле. Кырык бердә имгәнгән кулындагы чокырны һәм яра җөен хәтерлисеңдер дип әйтмим, күз алдыңнан югалта, бигрәк тә зиһенеңнән куып тарата алмыйсыңдыр. Ул ярчыкны син ишетеп кенә түгел, күреп тә беләсең. Миңа ач торырга күнегәсе җугые. Яшьли ятимә калып, миңа җиде тулганда беткән гражданнар сугышы михнәтләрен кичердем, ачлык елның мәхшәреннән исән-сау чыгуым анысы бер хәл. Мин сезне табып үстерүем бәхетенә бик шөкермен. Сезгә дә сугыш белән ачлык килде, минем сымак ятим калуыгыз бик ихтималые. Бөтен нәрсәгә тешемне кысып иренемне тешләп түздем. Сезнең арык хәлсез тәннәрегезне ипи кисәге күргән саен кук капусы кебек ачылып киткән авызларыгызны күрүгә дә түздем. Түздем. Сугышка түздем, ә сагышка түзмәдем. Бөтен эчне айкаган ачлыкның үзәкләргә төшкән авырлыкның зиһенне томалаган мәхрүмлекнең үземне, сезне, бүтән хатыннарны, аларның балаларын мәсхәрәләвенә түзмәдем. Соңгы сарыгымны суйдырдым да кечкенә агач чанага бәйләп салып Карнаук, Шәле урманнары аша Казанга тартып киттем. Атаңнар сугыш кырында, мин белгән тирә-юнь Чирмешән, Ырга, Солтан, Гобәй, Зәңгәрле, Олы Әшнәк, Ке-

че Әшнәк авылларындагы ирләре булырга тиешле ир кирәк булган бөтен хатыннарның матча шикелле асыл ирләре сугышта. Качып кайткан, качып ята дигән бер генә ят хәвефле хәтәр хәбәр дә ишетелгәне җук. Мин белгән тирә-юнь авыллардагы татар хатыннары андый хурлыкка төшмәделәр, шөкер. Ул елларны татар авыллары тирәләрендәге урманнарда сугыштан качып килгән бүреләр генә яшеренеп ятты. Татар хатыннары ирләрен тота белгәннәр дә соң ичмаса. Үз хатыныңны да фәлән качкын хатыны дигән мәсхәрәле даннан саклый күр балам. Казанга киттем. Хәсрәт мине сарык саткан акчага азык-төлек, ситсы, калуш алырга кыстады. Ә сагыш, ә сагышым бер кибеттә җырлап уйнап торган патефон күреп чыкты да җитәкләп кире алып кереп китте. Шул ук чанага салып Шәле, Карнаук урманнары аша Казаннан патефон белән тәлинкәләрен алып кайттым. Хәсрәтемә түзәр ием сагышка түзеп булмады. Хәсрәткә түзәргә сабырлык кына, сагышка түзәргә җыр кирәк икән ул. Мең дә тугыз йөз кырык икенче җыл мартының айсыз, нурсыз бер төнендә мин караңгылыкка чумган үз авылыбызга бәләкәй агач чанага салынган патефонны уйнатып кайтып төштем. Башта этләр өргән ие, тындылар. Бөтен авыл гармунчы атаң кайтып килә дип йокысыннан уянып каршыма чыкты. Ә син атаңның гармунда ничек уйнаганын бик яхшы беләсең ич, улым, бөтенегезне өйрәтеп бетергәние. Уйный ые да соң, әх уйнап та торып җибәрә ие соң. Әле миңа өйләнгәнче Ленинградта сезонлы эштән Кама өслөтә парахутта кайтышлый уйнаган дип сөйлилəрие. Ул уйнаган, бергә җөргән ахирәт иптәше биегән. Халык алар артыннан парахутның әле бер ягына, әле икенче ягына төшә төшә калмый ияреп җөргән. Парахутның янтаеп ава язуы бер хәер шуның әрле-бирле янтаюыннан Камада дулкын купкан дип үзем уйлап чыгарып әйтмим, халык үзе сөйли торганые. Хәзер сөйләмиме. Тыңла әле, тыңла, сөйли торгандыр, сөйли булса кирәк. Сугыш ачигыларын гына түгел, тыныч көннәрнең шундый Камада давыллар кузгатырлык итеп гармуннарда уйнаган кешеләрен дә онытырга җарамый ул. Тыңлап кара әле, халык әле дә сөйли торгандыр, сөйли булса кирәк, сөйләмичә булдыра алмыйлар. Безнең халкыбызның җөрәге туптан атылган рәхимсез шәфкатьсез ядрә түгел ләбаса, безнең халкыбызның җөрәге суларны кузгата-кузгата, күңелләрне үстерә-үстерә, җаннарны айкый-айкый, зиһеннәрне ача-ача уйный торган бер гармун лабаса ул. Җөрәк тә әле ачыла, әле кысыла, гармун да әле ачыла, әле кысыла, икесе дә әле ачыла, әле кысыла. Гармуннар сугышка китеп беткәч, җөрәкләр кысылып кына калганые. Шул кысылган җөрәкләрне ачып җибәрергә дигән ният белән патефон алып кайттым. Хәсрәткә түзәргә сабырлык, сагышка түзәргә җыр кирәк икән ул. Мең тугыз йөз кырык икенче җыл мартының айсыз нурсыз бер төнендә мин караңгылыкка чумган авылыбызга бәләкәй агач чанага салынган патефонны уйнатып кайтып төштем. Балам! Безне дошманның җиңә алмасына авылым кешеләре шул төнне тәмам ышанды. Бер кабынган ышанычны сүндерерлек караңгылык, бер җырланган җырны туктатырлык яшеннәр дөньяда җук. Балам! Аит!

— Төрекчә ясалган кофе рәхим ит, ханым, — диде ул һәм, Аит яңгыр юып киткән юан бүкәнне, әйләндергәләп, баскыч төбенә китереп куйды да кофе ясады. Эреп бетә торган кофеның чак кына көйгән һәм әчкелтем хуш исе бөтен ишегалдына җәелде.

Сөмбел чынаяктагы кофены иснәп карады.

— Әгәр дә минем йокыдан уянуыма шушындый кофе әзерләп торсалар, минем биредә бөтенләйгә калу-калмавымны уйлаганда да ярый.

— Бөтенләйгә? — дип сорады Аит.

— Алай да синнән җүнле ир чыкмастыр, — диде Сөмбел, җавап бирмичә.

— Нишләп?

— Җүнле ирләргә кофены хатыннары ясап эчертә.

«Кофены Солтания яхшы әзерли иде», — дип исенә төшерде Аит. Болдырдагы шкафтан ике бал калагы белән ике шакмак шикәр алып чыкты да бүкән алдына чүкте.

Шикәр салып, кофеларын болгатып эчтеләр.

— Әйе шул, җүнле ирләргә кофены хатыннары ясап эчертә. Ханымнар түгел. Син минем кунагым, шулай булгач, сый-хөрмәт миннән.

— Мин синең кунагың түгел. — Сөмбел, чынаягын бүкәнгә куеп, урыныннан торды.

— Кем соң?

— Бүгенгә хатының дип фараз ит.

— Хатыным? — Аит кофесын ялгыш йотып йөткергәләп куйды. Беренче тапкыр ул Сөмбелнең шаяртуын үзе дә сизмичә чын итеп кабул итә язды.

— Кофеңны түгәсең ләбаса, бүкән!

— Бүкән? — Аит көлеп җибәрде. — Хатынлы ир генә бүкән була ала бугай шул, әйеме?

— Гафу ит, ялгыш ычкындырдым... Арттырып җибәрдем.

— Тагын шундый берәр сүз ычкындыр әле. Тансыкка!

— Өлгерермен. Минем репертуарым шактый бай.

— Бәлки, шулай яшәү кызыктыр ул. Синеке шикелле бай репертуар белән диюем.

— Хатыныңның репертуары ярлы идемени? Сез тату торгансыздыр шикелле. Татулыкта матурлык, дип юкка гына әйтмәгәннәр.

Аит:

— Әйе, тату, — дип көрсенде.

— Алайса нигә көрсенәсең?

— Бүген минем иң авыр көрәшем көне.

— Минем белән көрәшергә җыенмыйсыңдыр ич?

— Синең белән татулаштык бугай инде. Шуңа күрә көрәшәм дә. Үз-үзем белән.

— Төшенеп җитмим.

Аит болдырга кереп китте. Күзе стенага, җилпуч белән янәшә элеп куйган гитарасына төште. «Түбән карамаска!» — дип уйлады ул. Күңелен тирән бер сагыш биләп алды. Ул үзенә аркан утырган Сөмбелгә карап куйды. Сөмбел таза, сау хатын, ялангач кулбашлары ташып тора, күлмәге тәненең һәр хәрәкәтен белдереп тора. Бүген ул нигәдер кичәгечә чибәр булып күренми иде инде. Күңеленә сава башлаган бушлыкны тутырырга теләп, ул кулына гитарасын алды. Текә таулар башында түбән карамас өчен, ул җырларга күнеккән иде.

Тормышның Каф тауларында
баусыз калдык икәү.
Түбәнгә ничек төшәргә,
ничек — белсәң икән!

Пар бөркет оча куышып —
ялкын-ут кебекләр.
Шундый канатлы иде ич
безнең дә өметләр!..

Таш кыскан эдельвейс кебек
шиңде безнең вәгъдә.
Пыскыган салкын учактай
яшәүдән ни мәгънә?

Бөркетләрнең ояларын
ташлар иште түбән.
Кайда син?
Ишетәсеңме:
бу — минем тәүбәм...

Сөмбел үзенең бу иртәдәге шаяртырга тырышуларының урынсыз булганлыгын аңлап алды. Бүген аңа үз-үзен бераз бүтәнчәрәк тотасы калган, ахрысы. Ул Солтания Аит алдында гаепледер, аңа берәр авыр, бәлки төзәлмәс җәрәхәт ясагандыр дип уйлап куйды. Хәер, нигә Солтания? Бәлки Аиттыр? Һәрхәлдә соңгысы дөресрәк, чөнки ачуы, үпкәсе булса, ул ир башы белән мондый моңсу җыр җырлап утырмас идедер. Аңа карата мөнәсәбәте дә бүтәнчәрәк булыр иде. Кайсыдыр хатынга үч саклаган ир башка хатыннар белән дә тупас кыланучан. Ә Аит үз-үзе белән көрәшә...

— Җырламыйсың син, — диде Сөмбел, Аит гитарасының кылын соңгы кат чиртеп куйгач.

— Нишләдем соң? — Гафу ит, мин синең өчен җырламадым.

— Әйе, бу — синең күз яшең. Күпмедер дәрәҗәдә моңа мин дә сәбәпче.

— Киресенчә, Сөмбел! — Аит, ашыгып килеп, аны арттан кочып алды.

— Миңа хатының турында сөйлә әле.

— Үткән эшкә салават, кирәкми... Альпинистларның «Түбән карама!» дигән законы бар. Үткәннәргә күтәрелсәң, төпсез киләчәккә егылып төшеп китүең бар. Ә мин киләчәгемдә берүзем. Альпинистлар, ичмаса, ялгыз булмыйлар.

Сөмбел аңа сыенып торды да, алга иелеп, аның кочагыннан чыкты:

— Кофе яса әле, — диде ул. — Үзең дә эч.

Янәшә торып, бер-берсенә карашмыйча һәм сүзсез генә кофе эчеп утырдылар. Аит абзар-кураны күзеннән кичерде. Йорт ул күз алдына китергәннән күпкә искергән икән инде.

— Син аны мин уйлаганга караганда да ныграк яраткан булгансың, — диде Сөмбел.

— Моны каян алып әйтәсең әле?

— Синең «түбәнгә карама» дигән законың үлем куркынычыннан котылыр өчен әйтеләдер ул, әйеме? Синең үткәннәрне уйламаска, аны искә алмаска тырышуың да үз-үзеңә шул «түбәнгә карама» дию сыманрак, ахрысы. Альпинистлар түбән караудан егылмас өчен сакланган шикелле, син дә... үткәннәреңне үлем янаган төпсез чоңгыл итеп күрәсең. Бәлки, бу миңа тоела гынадыр... йә булмаса мин шулай телимдер, га-

фу ит... Тик... синең өчен үткәннәрең үлем белән янаган төпсез биеклеккә тиң икән... син аны... («Аны» дигәнне Сөмбел басым белән, аерып әйтә, әмма аның кем хакында сөйләгәнен Аит болай да бик яхшы белә иде.) ...син аны яраткансың. Бик яраткансың. Яраткансың гына да түгел, хәзер дә яратасың әле. Син аны искә төшерергә куркасың. Югалтырга теләмәгәндә генә куркалар. Кадерсез нәрсә куркытмый.

— Без аның белән таулар ярата идек. Марух дигән үткелләрне кичтек. Данбайда булдык, тарлавыгын үттек, Эльбруска күтәрелдек. Донгус дигән бер урында — орун — безнеңчә Дуңгыз Борындыр инде — ...юлларыбыз аерылды... Ә без аның белән җирдән күренмәгән биеклекләргә күтәрелеп түбән карарга — аяк астыбыздагы үзәннәргә, болытларга, баш очыбыздагы кояшка, йолдызларга яки яшеннәргә карарга ярата идек. Кайчагында кояш аяк астында була, үзәнгә таба тәгәрәп төшә, ә шул ук мәлдә баш очында күк күкрәве ихтимал.

— Тормыштагы кебек икән, — диде Сөмбел.

— Дөрес әйттең. Тик тормышта яшеннәрдән качып, кояшларга сыеныбрак яшәү мөмкинлеге дә бар, син сайлый аласың. Ә тау башларында сайлау юк. Син анда берүзең. Хәтта икәү... бишәү булганда да берүзең. Безнең яшенле, күк күкрәүле урыннарга эләккәнебез булды. Күз алдында хәтта шарлы яшеннәр дә пәйда булгалады. Син ялгыш орындыңмы, әллә ул үзе килеп бәрелдеме — беттең, сине беркем коткара алмый, юкка чыгасың, хәтта көлең дә калмый! Яисә баш очында да, аяк очында да кояш, — ә син ишелеп-ишелеп яуган кар эчендә, тәмуг суыгында эленеп каласың, әмма тамчы да ашыгырга ярмый. Бәлки, син ашыккан җиргә иптәшләреңнең соңлабрак менеп яисә төшеп җитүе хәерлерәктер?.. Таулар менә нәрсә ул, Сөмбел, Эльбрус... Андагы кыяларда эдельвейслар гына чәчәк атып утырмый. Без бер үткелне кичкән чакта бозларга катып калган фашистларны күрдек. Күп иде алар. Туплар ята, пулеметлар... Һәм кешеләр. Яңа гына үлгән кебекләр. Үлгән түгел, ә бәлки йокыга гына киткәннәр сыман. Шунда ук үзебезнең солдатлар да. Җәрәхәтләреннән агып чыккан каннары да боз астында төсен җуймыйча сакланган... Мең тугыз кырык икенче елның тугызынчы августында гитлерчылар Пятигорскины басып алганнар да Кавказның төп сырты үткеллекләренә ташланганнар. Сайлап алынган башкисәр егер-альпинистлар. «Эдельвейс» дивизиясе. Исемен дә таба белгәннәр дә соң! Чәчәк исеме. Әйтерсең лә чәчәк утыртып йөрүчеләр!.. Эльбрус таулары түбәләренә менеп, алар фашист штандартлары кадап, ә үзәннәрдә үлем чәчеп йөргән. Тик озак түгел. Безнекеләр аларның кикрикләрен тиз шиңдерә. Без ул сугыш сукмаклары буенча әз йөрмәдек. Чистартырга кирәк иде. Тауларны чистартырга. Безнең үзебезне дә тауларда адым саен үлем сагалап торды.

— Шуңа карамыйча менә идегезме?

— Үлемне җиңүе рәхәт иде. Үлемне, авырлыкларны, куркуны. Таулар кешеләрнең йөрәкләрен бер итә иде.

— Юлларыгызны аерган да ич.

— Ә ул бөтен куркыныч артта калгач булган хәл. Кешеләр тормышларына куркыныч янамаганда ваемсызрак, бер-берсенә карата саксызрак... Яшәве җиңелрәк булган урында ялгышуы ансатрак.

Таулардан төшеп, базада соңгы көнне үткәргән чагында мин аны тау болынына алып чыгып киттем. Җылы иде. Чәчәкләрнең, үләннәрнең аяк астындагылары түгел, ә ялангач кыя уентыкларында берьялгызлары үсеп утырганнары җетерәк, матуррак шикелле, нык холыклы кешеләр сыман кырыслар... Унөч көн буена таш кыяларга чөйләр кагып, ыргаклар беркетеп, репшнурда күтәрелүләрдән, төшүләрдән, беркая ышыкланмыйча, кыялардагы өстәл шикелле генә уентыкларда салкын төн кунулардан тупасланып беткән кулым ул чәчәкләрне өзгәнче үк сытар сыман, яргаланып беткән ирен кыргый җиләкләрне авызга алганда да, аны үпкәндә дә әчетә, тау башларында сварка утыдай чагылып торган ап-ак карлар күзләрне талчыктырган — алардан яшел урман күләгәсендә дә яшь ага.

Ләкин безгә икәү булганда рәхәт иде.

Көтмәгәндә көн бозылып китте. Алдан һичнинди билгесен күрсәтмичә. Бәлки, бер-беребез белән мавыгып сизми калганбыздыр, белмим. Көрәп-көрәп кар яварга тотынды. Август ахыры гына иде әле. Шундук яшен яшьни, күк күкри, таулар өскә ишелердәй булып калтырый шикелле. Караңгыланды, әйтерсең лә көн уртасы түгел, ә төн уртасы. Ул аягын авырттырды. Чалгы белән чапкандай ауды. Әллә аягын тайпылдырды, әллә тамырын тарттырды... Ахырдан сынган икәне беленде. Күтәреп төшә башладым. Аяктан егарлык итеп җил исә, ниндидер торбадан безгә генә өрдереп торалар диярсең. Ышык урын табып, яшеренгән булдык. Кая анда! Үзәкләргә үтәрлек салкын. Туңа башладык. Ә буран... Котыра гына! Чәчәкле болын һәм буран. Җете яшеллек һәм җете аклык. Матур булгандыр ул. Һәрхәлдә минем тагын бер күрәсем килә. Билгеле, киенеп, туңмыйча, палаткадан. Палаткаларыбыз белән бергә безне күмеп киткән бураннарны мин әз кичердем. Унбиш минут саен чыгып, палатка түбәсен көрисең...

Ул көнне Данбайда өч турист туңып үлгән. Берсе — ике бала анасы. Таулар андыйларны да сихерләп чакыра, күрәсең. Фаҗига... Адашканнар. Группаларындагы кешеләр, ялгызлары котылырга исәп тотып,

кайсы-кая таралышып беткән. Ә тауларда бәладән ялгыз котылып булмый. Фаҗиганең икенче ягы шунда: бу туңып үлгән кешеләрнең өчесе дә башкаларны коткарам дип һәлак булган. Ике бала анасының үзен коткарырга кеше табылмаган, киресенчә, ул үзе... Ни уйлады икән ул?.. Башкалар өчен яшәргә теләүчеләр ешрак һәлак була... Кырыс статистика, әйеме?

Буранның очы-кырые күренмәгәч, аны ботаклар, үләннәр белән томалап калдырып, базага үзем генә төшеп киттем. Ярдәмгә кешеләр дәшәргә дип. Буран туктаганны көтеп утырсак, икебезнең дә озакка чыдамаячагыбыз ачык иде. Һәм адаштым мин. Моңа бернинди хакым булмаса да адаштым! Ә миңа ашыгырга кирәк иде. Үзебез өчен генә түгел, өченче, әле тумаган, әмма без инде өченче ай бик көткән җан иясе өчен дә ашыгырга тиеш идем... Адашкан кеше ничек кенә ашыкса да соңара. Аны табып алып, базага алып төшкәндә соң иде инде... Ул исән калды, тик... Тик аның аякларын кистеләр. Өшегән иде... Ул мине кичерә алмады. «Мин сине аяксыз хатыннан азат итәм!» — дип, аерылышырга үзе гариза бирде.

Бер караганда, минем гаебем юк ич, әйеме? Бөтенесенә ахмак очрак гаепле. Әмма шул ахмак очраклар өчен дә акыллы кешеләр гаепле шул. Яшәүнең иң дөрес, иң гадел законы шундый... «Син ялгышырга тиеш түгел!» дигән бурыч кешегә, бәлки, бер генә тапкыр биреләдер. Минем бер ялгышуым гомеремне мәгънәсез итеп калдырды... ул мине гафу итә алмады... Бәбиебез тумады. Икенче бәбиебез.

Ә безнең әтиләребез сугыштан да адашмыйча исән кайтырга омтылганнар. Ни өчен? Без һәм безнең кебек миллионнар дөньяга килсен өчен! Әгәр дә алар җиңелсәләр яки бөтенесе үлеп бетсәләр? Аларны кем гафу итәр иде? Безнең әниләребезме? Аларның үз аналарымы?

Данбай мине ялгыз итте.

Мин аның гафу итүен, кичерүен теләмим. Юк, юк, аның янына кире кайтмаска сылтау булсын дип түгел! Йөрәгем мәңге җәрәхәтле торсын дип. Җан авыртсын, сызласын. Аның аяклары өчен дә сызласын. Җаны сызламаган кеше тозсыз ипи кебек бит ул.

## Унөченче бүлек

Аит үзләренә каршы йорттан пыяла банка белән сөт алып чыкты. Ачык йөзле Асия карчык бушка бирергә теләгән иде, алмады, тиешле акчасын түләде. Аннары, аларның артык сөтләрен сатканын белгәч, иртәләрен миңа да кертерсең дип, ун сум акча биреп калдырды. Карлы базда төн кунган, салу белән банканы тирләтеп чыгарган салкын, куе сөт. Күңеле булган карчык, алъяпкыч итәген тутырып, ярылып китәм дип торган помидорлар да чыгарып бушаткан иде.

Сөмбел белән салкын сөт эчеп, яргаланып торган помидорларга эре тоз сибеп ашадылар. Тагын су кайнатып, кофе ясадылар. Бу юлы — Сөмбел.

— Җүнле иргә кофены хатыны ясый дидеңме әле?

— Кунагы да ясавы бик ихтимал!

— Син теләсәң ял ит, — диде Аит. — Мин бу әрҗәләрне бушатып, әйберләрне урнаштырыйм инде.

— Булышсам, хуҗабикә булып калыр дип шүрлисеңме әллә?

Аит хатын-кызның үзе белән бергә, бигрәк тә бертигез итеп эшләвен өнәп җиткерми иде. Бәлкем, бу гаиләләрендә ир балалар күп булып, ирләр эшен гел үзләре генә эшләгәнне күреп үскәнгәдер? Ә бу юлы ул килеште. Сөмбел белән бергәләп, өйдәге иске әйберләрне ишегалдына чыгарып өя бардылар. Иң элек киң матрас белән тимер караватны чыгарып куйдылар. Ул атасының шул матрасны йомшак мүк белән тутырып, яңа материя белән тышлаганын исенә төшерде. «Сиңайтәм, бу матрас хан кызы тәне ише гөбердәп калды, билләһи газим!» — «Хан кызларын тотып караганың бармы әллә?» Ерагаеп, тәмам югалып калган тыйнак кына бер көлешү авазы ишетелгәндәй булды. Аит үткәннәрне аермачык күрә һәм ишетә иде.

Аннары көйгән аяклы өстәл чыгарып куйдылар.

— Бу өстәлне мин әнигә стипендиямә алып биргән идем, — диде Аит. — Мич авызы янына куйган да көйдергән. Ашъяулык япкач, күзгә ачык бәрелеп тормый анысы.

Шулай һәр әйбернең диярлек тарихын сөйли-сөйли, алар икәүләп борынгы калын, әмма бозылып беткән көзге, ярык куна тактасы, күәс, самавыр, күреге ертык тузган гармун, какшап беткән тумбочка, этажерка, ватык савыт-саба чыгарып, ишегалды уртасына өя бардылар.

— Болары нинди чүп-чар инде тагын? — дип, Сөмбел җиргә кочагыннан тимер-томыр бушатты.

— Ә болары чүп-чар түгел аның, Сөмбел.

— Ни соң? Сынык кылыч, кисәү...

— Шушы иске йортка сыйган егерменче гасыр болар... Менә бу сынык самурай кылычы — рус-япон сугышыннан, бабай истәлеге. — Аит сабындагы агач тоткалары шылтырап торган сынык кылычны җиргә кадап куйды. — Бу дүрт кырлы күгәрек штык белән шул ук бабай ундүртенче елдан унҗиденче елга хәтле

германнар белән сугышып йөргән. — Ул штыкны да кылыч янына кадап куйды. — Ә менә монда тагын бер тимер-томыр булырга тиеш... — Аит йөгереп диярлек өйгә кереп китте, сәгать өстеннән бизәкләре кырылып беткән калай тартма алып чыкты да аны әкрен генә ачып җибәрде һәм тагын атасының тавышын ишеткәндәй булды: «Беләкне менә шушы снаряд ярчыгы каеп алды минем, улым»... — Бусы соңгы сугыштан әти алып кайткан истәлек, беләгеннән чокып алганнар, — диде ул һәм кызыксынып, шул ук вакытта шикләнгән сыман тартмага иелгән Сөмбелгә күгәрек, ләкин теткәләнеп беткән үткер кырлы, саргаеп беткән марляга төрелгән тимер кыйпылчыгын чишеп күрсәтте.

— Кызык чүп-чар монда, әйеме? Тарих чүп-чарлары... Без иске өйдән чыгарып аткан тузган әйберләр шикелле җиңел генә итеп, боларны кешеләр хәтереннән чыгарып атып булмый. Ярамый! Җир шарындагы барлык иске йорт-җирләргә моның өше истәлекләр шыплап тутырылган. Кайчандыр кеше өчен кулланылган әйберләр белән музейлар тулган... Бу кылыч белән штыкны стенага — баш очыма элеп куям мин.

— Дамокл кылычы итепме?

— Дөрес әйтәсең. Дөньядагы һәрбер кешенең башы турысына очлы кылыч элеп чыгарга кирәк.

— Ярый алайса, боларын кире керт, ташлама... Әйдә, урнаштырып бетерик.

— Бар да тузган, беткән монда! Бар да какшаган, уңып беткән... йа Хода! Үтсә дә үтә икән гомер...

Аит балта алып, болдырның бер ягына җайлап куелган такта әрҗәләрен сүтәргә тотынды. Монда яңа караватъ, диван, өстәл, шифоньер, ике кәнәфи... — ике бүлмәлек румын гарнитуры. Ә Сөмбел кое чыгырын чыгырдатып ике чиләк су алды да, күлмәк итәген авыл хатыннары шикелле кыстырып, өйне, өйалдын юып чыгарды. Кул арты белән маңгай тирен сөртеп алгач, ул кәнәфигә килеп утырды.

— Боларын кая куярсың икән инде? — диде ул, яңа әйберләргә ишарәләп.

— Әле үземне кая куярга белгәнем юк, — диде Аит. Ул такталарны, кочагына алып, келәт кыегы астына чыгарып өйде. Диван белән караватны, урындыклар белән кәнәфиләрне, өстәл белән шкафларны өйгә кертеп урнаштырдылар. Стенканы җыюы читенрәк иде, ул калып торды. Өй эче бераз сәеррәк төс алды.

— Менә бу интерьер! — диде Сөмбел, сокланып карап торгач. — Вилла. Җәннәтне көнләштерерлек.

— Беренче юлга ярый инде.

— Ә икенче юлга нишләтәсең?

— Өйне эчтән дә, тыштан да такта белән тышлап чыгам.

— Җәннәтең ничә урынлык булыр икән: берүзеңәме, әллә ике кешелекме?

Аит чүп-чарны чыгарып түкте, ә Сөмбел болдырны юып чыгарды да, юган чүпрәген сыгып, баскыч төбендәге ташка җәеп куйды.

— Бу минуттан аягыңны сөртеп йөри торган бул, тәкъсир!

— Менә соравыңа үзең җавап бирдең: синең бу өйне ике кешелек итеп ясыйсың килә. Ярый соң, әлегә тыңлыйм һәм буйсынам. Баш өсте, ханым, — дип сөйләнә-сөйләнә, Аит бик тырышып аклы-кызыллы йомшак аяк киемен чүпрәккә ышкып торды. — Элеккеге ситсылар нинди булган, ә? — диде ул, аяк астындагы чүпрәккә күзе төшеп. — Өйне, болдырны юып чыгарсаң да, төсе, чәчәкләре уңмаган.

— Күлмәк ул, — диде Сөмбел. — Заманында кемдер кигән инде аны.

Аит аягын алмаш-тилмәш җирдән күтәреп, чүпрәктән әкрен генә ташка чыгып басты.

— Ничек кулың барды? — диде ул, тешләрен кысып. Сөмбелдән ниндидер куркыныч янаганын тойгандай, беләге белән битен каплады. — Кабахәт, — дип пышылдады ул һәм ишегалдына чыгарып ташланган әйберләргә күзе белән генә түгел, ә җаны белән дә текәлеп калды.

— Рәхмәт. Бәлки, мин синең бу сүзеңә чыннан да лаекмындыр.

— Мин үземне әйтәм. Әнинең чәчәкле күлмәген шушы хәлгә җиткерүгә мин үзем гаепле. Тормышыбыз җайлы чагында нигә сукыр соң без? Әниләрнең тузганчы кияргә дә өлгерми калган күлмәге белән идән югач, кем соң без? Без аларның үзебез күрмәгән күпме кайгы-хәсрәтләрен шушы күлмәк шикелле итеп аяк астыбызга җәеп салганбыз ич!

— Бичара әнкәң белән мескен атаң... Алар минем бу күлмәк белән идән юганны түгел, ә бәлки синең менә бу әйберләрне чыгарып ташлаганыңны карап торсыннар иде әле. Ни әйтерләр иде икән?

«Әйе, әти дә, әни дә минем бу әйберләрне чыгарып атканымны карап тордылар, — дип уйлады Аит. — Хәтеремнең үткәннәргә төбәлгән салкын тәрәзәләре аша карап тордылар...»

— Мин начарлык эшләргә теләмәгән идем, — диде ул. — Мин бары тик үземә бишегемне кире кайтарып алырга гына теләгән идем. Кайчандыр үземне тирбәтә-тирбәтә арыган, тузган бишегемне... Җилләр, яңгырлар, карлар, кояш эссесе ямьсезләп бетергән, тик мәңгегә йомшак һәм җылы калган бишегемне. Мин бары тик әти үзенең гади крестьян акылы белән ясаган, әни исә гади җаны белән җылыткан бишегемә яңадан кайтып, арыган тәнемне, җанымны шунда ял иттерермен дигән идем... Әнинең күкрәк сөте белән сугарылган бишек... Бишек... Шуңа арыган тәнемне биләүләп салып, җанымны тирбәтергә... Кешегә

йокларга, яратырга, балалар үстерергә, үткән көннәрен санамыйча гына үлемен көтеп алырга туган бишек кирәк!.. Ләкин бишекләр кешеләр өчен генә, Сөмбел! Ә мин синең кулларың белән әнинең чәчәкле күлмәген чүпрәк итеп идән юдым... Мин үземә тыныч бишек тапмакчы идем, тик бишегемә хыянәт иткән булып чыктым...

Кеше табигатендәге мондый кискен үзгәрешне башка вакытта Сөмбел һич аңлап бетерә алмас иде. Кеше җаны — карурман. Ә Аитның, кичәге тыныч, шуклыкны да, чынлыкны да бөтен тирәнлегендә кабул итә торган, сизгер күңелле, кырыс холыклы икәнлеге һәр саран хәрәкәтендә беленеп торса да, кирәк икән — күзе, кирәк икән — сүзе, кирәк икән ымы-ишарәсе белән йомшак, ягымлы да була белүче Аитның кинәт шушындый төпсез төшенкелеккә бирелүен ул бөтен йөрәге белән төшенде. Моңа ул иң беренче чиратта үзен гаепләде. Дөрес, ул Аит күңелендә уянган үз-үзеннән канәгатьсезлек тойгысының чыганагы, беренче сәбәпчесе түгел, алай да үзе генә яшәргә дип кайткан, арыган-талчыккан, зур кичерешләрдән яңа гына арынып килә торган ир-ат янында аның — билгесез, таныш булмаган хатынның пәйда булуы кирәкмәс иде, күрәсең... «Югыйсә аның мине танымавы гаҗәп түгелмени? — дип уйлады Сөмбел. Хәер, ул аның күзенә бер генә чагылып калды калуын, анда да бөтенләй бүтән кеше белән мавыккан чагында, ләкин алай да, алай да, алай да... Ихтимал, бәлки, теге пасха төнен әйтәсе калгандыр. Әмма бу Аитның җанын тагын да ярсытмас иде микән соң? Аңа үткән бер тәүлек эчендә «түбән карамау» чынлап та хәерле булган. Теләгәнме-теләмәгәнме, ул Солтания белән чагыштырып караган лабаса Сөмбелне! Әгәр ул чакырылмаган кунак төсендә бирегә килеп кермәсә, кем белә, бәлки, Аит тыныч кына урнашыр, көннәрен уйланмый-нитми генә үткәрер идедер. Ә чагыштыруның Сөмбел файдасына хәл ителмәве ап-ачык: югыйсә Аит аның белән бөтен дөньядан ваз кичеп мавыкмас идемени? Ул Аитның иң авыр тойгылары көйрәгән күмерләргә җил өрдереп җибәргәндәй иткән икән лә! Аның бирегә вакытсыз килеп кергәнлеге бәхәссез. Ул монда чит, чит, чит... Хәер, әле чыгып китәргә соң түгел лә! Риваятьтәге Роза чәчәге сымак, аны биредә кабул итүен иттеләр, ләкин моның ахыры бүтәнчә дә бетә ала ич әле. Әле соң түгел, әле төзәтергә мөмкин, әле һәркемгә үзенчә калу җае бар. Һәркем бер-берсе алдында азат. «Тик безнең һәркайсыбыз аның алдында азат түгел, — дип уйлады Сөмбел. — Ул биредә юк, алай да без аңа бәйле. Солтания!..» Ул Аитны үзеннән азат иткән, имеш. Юк, ул аны үзеннән... коткарган!

— Беләсеңме мин кем? — дип сорады Аит һәм дерматины ертылгалаган, кайчандыр ялтырап торган тимерләре төртек-төртек күгәреп беткән патефонга барып утырды да дога укыгандагыча киң итеп ачып куелган учларына текәлде. — Трояя аты мин, Сөмбел.

— Троя аты?

— Троя аты. Шушы иске йортка, минем беренче һәм иң соңгы бишегемә килеп кергән Троя аты... Мин аны менә ничек итеп туздырып ташладым... Хәзер бу йорт белдерелгән кош оясына охшап калды. Син ничек уйлыйсың?

Сөмбел аның алдына килеп тезләнде, кулыннан тотып, күзләренә карады.

— Мин уйламыйм, мин күрәм, — диде ул, аның учын сыйпап. — Мин үземнең, йөгерек су сыман, синең бармак араларыңнан агып киткәнемне күрәм... Син күрәсеңме? — Ул аның учын йөзенә якынрак китерде. — Аркылы-торкылы сукмаклар белән кискәләнеп беткән уч төбендә яртылаш өзелеп калган бер эзне күрәсеңме син? Бел, ул мин түгел.

— Син минем белән каласыңмыни? Синең өзелмәгән эзең кайсысы соң?

— Юк, мин китәм. Мин таҗларын өләшеп бетергән теге Роза чәчәге сымак китәм.

— Ул Океанныкы булган лабаса!

— Кичә синең тыңлап бетерергә түземлегең җитмәде: ул Роза чәчәге таҗларын өләшеп бетерүгә карамастан үзен алырга әзер торган Океанныкы булырга теләмәгән — киткән...

Аитның алдында тезләнеп торган хатын әйткән бер генә сүзгә дә карышасы килми иде. Ул аның белеп сөйләгәнен, дөрес уйлаганын, тиешле карарга килгәнлеген төшенеп утырды. Нәрсәгәдер үгетләү, аннан тагын нидер көтү, теләү мәгънәсез һәм ямьсез булыр иде. Нигә? Сөмбел бу вакыйга агышын һәм, иң мөһиме, аның күңелендә ургып торган кичерешләрне сизгер тойган.

— Беләсеңме нәрсә? — диде ул, бераз тын торгач. Тавышы тыныч, дустанә, үкенечсез. — Хатының кичергән сине.

Аит аның мондый сүзләрен һич көтмәгән иде. Ул патефонны аударып сикереп торды да таш өстендә яткан балтаны гайрәтләнеп бүкәнгә чабып куйды.

— Кичергән булса, шул... этлекне эшләр идеме? — диде ул, уйчанланып, тавышында һичнинди ачу төсмере юк иде.

— Ул синең аяк-кулларыңны бәйләп тотмас өчен сине үзеннән азат иткән. Ышан, Аит, хатын-кыз йөрәге белән сизеп әйтәм. Ул иң изге бу эшен сине яратуы хакына эшләгән. Аның сине азат итүе кичәге хатлар белән тиң изгелек, Аит!..

Тынлык караңгы кое шикелле тирән, ә кояш тау башындагы мәңгелек кар түбәтәе шикелле якты, ләкин нигәдер салкын кебек иде. Аның каравы аяк астына эрегән кургашын ташкыны җәелдемени. Чикерткә аваз сала икән. Аның чырылдавы Аитка шул авыр кургашынның сүрелгәндәге чатнавы булып ишетелде. Аңа оят иде. Бөтен тәненә гарьләнү дулкыны җәелде, кайнар һәм ярсу каны йөрәгенә какты, аның тагын, бирегә кайтып кергән минутындагы шикелле кулларын киң итеп җәеп, ишегалдының җылы, яссы ташларына сузылып ятасы, җаны авыртуын балык кебек бәргәләнеп сүрелдерәсе килә иде, ләкин ул бар ихтыяр көчен Сөмбелгә тыныч күренер өчен тупларга кирәклеген уеннан ычкындырмады. Аның Сөмбелне «Синең ни эшең бар? Ник катнашасың яисә тыкшынасың?» дип битәрлисе дә бик килә, ләкин ул үзен:

— Рәхмәт сиңа, — дияргә мәҗбүр итте.

— Кызык. Без бер-беребезне яраттыра да, чиләштерә дә алдык.

Сөмбел торды, бодырга кереп, элгечтән кызыл сумкасын алып ачты да, көзгесенә карап, каш-керфекләрен төзәткәләп куйды, ирненә мул итеп куе чия төсендәге иннек сөртте.

— Кая барасың инде хәзер?

— Кая булсын инде: шунда, Океанга таба... — диде Сөмбел, елмаеп һәм ялан аягына биек үкчәле сабосын киеп, кызчыклар шакмак-шакмак уйнагандагы шикелле, таштан ташка сикерекләп куйды.

— Таҗларың җитәр микән соң?

— Ә синең үз чәчәгеңә... хатының Солтания янына кайтыр өчен... йөрәгең җитәр микән, Аит?

Аит уңайсызланып китте. Әйтерсең лә бер өйгә килеп кергән дә, хуҗалары өйдә юклыгын күреп, ни калырга, ни чыгып китәргә белмичә аптырап басып тора. Андый чакта кая барып төртелергә белмисең. Утырсаң, тыйнаксызлыкта, әдәпсезлектә гаепләүләре бар, чыгып китсәң, тагын әллә ничек: бүлмәләреннән берәр әйберләре югалып, шуны синнән күрсәләр? Сөмбелгә бирергә кирәк булган җавапны аның үз-үзенә бирергә дә кыюлыгы җитмәс иде. Кинәт кенә ул үзен эченә таш тыгып куелган һәм аңа таба очып килүче туп каршында калгандай хис итеп куйды. Тотаргамы, тотмаскамы? Тотсаң, җәрәхәт аласы, тотмасаң оттырасың. Читкә тайпылып калсаң, куркаклык санала. Анысы оят һәм хурлык. Әгәр дә ул хәзер Сөмбелгә, димәк, иң алдан үз-үзенә җавап бирмәсә, соңыннан хәтта үкенүе дә гарьлек булачак. Солтания...

«Туктале, каян белә ул?» — дип уйлады ул, менә хәзер, бу минутта гына булса да җавап бирми торырга сылтау табуына куанып. Куанып? Ул тагын оялып куйды. Ләкин инде ул:

— Син... аның Солтания икәнен каян беләсең? — димичә булдыра алмады.

— Теге пасха төненнән, Аит. Хәтерлисеңме? — Сөмбел аңа карт укытучы хатын сыман кырыс һәм үзенә буйсындырырга күнеккән кыяфәттә карап куйды. Аит аның күзләренең, өченче көн танышкан чагындагыча, каршындагы кешене сынап, шул ук вакытта шукланып кысылуын күреп алды. Юк, өченче көн генә түгел икән шул, Сөмбел аңа шул пасха төнендә дә нәкъ шушылай караган иде түгелме соң? Аит, берничә минуттан теше сызлый башлаячагын сизеп торган кеше кебек, арыну чарасы булмаган курку тойгысына буйсына барганын тоеп алды. «Аның белән тагын бер тапкыр очрашыр өчен, шулай, яшәүнең дистәләгән тауларын, үткеллекләрен, тарлавыкларын кичәргә, Солтанияне чыннан да читкәрәк куеп торырга кирәк булды микәнни соң?» Мондый хәлгә юлыгыр дип, ул башына да китерә алмас иде, ләкин чынбарлык, киселгән җирдән ага торган кан кебек, аның күз алдында лабаса.

— Ир кешенең кире кайтырга йөрәге җитәргә тиеш, Аит, — диде Сөмбел һәм, аның янына килеп, тавышына бик туры килеп тора торган ягымлы, тулы кулын сузды.

— Сау бул, — дип пышылдады Аит.

— Очрашканда исәнләшмәдек, аерылганда да саубуллашмыйк, — дип Сөмбел зәңгәр күлмәге итәген җилпеп борылды да капкадан чыгып китте.

Аит ялгызы калды. Әйтерсең лә, башын иеп, үзе менә алмаган тауның итәгендә басып тора. Ул әле беркем дә аяк басмаган бер, ун, йөз тау башына менәргә, кыяларга күтәрелүнең мең газабын кичәргә, үз күңеленә җыела башлаган яшенле һәм күк күкрәүле давылларның һәммәсенә дә риза, риза, риза иде. Тик ничек тә егылып төшмисе, ә шунда, кояш янында каласы иде.

Ул, бераз нишләргә белмичә басып торгач, ишегалдына чыгарып ташланган әйберләрне өйгә — элеккеге урыннарына ташып куярга кереште.

### Ундүртенче бүлек

Ике көннән соң, кичке сәгать алтылар тирәсендә Мөкатдис Аитка хат кертеп бирде. Үрелеп алганда хат күбәләктәй җиңел, җиңел генә түгел, ә бөтенләй авырлыгы да булмаган пөхтә бер кәгазь кисәге генә иде. Башта ул ирен чите белән генә елмаер-елмаймас төстә: «Сөмбелдәндер», — дип кенә уйлап куйды. Конверт күнегелгән зурлыкта түгел, ә озынча һәм тар иде. Аның тышына күзен йөгертүгә үк, — әйтерсең лә Мөкатдис аның кулына хат сузмаган, ә очлы башы белән без сузып, ялгыш учына чәнчеп алды, — Аит кискен генә итеп аңа карап куйды, гүя кыя күкрәгендә асылынып торган җиреннән бауда үзеннән соң килгән альпинистның «Саклан — елан!» дигән боерыгына буйсынып, күз алдындагы бер уч үлән арасыннан маңгаена текәлеп торучы агулы еланның салкын карашы белән очрашты. Кайчандыр чигәсенә бәс инәләре шикелле беренче чал чәч бөртекләре сибеп куйган ул елан, аңа кизәнгәндә ялгыш пычак тиюдән өзелә башлаган репшнурдай зыңлап, Аит күңелендә асылынып торган үткәннәрнең күзенә текәлде. Иң әүвәл ике көн элек үзе белән сөйләшеп утырган Мөкатдиснең Солтания атасы — үзенә «бабай» тиешле кеше икәне исенә килеп төште. Буш гипс мәчегә маңгаендагы тар ярыгыннан биш тиен бакыр акча килеп төштемени. Нәкъ менә шушыны аның хәтеренә төшерергә теләгәндәй, Мөкатдис, гадәти булмаганча кыюсыз, шуны искәртергә туры килгәне өчен оялып, җитмәсә элгәре үзенә кияү тиешле кешенең үзен танымавына бик эче пошкан кыяфәттә хәзер икесенең дә бер-берсенә шушындый хәлдә калуларына уңайсызланып һәм үкенеп, бәләкәйләнеп бетеп, коелып, ниндидер тирән бер сагыш белән тулып Аит каршысына баскан да, әле хат сузган кулын да төшермичә, түзем белән генә үзенә рәхмәт әйтүләрен йә хушлашып кул сузуларын көткән шикелле басып тора иде.

Хат Солтаниядән иде.

Үзәкләрне өзәрдәе, бәгырьләрне кисәрдәе хатның аннан булу, аларны үткәннәренә алып кайтучы бауны ике арадагы төпсез упкын аша әүвәл Солтаниянең ыргытуы, ике йөрәк арасындагы кап-караңгы тынлыкта башта аның авазы яңгыравы гына да түгел, иң авыры үз каршындагы Мөкатдиснең, бу хатта язылганга караганда да күбрәкне белгәнен сиздереп, почта йөгеннән аз гына янтаебрак, шул ук вакытта иңенә төшкән теләсә нинди авырлыкны сабыр гына күтәреп тора алачагын белдереп басып торуы иде.

Аит, хатны кояшка каршы куеп, кай яктан ачарга кирәклеген чамалап карады да, конвертның читен чеметеп ерта башлады.

— Солтаниядән, — диде ул, бу сүзенә Мөкатдиснең үзенә кем булуын таныганын да белгертәсе килгән мәгънәне салырга тырышып.

Кояшка караганда ук ул хатның кыска язылганын белеп алды. Уң як аскы почмагына ике йон йомгагы белән уйнап утыручы зәңгәр песи баласы төшерелгән буй-буй сызыклы шома кәгазьгә берничә генә сүз язылган иде. Тәкатьсез рәвештә сусагач, краннан стаканга агызып, суның тәмен авызына якынайтканчы ук күзе белән тойгандагыча, Аит ул сүзләрне мәгънәсе аңына барып җиткәнче үк укып йотты.

*«Якыным Аит!*

*Авылыбыздагы өебезнең алмагачлары теге елны салкын тиеп корып беткәндер инде. Көзен яңа алмагачлар утыртасы булыр инде, әйеме?*

*Солтания».*

— Яраса, миңа да укы әле, — диде Мөкатдис карлыккан тавыш белән һәм, тыңларга әзерләнгәндәй, сумкасының бавын җайлабрак куйды.

— Ярый, нигә ярамасын! — диде Аит, көр тавыш белән. Югартын бар нәрсәне изеп, сытып, ватып, чәрдәкләп, әвәләп ишелеп төшкән кар ташкыныннан кыяның тар кыегы астына елышып, үзе аша уздырып - җибәргәч, бөтен күкрәге белән тауның сыек һавасын сулап алдымыни. Аның хәттә: «Ярый, ник ярамасын, бабай!» — диясе килгән иде дә — теле тыелып калды.

— «Алмагачлар корып беткәндер, көзен яңаларын утыртасы булыр инде, әйеме», — дигән...

— Утыртасы булыр, ник утыртмаска ди! Тел төбе ачык ук түгел түгелен...

— Нәрсәсе?

— Әллә миңа гына утыртырга кушкан, әллә үзе белән бергәләшеп...

— Сиңа, Аит, — диде Мөкатдис. — Берүзеңә. — Һәм ул, йөге авырлыгына чыдап-чыдап та түзә алмагандай, капка баганасына сөялде дә шуның буенча аркасы белән шуып, җиргә сыерылып төште. — Солтания... бүген вафат булган ул бичара. Без әнкәсе белән телеграмма алдык. Йөрәге... Йөрәге, кияү. Әх, әх!..

— Бабай... — дип ыңгырашты Аит. Авыл күгенә борчак кырыннан ашап кайтып килүче каргаларның шәүлә шикелле тып-тын көтүе килеп керде. Ул Солтаниянең үзен тагын бер мәртәбә «азат» иткәнен аңлап алды. Инде — мәңгегә. Ул аптыраудан, ни соң әле бу дип сәерсенүдән, мондый көтелмәгән, бу мизгелдә гадәттән тыш гайре табигый тоелган хәбәрне кабул итә алмыйча кулын җәеп җибәрде, әйтерсең лә аның алдына чиксез ераклыктан бер алма очып килә, аның шул алманы тотып алып, яланаяк һәм күлмәге суга чыланып беткән, маңгаеннан борчак-борчак тир бәреп чыккан Солтаниягә бирәсе килә. Ул аны тирле учы

белән сөртеп куяр иде, елмаю белән тулы иреннәрен ачып җибәреп, тешләренең ак балкышын алма суы белән сүндерергә ашыккандай, дәү итеп бер тешләп алыр иде, һәм аның күкрәгендә җемелдәгән эре тир тамчылары белән ирен кырыеннан ияк очына сузылып төшкән, ә аннан күкрәгенә тамган алма суы бергә кушылыр иде.

Ә менә хәзер шул татлы һәм тозлы Солтания истәлегенә Аитның саран күз яше дә тамып төште бугай.

Бугай...

Юк, Аит каршына чиксез ераклыктан алма түгел, ә бәлки эченә кырлы-мырлы таш тыгып куелган иске туп очып килә иде бугай. Ул, үзәкләре өзелеп, аның үз күкрәгенә килеп бәрелгәнен көтеп калды. Бик күптән, инде әллә кайчан, Аит әллә бар, әллә юк чагында ук ул туп Нурисламга тимичә калган иде — тез астын озынборын тешләп, ул кинәт җиргә чүкте дә туп, аның башы очыннан гына үтеп, яшел чирәмгә барып төште.

Ә хәзер ул туп Аитның гомер орбитасын комета сыман әйләнеп үтте дә кире әйләнеп кайтты. «Ул туп — мин үзем, — дип уйлады ул. — Кая очам, күпме вакыт, кемгә төбәлгәнмен? — дип сорады ул үз-үзеннән һәм җавап бирде: — Үз-үземә табан очам, снаряд кебек төшеп шартлаганчыга кадәр, шушы бишегемә — нәселебезнең иске, ләкин изге нигезенә кылган хыянәтемә төбәлгәнмен».

Һәр кешенең бишеге бер генә — Җир шары.

Ул урам буенча әлеге күк җиселе буенча барган җигүле атны үзенең күз карашы белән озатып калды. Җигелгән атларның берсе дә Трояатлары түгел.

Бөркетләрнең ояларын
Ташлар иште түбән.
Кайда син?
Ишетәсеңме:
бу — минем тәүбәм...

— Сине Солтаниянең атасы белән анасы көтеп калды, Аит... Кичке самолетка өлгерәсез әле.

Күкләр тыныч иде. Ә йөрәк, йөрәк...

*1981*

## КҮЗЛӘРЕМНЕ ТУТЫРЫП

*Ике пәрдәле, сигез күренешле драма*

Катнашалар:

Мөхәммәт — хәрби хезмәттән яраланып кайткан егет.
Акчура — аның атасы.
Гөлҗиһан — анасы.
Хәдичә — Мөхәммәтнең сөйгәне.
Исхак — Хәдичәнең атасы.
Баян — анасы.
Камал — хат ташучы.
Майор.
Полковник.

Безнең көннәр.

### БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

#### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Авыл. Читән буе. Яз.

Мөхәммәт. Яшен яшьни, күк көлтери.
Хәдичә. Яшен. Көлтери.
Мөхәммәт. Ышыккарак барыйк мәллә?
Хәдичә. Бармыйк.
Мөхәммәт. Шушылай торыйкмыни?
Хәдичә. Шушылай.
Мөхәммәт. Ява башлады.
Хәдичә. Башласын.
Мөхәммәт. Бәлки, минем сине кочасым киләдер. Беренче мәртәбә. Соңгы тапкыр.
Хәдичә. Читән шыгырдар.

Мөхәммәт. Шыгырдаса әллә!
Хәдичә. Кеше ишетер.
Мөхәммәт. Кем?
Хәдичә. Әнә сандугач сайрый.
Мөхәммәт. Сайраган сандугач ишетми.
Хәдичә. Йөрәге тыңлый.
Мөхәммәт. Тынды бугай. Тыкрыкка керик инде.
Хәдичә. Керик. Тыкрыкка.

Юнәләләр. Мөхәммәт сигарет кабызып тарта.

Мөхәммәт. Төтен. (*Читкәрәк авышып.)* Йокмасын.
Хәдичә. Тын.
Мөхәммәт. Яңгыр басыла. Бугай.
Хәдичә. Аҗаган уйный. Торып тор әле.
Мөхәммәт. Нигә?
Хәдичә. Әнә күк капусы ачылды.
Мөхәммәт. Теләп өлгердеңме?
Хәдичә. Өлгердем. Теләп.
Мөхәммәт. Ни дип?
Хәдичә. Син дип.
Мөхәммәт. Мин?
Хәдичә. Син.
Мөхәммәт. Суң?
Хәдичә. Чыкмыйм дип. Сиңа.
Мөхәммәт. Бу теләк түгел.
Хәдичә. Ни?
Мөхәммәт. Ният. *(Тынлык.)* Нигә эндәшмисең?
Хәдичә. Ай ачылды. Чирек. Янында йолдызы да бар.
Мөхәммәт. Ай ялгызы йөрми.
Хәдичә. Йөрми. Ялгызы.

Тынлык.

Мөхәммәт. Алайса мин китәм инде.
Хәдичә. Ә читән?
Мөхәммәт. Шыгырдамасын.

Әкрен-әкрен, теләмичә генә аерылышалар. Мөхәммәтнең җырлаганы ишетелә:

Ал шәфәкъ батканда,
Сызылып таң атканда
Күзләрем тик сине эзлиләр...

Хәдичә *(тыңлый, елмая, моңаеп).*

Яңгыр тамчылары булып,
Керфегеңә тамармын мин...

**ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ**

Җәй. Чиллә. Авыл. Ишегалды.
Әтәч кычкырып, эт өреп куя, трактор-фәлән тавышы ишетелә, бәлки, мәче мияулап аладыр, бала-чага көлгәне яңгырыйдыр; кыска-сы, авыл
иртәсе.

Гөлҗиһан *(келәт ишегеннән торып, бодай сибә).* Кыт-кыт-кыт...
Акчура *(пычак кайрый, аны әле тырнагына сызып, әле мыек очына тигезеп үткерлеген чамалый).* Кыт-кыт дип... Теге симез тавыгың кыртлаган. Мәмүк Гөлсемемени!
Гөлҗиһан. Көнче ул.
Акчура. Тавыкмы? Нәрсәне? Кемне?
Гөлҗиһан. Сине. Мәмүк Гөлсеменнән.

Акчура *(ян-ягына каранып, таптанып куя).* Алайса нит... шул кыртлый тавыкка тагын берсен тотып куш та... әгүзе бисмиллаһи итим. *(Өйгә таба тын гына ишарәләп.)* Уянганчы.

Гөлҗиһан. Хәзер. *(Югалып тора. Тавык кыткылдаган, әтәч кычкырган, мәче мияулаган тавыш. Чыга.)* Мә. *(Аяклары бәйле ике тавык суза, өйгә ымлап.)* Ул — уяу.

Акчура. Бая караганыем. Йоклап ятадыр шикелле ие. *(Өйдә радиомы, телевизормы тавышы ишетелеп ала да тына, гитара аккорды зыңлап куя.)* Әллә, минәйтәм, сиңа бүген чөгендергә чыкмаска микән?

Гөлҗиһан. Чыгасы.

Эңгердән болдыр ишеге яктылыгында Мөхәммәт күренә.

Акчура *(тавыкларны күтәребрәк).* Ниттем ди. Ә аннары боларны кем кеше итә суң? Син — чөгендердә, мин — әллә кайда...

Гөлҗиһан китмәнен, аш-су салынган төенчеген барлый.

Гөлҗиһан *(каядыр еракка, әллә кая карап, моңсу төстә, кемдер ишетмәсен шикелле итеп).* Суелганны кем йолкысын, пешекләсен, киссен дә турасын... бөтен итеп... табынга куйсын соң инде? Ир-ат суя, сугыша гына белә. *(Капкадан чыгып китешли.)* Монда күз-колак буласы, яме! Озак тормам. *(Әллә шук, әллә моңсу итеп.)* Кирәгенә өлгерермен. *(Чыгып китешли.)* Нишләрбездер инде, Ходаем.

Акчура. Шул шул менәтерәгенәк, нишләрбез икән. Авыры ир беләгенә төшә ул. *(Көйләп.)* Нигә тала... нигә тала... икән минем... беләгем... Онытылганда бер талгалап куйгалый инде анысы. Беләгем. *(Бакча капкасын ачып кереп китә.)*

Мөхәммәт, чыгып, болдыр баскычына җайлап утыра.

Мөхәммәт *(кулындагы мәчене сыйпап, аның колак артын, ияк астын кашып).* Нихәл, Маракуйа? Нишләрбез икән диләрме? Бернишләмәбез — яшәрбез... Беләк нәрсә ул? Йөрәк кирәк. Әйеме?.. Мин югында күпме күсе бандформированиесен туздырдың? Әллә чыпчыкларны гына узындырдыңмы? Нишләсәң дә, тәпиләреңнән кан яламагансыңдыр әле, әме? Мин торган рота ике көн буена БМП тәгәрмәчләрендәге кеше канын юды. Башта теге яктан аттылар ич. Караңгы иде. Күренми. Сыттык та ары киттек.

Суелган ике тавык тотып, бакча капкасыннан Акчура керә. Капка боргычын бикли дә сугым пычагын бүрәнәгә ышкып чистарта. Ташка тамган канны ни белән сөртергә аптырап тора, тапмагач, тавык
канаты белән ышкып сөртә.

Акчура (*Мөхәммәтне тоеп, аркан торып, чүгәләгән килеш).* Утырасыңмыни?

Мөхәммәт эндәшми.

*(Болдыр ишегеннән узышлый, мәчегә.)* Монда... ялагайланып утырма әле, малакасус, энеңне борчып. *(Тавыкларның идәнгә йомшак кына, тик тынлыкта үле шапылдап төшүе, мәче кычкырганы, су аккан тавыш ишетелә.)* Пеәрс! Эче-башы сиңа инде, сиңа! Безгә генә ул (*үзенә пышылдап, тик ишетелә*) сөяге генә...

Мөхәммәт *(үзалдына уйлаган уе).* Сөяге генә. Коры сөяк... күзле бүкән.

Битен, кулын иңенә салган сөлгегә сөртенгәләгән Акчура күренә.

*(Акчурага.)* Мин мәчегә энемени?

Акчура *(сүз ачылганга куанып).* Эне генәме суң? Син аның каршында... ни... бишектә имезлек имеп яткан... малакасус кына!

Мөхәммәт елмаеп куя.

Ышанмыйсыңмы әллә? Бу Маракуйага уналтынчы яшь китте. Кеше гомеренә... чагыштырып исәпләгәндә, аңа бүген иң кимендә җитмеш өч яшьтә *(бармакларын бөгеп саный)*... унҗиденче көн.

Мөхәммәт *(сак).* Ә сиңа чагыштырганда?

Акчура. Миңамы? Әйтәм ич, малакасус әле ул! Мин күргәнне кичерсә, күз ачырмасые, у-у, мул кыргыры.

Мөхәммәт. Нигә «мор» түгел, ә «мул»?

Акчура. Үрчесен, мул китерсен. Мәчегә үлүе җиңел ул, кешеләргә яшәве авыр.

Мөхәммәт. Нигә?

Акчура *(янәшәсенә утыра).* Тартып алыйкмы әллә?

Мөхәммәт. Ә мәче?

Акчура *(үзе дә сизмәстән).* Ул тартмый. Әлегә.

Мөхәммәт. Алайса мин дә тартмый торам. Әлегә.

Акчура *(учы белән баскыч тактасын сыйпап)*. Җылы монда.

Мөхәммәт. Сездә быел җәй әйбәт килгән икән.

Акчура. Сездә? Икән? *(Кинәт сискәнеп куя, сүзне бүтәнгә борып.)* Теге атнакичне генә мин моны *(мәчегә ымлап)* төбәк муниципаль үзәгенә аппарганыем әле.

Мөхәммәт. Иптәшкә ияртепме?

Акчура. Иптәшкә әйбәт иптәш инде ул анысы... Лечебницага.

Мөхәммәт. Нигә?

Акчура. Ниенә... муенына әллә ниткән шеш бәреп чыккан күк тоелганые. Җарамаган бер-бер нәстә ашаган булгандыр инде, күз көеге. Моны шундук чыр кычкыртып... мияулаттырып, операциягә салдылар. Шуңа йөз дә илле җиде тәңкә ниттеләр... түләттерттеләр.

Мөхәммәт. Савыктымы соң?

Акчура. Үзеннән сора. Мырлый икән — тере. Ие! Тиктормастан көпә-көндез йөз дә илле җиде тәңкә түләттерттергәч, савыкмыйча кая китсен ул!.. Әле кичәгенәк инештән беләк шайлы бер бәртәсне авызына аркылы капкан килеш кайтып керде. Мәче генә түгел — дию пәрие ул! Әнкәңә ятышсыз бер-бер ни-мазар нитсәм... сүз!.. инде сүз генә... ычкындырсам, бу күзгә бер генә кырын карап куючан да... өнемнән яздырган мәлләре еш булгалый. *(Күз яшен сөртеп ала.)* Бик. Шуннан соң төннәр буена күземнең керфегенә-керфек какмаенча тоташлый очкылык тотып чыгам инде. Чыкмый кая китәсең? Нинең ни икәнлеген *(мәчене болдырга кагып кертеп җибәрә)* бу эзбир үзе... нитәдер инде, күрәсең. Мәче ич, андый-мондый кеше-мазар ише нәстә генә түгел.

Мөхәммәт *(кинәт, кырыс төстә)*. Тимерче Сөләйман абый эшлиме әле?

Акчура *(шулай ук кинәт җитди, сәерсенеп)*. Эшли. Эшләмичә нишләсен! Җәһәннәмгә китсен мәллә!

Мөхәммәт. Ул пенсиядә ич инде... дер...

Акчура. Дер шул. Дер-дер калтырап, пенсиясен учлап ятсынмыни? Эшли. Әйе!

Мөхәммәт *(чалбар кесәсеннән алып, акча суза)*. Миннән диярсең.

Акчура *(ала, әйләндерә-әйләндерә карагач)*. Файв долларс! Безнеңчә... *(уйлап торгач)* өч йөз тәңкә!

Мөхәммәт. Ярдәмчесе Әнвәр абый исән-саумы?

Акчура. Ул вафат. Былтыр җирләдек.

Мөхәммәт. Урыны оҗмахта булсын.

Акчура. Әмин. Шулай булсын.

Мөхәммәт *(акча бирә)*. Хатыны Тәнзилә апага.

Акчура *(бармак очын төкреклэп саный, шаккатып)*. Тэн долларс! Безнеңчә... ни *(бармагында исәпләп)*... тәңкә!

Мөхәммәт. Санама — таркатырсың. *(Акча бирә.)* Бусын һәммә әби-чәбигә ак шәльяулыкка диярсең.

Акчура *(инде битараф төстә)*. Уан хандрид долларс! *(Санамыйча.)* Бусын әнкәң өләшер. *(Сагаеп.)* Ә миңа... әнкәңә... ике сеңлеңә... төпчегебез энекәшеңә?

Мөхәммәт. Сезгә — мин.

Акчура. Безгә син дә бит... *(Акчаларны анда-монда авыштыргалап.)* Боларны каян ниттең... алдың?

Мөхәммәт. Минем кайдадыр... башта аунап, аннары суң җыеп... яндырылган сул кулым белән уң аягым курыкмый. *(Тынлыктан соң, кычкырып.)* Инде! (*Әкрен, иренен кысып.)* Курыкмый. Кичә кайтышлый зират турысыннан узганыем, әти. Коймасы буйдан-буйга тузган, йә авышкан, йә ауган икән. *(Тагын акча суза.)* Шуны очтан очка яңадан корасы.

Акчура *(ала, югалып кала)*. Файв хандрид... ертит-вертит долларс!

Мөхәммәт. Каян беләсең?

Акчура. Язылган ич.

Мөхәммәт. Язылыр ул. Ничек укып таныйсың?

Акчура. Латинча ич. Латин — безнең канда. *(Аркан борылып.)* Җанда. Теләгән шәттә мөнгесен дә, юан дигәнен дә чамалыйбыз аның.

Мөхәммәт. Арттырасың.

Акчура. Киметмим дә. Минем әти — синең бабаң — гвардия капитаны танкист Җәмлиханов фронттан хатларын шул-шул хәрефләрдә, шул-шул җирләрдән язган. Шулай язмаса, мин бу дөньяга каян килерием! Ә? Мин синнән «каян килерием» дип сорыйм! *(Тынычланып, кесәсендәге, учындагы акчага ишарәләп, җитди.)* Боларны сиңа кем бирде?

Мөхәммәт *(кырыс)*. Сугышта акча бирмиләр.

Акчура. Нишлиләр?

Мөхәммәт. Сөләйман абыйга дигәне — Псковтан Медведевныкы. Әнвәр абый... Тәнзилә апага дигәне — Алтай батыры Борынтайдан. Әбиләргә дигәне — якут егете Лугвинев исеменнән. Мәрхүмнәр... зиратка дигәне...

Акчура сагаеп кала, телендәген әйтә алмый тора.

*(Аңа карап, елмая төшеп.)* Миннән түгел. Әлегә. Минем өлешем Псковка, Алтайга, Якутия... әйе... Сахага китте.

Акчура *(кырыс).* Шулай... ниттегезмени... алмаштыгызмыни?

Мөхәммәт *(үтә гаҗәпсенеп, сәерсенеп, җавап бирә алмастай кыяфәттә).* Нәрсәне, эти?

Акчура. Каберләрегезне, улым... ядрит-виртит... файв.... хандрид!

Мөхәммәт *(җиңел сулыш алып).* Кадерләребезне.

Акчураның нәрсәдер әйтәсе, нидер сорыйсы килә. Ул, аны-моны җыйнаштырган, җайлаган булып, ишегалдында йөренә-йөренә дә капылт туктап ала, уй уйлап куя, тагын нидер эшли, тавык-чебешләрне әле чакыргандай, әле кугандай итә.

Акчура. Ниме? Бер сорау бирсәм, нитәме-юкмы дигәндәй... Карасана инде! Ата кешене үз улына бер сорау бирергә гаҗизләнү көненә калдырсыннар әле, ә! *(Мөхәммәткә арканмы, кырынмы хәлдә кинәт туктап.)* Сине кем болай... нитте? Тегеләрме?

Мөхәммәт *(сабыр төстә).* Түгел.

Акчура. Алты дистәдән артык хатыңда бу ниең... хәлең хакында ым да югые. Әйе, кем сине... болай нитте? *(Басым белән.)* Алармы?

Мөхәммәт *(тыныч).* Түгел.

Акчура *(сак).* Алайса... кем?

Мөхәммәт *(нык рәвештә).* Болар.

Акчура *(шаккатып).* Кем ул — болар?

Мөхәммәт. Тегеләр түгел. Шул гына.

Акчура *(Мөхәммәтне, бар дөньяны ничек кочакларга белмичә).* Бөтен улыма — шушымы, «шул гына»-мы?

Мөхәммәт. Шушы гына. *(Аркан үрелеп, песине кулына ала.)* Әйеме, песи?

Акчура *(ни әйтергә белмичә, тәмам аптырагач).* Ошбу акчаң... кушканыңча...

Мөхәммәт. Әйткәнемчә...

Акчура. ...Кушканыңча тапшырылыр, Алла теләсә. *(Болдырга кереп чыга, мунча басмасында яткан балтаны ала, күнеккәненчә үткерлеген чамалый, аны букәнгә каптырып чыгып китәсе дигән мәлендә туктап кала.)* Ә бу *(басым белән)*... боларга БМО ничек карый соң? Өстәп... Нәстә әле... совет безопасности? Фэсби?

Мөхәммәт. Карамый.

Акчура. Нитмәскә... карамаска, күрмәскә ичмаса синең ишеләрне! Сәбәпләре бармыни?

Мөхәммәт. Сугыш, эти. Бернишли алмыйлар.

Акчура. Берсе-берме?

Мөхәммәт. Кайсысы? Алар күп.

Акчура. Анда... син әйткән *(акча капшый)* Псковтыр... Алтай, Магадан, Карачай, Балкар *(глобус әйләндергәндәй хәрәкәт ясап)*... тагын кайда, кем... күп... бөтенесен бер Чечнәгәме? *(Уң кулының имән бармагы очын карап.)* Уймакка бармак очы гына сыя. Ә һәр бармак *(бармакларын уйнаткалый)* уймак алмас. Ә сез... бер яккан мунчагызга ата — кызын, ана улын белмәстәй көтү-көтү керәсез. Бер генә нәрсә... башы, әйе!.. сыярлык урынга... Ал да гөл — берәү генә ул. Бердәнбер кендегең чокыры шикелле. *(Мәгънәле итеп.)* Кеше ике кендекле булалмый! Ана тулгагы мең нитсә дә... тотса да.

Мөхәммәт. Үлгән солдат үлгәч, берәү генә була. Үлгән солдат — дембель. Азык-төлек исәбеннән сызыла.

Акчура *(ни әйтергә белмичә аптырагач).* Шулай... берәм-берәм үзара кырылышуларны нигә туктатмыйлар соң ул?

Мөхәммәт. Генераллар кушмый.

Акчура. Генераллар?.. Кронштадта хезмәт иткәнем чагында минем дус ике адмиралым бар иде: берсе — каптерщик Җаникян да, икенчесе — кок — Шәмәрдән җегете Салихҗан. Өченчесе — үзем *(честь биреп куя)*: Балык Бистинскидан старшина третьей статьи — Шаймурзин. Шулай... штурмыдамы, штильдәме... сугыш-нитеш уеннарыннан соң благодарныст алгачыннан ары өчәүләп... ниткәли иек тә чираттагы палундырага хәтле үк иртән-иртүк уянышып торгачыннан соң, очраклы рәвештә генә очрашып... тәүбә итешәдериек. Безнең нәрсә... эш кечкенә: фарватер билгеле, бакеннар, буйлар үз урыннарында чагында кингстоннар

*(тамак төбенә чиртеп ала)* — суны кертү, чыгару юллары инде — ябык була торганые... А! Тегеләргә болары кушмый, имештер. Без кушсакмы? Шуңа безнең каперанг керәшен Апушев та кушылсамы? Әйтәм ич: кингстоннар ябык, фарватер ачык — Кронштадтан бөтен Мәскәүләреңне аркылы-буйлыга үтә-үтә Тихий океандагы Татар бугазындагы братваларга тиклем. Бер капитан третьего ранга безнең Кронштадтан крейсер белән юлга чыгып... кем әле... Брежневка ультиматум куеп караганые каравын. Тыңламадылар гына. *(Кайнарланып.)* Хәзер әрмән Җаникян белән Шәмәрдәннән Салихҗан, өстәп, мин Акчура юк шул *(сүрелеп)...* инде. Кушып, каперанг Апушев та... Кингстоннары вакытсыз-нисез кирәккә-кирәкмәгәнгә ачыкларның төп ниятен без би-ик — бә-ә-әк! — чамаладык аны чамалавын. Идек. Ни хәл итмәк кирәк: биш-алты тапкыр минем үземә дә — хәтта минем! — гауптвахтада өчәр тәүлек буена коры су эчеп чыгарга насыйп иткәние, Алла рәхмәте. Биш елга җыенысы җитмеш өч тәүлеккә җыйналды... Әстәгыйфирулла тәүбә, тәүбә... *(Чыгарга барган җиреннән туктап кала.)*

Мөхәммәт. Әти, карале.

Акчура. Әү, әү.

Мөхәммәт. Әти, минем бер унҗиде көннәргә барып киләсе җирем булыр.

Акчура. Ниткән унҗиде көн тагын?

Мөхәммәт. Кирәк инде. Унҗиде көннән соң... менә шушы ук җылы баскычка килеп утырырмын.

Акчура. Кайтып төштең генә ич әле! Аңынчы кайда булмакчысың?

Мөхәммәт. Шулай килешенгән.

Акчура. Ярар. Үзең беләсеңдер тагын. Бөтен ил мәдрәсә, ие: сезгә — ите, безгә — сөяге. *(Чыгып китә.)* Әйдә, Акбар, авыл хуҗалыгы җитештерү ассоциациясе хуҗалыгын нитеп... барлап кайтыйк әле. Карале, ә, Акбар, файвтэн долларс...

#### ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Тынлык. Еракта трактор авазы, бала-чаганың көлешеп узып киткән тавышлары ишетелә.

Мөхәммәт *(уе).* Сеңелкәшләр мәктәп бакчасында чүп утыйдыр инде. Төпчек энекәш — үзе беләдер. Әни — чөгендердә, әти тере бармакларын язмактадыр. Тимерчелектә. Сөләйман абый белән. Яхшы.

Болдыр баскычыннан тора, төшә. Сул кулы — протез, уң аягы тездән бөгелми, анысы да протез бугай. Ишегалдын, агач ябалдашларын, күк йөзен күздән кичергәч, келәткә кереп китә, аннан бер калай чиләкне тибеп очырып чыгара. Үзе күренеп басмадан төшкәч, ул әлеге чиләкне
ала.

Төбе юк. Чиләкнең дә *(басым белән)* минем... безнең дә. *(Чиләкнең төшкән төбен җайлагач.)* Кирәктер инде, күрәсең. *(Чиләкне келәт ишегенә ата. Үзе дә шунда кереп гармун тотып чыга. Уйнаган була. Көйләп.)* Күзләремне тутырып... Чыкмый. *(Гармунны үбеп.)* Хуш. *(Эчкә ыргыта.)* Әйе, хуш.

*(Мөхәммәт утын пүләненә чабылган балтаны ала да, үткерлеген чамалагач, читкә куя. Аннары мунча алачыгыннан калун алып чыга, сыңар уң кулы белән кочаклап алып, бүкәнгә утын пүләне куя. Аны ярып бетергәч, берсенә соңгы тапкыр бәрер алдыннан тоеп, сагаеп, калунын күтәргән килеш кала. Күз кырые белән үткер карап.)* Синме?

Көз. Авыл.

Мөхәммәт. Кызлар сайлап йөрүне өнәмәдем.

Хәдичә. Шулай тоелгандыр инде. Тоелган гынадыр.

Мөхәммәт. Берзаманны — коры көзнең инде дөм караңгы кичендәме, төнендәме соң — мин сине капка төбегезгә хәтле озатып куйганыем.

Хәдичә. Чикерткәләр зыңын хәтерлим.

Мөхәммәт. Әйтәм ич, кызлар сайлап йөрергә җае килмәде.

Хәдичә. Гармунчы сайлый димени, җүләр?

Мөхәммәт. Нишли?

Хәдичә. Бернишләми. Уйный гына. Аны кызлар сайлый.

Мөхәммәт. Шулай инде. Гармун уйнаганда беркем күренми. Күп карансаң, телләренәме, төймәләре, бакаларынамы ялгыш басуың ихтимал ич. Ул чагында биючеләрнең аяк җае бозыла.

Хәдичә. Ә йөрәк көе? Кемнеңдер. Гармунчы иң шәп уйнаганы мәлендә.

Мөхәммәт. Бәлки. *(Көйләп.)* Гармунчының бармаклары...

Хәдичә *(кушылгандай итеп, тик сыкрап).* Саен мәхәббәт аның...

Кайдадыр җырлыйлар бугай:

Суда, суда, суда йөзаласыңмы,
Мин сине күрми түзалмыйм,
Ә син түзаласыңмы...

Койма буе. Чәче.

Хәдичә. Без алып бетердек инде.

Мөхәммәт. Безнеке биш-алты буразна чамасы калды әле.

Хәдичә. Бетә лә ул.

Мөхәммәт. Калмас.

Хәдичә. Бәрәңге сабакларын киптерергә чәчегә куйдык. Кирәсеңме?

Мөхәммәт. Монда утырырга бүрәнә бар ич.

Хәдичә. Күлмәгем юка. Бүрәнә каты ул. Анда җылырак та.

Мөхәммәт. Ышыктыр да.

Хәдичә. Ышык. *(Бакча капкасының боргычын ача.)* Сабакларның чәчедән артканын эчкә җәеп салдык.

Мөхәммәт. Безнеке койма башларында.

Хәдичә. Кирәге шул тиклем генәдер. Кер, кер. *(Әйдәп кертә.)* Капканы яп.

Мөхәммәт. Яхшы. *(Керешли миләш тәлгәше өзеп ала. Чәче куышына узалар. Бәрәңге сабакларын җыйнаштыргалап.)* Утыр.

Хәдичә. Ятуы иплерәк.

Утырышалар.

Мөхәммәт. Исе тәмле.

Хәдичә. Синең чәчең исе ул. Үбим әле.

Мөхәммәт *(сәерсенеп).* Кемне?

Хәдичә *(тыенкы көлеп).* Сине.

Мөхәммәт. Нигә?

Хәдичә. Китәсең ич. Ике елга. Әллә кайтасың, әллә каласың.

Мөхәммәт *(миләш каба).* Әче. Ярмаланган инде.

Хәдичә. Дәшмәле. Дәшмәсәнә инде.

Хәдичә башлап үрелгәч, үбешәләр.

Мөхәммәт *(тын алып).* Гармун кала инде.

Хәдичә. Син уйнаганда, мин биемәдем бит.

Мөхәммәт. Син биегәндә, мин уйнамадым.

Хәдичә. Яратасыңмыни?

Мөхәммәт. Сөям.

Хәдичә. Әү, әү! Тагын әйт әле.

Тынлык.

Моңарчы ниме дип әйтмәдең соң?

Мөхәммәт. Аны әйтмиләр.

Хәдичә. Нишлиләр?

Мөхәммәт. Бернишләмиләр. Сөяләр генә.

Хәдичә. Генә?

Мөхәммәт. Генә.

Хәдичә. Хәтереңдәме?

Мөхәммәт. Нәрсә?

Хәдичә. Кармакка балык тотканда иң зурысын миңа биргәнеңне.

Мөхәммәт. Исемдә. Алганыеңмы соң?

Хәдичә. Синнәнме? Тиргә баткан, кояшта пешкән, янган, сусаган, чат сипкелле, кара трусикчан гына. Иренең кипшеп яргаланган, чәчең, каш-керфегең сап-сары, кушаматың — Сары Пышлак. Ямьсез, килбәтсез... Синнәнме балык? Зур!.. Син үпкәнне дә үбә белмисең. Ич! *(Үбә, кочаклый, үзенә яткыра.)*

Мөхәммәт. Юк.

Тынлык. Утыралар.

Хәдичә. Яратам дигән буласың тагын!

Мөхәммәт. Тагын? Мин аны бер дә әйтмәдем әле.

Хәдичә. Нәрсәне?

Мөхәммәт. Шул сүзне.

Хәдичә. Ул... сүзмени?

Мөхәммәт *(кочакларга ясканып, тик сабыр төстә).* Ул — син.

Ниһаять, кочаклашып тын калалар.

Хәдичә. Синең күз яшең кайнар. Икән.

Мөхәммәт. Син дә күз керфекләреңне чылатма. Инде.

Ишегалды.

Хәдичә. Мин. Исәнме.

Мөхәммәт (*калунны сөяп куя, аркан торган килеш).* Саумы?

Хәдичә. Таныйсыңмы соң?

Мөхәммәт. Карамадым ич әле.

Хәдичә. Карама. Күзеңне талдырып... Мине яшен сукты.

Мөхәммәт. Беләм.

Хәдичә. Мине кичә көттеңме?

Мөхәммәт. Кичә генә түгел.

Хәдичә. Килә алмадым инде. Мин төнлә яхшырак күрәм анысы. Рәшит абыйларның этеннән шикләндем. Аның өргәне яшелле-зәңгәрле. Алама төс. Капка асларыннан дөбер-шатыр чыгып мине куркытты. Мин икәнен белгәч, кереп качты тагын.

Мөхәммәт. Син икәнлекне ул каян белә?

Хәдичә. Көн саен диярлек йөргәнгә күрәдер.

Мөхәммәт. Көн саен... алай итеп... төннәрен кая йөрисең?

Хәдичә. Көн саен түгел инде анысы. Диярлек дидем ич. Болай... байтак кына инде. Төшләремә кергән саен.

Мөхәммәт. Кем?

Хәдичә. Син.

Мөхәммәт. Ни җитми?

Хәдичә. Җитә. Инде җитә... бугай. Син кайттың.

Мөхәммәт. Мин түгел.

Хәдичә. Син ич — күрәм.

Мөхәммәт. Мин. Тик син... әүвәлгемне күрмисең инде.

Хәдичә. Күрәм.

Мөхәммәт. Мин беркемгә язмадым.

Хәдичә. Нәрсәне?

Мөхәммәт. Үземне.

Хәдичә. Белеп тордым. Күреп.

Мөхәммәт. Күреп?

Хәдичә. Сул кулың, уң аягың.

Мөхәммәт. Моны әти-әнигә дә... яздырттырмадым. Каян белдең?

Хәдичә. Белмәдем. Мине яшен сугып сукырайткач кына күрдем.

Мөхәммәт *(үтә сәерсенеп).* Нәрсәне?

Хәдичә. Күзең яшьле.

Мөхәммәт *(кырыс).* Алайса әйтеп бетер: теге күзгене ваткандагыча тозлымы, татлымы?

Хәдичә. Җанлы. Йә, борыл инде. (*Мөхәммәт Хәдичәгә таба борыла.)*

Исеңдә тот: минем кызгануымны көтмә.

Мөхәммәт. Ни көтим?

Хәдичә. Сөю дияр идем... Хәер, юк. Әйе, юк. Минем сине мәңгегә күрмәвемне көт. *(Аңа елыша.)* Кайттыңмы?

Мөхәммәт. Җибәрделәр.

Хәдичә. Кем?

Мөхәммәт. Ямьсез.

Хәдичә. Күзсезгә бөтен нәрсә матур.

Мөхәммәт. Мин матур яуларга кайтмадым.

Хәдичә. Матур эзләргә кайтмагач, ямьсезне нигә кочмыйсың соң?

Мөхәммәт. Кулым буш түгел.

Хәдичә. Куй.

Мөхәммәт калунны сак кына итеп бүкәнгә яткырып куя. Тик кочарга кыймый.

Хәдичә. Онытkансың.

Мөхәммәт. Онытмадым.

Хәдичә. Алайса нигә... үпмисең?

Мөхәммәт. Онытканмын. Теге читән буен. Мәңгегә.

Хәдичә аның ирененә үрелә, Мөхәммәт, сул кулы белән аның күкрәгенә ягыла, сыйпый, ягымлый. Ә бу — аның протез кигән кулы. Ул, шуны үзе күргәч, аңлагач, кисәк читкә атлый.

Чыгып кит!

Хәдичә. Ни булды?

Мөхәммәт *(тыныч сурәттә).* Чыгып кит.

Хәдичә. Ни булды суң? *(Мунча басмасындагы балтаны алып капшый.)*

Мөхәммәт *(соң чиккәчә тыныч).* Булмады. Чыгып кына кит.

Тынлык. Бәлки, әтәч кычкырып куядыр, тавык кытаклыйдыр, эт өрәдер, трактор-мазар узып киткән аваз ишетеләдер, тик... тынлык. Фәкать чикерткә зыңы гына ишетелеп тора.

Хәдичә. «Кит» дигәнеңне тагын кабатлыйсыңмы?

Мөхәммәт. Кояшка әйт.

Хәдичә. Ул мине күрми.

Мөхәммәт. Минем бу килеш... сиңа ни пычагыма кирәгем бар? Кит.

Хәдичә *(итәген җыйгандай итә, балта тоткан килеш нәкъ утын бүкәне турысына баса. Пышылдап).* Моннан соң... кит дигәнең саен... тагын дүрт тапкыр... шушылай булыр.

Аның үз чәнти бармагы очын чабып өзәргә дип селтәнгән балта йөзе астына Мөхәммәт сул кулын — протезын куеп өлгерә, күз ияр-мәстәй җәһәтлек белән балтаны тартып ала.

Мөхәммәт *(көлеп).* Чыннан да нык икән. *(Протезын карый.)* Әти балтасы да үтмәгәч. Бер кискән чабылмый шул... Кит.

Хәдичә *(югалып кала, ни әйтерен уйлап-нитеп тормастан, тиз-тиз).* Мин бүген Кызыл Елгага җиләккә менәм. Әни белән. Иярәсеңме?

Мөхәммәт *(протезын күлмәк җиңенә каплый, угалап).* Бу... син җәрәхәтләгән кул белән җиләк кенә җыясы инде. *(Кул сәгатенә карап ала.)* Бүген синең сәгать өчкә өегезгә кайтып җиткән булуың кирәк.

Хәдичә. Нигә?

Мөхәммәт. Кирәк.

Хәдичә. Кемгә?

Мөхәммәт *(сүз табалмый тора).* Яшәүгә.

Хәдичә. Мин яшим ич! Әле!

Мөхәммәт. Әйе. Минсез.

Хәдичә. Сәгать өч тулгач — синсезмени?

Мөхәммәт *(кырыс).* Күзсез.

Хәдичә. Нинди... күзсез? Мин — дөм сукыр!

Мөхәммәт *(тыныч кына).* Түгел.

Хәдичә. Ничек «түгел» булсын ди инде! Караңгыда сине генә күрәм ич!

Мөхәммәт. Яктыда мине күрмәс өчен сиңа күз кирәк. Бүген... сәгать өчтә өеңдә буласы. Ә сәгать уналты ноль-нольдә әйтерләр. Тыңла. Хәзер бар кит. Утын ярасым бар. Ир-ат эшләгәнне хатын-кызның карап торуы килешми.

Хәдичә нишләргә белми аптырый.

Чыгып кит! Минем җаным гына булса да ике түгел ләбаса! *(Уйланып.)* Булыр, булыр.

Хәдичә. Ни булыр?

Мөхәммәт. Белмим. *(Утын пүләненең ярылмый калган өлешен бүкәнгә куеп, гайрәт белән чабып яра.)*

Хәдичә. Дисеңме?
Мөхәммәт. Дим.
Хәдичә. Кемгә?
Мөхәммәт. Үземә.
Хәдичә. Син дә... әллә кем түгел ич.
Мөхәммәт. Һәммәсе фани. Бернәрсә дә бакый түгел.
Хәдичә. Каян беләсең?
Мөхәммәт. Белмим.
Хәдичә. Оныттыңмыни?
Мөхәммәт. Син дә оныт.
Хәдичә *(кече капканы ачып чыгышлый).* Сәгать ничәгә дидең әле?
Мөхәммәт. Оныттым. Килерләр. Алып китәрләр. Кайтарып куярлар.
Хәдичә. Ә син?
Мөхәммәт. Килерләр. Алып китәрләр, кайтарып куярлар... Безнең бүтән чарабыз юк. Сайлый алмыйбыз. Әти тавык чалганые, йолкып пешеклисем бар. Бар инде. Бар!
Хәдичә. Юк! *(Чыгып китешли.)* Әйтте диярсең.
Мөхәммәт. Мин әйттем инде.

**ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ**

Тирән, текә ярлы коры ерганак буендагы тугай.

Баян *(куркынып, тыны бетеп).* Хәдичә, кызым.
Хәдичә *(тыныч, сабыр).* Әү, әни.
Баян. И анау үр кашындагы җиләк! Чирәмгә юарга дип салган келәммени! Күзне әлҗе-мәлҗе китереп тора инде менәтерә.
Хәдичә. Җый, әни.
Баян. Җыярсың, бар! Аның башындагы чокырда бер кара елан бөгәрләнеп ята. Кораеш елан диярсең.
Хәдичә *(тыныч).* Хәзер, хәзер, әни. Күрсәт.
Баян. Күрсәт дип... Карасам — ята.
Хәдичә. Ә син карама, әни. Еланнар күрмәгәннәргә тими ул.
Баян. Ничек карамыйм ди, күрмим ди инде? Ята ич. Бөгәрләнеп. Кап-кара.
Хәдичә. Ак җылан булмый. Теләсә, бөгәрләнеп ята, теләмәсә, сузыла да китә. Үз оясы. Елан тимәгәнгә тими. Кеше тисә, үзенә карый инде. Әйдәле.
Баян. Җиләк дип җылан авызына керәсеңмени?
Хәдичә. Җылан алдында җыламыйлар.
Баян. Барма! Куркам.
Хәдичә. Курык. Курыкмаска кем куша? *(Ары китеп бара.)*

Тынлык. Бытбылдык кычкырып куядыр.

Баян. Нигә алып килдем? Җиләк монда беткәнме? Иҗниган лабаса. Уйдык-уйдык. *(Җыя.)* Бакчы моны. Үз насыйбың үзеңә инде ул анысы. *(Бер җиләкне өзеп, тәмен белеп ашагач.)* Тамак туйса да, күз туймый шул. *(Учына җыйганны ашап куя.)* Тагын кабасы килә. Өлешеңә тигән көмешне... дигәндәй. Әй! Монаусы бигрәкләр инде. *(Кабып куя.)*

Хәдичә үр кашыннан чигенә-чигенә җиләк җыеп төшә.

Суң?
Хәдичә. Җылан күрми ул.
Баян. Нишли?
Хәдичә. Чага гына. Чакса.
Баян. Сине... чакмыймы?
Хәдичә. Күзсез күзсезне чакмый.
Баян. Нишли?
Хәдичә. Ишетә.
Баян. Җылан ишетәме?
Хәдичә. Тыңлый.

Баян *(кинәттән авыр сүзне бүтәнгә борып).* Кызым, әле минем чиләгемнең төбе өч бармак хәтле генә күмелде, ә син инде *(басынкы)* тутырып та өлгергәнсең.

Хәдичә. Күзеңне тутырып карап җыйганда, тулганын күрми дә каласың аны.

Баян. Тутырып? Ни арада?

Хәдичә. И, бармаклар үзе әйтә инде ул. Саннар.

Баян. Санап җыясыңмыни?

Хәдичә. Санлап. Кеше чиләккә генә җыя.

Баян. Ә син?

Хәдичә *(үз-үзенә генә дигәндәй итеп).* Җаныма... Бер литрга күпме җиләк сыя, әни?

Баян. Кем белгән инде?!

Хәдичә. Бер стаканга илле сигез җиләк сыя.

Баян. Аны кем санап торсын ди?

Хәдичә. Мин бүген ике мең дә сигез йөз җитмеш... җир җиләге җыйдым. Җыенысы кырык ике стакан була.

Баян. Әле минем чиләгем тулар-тулмас кына. Ә синеке — мөлдерәмә.

Хәдичә. Күзеңне тутырып җыйганда тиз тула ул.

Баян. Ни булды сиңа, кызым? Бүген.

Хәдичә. Нигә алай дип сорыйсың әле?

Баян. Кеше болай... каударланып җыя димени. Әйтерсең иртәгә көн җук.

Хәдичә. Әйе. Юк. Иртәгә. Көн.

Баян. Чиләгең мөлдерәмә тулган.

Хәдичә. Чиләгем тулган. Мөлдерәмә. Ә бүген җаным ташып чыкты. Мөлдерәмәдән ашып.

Баян. Әллә нәстәләр сөйләп куясың инде шунда.

Хәдичә. Берни әйтмим ич әле. Мин — егерме беренче яшемдәге кыз... әллә ниткән көмеш эзләмәстән... өлешемә җиләк ашатып тотыйммыни? *(Әкрен.)* Ярый ул... син шундый яшеңдә абыйны, мине тапкан булгансың... инде.

Баян ни әйтерен, нишләрен белми тора.

Әни.

Баян. Әү.

Хәдичә. Каен җиләге җыясым барые.

Баян *(сәерсенеп).* Арыш әллә кайчан серкә очырды ич инде. Бу вакытта каен җиләге беткән була.

Хәдичә. Әй, күрмисең дә инде, әни. *(Чокыр кырыена барып баса.)* Әнә ич.

Баян. Текә. Түбән төшәсе.

Хәдичә. Менәсе.

Баян. Таймагаең.

Хәдичә. Таймам. *(Ерганак ярына төшеп китә.)*

Тынлык. Чикерткәләр зыңы ишетелеп тора.

Баян *(аска карап).* Бармы?

Хәдичә. Күп.

Баян. Җыйганың җитмимени?

Хәдичә. Бусы бүтән, соңгылары. Иң кирәкләре.

Баян. Кемгә?

Хәдичә *(күтәрелеп).* Аңа, аңа.

Баян. Үзеңә түгелмени?

Хәдичә. Аңа. Каен җиләге кирәк түгел кешегә.

Баян *(гаять авырсынып, аңлап).* Барганыеңмыни?

Хәдичә. Килмәгәние ич.

Итәген киң итеп җәеп, җәелеп китеп җиргә утыра, җыр җырлый.

Айга менеп китәр идем,
Сине анда дисәләр.
Җилләр, җилләр... *(Тынып калып.)*
Алар да әйтми исәләр.

Бүтән көйгә күчә.

Җылы яклардан җилләр иссәләр,
Тәрәзәмне ачып куярмын.

*(Күңеленнән, авыз эченнән генә җырлап.)*

... дисәләр,
Ул җилләрне кире куармын.

Баян. Күрешкәнсез икән.

Хәдичә. Хушлаштык.

Баян *(үзалдына).* Аллам, Ходаем, боларга мәдәт бир инде берүк. *(Хәдичәгә.)* Ни диеп бара?

Хәдичә. Кит диеп.

Баян *(әллә нишләп, әллә гарьләнеп, әллә хәсрәтләнеп).* Бигрәк тагын! Шуңа атап каен җиләге җыйдыңмы?

Хәдичә. Соңгыларын. Соңгы тапкыр. Онытсын дип.

Баян. Нәрсәне?

Хәдичә. Онытканын да онытсын дип. *(Җырлый.)*

Ник оныттың, ник оныттың соң син
Чеме белән җиләк җыйганны?
Ак кар яткан яфрак астында
Соңгы чикләвекне җыйганны.

Ник оныттың, ник оныттың соң син
Ташуларны ерып барганны?
Сиздекме без авыр булган чакта
Егылганны, хәлсез арганны?

Ник оныттың, ник оныттың соң син
Баланнарның кызыл тамчысын?
Мөлдерәшеп пешкән чияләрнең
Күз яшедәй ачы татлысын.

Әллә кайдан — ерак-ерактан якыная килеп җырланган җыр авазы ишетелә. Әүвәл гитара аккорды, шуннан соң гына сүзләре ишетелә
башлаган җыр. «Күзләремне тутырып».

Баян. Кемне җырладың?

Хәдичә. Аны.

Баян. Әле генә җырлаган — ул идемени ул?

Хәдичә. Кем?

Баян *(аптыраганнан).* Бөтен авыл белә ич инде. Бөтен дөнья!

Хәдичә. Җыр җырлау дөньяга сыймый.

Баян. Нишли?

Хәдичә. Дөньяга сыймаган җыр гүргә иңә. Җаныма, иманыма. Аллаһы Тәгаләнең каһәре бер гөнаһсызым өчен миңа сарыф ителгән икән, җавапка һичкемне тартмыйм.

Баян. Әллә ниләр әйтеп ташладың әле, кызым.

Хәдичә. Ташламадым — алдым.

Баян *(сагая калып).* Нәрсәне?

Хәдичә. Белмим. Белгәч... күргәч әйтермен әле.

Әкрен-әкрен генә көйләнә барып, теге җыр көчәя башлый.
«Күзләремне тутырып»...

Баян. Әллә кайдан бер җыр ишетелеп торган күк, кызым. Монда таба килә шикелле.

Хәдичә. Килә икән — китәр. Адым белән адым арасы ерак түгел.

Тынлык.

Баян *(сәерсенеп, сүзне бүтәнгә күчерергә теләп).* Якында гына җырлый сыман.

Хәдичә. Җан белән җан ераклыгында гына. Ай белән аның янындагы йолдыз арасында... Кайтыйк инде. Төш җиткәндә, җиләкләр кача.

Баян *(сабыр гына).* Әллә кая ашыгасың... ашкынасың диимме суң?

Хәдичә *(җиләкле чиләген ала).* Үз насыйбым үземә анысы. Тик... яшелләнеп таңнар атканда... күрмәс күзгә салкын итәк каплыйсым килә.

Баян. Әстәгыйфирулла!..

Хәдичә. Әйт, әни! Теге яшен астына хәзер... бүген дисә күрәләтә кереп ятар идем дә бит кана... сугам дисә. Тагын бер сукса, яңадан күрмәм микән дип... Әй, әни...

Җыр:

Күзләремне тутырып...

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

Ишегалды.

Мөхәммәт *(балтаны бүкәнгә каптырып куя, уң кесәсеннән сәгать алып карый, үзалдына).* Час — икс. *(Кече капканы барып ача.)* Кер, капитан.

Майор керә.

Майор. Нихәл, сержант. Мин майор инде. Соңгы майор.

Честь бирешәләр, башта кулга-кул, аннары кочаклашып көрешәләр.

### БИШЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Майор. Именем Российкой Федерации. Правом моей присяги служению Отчизне. Я — командир разведроты танкового полка капитан *(ату тавышы)* по законам временных военных операций в пределах Российской Федерации приговариваю вас к высшей мере наказания — к расстрелу. Приговор окончательный, обжалованию не подлежит. К исполнению приказа — рота! В ружьё!

Полковник. Братцы! Христа ради!

Майор. В уставе ни Христа, ни Магомета нет. Нет тебе прощения всеми богами. Полковник! Приказ окончательный. Вы надлежите к немедленному уничтожению как враг Российской Федерации за изнасилование и убийство чеченской девушки.

Полковник. Ну... изнасильничал. Признаю. Загубил. В аффекте был... У меня жена, сын, дочка...

Майор. А она, эта девушка, и родить не успела. *(Үзалдына.)* Унсигез яшь...

Полковник. Братцы... Капитан... У меня там... в чемодане... в КП штаба полка двести тысяч долларов...

Майор. Полковник! Ты демобилизован! Командир первого взвода разведроты *(ату тавышы)* танкового полка сержант Муртазин!

Полковник. Майор, прошу тебя!

Майор. Я — капитан. В списке только погибшие. Гадам в моей разведроте мест нет. Командир первого взвода разведроты танкового полка сержант Муртазин! На приказанный мной огневой рубеж! К исполнению!.. Рота! Смирно!

Мөхәммәт. Иптәш капитан!..

Майор. Беләм, сержант. Рота! Отставить!

Мөхәммәт. Ә боерык... приказ?

Майор. Не обсуждается. *(Пистолетын чыгарып, полковникның чигәсенә төби.)*

Полковник. Братцы!..

Майор *(полковникның колак төбеннән ата, пистолетын тыгып куя).* Живи, полковник. Не тужи. Ә яхшысы... по-хорошему... сгинуть, чем жить с ношей, что у тебя на душе... нет, испоганенной... нет!.. Испражненной тобой на всю Отчизну бесчеловечья. *(Сигарет каба, кабызгычы янмый.)* Сержант...

Мөхәммәт *(аңа шырпы сыза, полковникка ымлап.)* Нишләтәбез?

Майор. Бернишләтмибез. Ул — демобилизован. *(Полковник алдына пистолет ыргыта.)* Твой, табельный. Все, чем могу помочь. Прощай, командир.

Полковник. Спасибо, братцы.

Майор. Спаси честь семьи своей. Хәер... Хотя растоптавший свою честь семью не имеет.

Полковник. По-че-му?

Майор. Потому, полковник, ты — расстрелян. Иди, яшә.

Полковник. Ну, капитан! Мы еще посмотрим. Мы — вся Россия!

Майор *(уйчан).* Вы? Еще? Посмотрите? Вся Россия? *(Кырыс.)* За что боролись, на то и напоролись. Мир белән... всем миром. Земным грешным, как ты. *(Чишелгән иң өске төймәсен каптыра, чәчен, пилоткасын төзәтә, катгый.)* Лежать! Руки под грудь! Ползком! До штаба танкового полка! Сержант Муртазин!

Мөхәммәт. Мин!

Майор. Оружие — на изготовку! Согласно моему приказу — сопроводить!

Мөхәммәт. Есть!

Полковник. Ну!..

Майор. Лечь! Ползком! По испоганенной тобой Отчизне! *(Үзалдына.)* Отчизна, распереэтак!.. Әстәгыфирулла!..

Мөхәммәт *(полковникка).* Товарищ командир... бывший... согласно приказу — алга! Ползком!

Китәләр.

Майор *(сигарет каба, шырпы эзли, җирдән пистолетны иелеп ала).* Забыл. Шулай. Гүр иясенә көрәк кирәкми. Старшина! Оприходовать... Рота! *(Арыган сурәттә.)* Вольно!..

Тынлык.

Полковник. Ну!.. Сучье поганое! Изменники! На! В подарок!

Граната шартлаган тавыш яңгырый.

А я доползу. Честь имею!

Майор *(талпынып, ялкынга ыргыла).* Сержант! Мөхәммәт...

Граната шартлавының кучкыл ялкынында докторның тып-тыныч та-
вышы ишетелә.

— Согласно врачебного консилиума — ампутация по предплечью левой руки. Ампутация по подбедренную область правой ноги. Готовы?.. Извини, солдат.

Мөхәммәт *(тавышы).* Юк!

Доктор тавышы.

— Извини. Алла хакы — Тәңре хакы.

Шул ук ялкында чатырдатып яшен яшьни.
Авыл. Куе бер агач төбе.

Хәдичә. Юк! Мин күрмим! Мәсрүрә әби... Гайшә апа!.. Мин күрмим...

Граната шартлагандай гөрселдәп күк күкри. Бөтен җиргә, хәтта күк йөзенә дә, кучкыл кан тамчылары булып, Хәдичәнең алсу-зәңгәр чиләгеннән кып-кызыл җир җиләкләре чәчелеп, сибелеп, тәгәрәшеп китә. Кайдадыр тәкәрлек, акчарлак, әтәч кычкырып куядыр; җил исә, бәлки, яңгыр сибәли башлый булыр; эт өреп ала; узып китешлидер
инде бала-чаганың көлешкән авазы яңгырый.
Ишегалды.

Майор. Нихәл, сержант.

Мөхәммәт. Аллага шөкер, майор. Инвентаризация генә бераз төгәл түгел.

Майор. Ярарсана! Минем әти «ык итмәгәйләре мык итсеннәр» дия торганые. Иң мөһиме, «лейтенантың» үз урынындадыр ич?

Мөхәммәт. Довольствиегә алырга... амбар кенәгәсе юк әле.

Майор *(кул сәгатенә күз төшереп ала).* Сиңа — бәрәңге бакчагызның башына. Хәзер Хәдичә дә китәр... Бүлдермә! Китәр. Честь имею! *(Чыгып китә.)*

### АЛТЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Җәй. Чиллә. Авыл. Бүтән капка төбе, ишегалды.
Почта йөртүче Камал килеп туктый.

Исхак. Бармы?

Камал. Нәрсә?

Исхак. Гәҗит.

Камал. Бүген дүшәмбе.

Исхак. Булса суң.

Камал. Якшәмбе гәҗит чыкмый. Дүшәмбедә таратасы юк.

Исхак. Сиңа рәхәт. Алайса ниме дип килдең? Шушы эсседә. Аксап-туксап.

Камал. Телеграмма. Ә телеграмма — җитди нәстә. Ул мин почтальон Камалның чулакмы, чатанмы икәнлеген сорап-нитеп тормый: килә дә төшә, чукынчык. Ә син — мин ягъни — илт тә бир. Рәхәт!

Исхак *(сагаеп).* Кая барам дидең?

Камал. Бүген сездән ары узыш юк.

Исхак. Без мәрхүм әти-әнидән кала унике генә бала. *(Катгый.)* Кайсыбыз вафат, почта? Турысын әйт.

Камал. Син түгел.

Исхак. Яшиселәр алда икән әле.

Камал. Берегез дә түгел.

Исхак. Мин мәллә дип котым калмады. Билләһи газыйм, Камал абый. Оторви да брось!

Камал *(букчасыннан кәгазь, папка чыгара).* Бу бирәсе дә аласы гына түгел.

Исхак. Аллага шөкер. Әлегә уникебездән беребезне-беребез җирләп расхутланмыйсы икән.

Камал. Хәдичә өйдәме?

Исхак *(сагаеп).* Өйдә булмыйча кайда булсын ул. Әнкәсе белән әле генә Кызыл Елгадан җир җиләге җыеп кайтып төштеләр. Мөлдерәмә тутырып. Әйдә, Камал абый, уз, җиләктән авыз итәрсең. Күчтәнәчкә биреп тә җибәрерләр.

Камал. Юк. Эш мөһим тора. Бик. Әйтәм ич, мин бирәсе, сез аласы гына түгел.

Исхак. Ул хәтле нишлисе суң?

Камал. Мин кызыгыз Хәдичә Исхак кызы Сәрвәровага укып бирәсе, ни укыганымны аның белән миннән кала һичкем белмәсенгә үз имзамны саласы.

Исхак. Ниме дигәнгә?

Камал. Каян белим. Итәген кайтарып салмас бортын... текстны кемнең укып караганы бар?

Исхак *(тәмам аптырашта калган кыяфәттә).* Чү! *(Йорт-кура тарафына борылып.)* Гыйзделбаян! Кайда син? Чык. Монда почтальон Камал абый бик важный телеграмманың тексты синдә дип бара!

Баян күренә.

Камал. Исәнме, Баян сеңлем. Түгел. Исхак бераз арттыра. Монда ни... Хәдичә сеңелкәш кирәк иде.

Баян. Ул... җиләк бөрчеп торадырые әле.

Камал. Кирәк. Үзе.

Исхак *(Камалга).* Бир. Кертеп апчыгам.

Камал. Юк. Үзенә генә. Шәхсән. Кулын куйдырттырып.

Баян. Ул... укый ала да... күрми ич.

Камал. Беләм. Тик үзенә генә. Мин укып биргәнгә кулын куйдырттырып.

Хәдичә күренә.

Хәдичә. Бир, Камал абый. (*Почтальонның ипләп куйган кәгазенә имзасын сала, телеграмманы, учына йомарлап, йөрәге турысына куя.)* Әни, җиләкне үзеңә кайнатасы кала. Хәзер миңа китәсе.

Баян. Кая?

Хәдичә. Белмим. Алып барганнары җиргә.

Исхак. Камал...

Баян. Исхак...

Камал. Тегендә *(Хәдичә йомарлаган кәгазьгә ымлап күрсәтеп)...* шулай диелгәние, покрайнимир. Тагын *(кул сәгатенә карап ала)...* утыз минуттан суң.

Исхак. Ярты сәгатьтән.

Баян. Кая?

Камал. Анысы әйтелмәгән.

Хәдичә. Белмим дисәм?

Исхак. Нәрсәне?

Хәдичә. Минем пешкән зәңгәр җир җиләкләрен күрәсем килә. Беләм, алар пешкәч кызыл була. Яшел бал кортларын... Ал миләүшә чәчәкләрен... Беләм, алар — шәмәхә төсле. Бәрәңге бакчабыз очындагы Шири чишмәсенең ак суын... Беләм, су — сөт төсендә түгел ул. Безнең ал сыерыбызның... кучкыл кызыл арыш арасында үсә торган сап-сары зәңгәр чәчәкнең... һәммәсенең... үз төсләрен... күрәм мин. Кояшның сипкелле икәнлеген дә. Мин барасы юлымның гына ни төсле икәнен белмим. Мин әйләнеп кайтасысы акпакь булыр шикелле. *(Кереп китә.)*

Тынлык.

Исхак *(кискен итеп, Камалга).* Ниткән телеграммалар өләшеп йөрисең син, ә? Дүшәмбе көнне. Сәгать... дүртенче ярты да җитәр-җитмәстә. Авыл көтүе дә кайтмас борын. Әйе! Бүген... гәҗит булып гәҗитләр дә чыкмый.

Камал *(тын).* Чыкмый.

Исхак. Шуңа карамастан... син йөрисең. Йөрисең дә йөрисең. Бимазалап. Моның өчен сине нишләтергә икәнен беләсеңме суң син? Әйеме, Баян?

Баян. Әйе... Белмим.

Камал. Кыйнама гына.

Исхак. Хәзер. Кыйнап торам ди. Өшәнеп. Мин сине... моның өчен... судка бирәм!

Баян *(ачынып).* Әй!.. *(Кулын җәеп.)* Бу дөньяны... мондый бәхетсезлекне судка биреп бетерерлекмени суң!

Исхак. Ә мин... бетерәм. Ким дигәндә... бетерәсем килә. Оторви да брось — килә!

Камал. Яшәүгә хөкем юк, Исхак. Нинди булса да.

Исхак *(сүзсез ишарәләре белән ярсып ала да, кинәт тын калып, Камалга).* Ул яшәү дигәнең... синең эше... чулак... чатан булса дамы?

Баян *(кисәтеп).* Исхак!..

Камал. Бәлки.

Исхак. Тегенди-мондый телеграмнар өләшеп йөрергә... чат үзе инде.

Баян. Исхак!..

Исхак *(Камалга).* Дөрес түгел мәллә?

Камал. Дөрес, нәрсә аны. Зират... әнә генә. Бар, әти-әнидән хаклатып кил алайса.

Исхак. Үпкәләмә. Әрепләмә. Безгә синең ата-анаңның каен төбе насыйп итмәс инде... дер! Ярар, кычыткан үсәр әле. Чага торган! Синең телеграммаларың шикелле.

Баян. Исхак!

Камал. Ул телеграммаларны мин суккан мәллә? *(Исхакка.)* Мә, илтеп бир. Вакыты узмаган әле. Кичке автобуска... сәгать биш тә ноль-нольгә нәкъ өлгерәләр.

Исхак. Кая?

Камал. Акчураларга. Илтеп бир! Бая гына өй турыларыннан керергә ике мәртәбә кыймый узып киттем дә... сезгә килдем. Аларның улларына — Мөхәммәткә дә сукканнар.

Баян. Ул нишләгән?

Камал. Бернишләмәгән.

Исхак. Алайса... Нигә телеграмм сукканнар?

Камал. Танырга дип. Әле ярый янында документы булган. *(Кинәт.)* Мә, Исхак энем, илтеп бир! Син ни чулак, ни чатан түгел. Менәтерә мин — чулак, чатан. Миңа ярый. Чыдарга күнеккән инде. Бар, илт. Беләчә Тәлгатләренә. Норильски никелендәге уртанчы малае... автокатастрофа... хатыны... бер улы, бер кызы... Уптымы белән бөтен бер гаилә. Фаҗига.

Исхак. Баян! Бу ни диеп бара бу, ә? Мине ни... үзе шикелле... чулак итмәкче.

Баян. Түгел, Исхак. Күзле итмәкче.

Исхак. Инде мине сукырайттыгыз дамыни?

Камал. Сукыр бүтән сукыраймый. Мин дә... чулак, чатан булмас өченгә үзем алты яшьтән егылып төшкән зират каены башына яңадан үрмәләп менә алмыйм ич инде. Менәр идем дә... Ул каен картаеп авып ятты да шунда череп бетте инде. *(Баянга, Исхакка.)* Мәгез, йөрәгегез җитсә, менә шушындый хат-хәбәрләрне илтеп тапшырыгыз. Илтеп бирәсе генә дә түгел, ә бәлки тәгаен алганнарына кул да куйдырасы. Бәби туемы ул, шушының ише үлем гарасатымы — барысы да бер иштән. Почта ташучы дигәч тә... Муса Җәлил теге... «хат ташучы» дип язганга карамагыз сез. Кем әле? Әйе, Тимербулат. Типсә тимер өзәрдәй егет. Хат ташып йөри. Бүтән эшкә ярамаган. Имеш. Ул чакта буласы егетләр, танкист булам дип, тракторга утырганнар ул. Тимербулат — адәм страмы ул, герой түгел. Әйе. Ә мин чулак, чатан Камалга ярый. Көн күрергә кирәк ич. Мең дә йөз егерме дүрт тәңкә дә алтмыш өч тиен алып барганымны да... хөкүмәт... киләсе айдан кисмәкче. Шикләнмәсеннәр: Аллага шөкер, кисәсе бер киселгән инде — сөннәтле. Иманнарына китерер идек тә... бер имансызны бүтән иманга китереп булмый шул. Почтаны бетерделәр, медпунктны бетерделәр. Хәзер мәктәпне бетерәбез дип баралар.

Исхак *(аны тәмам аңлап, жәлләп, туктатып).* Камал!

Камал. Ун минуттан машина киләсе.

Баян *(талпынып).* Камал!

Камал. Галиәсгар түгел. *(Чыгып китешли.)* И драматурглар! Ә мин артистка режиссер да юк. Тамашачы кирәк.

Хәдичә *(җыенып чыга).* Оныта язганыем — исемә төште. Алдым.

Исхак. Нине?

Хәдичә. Көзгемне.

Баян *(сәерсенеп, шикләнеп, утә өркә калып, Исхакка).* Карале. *(Илтифатсызлыгына карата.)* Карале, дим! (*Әкрен.)* «Көзгем» ди.

Исхак *(уеннан аерылып, кискен).* Әй! Чуен кыздырып бөккәндә, тимердән узып бакыр сөйләшәләрмени! Асылында көмеш ятканда. Оторви да брось! — барсын.

Баян *(тын гына).* Кайларга гыналай йөртеп бетермәдек ич инде!..

Камал. Тагын бер кузгалудан гына әллә ни бүтән хәтәррәк зыян өстәлмәстер инде ул дисәм, ничектер инде ничегген... тик... телеграмма бит.

Хәдичә *(чыгышлый капканы япканда).* Озатмагыз... Әни, җиләкләрне җиетә күрмә инде. Кайнатырга куй. Быел сусылрак. Шикәрен күбрәк саласы. Югыйсә күзгә дә кырып салырга дигәннән дә әз генә кимрәк җибәрә торган гадәтең бар.

Камал *(чыгып китешли, һичкемгә игътибар итмәстән, үзалдына шикелле генә булса да, бөтенесе ишетерлек итеп сөйләнә-сөйләнә).* Ә менә бусын ничек атлап барып... кайсы кулым белән тапшырасы булыр инде. Ка-тас-трофа диң, ә. Кыенгарак туры килә. Аяк тартмый, кул бармый. Дүшәмбе көн булуга карамастан бит, ә. *(Телеграмманы түш кесәсенә тыгып куя.)* Киләсе якшәмбегә хәтле бер-бер әйбәте дә килә аның. Пенсиям генә әзрәк инде әзрәккә... Ә кешене өмет тота. Барыбер. Моны мин бик яхшы беләм...

**ҖИДЕНЧЕ КҮРЕНЕШ**

Гөлҗиһан. Эт тә җук... *(Дәшә.)* Улым! Мөхәммәт!.. Ярар. Бер-бер җиргә чыккандыр инде. *(Эзләнгәч.)* Әйе, чыгып торгандыр. Әллә ни ерак китмәс. Китә алмастыр инде... Кыртлый тавык белән әтәчне пешекләдем. Аш салдым. Битем, кулым чиста шикелле. Хәзер юынып та чыгыйм инде. Юынып дигәч тә... коенып. Мунча әзер. Әйе, коенып кына инде. Бәлки, юынырмын да әле. Анысы юыну төнгә каршы була инде ул. Ирең катына ятканчы. Тәһарәт алып булса да. Госел коенып. Шулай язылган диләр... *(Дәшә.)* Улым!.. Ярар, кайткан китмәс. Шул хәлендә кая китсен? Исән-сау ич. Алла кушып. Кул, аяк... Кулының сулы, аягының уңы. Аның каруы күзе исән-сау. Күрер күздән ерак китмиләр ул. Хәзер, хәзер. Ашның өресе чыкканчы өлгерәм әле... *(Мунчага кереп китә, бераздан чыга.)* Менәтерә. *(Болдырга йөгереп кереп чыккач.)* Аш пешә ул. *(Анда-монда каранып алгач, шәрә тәненә япкан халатын ачып җилпенгәли.)* Менәтерә. Ул чөгендердәге тузанны әйтер идем. Дөньяда аның куелыгындагы... сүгенү сүзе дә юктыр. Зәһәр инде. Котылыр, чистарыр әмәл җук. Моны гариза язып та алалмассың, билләһи газыйм. Чөгендер өч чакрым буена сузылган ул. Дүрт түтәл. Башына чыгарга өлгермисең, — тын буыла башлый. Әле дә ярый йөрәк таза. Теге-бу җирем дә *(халат итәген ачып җилпендерә)* Аллага шөкер кук. Татар хатыннары түзә инде. Без — Татарстанның чөгендер хатыннары бит! Берәр татар хатынының йөрәге таза икән, — димәк, Татарстан чөгендере дигән тулгак тотып карамаган. Чөгендер түтәленең очына җиткәндә тамак төбе генә түгел, ә бәлки... әллә кайсы төшләрең... кымырҗыргa... әллә нишләргә тотына. Татарстанның мең суверенитеты әнкә кешеләрнең бер тулгагына тора торган булса — ярый. Ә инде минем улымның сул кулын, уң аягын алдыртып кайтарган Рәсәйнең ни уң кулы, ни сул аягы булмас. Иманым камил. Бу илнең тыныч дигәне минем Мөхәммәт улымны тапканда түккән канымның бер тамчысына да тормый. *(Болдырга кереп чыга.)* Аш пешәр ул анысы. Кая китсен. Улым Мөхәммәт тә әллә кая түгелдер. Кайтты ич. Кайтып төште. Аяк-кулы... Аллага шөкер, күзе бөтен булгачыннан суң тагын ни кирәк? *(Елап диярлек көйләп.)* «Алма кебек тулган... бөтен... пешкән чагым, сиңа ни кирәк тагын» диючесе... килеп чыгар әле. Кая китсен ул! Көмешенә өлеше табылыр. Йа Рабби. Ярар инде, шөкер: карыныңнан бөтен килеш төшкән җан балаңны... шундый-мондый итеп кайтарып җибәргәннәр икән... яхшы, яхшы. Яңатәдән кертеп чыгарыйммыни *(итәген ачып)* инде... аны *(чебешләргә)* бәгырькәйчекләрем, әйеме? Телем белән суырыплар торып алырыем да бит... телчеккәем моңа яратылмаган шу-ул... *(Гел йөри, ирене ябык, эшли дә эшли, кайбер чакны гына тирән итеп сулыш алгалый, туктап калгалый да үз дәвамында бара.)* Әле ярый юынып чыктым. Госел коенып булса да. Югыйсә чәч шырт ише катканые. И, бу тәннән бөтерелеп-бөтерелеп чыккан керне килолап үлчәсәңме? Күпме тоннага тартыр икән? Ирең сиксән килолы. Ә миңа күчергәндә *(уйланып ала)* тонна. Аллам сакласын!.. Кайда суң инде син, Мөхәммәт? Аш куйганыма да унҗиденче көн ич инде. Унҗиденче көн буена шушылай йөрим дә йөрим. Әллә унҗиде көн, әллә... әлмисак буена.

Капка келәсе һичкемне сиздермәстән күтәрелгән, кече капка һичкем
күрмәстәй итеп ачылган, аннан бер ир кеше кергән иде инде.

Акчура. Бу Акбар нигә өрми ул? (Э*чтән.)* Теләсә кемгә өрергә Жириновский түгел ич ул. Челләдә эт өрү генә түгел, күке дә саңгырау. *(Чыга, күрена.)* Ни дигәниең әле?

Гөлҗиһан. Монау колорад коңгызларыңны нишләтәсең? *(Банкага ишарәли.)*

Акчура. Нигә минеке булсын ди алар? Син җыйгансың ич — синекеләр.

Майор *(керә).* Әссәламегаләйкем.

Гөлҗиһан. Вәгаләйкем...

Акчура. ...әссәлам!

Майор. Узып бара идем.

Акчура. Суң... уз...

Гөлҗиһан *(Акчурага).* Туктале син. *(Майорга.)* Җиләк җыйдыңмыни?

Майор. Җыйдык.

Гөлҗиһан. Җыйдык дигәч... хатының беләндер ич? *(Җиләкләрне каба-каба карый.)* Чат өлгергән. Без җыйганнарга караганда да пешебрәк тора шикелле.

Майор. Җиләк... кояш тәме сеңгәч кенә өлгерә ул.

Гөлҗиһан. Каенлыктан җыйдыңмы?

Майор. Шуннан. *(Бер җирен кашып ала.)* Кадалган, ахрысы.

Гөлҗиһан. Урман бете мәллә?

Майор. Каян беләсең?

Гөлҗиһан. И-и, белмим диме инде?

Акчура болдыр баскычына утыра да, сигарет кабызгач, тарта-тарта карап кына тора.

Мин инде ни... беләм. Күлмәгеңне сал әле. Сал, сал, — ятсынып торма.

Майор чишенә.

Менә ич, кадалган, үләт кыргыры. *(Бармакларын мул төкереклəп юешләгәч.)* И, бу чукынчык сиңа башыние белән чумып береккән икән. *(Бармагын тагын да мулрак төкереклəп юешләгәч.)* Хәзер, хәзер. Чукындырып алып атам мин аны...

Акчура. Кара аны, башы өзелеп калмасын.

Гөлҗиһан. Кергән башның миндә өзелеп калганы юк әле. Керсә. Әгәренки.

Акчура *(тыны капкандай)*. Кхм!

Гөлҗиһан *(баш бармагы белән имән бармагыннан читкә чиртеп, чирткәнен үкчәсе белән изеп, сытып).* Булды.

Майор. Рәхмәт яусын. Эчәр суыгыз булмас микән?

Гөлҗиһан болдырдан су алып чыга, ул арада Акчура, утын пүләннәре арасыннан бер шешә аракы алып, стакан тотып килергә өлгерә.

Гөлҗиһан. Мә...

Акчура. Мә!

Сүзсез аңлашып алу булып куя.

Гөлҗиһан. Мә, майор Сәйфиев.

Майор. Каян беләсең?

Гөлҗиһан. Мин улымның аннан — сугышыгыздан язган алтмыш җиде хатын яттан беләм. Кайсыгызны үтергәннәрен, кайсыгызның кайда ярасы булган да шуннан нинди җөй калганын.

Майор бер җиренә кагылып ала.

Әйе, нәкъ шунда. Җиденче кабыргаңнан өстәрәк. Йөрәгеңә биш миллиметр җитми калганмы әле?

Майор. Өч. Өч миллиметр. Су сораган идем.

Гөлҗиһан чынаягындагы суын суза, Акчура аракы шешәсенең бөкесен ача алмый интегә.

Акчура. Аптыраган инде. Нителми бит әле, энем!.. Кирәк чагында һаман шулай. Беренче тапкыр үбешкәндәге шикелле... авыр. *(Стаканга аракы сала.)*

Майор. Яхшы. *(Эчә, чиләгендәге бер җиләкне каба да читкә атлый, сәгатенә карап алгач.)* Час — икс. *(Дәшә.)* Сержант!

Мөхәммәт керә.

Мөхәммәт *(шат кыяфәттә).* Бу мунчага дигән утын пүләннәре гел ярылмыйча өелеп тора икән әле. Әйткәнемчә, иптәш майор.

Гөлҗиһан. Әй, улым! Көтә-көтә көтек булдым... булдык ич инде! *(Читенсенеп-читенсенеп карагач.)* Бу күзең кайда, улым?!

Майор. Ерак түгел.

Мөхәммәт. Мең күз күргәнгә берсе түзәр әле, әти... әни...

Гөлҗиһан *(бөтен дөньяга аркан борылып, үз-үзенә пышылдап кына, тик бар җиһанга ишетелерлек итеп).* Йа Аллам! Син түзгәнгә ана ничек чыдасын?

#### СИГЕЗЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Гөлҗиһан. Тагын... ниттеңмени?

Акчура. Минем синнән бүтәнне... ниткәнем җук. Улыбызның унҗиде көннән соң тагын бер әйләнеп кайтканы шәпкә бераз... ниткәнмен икән, син моны бу *(Гөлҗиһанның бил түбәнтен җиренә сугып куя)* шактый мул амбар кенәгәңдә... нитми... теркәми тор инде, Гөлҗиһан.

Исхак. Карале, Баян! Бая гына егетләр сөйләп торганые. Теге майор килеп тә төшкән, име, Акчураларның утын пүләннәре арасыннан бер «ярты»ны стаканы-ние белән суырган да чыгарган, малай! Югыйсә безнең дә... менә... ярмыйча өелгән пүләннәр дачурта бит ул, име. *(Ишарәләп.)* Болар туйларын озакка сузмас күренә. Әллә, мәйтәм, берәрсен ача торганда әллә ни зыянга төшмәстер... димәкче булам инде. Үземчә.

Баян. Ассортиментың! Никах укытмый торып. Мин әле ни дип торам. *(Әле елый-елый, әле аптырап, әле үзенең сөйләгәннәренә елмаеп, көлеп.)* Тана гына җитеп җитмәс күк. Янына теге тәкәне дә кушмаска микән? Сезоны үтте, сикерми дә. Кодаңа бер... өч йөз дә илле тәңкәлек түбәтәйсез ярамас. Кибеттә бар, күптән чамалап куйганыем. Кодагыебызга яшел бутый бар. Үзенекенең табан асты ярылганлыгын күптән карап йөридерием инде. Касыйм хаҗига никах укыганына дип адарынып куелган ике йөз тәңкәм... нидә... китап шүрлегендәге Габдулла Тукай китапларының бишенче томындагы йөзенче бит белән йөз дә беренче бит уртасында. Кыл. Шуннан соң табын китә. Килосы сиксән-туксан тәңкәдән күрәгә... өч кило җитеп торырдыр. Кара җимеш кыймматрәк кыймматрәккә, барыбер ике килосыз ярап бетмәс. Яннарына иң кимендә чирек кадак как куймасаң, килешмәстер. Аннары суң Сабан туе мәҗлесендә Тәүбә Камәриясе маймыл ризыгы... ни әле... сап-сары... ие, банан куйганые. Шуңа да башлары җитмәгән икән дигән гайбәт чыкмаска бер... сигез кило чамасы алмый булмас.

Исхак *(түземсезләнеп, утын пүләнен суырып чыгарып карый).* Banансыз һич ярамый. Оторви да брось — һич! *(Үз-үзенә.)* Фарватер ачык та бит *(бугазына чиртеп куя),* кингстон буш әле монда.

Баян. Бәлешкә ак он күп. Тансыкка кыстыбый да куям дип торам әле. (*Бармагын бөгә башлый.)* Кияү төшенә бал кирәк. Балны Күпер төбе Илгизәреннән апменерсең. Кара аны: өч йөз җитмеш биш граммлы банкалысын аласы. Юкәнекен литырын йөз дә илле тәңкәдән җибәрә бугай диделәр.

Акчура чалгы тапап утыра. Камал керә.

Камал. Нишлисең?

Акчура. Ә син?

Камал. Хәзер почта шундый — космос аша нитәләр. *(Кәгазь чыгарып.)* Сине дә ниткәннәр әле. Хатының белән бергә.

Акчура. Мине бөтен дөнья нитте инде: ысысыры да, капеэсэ да. Әле рәхмәт фашист пулясына дип торам.

Камал. Фашистка ниткән рәхмәт ул?

Акчура. Әтинең күт битен Сталинградта үтәли тишеп чыкмаган булса, мин хәзерге печән өсте шикелле җаваплы мизгелдә чалгы тапап утырыр идеммени ул?.. Ә!.. хатыным... белән бергә дидең ич әле, әме.

Камал. Менә телеграмма. Кул куясы.

Акчура. Тагын кем инде?

Камал. Күрәм дигән.

Баян. Үземә хәләл доганы кешегә калдырасым юк әле.

Исхак. Никах дигәнең... сиңа түгелдер ич?

Баян. Надан! Черки мие дә сыймаслык бывши коммунист башы белән сөйләнеп торган була әле, ә! Мәйтәм, анысы, шөкер, кодаларның үз дәүләтләре дә җитәрлек. Тик көтмәс төштән иңгән кучтәнәчне беркемнең язык иткәнен моңарчы күргәнем юк әле. Теге как-төштән ары әфлисүндер, алмадыр куюдан гына бөлмәбез. Шулар өстенә эресе-вагыннан чәчәкле конфетлардан да бер... өч-дүрт кило тирәсе өлеш чыгарганда да ярап торыр. Бер дистә чамасы гына лимон алып, телем-телем куйсак та әйбәт булыр.

Исхак. Булыр!

Баян. Моның белән генә бетми әле. ЧП «Әндери» кибетендәгене күптәннән күреп йөридерием: аш артыннан тәмле суга дип, өч кадак киптерелгән чиям тәгаенләп куелган. Бер адарынганны кире уйлауның гөнаһысы бар аның. Име.

Исхак. Ие.

Баян. Шуннан ары... Шулай ук... кадак хәтлек кенә... бүлгәнием. Куйган нәрсәләрем ишле күренсенгә өстәсәк... таман булыр.

Исхак. Җитеп торыр. Монда әллә әндри казнасы бар дип белдеңме?

Баян. Тагын...

Исхак. Тагын? Инде кичке *(кул сәгатенә карап)...* сәгать. Ә пычак калынлыгы да капкан юк.

Баян. Тагын димәктән, моның белән генә бетми әле ул. Бәлкем, как-төш өстенә диган өч-дүрт кило кәнфитләрне бер килога калдырып, сумсага, катламага дигән атланмайны арттырмаска микән дигән идем. Безнең дә төшеп калганнардан түгел икәнне белгертеп куйганда бик ярап торырые...

Акчура тавышы: «Исхак, ниттегезме әле?»

Исхак. Керешеп кенә бара.

Акчура. Монда почтальон Камал зарыга.

Исхак *(өеп куелган әрдәнәдән бер пүләнне алып, аның урынындагы бер шешә аракыны кесәсенә тыгып куя).* Бүген бөтен дөнья зарыккан көн.

Хәдичә *(тавышы).* Пәйгамбәр тырнагы чәчәгенең сары башлы икәнлеген беләм мин. Җир җиләгенең миләүшә төсендә түгеллеген дә. Шири чишмәсе суы да ак була димени? Су — былчыранмаса, пычратмасалар — гел пакь кенә. Судан чиста булып булмый. Суга төс кирәкми. Минем күзем генә ул. Яшен сукканчыга хәтле нинди иде әле?.. Зәңгәр иде... Хәзер әллә нинди... көрән. Аныкы төсендә.

Машина килеп туктаган тавыш ишетелә.

Хәдичә. Рәхмәт яусын сиңа.

Тавыш. Ягъфәр мин, туташ. Кура җиләге җыйганың чагында әйттем ич инде.

Хәдичә. Сау бул, Ягъфәр!

Машинаның ишеге ябылып, кузгалып киткән авазлар.
Хәдичә күренә.

Хәдичә. Әни, әти!.. Менә кайттым әле. Күчтәнәчем бар. Кайтышлый Карамалы чокырыннан менә (*чиләк күрсәтә)* кура җиләге җыйдым. Анда тирән. Өстәнрәк йөрдем инде. Кура җиләге куагын очыннан тотып сак кына кайтарып саласың да... и, җиләге! Иҗниган. Ялгыш кагылсаң, җиләге өзелә дә төшә. Тотып алырга өлгермисең. Шулай итеп күз яше тамчысын гына тотып алырга өлгермисең. Ишетәсезме, әни, әти: күз яшен!..

Баян. Күзеңнең... төсе... бүтән...

Хәдичә. Беләм. Хәзер беләм инде. Ул... минеке түгел ич.

Баян. Кемнеке?

Хәдичә. Мин аңа каен җиләге җыйдым. Күзе саен меңне.

Исхак *(катгый).* Кемнеке, кызым? Күзең.

Хәдичә. Кемнеке икәнлеген белү минем гомеремә җитәрлек. Инде җитәрлек... Әти, әни, кура җиләге җыеп апкайттым! (*Үз-үзенә.)* Сәер, мине яшен сугып сукырайткач, күзем яшьләнмәде микәнни? *(Бармак бите белән сак кына күз төбенә кагылып куя.)* Гаҗәп, бу — күз яше ич. Күз яше. Әти-әни!.. Машинага утырып кайтышлый шофер Ягъфәргә Карамалы чокырына кереп чыгыйк әле дигән идем. Ул кайдалыгын каян белсен инде. Өйрәтеп *(басым белән),* күрсәтеп бардым. Менә җыеп кайттым әле. Минем сезгә кечкенә генә бер күчтәнәчем. *(Кесә көзгесенә карагач, өйгә кереп китә.)*

Исхак. Баян!

Баян *(югалып кала).* Өстәп... Виноград... йөзем инде... куясы булыр икән әле *(сөйли дә сөйли)* килосы... тәңкәдән...

Исхак *(ниһаять, кырыс төстә).* Оторви да брось!.. Аш пештеме?

Баян *(кинәт, өркә калып)*. Мунча да әзер инде... Тагын ни дип торам әле: ике кадак чамасы фейхуа да куйсак, ничек булыр икән дим.

Исхак. Нәкъ таманга килер! *(Яшерен генә сулык-сулык елап ала, күз яшен җиңенә сөрткәли.)*

Баян *(күреп).* Әй...

Мөхәммәт күренә. Җырлый. «Күзләремне тутырып».
Хәдичә аңа, капкачын ачып, каен җиләкле банка суза.

Мөхәммәт. Челләдә ничек таптың?

Хәдичә. Күзләремне тутырып...

Мөхәммәт. Каен җиләге!

Хәдичә *(кырыс).* Инде — кит. Бәгыреңне кыл урталай ярсаң да, хәзер — кит. Калган бар дөньяга инде синең күзең белән каравыма карамастан — кит!

Мөхәммәт. Яхшы.

Жыр.

Хәдичә. Телисеңме сул кулымны, уң аягымны бирәм.

Мөхәммәт. Телим. Берзаманны улыңмы, кызыңмы булыр. Бөтен җиреңне аңа бирүеңне телим.

Хәдичә. Нигә сорамыйсың?

Мөхәммәт. Нәрсәне?

Хәдичә. Кит дигәнемне.

Мөхәммәт. Белгәнне сорамыйлар.

Хәдичә. Минем сине... яратмавымны дамы?

Мөхәммәт *(кырыс).* «Яратам» дигән ялганнан «яратмыйм» дигән чыны кадерлерәк. Шунысы мәңгерәктер.

Хәдичә. Мәңге дисең. Аның очы-кырые, башы-ахыры юк ич.

Мөхәммәт. Бар.

Хәдичә. Кайда?

Мөхәммәт. Ерак түгел.

Хәдичә. Анда барып җитешле микән?

Мөхәммәт. Өлгерсәң.

Хәдичә. Кайчан?

Мөхәммәт. Үлгәч.

Җил исеп узган, инеш аккан тавыш ишетелә. Ә теге бала-чага урамнан тагын бер тапкыр чыр-чу килеп көлешә-көлешә уза әле. Бәлки,
кайдадыр ниндидер бер сабый елап куядыр.

Хәдичә. Аҗаган уйный.

Мөхәммәт. Яңгыр явасы. Болыты шундый.

Хәдичә белән Мөхәммәтнең сөйләшүе әкрен-әкрен генә җырга әйләнә
бара.

Хәдичә.
Сандугачлар ия инде җәйгә,
Җәймә-җәймә тузганак оча.

Мөхәммәт.
Умырзая сулып тузган чак бу, —
Ә мин сине йолдыздан кочам.

Хәдичә.
Соң җиләктәй, учка тама йөрәк,
Кирәк түгел соңгы сулкылдау.

Мөхәммәт.
Шау пешкәндә уйдык-уйдык җиләк,
Ялгыз чемем зыңлый мең кылдай.
Алдый алмый инде җиде кыллы җаным:
Бер йөрәккә тамчы су җитми...

Хәдичә.
Җиде якка бәгырь телгәләнә, —
Өзгәләнгән җиргә җан илтми.
Бер йолдызның чиксез сәфәренә
Җан сәдәфен чигеп тезәрмен...

Мөхәммәт.
Айның аргы ягын күрмәгәндәй...
Синсез дә бер гомер түзәрмен,
Соң гомерне... тиңсез гизәрмен...

Хәдичә *(омтылып).*
Айның аргы ягын җәяү үтеп,
Гомер буе сине эзләрмен.

Мөхәммәт.

Эзләреңне тезмә йолдызларга,
Йөрәктәге эзең — мәңгелек!

Хәдичә *(тын).*

Эзне эздән эзләп күзләмәсәк,
Кояш... боздай эрер иң элек.
Чишмә булып ташып килдем сиңа,
Һәр тамчысы сөю — мәңгелек.

(*Уйчан.)* Әрем дә серкә очыра икән.

Мөхәммәт. Очыра.

Хәдичә. Хәзер кая барасың инде?

Мөхәммәт. Еракка түгел.

Карашып торалар да ятсынган шикелле итеп кенә бер-берсенә кара-
каршы атлыйлар.

Хәдичә. Кайларда йөрдең?

Мөхәммәт. Күрмешне күрдем инде.

Хәдичә. Мин дә... күрәм. Күрәсеңме — күрәм! Күрәсеңме — минем күз яшем чыга. Минем... синең күзеңнән тамчы-тамчы яшем тама. Ул — безнең күзебез яше.

Мөхәммәт. Безнеке.

Бер-берсенең күз яшьләрен сөртешәләр: берсе — уңын, берсе — сулын.
Җыр: «Күзләремне тутырып».
Бер-берсенә аркан килеш тә, кара-каршы торып та тыңлыйлар.

Мөхәммәт. Яшен яшьни, Хәдичә.

Хәдичә. Бу юлы миңа... безгә тими ул. Син барында бөтен җир ышык, Мөхәммәт.

Яшен яшьни, күк күкри.
Хәдичә Мөхәммәтне кочып ышыклый.
Аларга һәммәсе үзләренчә карап тора.

Акчура *(җыр әйтә).*

Карурманны чыккан чакта
Юа тапмый атларым;
Юаныр юлга юлыкты
Минем кыек атлавым.

*(Кинәт тынып кала да әллә кая — күк гөмбәзенә карап.)* Аһ, бу... дөньяның мин теләгәнчә тормаганын *(сулып)*... алабутадан күрәм... Ә тормыш... яшәү — бөтенләй бүтән ләбаса. Болайрактыр... Маракуйа, син мырла, яме, ә мин җырлыйм... *(Җырлый.)*

Олы юлда атлар буза
Йөрәк ите тузганга...
Кушыл, песи, Маракуйа!
Тоякларны кыеп була,
Коеп булмый тузанга...

Камал күренә. Бөтенесе әкрен-әкрен, һәркайсы үзенчә аңа карый.

Хәдичә. Камал абый...

Камал *(букчасыннан бер кәгазь алып карый да кире тыгып куя.)* Телеграмма иде, күрше авылга. Тапшырырга куркам.

Мөхәммәт *(кырыс).* Бир. Тапшырырмын.

Тәмам.

*2004–2005*

**ЭЧТӘЛЕК**

**Талантлы әдип.** *Вакыйф Нуруллин ..................*

**Хикәяләр**

Кешеләр ............................ ....
Көзге ........................... .... ...
Җирләгәч ............................ ...
Карачкылар ............................ ..
Кылчык ............................ ....
Ара ............................ .......
Әллә тагын ............................ ...
Казыйныкылар ............................
Иде ............................ .......
Энә күзе ............................ ....
Шом ............................ ......
Акбар ............................ .....
Күргәзмә ............................ ....
Antiquarius ............................ ..
Тәңре юлында ............................ .
Венски гармун ............................

**Повестьлар**

Яра ............................ .......
Сиртмәле бишек ............................

**Пьеса**

Күзләремне тутырып .........................

Литературно-художественное издание

**Гаффаров** Габдулахат Абдрахманович
(**Ахат** Гаффар)

**ГЛАЗОК ИГЛЫ**

*Рассказы, повести, пьеса*

Казань. Татарское книжное издательство. 2006

(на татарском языке)

Әдәби-нәфис басма

**Гаффаров** Габделәхәт Габдрахман улы
(**Әхәт** Гаффар)

**ЭНӘ КҮЗЕ**

*Хикәяләр, повестьлар, пьеса*

Мөхәррире *Р.Ә.Заһидуллина*
Рәссамы һәм бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *Ф.Р.Гыйсмәтуллина*
Корректорлары *Р.Н.Шакирова, Г.М.Хәбибуллина*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 06.07.2006.
Форматы 84×108 $_1/_{32}$. Офсет кәгазе. «School Book» гарнитурасы. Офсет басма. Шартлы басма табагы 15,12+форз.0,21. Шартлы буяу-оттиск 16,38. Нәшер-хисап табагы 16,09+форз.0,36. Тиражы 2000 д. Заказ 3-496.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
**http://www.tatarstan.ru/books/**
**E-mail: tki@books.kazan.ru**

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы ААҖ. 420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.